ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

2.1995



## Рашат Низамиев

### Ирек мәйданында уйлану

Ватан бит ул — һәркайсыбыз өчен
Күкрәк сөтен биргән әнидер:
Мәйданнарда чәчрәп чыкмасам да,
Милләт өчен җаным әрнидер.

Басып торам Ирек мәйданында.
Аһ, йөрәкнең авыртулары!
Утызынчы август көннәредәй,
Тыгызланып килә уйларым.

Ул чакларның кайнарлыгы истә:
«Дубинка»лар кисте һаваны...
Ак яулыклы әбиләре белән
Мәйдан тотты татар гавәме!

Кайтардыкмы илнең — гасырлардан
Күчә килгән кодрәт-шәүкәтен?
Һаман әле камалышта яши,
Ут эчендә яши дәүләтем.

Җирләр уртак, язмыш уртак, диеп
Сөйләнмәгез, Ходай хакына.
Хәләл малларыбыз һаман әле
Рәсәй кесәсенә агыла.

Шовинист та бер аңласа икән,
Акылы калган булса әз генә:
Империя упкан халыкларның
Күз яшьләре — милли хәзинә.

Бу Рәсәйнең тормыш-яшәешен
Кулда тота нинди сатана:
Мескен булсаң, тотып яңаклыйлар,
Ирек, дисәң, әнә, аталар.

Татар булган җирдә хәтәр бар, дип
«Бүкәй» ясаганнар безләрдән...
Тетрә, Рәсәй!
Без кайтарып алачакбыз әле
Мөстәкыйльлек язын сезләрдән.

Халкым әнә: «Ирек! Азатлык!» — дип,
Ил өстенә ташлый чакыру.
Иген игә, сабантуйлар ясый —
Мөмкин түгел
Бу халыкны төпкә батыру!

#  КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**2**

**(868)**

**1995**

КАЗАН

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Ф. ЯРУЛЛИН. Манаралар, айлы манаралар. *Шигырьләр* ... 3
Х. КАМАЛОВ. Түләнмәгән күз яше. *Роман* ... 10
Г. АФЗАЛ. Хәтер көне. *Шигырьләр* ... 77
Т. ГАЛИУЛЛИН. Кияү. *Хикәя.* ... 84
Р. ГАТАШ. Чулпан йолдыз калыкканда. *Шигырьләр* ... 98
Г. АХУНОВ, М. ГӘРӘЕВ. Арча жиренең ачык китабы. *Документаль повесть.* ... 105

СӘНГАТЬ

Тургай картаямы? *(Илһам Шакировка 60 яшь).* ... 153

ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Ә. КӘРИМУЛЛИН. Милли китабыбыз тарихы турында. ... 166

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

И. НУРУЛЛИН. Булган ул тәнкыйди реализм! ... 176

ӘДӘБИ МИРАС

Ш. МАННАП. Алтын бөртекләр югалмый. 181
С. СҮНЧӘЛӘЙ. Азан. *Шигырьләр* ... 182

Безнең календарь ... 186

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 187

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*
**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Б е з н е н   а д р е с: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Т е л е ф о н н а р:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: продолжение романа Х. КАМАЛОВА «Неоплаченные слезы», рассказ Т. ГАЛИУЛЛИНА «Зять», документальная повесть Г. АХУНОВА, М. ГАРАЕВА «Открытая книга Арской земли»; стихи Ф. ЯРУЛЛИНА, Г. АФЗАЛА, Р. ГАТАША.
«Искусство»: статья «Стареет ли соловей?» посвящена к 60-летию народного артиста РСФСР и Татарстана, лауреата государственной премии имени Г. Тукая Ильгама Шакирова.
«К истории народа»: статья А. КАРИМУЛЛИНА «Об истории татарской книги».
«Литературная критика»: статья И. НУРУЛЛИНА «Был он, критический реализм!»
«Литературное наследие»: стихи С. СУНЧАЛИ.
Наш календарь.
Дневник общественно-культурной жизни.
«На наших обложках»: «Шурале» — картина художника Б. Урманче; известный писатель М. Галиев.

## IN OUR ISSUE

«Prose and Poetry»: the sequel of Kh. Kamalov's novel «Unpayed Tears», T. Galiullin's story «Son-in-law»; G. Akhunov's and M. Garaev's documentary novel «The Open Book of Arsk Land»; the verses of Ph. Yarullin, G. Aphzal, R. Gatash.
«Art»: the article devoted to the 60 anniversary of People's artist of the RSFSR and Tatarstan, Tukay State prisewinner Ilgam Shakirov «Whether the Nightingale Grows Old?»
«To the History of Nation»: A. Karimullin's article «About the History of Tatar Book».
«Literary Critique»: I. Nurullin's article «Critical Realism Was!»
«Literary Heritage»: S. Sunchali's verses.
«Our Calendar»
«The Diary of Social and Cultural Life».
In our corvers: the picture «Shurale», the well-known writer M. Galiev.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Марсель Галиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 4.01.95 ел. Басарга кул куелды 21.02.95 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 11 056. Заказ Д-2.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1995 ел.

# ШИГЪРИЯТ



## Фәнис Яруллин

### Манаралар, айлы манаралар

Тәрәзәмнән мәчет күренеп тора,
Манарасы аның яшел фәсле.
Түбәсенә кунган алтын ае
Чакырып тора үзенә картны-яшьне.

Һәркөн иртән шул мәчеткә карыйм,
Аумаганмы, димен, манарасы.
Тыныч кына ятып буламыни —
Гел болганып торгач заманасы.

Тәгәрәде күпме манаралар
Чалма чалган башлар белән җиргә.
Урак белән чүкеч ясап куйдык,
Айны кушып тәре белән бергә.

Берләштердек шулай, укмаштырдык
Динне, телне, гореф-гадәтләрне.
Озыннарны Урак урып торды,
Чүкеп торды Чүкеч шәбрәкләрне.

Сезне кискән саен, манаралар,
Үзебез дә гел кыскара бардык.
Манаралар белән киселә-киселә
Бөеклеген җуйды безнең халык.

Манаралар, айлы манаралар,
Заман йөзен күрсәтүче көзге.
Сезне кисеп — сезне аудармыйлар,
Сезне кисеп — аударалар безне.

## Оялчан халык

Күптән шуны шәйләп киләм:
Без — бик оялчан халык.
Алыштырабыз исемне
Татарлыктан оялып.

Эчәсе килмәгәндә дә,
Бирсәләр әгәр салып —
Эчәбез, янда утырган
Исерекләрдән оялып.

Җаныбыз бик тартмаса да,
Чишендек, шәрә калдык.
Фәхеш кылдык... үзебезнең
Тыйнаклыктан оялып.

Сүгендек без катлап-матлап,
Һич тә кимен куймадык.
Чөнки без әдәпле булып
Күренүдән оялдык.

Ыштанын пычраткан бала
Әйтмәгән күк оялып,
Йөрибез чистара алмый —
Бар пычракка буялып...

*1994*

## Туй

Күршедә туй,
Дер селкенә өйләр,
Җырлашалар төрле тавышка.
Кем катырак кычкыра дип гүя
Җыелганнар монда ярышка.

Күп тә үтми берсе биеп китә,
Бүтәннәре аңа иярә.
Гармун күчә җырдан биюләргә,
Гармун күчә көйдән көйләргә.

Күршедә туй,
Татар егете әнә
Урыс кызын алган — ут алган.
Телләр белән телләр буталганнар,
Җырлар белән җырлар буталган.

Табындагы урыс аракысы
Бөтенесен бүген бер иткән,
Мондый чакта безнең гореф-гадәт
Карап тора бары бер читтән.

Гадәти туй,
Гап-гади туй бүген,
Юк бу туйның аерым хикмәте.
Тик бер ана бүген улын җуйды,
Бер егетен — татар милләте.

*1993*

## Һәркөн шулай

Һәр иртәдә яшь дворник хатын
Урам себерә, җыя чүп-чарларны.
Карап торулары рәхәт хәтта
Менә шундый эшчән, уңганнарны.

Бар нәрсәгә җитә аның кулы —
Газоннарны шәпләп тарап чыга.
Артта берәр чүп калмаганмы дип
Бөтенесен кат-кат карап чыга.

Рәссамнарның пумаласы кебек
Аның кулындагы себеркесе.
Ул кагылган саен матурлыкның
Сызылып кала җирдә бер өлгесе.

Күп тә үтми ләкин өй тирәсе
Өр-яңадан чүп-чарларга бата.
Яраланган кошлар кебек җирдә
Кәгазь кисәкләре аунап ята.

Чибәр кызлар чирәм өсләрендә
Эт уйната көтү-көтү тулып.
Эт пычрагы кала чирәмлектә
Тәрбиясезлеккә медаль булып.

Һәр бирмеш көн кабатлана бу хәл,
Ишегалды гүя нәни дөнья...
Ә дөньяны кемдер пычрата гел,
Ә кемнәрдер — аның чүбен җыя.

*1993*

## Язмышларны язучы кул

Тормыш — базар, базар кайный,
Монда һәркем нидер сайлый.
Берәүләре көлмәк сайлый,
Берәүләре чүлмәк сайлый.

Кияү сайлый, кәләш сайлый.
Торыр өчен өйләр сайлый.

Өзәр өчен гөлләр сайлый,
Яшәр өчен һөнәр сайлый.

Уңайлыгын сайлый-сайлый,
Үз тормышын һәркем җайлый.
Ошаганын алып китә,
Ә ошамый икән — алмый.

Һәр кешегә нидер табыла,
Беркем дә өлешсез калмый.
Кемдер ятимнәр йортыннан
Асрамага бала сайлый.

Бала күңеле гаҗәп сизгер,
Алар барсын бик тиз аңлый.
Аларны сайларга ярый,
Алар ана сайлый алмый.

Җирдә күпме гаделсезлек,
Уйлый китсәң йөрәк каный.
Язмышларны язучы кул
Белмим инде кая карый?

*1993*

## Калыйк вакытында сорап

Озын-озын нәрсә озын? —
Озын-озын бәхет юлы.
Үз бәхетенә бара кеше
Кайвакытта гомер буе.

Олы, олы, нәрсә олы?
Ата-ана хакы олы.
Онытмасын иде кеше
Үлгәнчегә кадәр шуны.

Авыр, авыр, нәрсә авыр?
Авыр — аналар каргышы.
Бу каргышны алганнарны
Көтә Сак-Соклар язмышы.

Ерак, ерак, нәрсә ерак? —
Үткәннәргә юллар ерак.
Ата-ана фатихасын
Калыйк вакытында сорап.

*1994*

* * *

Тимәгез гөнаһсыз гөлләргә,
Сагышы гөлләргә ягылыр;

Атмагыз күктәге кошларны,
Бәлки ул кемнеңдер җаныдыр.

Бумагыз чишмәләр агышын,
Чапсын ул, гел алга йөгерсен.
Бәлки ул кемнеңдер сөюе —
Дөньяның серләрен кем белсен.

Ишмәгез мәһабәт тауларны,
Калсын ул биеклек, калсын сер.
Бәлки ул халыкның зурлыгын
Күрсәтеп торучы үлчәүдер.

*1994*

## Бөркет булмый

Күпме генә үстермә син
Кулыңда өф-өф итеп —
Чыпчык булып туганнарны
Булмый ул бөркет итеп.

Биек чөйсәң — егылып төшә,
Кыяга кунмый чыпчык.
Үтә аның бөтен гомере
Өй тирәсендә очып.

Ләкин шушы хакыйкатьне
Күпләр аңламый кебек:
Чыпчык чөяләр дә күккә
Көтәләр: булыр бөркет.

Ә өметләр акланмагач,
Нәләт ява чыпчыкка.
Чыпчык мескен нишләсен соң? —
Аның тәхете чыбыкта.

*1994*

## Бер үк бишмәт

Әйләндерәбез дә киябез гел
Бер бишмәтне гомер буена.
Әйләндергән саен бишмәтебез
Матуррак булып тоела.

Бер мәртәбә әйләндергән идек
Унҗиденче елда без аны.
Өстебезгә шуны киеп чыгып
Шаккаттырган идек дөньяны.

Ул бишмәтне озак киеп йөрдек,
Ятканда да өстән салмадык.
Итәк кисеп җиңен ялгадык та
Тузган саен аны ямадык.

Ямаулары кызыл булгангамы,
Безнең бишмәт бигрәк шәп иде.
Аны кигән кеше бу дөньяда
Бер кайгысыз иде, шат иде.

Күнегеп беткәч кызыл ямауларга
Бутап бөтен уйны-исәпне,
Әйләндереп кигерттеләр безгә
Тагын бер кат шушы бишмәтне.

Хәзер инде җеп тә тоталмый ул,
Һәрбер җөе тузган, сүтелгән.
Җилләр өрә һәрбер ертыгыннан,
Өзелеп чыга торган җиреннән.

*1994*

## Дөнья бик тә катлаулы

Акча — нәфес шайтаны,
Шайтанның бар мең җаны.
Арындырып булмый һич
Шайтаннан бу дөньяны.

Ул керә безнең эчкә
Әйләнеп үрмәкүчкә.
Чорный, кыса җаныңны
Һәм суыра каныңны.

Акча — патша, акча — хан,
Ул йөри бездән алдан.
Арткан саен акчабыз,
Кими бара бит Вөҗдан.

Саклау авыр саф җанны,
Дөнья бик тә катлаулы:
Таләп итә йә малыңны,
Йә җаныңны сатканны.

*1994*

## Курай иткән

Кай чагында сөенәмен йөрмәвемә,
Дөньяның күп явызлыгын күрмәвемә.
Каным кайнар: менеп төшми түзмәс идем
Явызларның авыз дигән мөнбәренә.

Андый эшкә башсызлыгым житәр иде,
Ахры ничек бетсә дә бер бетәр иде:
Йә тукмалып кайтыр идем, яки тукмап,
Гомер буе яши алмас идем сыктап.

Беләм, беләм: явызларның кулы озын,
Теле уклы, ә очында агу була.
Чаккан саен аның да бит агуы кими,
Шуңардан да күңелләргә ару була.

Ярый инде язмыш мине болай иткән —
Йөрәгемне басудагы тургай иткән.
Сугам дигән чыбыгымны алган да ул,
Җырлы-моңлы уйнап туймас курай иткән.

*1993*

## Иң яраткан бәндәсе

Мин Алланың иң яраткан
Бәндәсе микән әллә?
Өя дә өя чирләрне
Кечкенә генә тәнгә.

Сыныймы түземлегемне
Шушындый юллар белән —
Берсе ун елга торырлык
Газаплы еллар белән.

Бер-бер артлы чирләр өйсәм,
Язмышын каргар диме.
Әллә яшәүнең кадерен
Ныграк аңлар диме.

Яшәү кадерен мин болай да
Бик яхшы беләм кебек.
Дөньяның һәрбер гөленә
Карыйм сокланып, сөеп.

Ә язмышны каргамыймын,
Әйтәм моны хәйләсез.
Юанам: мин бит Алланың
Иң яраткан бәндәсе.

*1994*

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



**Хисам Камалов**

# ТҮЛӘНМӘГӘН КҮЗ ЯШЕ

РОМАН

000

Ниһаять, болдыр баскычында инспектор пәйда булды. Ул учы белән авызын сыпыра-сыпыра килә. Адымы, хәрәкәтләре сизелерлек җанланган. Йөз чытыклыгы язылган, битен ерып-ерып төшкән тирән җыерчыклар да тигезләнгән, шомарып киткән. Рәис белән «баш төзәтеп» алганнар, мөгаен. Нindидер эчке кәефенә рәхәтләнеп, тәмәке суыра. «Председатель хәзер чыга»,— диде ул күтәренкелек белән. Баскычта ак картуз кигән таза гәүдәле, янып торган кызыл битле колхоз рәисе Минъяров күренде. Аңа өч егет ияргән, Минъяров аларны нindидер гаепләре өчен тирги иде. Сүзләреннән шул аңлашыла: әллә утырасыгыз киләме, гөмбә башлар, ә? Минем сүз анда закон. Сезгә тамчы да ышанмаячаклар, едранаматьлар!.. Ә егетләр аңарга тагылганнар, башларын иеп, ныграк тиргәсен дигән төсләр иде... Алар машинага килмәделәр, кырыйдагы кибет ишегалдына, складлар шәйләнгән җиргә кереп киттеләр.

Озак та үтми, машина алдында гына торган тимер ишекләр ачылып китте. Эчтән рәис тавышы ишетелде. Аның нәрсәдер хәстәрләп йөрүен машинадагылар бик ачык белделәр, шуңа берни дә дәшми тордылар. Кара кирза сумкасына нидер тутырып, Минъяров килеп чыкты. Икенче кулында сетка иде. Ул, сумкасын җиргә куеп, иптәшләр белән кул биреп күреште. Тартакиев белән дусларча хәл-әхвәл белешеп алдылар. Байкин алгы утыргычны рәискә тәкъдим итте, чөнки юлны, җирләрне белми иде. Минъяров, кереп утыруга, шоферны танып алды.

— Тукта, син Әлфис түгелме соң?— дип кычкырып куйды ул. Шофер кинәт комачтай кызарды.— Ах, шилма, колхоздан качып киткән идең, эләктеңме? Әйдә, хәзер милициягә алып барам мин сине! Кем шоферы бу?— Минъяров юан үгез муены белән артка борылды. Байкин аңа карап елмайды.

— Ярый, ярый, ул безнең шофер, тимә,— диде йомшак кына. Председатель шаярта дип белде, ахры.

---

[1] Дәвамы. Башы журналыбызның 1 санында.

— Нәрсә, Бөгелмәгә барып урнаштыңмыни?— Ул шаяртмый, шулай да «баш төзәтү» шаукымы белән сөйләшүе сизелә. Шуңа Байкин, һаман рәискә елмайган килеш, шоферның җилкәсенә учын куйды. Шофер, шуны гына көткәндәй, машинаны бик тиз кабызып алып та китте. Кая таба юнәлергә кирәген дә бик шәп белә икән. Минъяров шоферга текәлеп-кадалып карый, тагы аңа һөҗүм итәргә әзерләнә кебек иде. Байкин татарча аңласа да, сөйләшә белми иде, русчалатып шоферны араларга керешге.

— Кулыңда тота алмагансың, үзең гаепле,— диде сүзне шаярулы эзгә күчерергә итеп.— Хәзер пожардан соң...

— Паспортны блат белән алганнар. Участковыйга ике каклаган каз биреп. Миңа бары да билгеле...— Ул Байкинның шактый зур, абруйлы башлык икәнен чамалап алды һәм сизелерлек йомшады.— Яшьләр авылдан качу ягын карыйлар...

— Шәһәрдә материаль яктан кысан яшәсәләр дә...— дип, сүзгә куәт бирде Тартакиев.

— Ул як хәзер бик кызыксындырмый, колхозда икешәр тонна бодай алучылар байтак... Шулай да гарьлек, карт әти-әниләрен колхозга аударып китәләр.

— Нефтькә килеп егет дөрес эшләгән,— дип куйды Тартакиев, әллә болай, әллә шоферны яклыйсы килеп.— Нефть хәзер сәясәт! Ил престижы өчен мөһим! Политиканы нечкә тойган, ә?

— Нефть агрессорның борынына чиертә ул. Теге коерыгын кысарга мәҗбүр! Һе!— дип сүзгә кушылды инспектор. Аның кәефе күтәренке, папиросын конфет урынына суыра. Кыяфәте нииндидер җиңүле, масаюлы иде. Байкин аңа карап, нәтиҗә чыгарды: бу эчә торган адәм булырга тиеш. Эчкечеләр кызыл сүз сөйләүчән, гәзит сүзе белән шапырынучан булалар. Алар һәр көч коньюнктурасына җайлашып яшиләр. Бүтәндә гамьнәре юк. Партиядә җыелыш саен кызыл сүз, партком сүзен үткәргәнгә күрә генә тоталар үзләрен. Хәлнең тышкы ягы белән канәгать булалар. Ә мәсьәлә тирәнрәк: безнең нефтьне демократик илләргә бушка дип әйтерлек бирәләр. «Дружба» нефтьүткәргече — илне бөлдерә торган убыр ул. Шуны мактап җырлар язалар, романнар. Җитәкчеләр идея белән сукыраеп беткәннәр, шуннан башка нәрсәне күрмиләр. Ә уйларлык нәрсәләр бар: бу байлыклар мәңгелек түгел бит, шуны аңламыйлар микәнни? Менә бервакыт нефть тә, газ да бетәр, шулчак ни булыр? Демократик илләрдә социализм төзибез дип, Кытайга күпме байлыкны тутырдылар, заводлар төзеделәр, ә ул безгә каршы баш күтәрде, дошманга әйләнде. Европадагы демократик илләр дә шулай булачак, без аларга күпме нефть, газ озатсак та, барыбер безне үз итмәячәк алар. Юк! Болар барысы да илне экономик яктан какшатуга алып бара торган хәлләр. Чехословакиядә яңа өйләнешкәннәргә, загс язуы белән бергә, фатир ачкычы да тапшырыла, дип газеталар шапырына. Ягъни, социализм лагере әйбәт яши. Ләкин үзебездәге хәлне белгертмиләр. Барактагы бер бүлмәдә ике гаилә тора, чаршау белән генә бүлгәннәр. Балалары салкын идәндә ауный. Кинәт кенә берсенең уенчыгы өчен сугышып китәләр. Елаш, кычкырыш. Балалар сугышы олылар ызгышына сәбәп була. Дошманлашалар, бер-берсенә дәшмиләр, сөйләшмиләр. Әмма тагы балалар сугышы. Телне худка җибәрергә, пычакка пычак килергә мәҗбүр булалар. Яшәүнең бер яме-тәме калмый, көн итү бер саташулы төшкә әйләнә. Әмма шушы түзеп булмаслык хәлдән берниндн котылу әмәле күренми. Начальниклар ел саен квартира вәгъдә итәләр. Барысы да буш сүзләр генә. Алдау арты алдау. Югыйсә без җиңүче ил бит? Җиңелгәннәр бездән күпкә әйбәт, житеш яшиләр, нишләп болай бу? Моның сәбәп-тамырлары нәрсәдә?

Нефть ул гаҗәп байлык, әнә шундый уйлар тудыра. Ләкин ул уйларны беркемгә дә әйтә алмыйсың. Әйтсәң, көне-сәгате белән «тегендә» барып ишетелә һәм сиңа кырын карый башлыйлар. Син ышанычны

югалтасың. Моны һәркем үз тиресе белән тоя һәм артык сүз ычкындырудан куркып яши. Хәтта үзеңдә туган чын фикерләрне хатының белән бүлешергә дә шүрлисең. Шуңа күрә иптәшләр белән очрашканда юк-бар сүз сөйләшәсең. Күз буйыйсың. Эштә исә күз буяу коточкыч дәрәҗәдә...

Эчтәге уйларын чагылдыргандай, инспекторның күзләре очкынланды, нәрсәдер әйтергә җыена иде.

— Безнең су асты көймәләре кинәт Америка суларына барып чыккач, тегеләр шыр җибәргәннәр,— диде инспектор, бер сенсация турында әйткән кебек кәефләнеп.— Кызыл шайтаннар килә, дип, паника купкан. Бер миллионер тәрәзәдән ташланып харап булган...

Ул гөлдерәп көләргә тотынды. Ләкин берәү дә аңа кушылмады, шуңа бик тиз туктады. Әйе, газеталарда безнең су асты көймәләре хакында бик шапырындылар. Җитәкче полковникларга герой исемнәре, орденнар бирделәр. Әй, орденнар өләшергә яраталар да соң! Гаҗәпкә каласың. Кемнәргәдер Ленин ордены тапшырдылар. Нинди хезмәтләре өчен, һич аңлашылмый. Кешеләр эчтән генә үзенчә нәтиҗә чыгара: беләбез нинди «эшләр» өчен бирелгәнен, беләбез...

— Чуканов, бик күп белә башладың әле,— дип, Миньяров аны бүлдерде. Шунда Миньяровның да кызмача икәне беленеп калды.

— Әйт әле конкрет кына, җирләр өчен күпме түлисең? Ә?

— Безнең шкаланы син беләсең бит инде,— диде инспектор аңа сәерсенеп карап.

— Шкалаңны фәлән итимсәнә,— диде көлә-көлә Миньяров. Инспектор башын тәрәзәгә борды. Машина кызыл маңгайлы Чагыл тавы буеннан чаба иде.

— Тукта, син бу җирләрне өченче ел саткан идең түгелме?— Инспектор, ияк кагып, тау буйларына ишарәләде.

— Нәрсә сиңа әзрәк булдымы? Хәзер өстәрбез...

— Бер яртысыз төшенеп булмый диген, ә?— дип куйды Тартакиев кет-кет көлеп.

— Миньяров, җирләр сатып тәмам баеп беттең, ә нәфсең һаман төкәнми, парин?— Чуканов колхозның тернәкләнүенә ишарә итеп әйтте, ә Тартакиев аны үзенчә аңлады.

— Йорт салдырадыр әле?— диде.

— Ансын өченче ел ук эшләдем,— дип, Миньяров папирос кабызды.

— Алайса Әлмәткә салдырасыңдыр. Председательләр алдан хәстәрлиләр, ирдән төшергәч, районга шыларга. Ә йорт әзер... Егыласы җирләренә салам түшиләр, ә?— Тартакиев кыска гына көлеп алды. Ә Миньяровка кыек атып, туры тигезде, рәис район үзәгендә җир алып, бура күтәртү эшләрен башлап җибәргән иде. Шуңадырмы Миньяров, моны колагы янында уздырып, сүзне икенчегә борды.

— Запчасть менә болай кирәк,— дип Миньяров тамак астын уч кырые белән сызып алды.— Нишләргә? Киттем Әлмәткә. Бер завгарга бардым. Таза гәүдәле, үгез муенлы кеше. Янында ярдәмчесе — куштаны бар. Шуны чамаладым: куштанына сүз үтәр төсле иде. Үгез муен эчкәре кереп киткәч, йомышымны әйттем. Завгар нindидер кәгазьләр тотып чыкты, өстәл артына утырып, язарга керешге. Куштан тегенең колагына минем гозерне пышылдады. Завгар башын күтәреп, миңа әһәмият итте.— Иптәшең белән килдеңме, диде ул җитди һәм бер кинаясез төстә. Юк, мин әйтәм, иптәшем өйдә, үзем генә.— Ярар, иртәгә иптәшең белән килерсең — дип, завгар үгез муенын аска иеп, кәгазь кыштырдата башлады. Мин аңлап җитмим, аптырап басып торам, ул исә карамыйча гына кулын селки: бар, бар!.. Табаннарымны идәннән көчкә кубарып, чыгып киттем. Болдырда тәмәке кабыздым, уйланам «иптәш» хатын дигән мәгънәне аңлата, нужәли хатынны алып килергә куша икән? Шунда куштан килеп чыкты: хатын монда причем, мин әйтәм. Әй, син гөмбә баш, жаргонны үзләштермәгәнсең: «иптәш» дип ул ярты әйтә... Ә-ә, шайтан алгыры, шулаймыни — шатландым. Кибеткә барып, ике акбаш-

ны — «Неру»ны алып килдем. Һәм кирәкле запчастьне сумкага салып, кайтып та киттем...

— Кибеттә «Сукарно» юк идемени, «Неру»ны алгансың,— дип көлде Тартакиев, кепкасы кырыеннан бүселеп чыккан сары чәч алкаларын селкетә-селкетә.

— Бар эш «шайтан суы»на корылып бара, ай-һай, кая илтер бу?! — диде Байкин авыр уфтанып. Аның күзләрендә күзлеге аша мөлдерәгән кайгы беленеп китте. Тик моңа әһәмият итмәделәр шикелле.

— Кая булсын, коммунизмга илтер,— дип куйды Чуканов шаярулы-җитди итеп. Әмма бу сүз шаярту өчен куркыныч иде, кызмача Чуканов шуны бик тиз сизеп, шаяруын кире алырга теләгәндәй, коммунизмга мактау сүзләре сибәргә керешге. Политик капитал өчен тырыша иде. Байкин уйланды: кешеләр мөнәсәбәтендә кешелеклелек, намус булмагач, коммунизмда ни мәгънә? Коллективта кешеләр бер-берсенә эчке дошманлык яшерәләр. Безнең гроссмейстерлар чит илгә шахмат матчына барганнар, әмма бер-берсе белән исәнләшмиләр икән... Мин моңа гаҗәпләнмим, безнең коллективта мине дошман күреп йөрүчеләр байтак. Исәнләшмәүчеләр дә бар. Ни сәбәптән? Мәскәүдән килгән препаратор сөйләп торды: сездә нәрсә, әнә бездә чын баталияләр бара. Астан яшерен көрәш кыза-кыза да кинәт бервакыт гөлт итеп кабынып тышка чыга, ди... Әйе, булыр, Байкин андый хәлләрне үз җилкәсендә татыды, бик яхшы белә. Ул чагында алган йөрәк яралары әле дә төзәлеп җитмәгән. Шул, әледән-әле җанны җәрәхәтләп торуларына чыдый алмады Байкин һәм менә шушы провинция тирәнлегенә кереп качарга мәҗбүр булды.

Кызыл маңгайлы Чагыл тавы буеннан баргач, Гөлле чишмәсе күперен чыгып туктадылар. Алда сөзәк кенә үр, шул үрдә борчак чәчкән җир. Борчак инде тармакланып чәчкә ата башлаган, ак һәм шәмәхә чәчкәләр үлән өстенә килеп кунган нәни күбәләкләр шикелле булып тоела.

— Бу Этаскан үр дип йөртелә,— дип аңлатты Миньяров, ул хәстәрләнгән икән, бер сумкасына очлы казыклар тутырып алган.— Бер землямер чатлы агачка этен асып киткән булган... Шуннан калган...— Ул топографик картаны алдына тотып, караштырып торган Байкин янына килде.— Скважинаны чәчү җиреннән читкәрәк куярга булмыймы?

— Хәзер, хәзер...— ди-ди, Байкин картасын бөгәрләмәгән килеш җир кырыеннан үргә таба атлады. Башкалар аңа иярделәр. Быел чүп үләннәре шәп: сөтле билчән чәчкәгә бөреләнгән, каты билчәннең дә очында шәмәхә кәрзинчәләр, сырлан да чалбар балагына ябыша башлаган, күкчәчәк сабаклары озын, чәчәкләре керфекләнеп ачылырга тора. Тагы бик күп төрле кыр чәчәкләре — ак һәм алсу тукранбашлар. Ак тукранбашка бөҗәкләр күп куна, нектары мул була аның.

Үр өстенә менеп җиткәч, Байкин туктады.

— Менә шушы төштән бер гектар алына,— диде. Карадылар, бар төшен дә борчак биләгән. Тартакиев тасмалы рулетка чыгарды да суза-суза китте, икенче очыннан Чуканов барып тотты. Илле метрлы тасманы җирнең бер ягына ике мәртәбә билгеләп алдылар. Икенче ягын күз белән генә үлчәделәр. Байкин, чирәмле җиргә утырып, үзенең картасын һәм катлам сызыклары төшерелгән кәгазьләрен тикшерде. Скважина утырырга тиешле ноктаны билгеләде. Аннары борчакларга басмаска тырыша-тырыша сагаеп атлап эчкә керде, шунда казык кагарга кушты. Миньяровның йөзе җитдиләнде, аңа җир кызганыч иде. Әнә түбәндәрәк сөрелми торган вак ташлы кисәк бар, шунда ничегрәк булыр икән,— дип, Байкинга үз теләген белдерде. Байкин, борчак эченнән чыгып, шул вак ташлы түбәгә кырын ауды һәм үзенең талмутларына кадалды.

— Катламнар горизонты рөхсәт итә, ярар,— диде, башын күтәреп. Һәм скважина урынына ак казык кадап куйдылар.

Аннан түбәнең икенче ягыннанрак үзәнгә төштеләр, урманнан агып төшә торган ниндидер чишмә суы аша чыктылар. Суда юынмакчы, тирле бит-кулны рәхәтләндермәкчеләр иде, булмады, чөнки су нефтьле иде.

Үзән аркылы куе үлән түшәлгән җирдән барып, каршыдагы урман белән капланган тауга күтәрелергә тиешләр иде. Куе күрән үзәнен ярып чыккач карасалар, чалбар балаклары мазутка буялып беткән. Ә өстән берни беленми. Ә үләннәр, күрәннәр, чәчәкләр, берни булмагандай, шул нефть мае белән сугарылган җирдә үҗәтләнеп үсә. Ни хикмәт, шундый ярага табигать чыдаган. Табигатьнең талымсызлыгына, яшәүчәнлегенә исең китәр.

Үзәннән сирәк агачлы Чатра тау өстенә күтәрелделәр. Анда да берничә нокта билгеләп, казык утыртылды. Биредә берничә гектар урман киселәсе иде. Минъяров эчтән колхозны кайгыртып уйланды: моның агачлары эре, эшкә ярарлык, тизрәк үзебезгә яздырып, алып калырга кирәк. Ботак-чатагы колхозчыларга китәр. Барысы да бушка бит.

Таудан үзәнгә кире төшеп, аның урманга якын җирләренә берничә казык утырттылар. Бирерәк килгәч, тагы өч нокта. Минъяров һаман үртәлде: бу үзән бетә икән, күпме печән чыга иде, силоска гел шушыннан чабып, берничә баз тутырыла иде. Хәзер моны ни белән алыштырырга булыр, белгән юк. Силос өчен көнбагыш чәчелә, әмма көнбагышны күрән, үзән үләне белән бергә катнаштырырга кирәк. Шулай итсәң, туклыклылыгы, файдасы бермә-бер арта. Ләкин берни эшләр хәл юк, авыл хуҗалыгына зарар килсә дә, нефть чыгаруны арттырырга кирәк. Нефть сәясәт өчен кирәк, ди. Илнең абруе өчен. Аны гына аңлыйбыз инде, политика һәр нәрсәне корбан итә...

Инде өйлә авышып бара иде, пландагы эшне башкарып бетергәч, тау итәгендә үсеп утырган каралып, кайрысы җирдә машина эзе шакмакларын хәтерләтеп яргачланган карт каен төбенә күләгәгә килеп аудылар. Изүләрен чишеп, кепкаларын салып җилләнделәр. Бүген кояш артык кыздырмый, нindидер элпә болытлар аша талгын җылысын коеп тора. Һавада чәчәк исе, баллы куәт исе аңкый. Сулышка иркен, ләззәтле җылы сөт кебек һава рәхәт.

— Председатель,— дип, Чуканов нindидер кызык әйтергә теләгәндәй итте.— Кешеләрең нефтькә китеп бетсә, Чарли-безработный булып калачың бит?

— Бетми,— дип суздьı Минъяров юан муеныннан тирләрен кульяулыгы белән сөртә-сөртә.— Бездә пленныйлар шактый, алар китәргә куркалар.

— Власовчылармы?

— Түгел. Башта бер бик зур рус авылында торганда немец тылында калганнар. Шуны белгәч тә үзләренең армеец икәнен яшерер өчен граждански кием юнәткәннәр. Без шушы авылныкы, дип барганнар. Фамилия-исемнәрен шунда ук русча яздырганнар. Бераздан авыл кешеләре белән боларны Германиягә эшкә алып киткәннәр. Пленныйлар чутында булмагач, ачтан үтермәгәннәр. Хәзер барысы да шуннан кайткандагыча рус фамилияләре белән йөриләр. Сидоров, Александров, Николаев, Волков... Берсе, элеккеге татар фамилиясенә кайтырга теләп, милициягә барган икән, өстәл аша кычкырганнар: тайгада урман кисәргә барырга телисеңме? — дип җикергәннәр. Шуннан шып булдылар. Бар эшне шулар алып бара. Өчәр смена эшләсәләр дә, дәшмиләр, чөнки куркалар... Курку әйбәт нәрсә. Хәзер әнә яшьләр курыкмый, шуңа тәртипләре дә юк...

Бераз тынып, уйланып калдылар.

— Катылык кирәк ул, шунсыз булмый,— дип куйды Тартакиев.

— Минә берни булса, искелек калдыгына сылтыйлар. Ә совет чорында туып тәрбияләнгән кешеләр югыйсә? — Чуканов ничектер моны күңеленнән алып түгел, кемнеңдер кылын тартып карар өчен әйткән төсле булды. Байкин моны абайлап тормады, бу җимгә чиерткәндәй итте. Аның беркатлы булуы тагы сизелеп калды.

— Адәм баласы үзе бик иске бит, шуның өчен аңарда искелек күп,— диде.— Бер дә гаҗәп түгел...

— Миндә бернинди искелек юк,— диде Минъяров ничектер пионерларча. Аңардагы әнә шундый наив-ясалма дәртлелек һәр минутта бәреп тышка чыга иде.— Мин баштан аягыма чаклы совет кешесе...

— Син характерың белән кемгә охшагансың?— Байкин бик кызыксынган төстә торып утырды, мөлаем елмайды, күзлеген рәтләде.

— Тач әтиең, диләр. Әти дә озак еллар колхоз председателе булды...

— Әтиең синең һавалы, начальниклар сүзен бик тыңлаучан, кул астындагыларга шактый кырыс булгандыр, ахры. Йә, хакмы?— Байкин тәкәллефле елмаеп карый иде.

— Точно, нәкъ өстенә бастың. Әллә минем әти белән таныш идеңме?— Минъяров Байкинның яшен билгеләргә теләп, сынап төбәлде.

— Юк,— диде Байкин.— Синең холык-фигылеңә карап әйтүем... Характерың белән әтиеңне кабатлыйсың, әтиең геналары сиңа күчкән...

— Кара, кызык булып китте әле бу...— Чуканов яңа папирос кабызды. Минъяров ни әйтергә белми кет-кет көлде.

— Шартлар үзгәрсә дә, адәм баласы үзгәрми димәкче буласыңмы?— Тартакиев ничектер Байкинның җаена ятарга теләгән кебек иде. Байкинның эчендә үзенә карата начар уй посып торганын сизә. Байкин да сагаеп маташмый, берәр шырпы кадарга гына тора, ләкин биредә сер бирми, төксе булса да, аңа елмаеп карый. Эчендәге өнәмәү хисен тышка чыгармаска тырыша иде.

— Мин әйтмим, чынбарлык шуны күрсәтә...

— Юк, кеше шартларга карап йөри, ул — шартлар колы!— Тартакиев үзенең төшеп калганнардан түгел, шактый гыйлем кеше, заманча булуын сиздерергә теләгәндәй иде. Ул Байкинга белгертергә тырыша: син уйлаганча ук мин алама кеше түгел, аракы эчү белән канәгать булып, көнне шулар белән тутырып яшәмәгән, ә башын да эшләткән. Шуның өчен ихтыярлы, максатлы, абруйлы кеше. Аның белән санлашалар...

— Әйе, әдәм заты шартлар таләп иткәнчә булырга тырыша,— диде Байкин, нindидер тыныч тонга күчеп.— Ягъни, шартлар мәҗбүр иткән рольгә керә, шуңа кирәкчә уйный. Ә үзе үзгәрми ул!

— Әйтик, бүтән шартларга эләксә, бүтән сыйфатларын күрсәтер иде, шулаймы?— Тартакиев сүзне сәясәткә кертмәскә итә иде шикелле.

— Элек кешеләр әйбәт булган, ә хәзер алай түгел, нилектән бу, ә? Ә бит киресенчә булырга тиеш иде?— Минъяров үз практикасыннан чыгып фикер йөртә иде. Бүтәннәр нигәдер дәшми, сәбәбен Минъяров сизеп бетермәде. Ә сәбәп — сүзнең сәясәт сферасына кереп китүе иде. Иптәшләр сагайдылар.

— Әйе,— диде Минъяров турыдан ярып,— хәзер адәм баласын тыңлатып булмый. Эшне өнәмиләр, шабаш! Юк, адәм заты әллә һаман начарлана гына барамы?

— Юк, ялгышасың, кешеләр яхшыра бара!— дип куйды Чуканов ныклы итеп.

Аңа җавап бирүче, каршы төшүче булмады, уйланып калдылар. Адәм заты начарлануга тормыштан күп мисаллар китерергә булыр иде. Ләкин, телеңне кыска тоту яхшырак дип, эчтән үзләрен тыйдылар шикелле. Һәркемдә тормыш тәҗрибәсе, нишләсен. Һәркемдә югарырак баскычка күтәрелү, карьерага өмет итү иде. Дәрәҗә эшләргә өмете, чамасы калмаган кеше генә эчендәген ачып сала, дөресен сөйли. Күтәрелергә әз генә чамасы булган кеше бервакытта да эчендә туган чын фикерен тышка чыгармый, дипломатка әйләнә. Һәр сүзен заманга яраштырып сөйли. Моны ничек гаеп итәсең инде? Һәркем үзенчә яраша. Күпләр әнә Чуканов кебек газетча гына сөйлиләр. Шул рәсмилек буенча гына гамәл ит, һәрчак хаклы булырсың, беркемдә дә шик уятмассың. Тегендә синең хакта «мнение» әйбәт булыр... Шул тәҗрибәгә таяналар. Икенчеләр турыдан-туры караны ак дип әйтергә эчке уңайсызлык тоеп яшиләр һәм фикерләрен йә әйтеп бетермиләр, йә томанландыралар. Тартакиев кебек тәгәллектән качарга тырышалар, абстракт фикергә тотыналар. Үзләрен

хаклык яклы, кирәк чакта халык мәнфәгатен кайгыртучы итеп күрсәтәләр. Кайберәүләр исә, Минъяров кебек, эчендәге — тышында кыяфәтенә керәләр. Алардан дөрес сүз ычкынса да, чудаклык итеп бәяләнә. Билгеле җирдә шик уятмыйлар һәм куркыныч саналмыйлар. «Ә мин үзем нинди кыяфәттә яшим икән соң? — дип уйлавын дәвам итте Байкин.— Мин дә ярашаммы соң? Бөтен хикмәт тә шунда, мин яраша белмим. Бу минем тумыштан килгән уңышсызлыгым»...

Байкинның уйлары бүленде, алар янына машина килеп туктады. Нәкъ кирәк чакта бит. Шофер зирәк, башын эшләтә торган егет икән. Утырыштылар. Минъяров шофер колагына нидер әйтте. Теге шунда ук аңлады. Үз кешеләр бит. Минъяровның: авылдан качтың бит, дип ачулануының эзе дә калмаган иде.

Борчак җире кырыеннан үргә таба менеп, урман эченә керделәр. Шактый гына урман эчендәге сикәлтәле юлдан баргач, бик матур кояш тулы урман аланына килеп чыктылар. Бу — колхоз умарталыгы иде. Аланның нәкъ уртасыннан чишмә суы агып үтә. Шуның ике ягы буйлап бик күп умарта оялары тезелеп киткән... Аскы буйда карт каен, имәннәр ышыгында өч тәрәзәле бүрәнә йорт һәм шуның артында берничә келәт күренә. Өстәрәк озын чүнникнең бер башы шәйләнә иде.

Иң элек машинадан Минъяров сикереп төште һәм умарталар арасына кереп китте. Битлек кигән умартачы нидер эшләп маташа иде. Рәисне сүзсез дә аңлады, эшләрен җыештырды, кунаклар янына ашыкты. Председатель кунакларның дәрәҗәсен аның колагына пышылдап өлгергән иде. Ул бик ачык чырай белән килеп күреште дә өенә керде, аннары нидер хәстәрләү өчен амбарларына ашыкты. Кунаклар сизенделәр, димәк, аларны сыйларга телиләр. Шуны белмәмешкә салынып, чишмә суында бит-кулларын юдылар, кульяулыкларын чыгарып сөртенделәр. Шунда өй ишегендә Минъяров башы күренде, ул шатлыклы чырай белән кунакларны чәйләп алырга дәште. Кунаклар кыстатып тормадылар. Алар кергәндә өстәлдә табагы белән кәрәзле бал, берничә тавык тураклап куелган, шулар янына Минъяров зур ак калач та алып килергә онытмаган. Күкрәгенә терәп калач кисә: менә безнең пекарняда пешкән ипине ашап карагыз, ди-ди, нинди дер горурлык белән сөйләнә.

— О, монда патша туе! — дип, Чуканов хәлгә бик тиз бәя куйды. Ул арада җитез умартачы чирекле шешә белән ачы бал китереп утыртты. Ачы бал, гадәттә, саргылт төстәрәк була, ә бу көрән, нәкъ коньякны хәтерләтә иде. Шуңа күрә барысы да игътибар иттеләр.

— Бу өченче елгы иске балдан,— дип аңлатырга мәҗбүр булды умартачы.— Узган ел ук куелган иде.

— Торган саен әйбәтләнә, имеш, диләр?..

— Ничектер инде, чамалап карагыз,— дип, умартачы мыек астыннан гына елмаеп, стаканнарга эчемлекне бүлеп чыкты. Аның исе борынны ярып керә, авыздан сулар китерә иде. Башлап стаканны Минъяров тотты һәм кунакларны хәзинәдә бары белән сыйланырга кыстады.

Бал бик зәһәр-үткен иде, чынлап та коньякка торырлыгы бар, ахрысы. Иң элек моны Чуканов сизде һәм урыныннан кузгалып, Минъяров җиңенә тотынды: без теге эшне төгәлләп куйыйк, диде. Җирләрне контрактавать итү документларын тутырырга, кул куярга кирәк иде. Алар ишек төбенәрәк китеп, рам ясый торган верстакка сөялделәр. Чуканов портфеленнән кәгазьләр чыгарды. Җир өчен 80 мең күчерелә, диде. Минъяровның йөзе җитдиләнде, табындагы иптәшләргә борылып карады. Ул әрсезләнергә уйлады, мине якларлар микән, дип сынавы иде. Җирләрне беренче генә сатуы түгел, еламаган балага... Әллә үз кесәсеннән алып бирәме...

— Йөз мең итик инде,— диде һәм табындагыларга башын борды. Тегеләр мәнсезләр түгел иде, аңладылар.

— Чуканов, кысма,— дип аваз салды Тартакиев, маңгаенда бөжраланып-бөжраланып торган сары чәчләрен селкеп.

— Яхшы кеше өчен жәлләмә! — диде Байкин. Ул аңлый, бирәдә җавапсызлык яки дәүләт хисабына юмартлану юк. Нефтьчеләр бик бай, чөнки оборона министрлыгына карыйлар. Аннары колхозлар белән әйбәт мөнәсәбәттә булу үзләре өчен дә файдалы. Җир-суларны пычраткан өчен тавыш куптарып йөрмәсеннәр дип тә контрактация вакытында 10—20 мең белән санашып тормыйлар иде.

— Ярар, чукынсын, — дип кул селтәде Чуканов һәм йөз мең иттереп язды. Иң элек герблы документка үзе кул куйды, аннары тегеләрдән дә имза салдырды. Йөз меңгә чек кәгазе Минъяровның эчке кесәсенә кереп ятты.

Шуннан соң ныклап сыйланырга керештеләр. Минъяров белән Чуканов, ай-һай, таза салалар икән. Әмма бал куәтле иде, тегеләрне тиз мәлҗерәтте. Алар бик кычкырып сөйләшә башладылар. Тартакиев белән Байкин шул бер салган стаканнарыннан әз-әз йоткалап кына утырдылар. Ныграк ашадылар, бал белән калачны урдылар. Шофер председатель бәйләнүдән куркып кермәгән иде, Байкин аңа калын гына калач телеменә бал ягып чыгарып бирде.

Ул кире әйләнеп кергәндә Минъяров белән Чуканов кочаклашып җырлыйлар иде. Ахры, боларның беренче утырулары гына түгелдер, дип уйлады Байкин. Көе дә әллә нинди борынгы, фаҗигале, күңелнең кай төшенәдер барып тия. Шәрекъ көйләре кешенең газаплы өметсезлеген, адәм затының шул газаплардан котыла алмаслыгын, шуларга дучар ителгәнлеген моңлыйлар. Җырның сүзләре дә гадәти генә түгел иде:

> Тормыш юлларыннан барган чакта
> Бер бик кыен була, бер рәхәт...
> Кайсы аллаларга йөзем борыйм,
> Тарта Исус, тарта Мөхәммәт...

Бу — Чуканов җыры булырга тиеш. Ул үз язмышын чагылдырып җырлый.

Кайбер чуашлар мөселман дине тоталар. Кайберләре әле мөселман, әле христиан диненә күчәләр. Заманасына карап. Христиан динендә булган керәшеннәр кебек. Нигә алар мөселман динендә түгел? Аларны да чукындырганнар шул.

Форсаттан файдаланып, Байкин кысталган кыяфәт белән һавага чыкты, аның артыннан мыштым гына Тартакиев кузгалды. Алар, күз алдыннан югалу өчен, урман эченә таба атладылар. Икесенә дә сый килешкән, каннарын кызуландырып, арыган буыннарны язып җибәргән. Кәефләрен күтәргән. Мондый моментта хатын-кыз искә килә. Тамырларда кан җәһәт йөри һәм шунлыктан баш миендә төрле фикерләр калка. Моңарчы әйтергә куркып, яшереп тотылган уйлар чыгарга сорап, лепкәгә шакый башлыйлар. Икесенең дә күңелле хәлләр турында сөйләшәселәре килә иде. Ләкин тормыш киресен мәҗбүр итә.

— Платон Никитич үлеменә син гаепле бит, Тартакиев, — дип әйтеп куйды Байкин үзе дә сизмәстән. Сүз теленнән ычкынгач кына аңы эшли башлады. Ялгышканына, кешегә каты бәрелүенә уңайсызланды. Эчтән үкенү кичерде. Әмма ул хаклыкны әйткән иде, шушы нәрсә артык кичерүдән тыйды... Ә Тартакиевның йөзе кинәт кара коелды, дәһшәтле сызыклар чыгарып җыерылды.

— Ташла, син ни сөйлисен?! — диде, битләре тартылып, иреннәре югарып калды. — Шаяртасыңмы? — Күзләрендә ачы елмаю чаткылары уйный иде. Байкин исә чигенү мөмкин түгеллеген сизде, әмма аңа бик нык оят иде, шулай да оятын аяк астына таптап, дөреслек дәгъва итәсе килде. Бу аның үзенә буйсынмаган эчке таләбе иде.

— Оныту сиңа файдалы, конечно...

— Юк, һич аңламыйм, син нишләп бутыйсың, Байкин?

— Тартакиев, йә, ир бул әле, Платон Никитичны нишләткәнеңне онытмагансың, кыланма! Гаебең бик зур...

— Бернинди гаеп юк, Байкин, син ялгышасың! Син ничек шулай әйтергә җөрьәт итәсең? Кем дип беләсең син мине?

— Гаебеңне мин шаһитлар белән исбат итә алам. Ухбаев миңа барын да әйтте.

— Шул жуликка ышанасыңмы? Җайга җайлашу өчен әтисен сата торган бәндә бит ул...— Тартакиев, җирәнгәндәй йөзен җыерып, читкә карап бара башлады.

— Нигә нәтиҗәне яшердең? Нефть чыккан булган, ә син юк, дип хәбәр иткәнсең. Ухбаевны да дөресен әйтмәскә кисәткәнсең? Эх, син! Бу бит коточкыч этлек!

— Юк, син хатыннар гайбәте сөйлисең...

— Нефть булу-булмау Платон Никитич өчен йә үлем, йә яшәү икәнен син бит яхшы белә идең. Шуны белеп, махсус рәвештә һөҗүм ясагансың!

— Аның үз-үзенә шулай хисап бирүе ул эшкә бәйләнмәгән. Ә психикасының нормаль булмавын гына күрсәтә. Һәр ударга үзеңә кул салу белән җавап бирсәң, нәрсә була инде! Чын галим теләсә нинди һөҗүмне күтәрә алган чакта гына чын була. Юк, нәтиҗәне ничек итеп әйтүемнең бернинди ролен күрмим. Хәтта мораль җаваплылык та тоймыйм...

— Моралең булмагач, тоймыйсың, билгеле! Йә, нигә нәтиҗәне ялгыштырып әйттең?

— Начальник чылтыратты, хәл үзгәрде, диде, нәтиҗәне яшерергә боердылар, дип аңлатты. Әллә өстән килгән фәрманга синең каршы килгәнең бармы? Берни белмәгән кебек, бик чиста гына булып сөйләшәсең! Моральсез, имеш!

— Юк, мөмкин түгел, Платон Никитич өстән рөхсәт алган иде.

— Шуны кара, менә без бүген буровой өчен мәйданнар сатып алдык, әйе. Ә иртәгә өстән чылтыраталар, юк, ул җирләрне үзләштерергә кирәк түгел, әнә фәлән-фәлән төшләрне бораулагыз... Күпме шулай булды һәм булып тора. Башны әйләндереп бетерәләр. Бар җирдә шулай.

Тартакиев эт каешына әйләнеп беткән, тиз генә бирешә торган түгел. Начальниклар белән дә бик әшнә. Мәскәүдә главкадагы шишканың «любимчигы». Начальник бирегә ауга килеп чыккалый һәм шул чакта Тартакиев аның белән йөри, аңа ау эте ролен ул башкара икән... Ни өчендер Байкинга элекке танышы турында шундый сүзләр килеп ишетелде. Әллә юри сөйлиләр идеме икән?

Байкин күрә: аның сүзләре Тартакиевка берничек тә тәэсир итми иде. Үзендә әз генә дә гаеп тоймый микәнни бу? Ким дигәндә, ул мораль яктан гаепле бит. Дөресне әйтмичә, кешене алдалау ничек гаеп саналмасын, ди?.. Тартакиев бераз дәшми баргач, әйтте:

— Болар бары эмоция, Байкин,— диде, үзен рухи-мораль яктан бик хаклы итеп санаган төстә.

— Син бит аның соңгы өметен алдадың, соңгы терәген кистең! — ди-ди, үрсәләнеп сөйләнде Байкин.

— Терәк дип, үзен дә дәүләт серен әйтмәс идең. Кешенең эчке хәле белән рәвбе санашалар? Әллә айдан төштеңме? Кычытмаган җирне кашып йөрмә, зинһар!

— Мораль яктан гаебең бар синең, әмма мораль гөнаһ хөкем ителми, шайтан алгыры! — Байкин үртәлүле зәһәр итеп көлгән итте. Бу кеткелдәүдә үзенең көчсезлеген тою чагылды. Тартакиев исә үзенең гаепсезлеген һәм көчлелеген тоя иде, ул тәкәллефле елмаеп барды, бүтән сүз кайтармады... Алар агачлар арасында урап йөри торгач, амбарлар артына килеп чыктылар. Шофер кайтырга ашыгып көтеп тора иде. Тегеләрне уятып булырлык түгел, дип аңлатма бирде ул. Минъяров бер өч тәүлексез бирердән китмәячәк. Умартачының ачы балын бетермичә...

Сүзсез генә машинага утырдылар. Шофер машинаны бик кызу алып китте. Әлмәт — Азнакай юлына чыгып, НСУга җиткәч, Тартакиев: «Ми-

нем монда эшем бар»,— дип төшеп калды. Шуннан соң шофер Бөгелмәгә элеккеге, күтәрелгән юлдан элдерде.

Кузгалган уйлары, ярсыган баш мие һаман әлеге тартыш турында бөтерелә иде. Әйе, карьера өчен, үз мәнфәгатьләре өчен кешеләр иң якын иптәшләрен дә алдыйлар. Таптап үтәләр. Платон Никитич фаҗигасеннән соң Тартакиевны участок начальнигы итеп күтәрделәр. Ләкин өскә үрли алмаган ахрысы, номенклатур шәхескә ирешә алмаган. Нәрсә өчендер илле икенче елны аны түбән тәгәрәткәннәр дип ишетелгән иде. Политика микән, хатын-кыз микән? Ир-атка аяк чалучылар шулар бит! Ә нинди яраша торган кеше югыйсә?

## V

Сәлим кайчандыр безнең Беренче белән бергә укыган икән,— дип башлады тикшерүче Ефимов, үтерелгән абыйсының эшен белергә килгән Зәйгә. Ул нииндидер канәгатьләнү белән учын-учка угалап алды. Зәй гаҗәпләнде. Беренче турында ничек иркен уй йөртә ала. Әйе, Сәлим — Зәй әнисенең бердәнбер энесе, гел читтә булды. Унике яшеннән детдомга эләгеп, аннан качып, тагы тотып шунда кайтарылып йөрде.— Октябрскида, техник училищеда. Беренче — ул чагында комсомол комитеты секретаре. Бер бик чибәр кыз белән күңелсез хәле булган, дирекциягә ишетелгән. Тикшерергә куйганнар. Моны белеп, кыз янына барган, елый-елый ялынган: без өйләнешәбез, ул мине ала, безнең арада берни дә юк, без аңлаштык, дип язып бирүен үтенә. Мин сиңа өйләнәм, курсны бетерүгә язылышабыз, ди. Өзелеп, чын йөрәгеннән алып, ышандырып вәгъдә бирә. Кыз ышана һәм ул әйткәнчә эшли. Тегене позордан коткара, биографиясе дә чиста кала. Ләкин соңыннан ул кызга өйләнми. Төрле сәбәпләр таба, тарта-суза, кача... Моны Сәлим белгән, яңа шәһәрдә эшли башлагач, тишкән дә булса кирәк. Беренче әле ул вакытта — горкомның оештыру бүлеге мөдире. Бу сүз аңа барып ишетелгән. Начар сүз тиз йөри, җир астыннан йөри, ди бит. Беренче житез кеше. Сәлимнең эштән кайткан чагын чамалап, бер почмакта очраткан. Сөйләшкәннәр. Беренче башта, фатир мәсьәләсендә ярдәм итәрмен, дип, хәерхаһ сөйләшкән. Аннары кинәт: «Нигә син минем хакта юк сүзләр чәчеп йөрисең?..— ди-ди, янарга керешкән.— Моның өчен мин сине таш капчыкка тыга алам, колагыңа киртлә»,— дигән...

— Туктале, Алексей дәдәй, моның абый вакыйгасына ни катнашы бар?— дип сүз кыстырды Зәй, аптырап.

— Сабыр, тыңлап бетер... Беренчебез бик югарыга үрләргә исәп тота. Андыйлар үзләренең гөнаһлары шаһитен бер дә өнәмиләр. Бигрәк тә хатыны. Сәлим белән булган хәлдән өч-дүрт ай элек кенә хатынның Керкәледәге туганнан-туган энесе «тегеннән» кайткан иде. Рецидивист. Бер ым гына кирәк, аңа кеше үтерү — бер төкерү генә...

— Җеп очы шуңа таба сузылып бара мәллә?

— Әйтерлек фактлар юк әлегә. Без һәр версияне тикшерергә бурычлы.

— Тәнәшев дигән тракторчы аңа каныгып йөргәнен хәтерлим. Абый ничектер тишкән иде?

— Ә-ә, аны әйтергә онытып торам икән. Әйе, алар арасында каты дошманлык булган. Тәнәшев белән сөйләштем. Сәлимне дөмектереп яхшы эшләделәр, ди.

— Чынлапмы? Ай-һай, бар адәми затлар,— дип, Зәй шаккатуын белдерә алмый чыдамады.

— Сәлим хатыны чибәр нәрсә бит, завгар белән йөргән икән...

— Әйе, абый салган баштан килеп елап утырды. Өсләренә барып кердем, нишлим, ди-ди ачырганалды. Әмма хатын үзенә бик яхшы карый, өф итеп кенә тота. Тик әнә шул ягы суя. Бүтән бервакытта да

кабатланмас, дип яшен агыза-агыза муенга асылына. Гафу итәм инде, нишлим. Бераздан тагы ычкына. Запой кебек, ди... Шулай өзгәләнгәне хәтердә. Җиңги безне абый белән аралаштырмаска тырышты.

— Булыр, булыр,— дип, Ефимов сүзен дәвам итте.— Завгар һәр кайткан яңа тракторны Сәлимгә бирә икән. Ни өчен шулай икәне һәркемгә мәгълүм. Завгар усал адәм. Тәнәшев бу хәлгә тәмам котырына торган булган. Сәлимгә йөзенә бәреп әйтә икән: хатының завгарга бирә, завгар сиңа бирә, дип. Сәлим юаш, сабыр кеше. Бер сүз дәшми. Ни әйтә алсын бу очракта. Чираттагы яңа трактор тагы Сәлимгә булгач, Тәнәшев ачудан шартларга җитеп, завгарның бугазына барып ябышкан, милиция чакырганнар. Сәлимне үтерәм, дигән сүзләр ычкындырган. Тәнәшев бит утырып кайткан кеше. Милициядә янаган өчен статья чәпәргә уйлаганнар. Тик завгар үз порукасына алып калган...

— Бер анда булган кеше тагы... Ничектер башка сыймый...— дип куйды Зәй.

— Адәм заты турында алдан берни дә төгәл әйтеп булмый. Әллә ниләр эшләп куюы бар. Кешене теге яки бу эшкә табигате тарта бит. Теләмәгән эшен дә эшләп ташлый. Соңыннан гына аңга килә. Язмыш дими ни дисең...

Ефимов яныннан Зәй авыр уйлар белән китте. Нәрсәгә дип йөрим, үлгәнне барыбер кайтарып булмый. Гаделлек өскә чыксын өченме? Явызлык фаш ителсен, яшеренеп калмасын дипме? Тыштан караганда тормыш әйбәт, шома, музыкалы, чәчәкле. Ә шул җырлар, чәчәкләр артында күпме явызлык яшеренгән? Качып-посып кына үз явызлыгын намуслы кешеләргә салып ята. Күпме көрәшәләр ул явызлык белән, күпме оешмалар чын көрәш алып бара, ә явызлык һаман кимеми. Арта гына бармый микән әле? Каян туа соң ул явызлыклар? Уйласаң, гаҗәпкә калырлык. Андрей Казан белән очрашканда Зәйнең шул хакта сүз кузгатканы бар. Ул галим — башын гел уйлатып тота торган кеше. Ул әйтә: яшәү шартларын яхшырту белән генә явызлыкны бетереп булмый. Һәм мисал китерә. Әнә өченче ел биредә Мәскәү нефть институтының филиалы ачылды. Анда элеккеге таныш Ленинградтан дымлы климат ярамаганлыктан килгән доцент эшли. Квартиры дүрт бүлмәле, хатыны горонода, күп акча алалар. Рижский мебель, хрусталь. Шуның 15 яшьлек малае жуликларга ияреп, парфюмер лагерен басуда катнашкан. Аңа бит берни кирәк түгел. Ни сәбәптән ул шулай эшләгән? Моның этәргече нәрсәдә? Ата белән ана — икесе дә педагоглар, шул сорауга җавап таба алмыйлар. Барча хәлне күздән кичергәннән соң, аңа нинди дә булса хәрәкәт, эш кирәк булган, дигән фикер чыгаралар. Әйе, адәм баласында нәфсе бик әшәке, аның төбе юк, дип нәтиҗә ясый Казан. Явызлык әнә шул нәфседән килә... Ерткыч нәфсене йөгәнләп торган намус, оят, үкенү дигән нәрсәләр безнең катлаулы тормыш барышында әкренләп бетә бара. Кирәкмәс, комачау итә торган нәрсәләргә әверелә. Явызлык тәмам иркенгә чыкты. Бәлки дөньяны яхшылык белән генә алып барып булмый торгандыр? Яхшылыкның да кайбер аерым шәхескә явызлык булып төшүе мөмкин бит. Шул ук вакытта явызлыкның да кайберәүгә яхшылык булуы ихтимал. Димәк, шулай булгач, үз нәүбәтендә, явызлык та кирәк нәрсә булып чыга түгелме?

Кич белән балалар кухнясыннан чираттагы «смесь» сөтен алып кайтып барганда Фалия очрады.

— Бала ничек, тереләме инде? Нигә сөткә килмисең? — дип, йөзеннән чәчелгән нурга һәм сорауларга күмеп ташлады ул.

— Әллә ни алга китеш юк әле,— диде Зәй исәпсез сөенгәнлеген аңы белән басып. Фалия, бала авыруына резус дигән нәрсә сәбәп булуы мөмкин, дип әйтеп куйды. Зәй мондый сүзне беренче ишетә иде. Фалия аңлатты: ата белән ананың резуслары, ягъни генадагы нәрсәләредер туры килмәү очраклары була икән. Бу хәл балада көчсезлек, авыру хәл китереп чыгара. Аны дәвалый торган дару да юк. Бала организмы әкренләп үзе җиңеп чыкса гына.

Шулай бала турында, бүтән нәрсәләр хакында сөйләшәләр дә сөйләшәләр. Бер-берсеннән аерылып китә алмыйлар. Чөнки икесенә дә ничектер әйбәт. Ләкин моны сүз белән әйтергә, бер-берсенә белдерергә теләмиләр. Бер-берсенә танырга уңайсызланалар. Әллә Фалиянең берәр өмете бармы? Юк, Фалия акыл белән эш итә торган кыз, зәңгәр рәшәләргә алданыр вакыты узган. Әмма ул барыбер очратуына шат.

Зәй Фалияне очраклы гына күреп, сөйләшеп йөргәннән соң, өенә уңайсызланып кайтып керә. Ничектер үзе дә сизмәстән Рамиләгә, балага хыянәт иткән сыман тоела. Рамилә кызганыч булып китә. Бу бала белән күпме газаплана ул. Аның юбалгылыгы тудырган ачуларны онытасың. Рамиләне бернәрсәгә дә өйрәтмичә үстергәннәр. Бик иркәләп-кадерләп кенә. Җил-яңгыр тидермәгәннәр. Безнең чорда баланы шулай теплицада үстереп була микәнни? Әнисе кызын артык яраткандыр, күрәсең, үзенең наданлыгы белән үз баласын бәхетсез итүен аңлап җитмәгәндер. Бер эшнең рәтен белмәү, һәрнәрсәдә балаларча уй йөртү хәзерге вакытта чын бәхетсезлек бит инде. Менә шул бәхетсезлеген алып иргә чыкты һәм ирен дә бәхетсез итте... Зәй бу хакта уйламаса да, кайчагында башына канәгатьсез фикерләр килә. Үзен уңышсыз итеп саный. Әтисе дә, хатыныннан бәхетем булмады, дип гомер буе зарланды. Зәй сабыр булырга тырыша, зарлануның файдасы юклыгын белә. Ярар, тора-бара җайланыр әле, ди. Тик бала гына терелсен, тернәкләнсен иде...

... Байкин белән Андрей Казан очрашса, бары Платон Никитич турында гына гәпләшәләр. Казан өчен аның тормышы турында белү икеләтә тансык. Беренчедән, бергә укыдылар. Икенчедән, ул үзенең тормышындагы кинәт начар якка үзгәреш булуын өлешчә Платоннан күрә иде. Шуңа Байкинны тыкырдатып сөйләттерә:

— Платон Никитич безнең якларда утыз алтынчы елларда ук күренә башлады. Бер җәйне ул бездә фатирда торды. Мине үзенең лабораториясенә эшкә алды. Без җәй буе тауларда, тирән үзәннәрдә, болыннарда, чишмә, күл тирәләрендә тикшерү эшләре алып бардык. Мин, билгеле, биштәремә тутырган токым үрнәкләрен күтәреп йөрүче генә идем. Әмма ул үзе дә минем белән тигез күтәрә. Аңарда бер тамчы да аристократлык чалымы юк иде. Кешеләр белән гади аралаша, ләкин тирәнгә керми. Мөнәсәбәтләр катлаулануыннан качар иде. Хатын-кызлар белән якынаерга курка. Мине һәрвакыт хатын-кызлар алдыйлар, ди иде. Миңа тугры булмыйлар, хыянәт итәләр. Бәлки гаеп үземдәдер. Хатын-кыз вакытны күп ала. Иркәләмәсәң, ул сиңа үч белән төйнәлә. Уңай шарт туры килдеме, хыянәт иткәнен сизми дә кала, дип сөйләнә торган иде.

Бездә подпольный старательләр бик күп иде. Платон Никитич ничектер шулар белән уртак тел таба. Аларда ышаныч казана. Бервакыт ул ике старатель белән танышты. Берсе бер аягына аксый, әүмәл-тәүмәл килеп атлый, үзе эре сөякле, озын куллы, кара чырайлы тәбәнәк адәм иде. Икенчесенең күзләре кылый. Таушалган, каешланган адәм. Шуларга ияреп, алтын юарга чыгып киттек...

... Бер чаука урманын чыккач, биек булмаган тау буена килеп туктадылар. Чокып эчкә кергән тау куышлары төнлектәй кара булып торалар. Кызгылт-яшькелт комлы балчык. Аяк табаны астында уалып ишелә иде. Тау итәгеннән генә каяндыр чыккан чишмә суы челтерәп агып ята икән.

Кояш баеп бара, шуңа күрә урманга кереп, ботак-яфрак җаеп, ял итәргә яттылар. Тамакка капкаладылар. Аксак белән Кылый һәрберсе аерым-аерым гына берәр чөлти эчте. Шул башларына китте, ахрысы, телләре ачылып, зарланырга, сүгенергә керештеләр. Әллә юри, әллә чынлап, белмәссең. Чөнки өс-башлары әйбәт, бөтен. Тормышны тетепме-тетәләр.

— Бар начарлык алланы бетерүдән башланды,— диде Аксак юл капчыгын ятарга җайлый-җайлый. Платон Никитич бер сүз дәшми. Сагаеп калды шикелле.

— Алла ярдәм итә идеме? — дип сорады ул, аңардан сүз көтеп торуларын сизеп, дәшми калмас өчен генә.

— Урлашулар алласызлык башланганнан соң көчәйде,— диде Кылый, иптәшен куәтләп.— Кеше хакына кермә, якыныңны ярат, дигән кагыйдәләр яхшыга өнди иде.

— Әйе, алла ярдәм итә,— дип Аксак һаман яфракларда кыштырдады.— Гөнаһка керүдән тыя...

— Алласыз-денсез адәм куркыныч ул! — диде Кылый.

— Менә без сезгә куркынычмыни? — Никитичның тавышында әз генә дә шаяру сизелми иде.

— Кем белгән сезне, маңгайларыгызга язылмаган...

— Дин тотучы жуликлар да җитәрлек,— диде Петя Байкин шук тавыш белән.

— Юк, әхлакый яктан диннең файдасы булган,— дип, Никитич тегеләрнең күңелен табарга теләгән кебек әйтеп куйды. Юньләп белмәгән кешеләрне үзенә каршы торгызу мәгънәсезлек иде. Петя икенче нәрсәдән сагайды: болар бик астыртын күренәләр. Никитичның йомшаклыгын сизеп алып, басымчак итмәсләрме? Үзеңне төшеп калган итеп таныту ярамас. Алар бездән әзрәк шүрләп торырга тиешләр.

Икенче көнне эшкә керештеләр. Петя, кәгазь кебек төреп, бер табак калай алган иде. Никитич шуны тәртә юанлыгы ике агачка кадаклап беркетте. Менә тачка әзер. Тегеләр лоток әмәлләделәр. Эре иләк белән вак иләк үзләрендә бар иде, ә зур гына кисәк шинель сукносын Никитич бирде.

— Үзем юам,— диде киң битле Аксак, лоток детальләрен ике тәртәгә әйбәтләп ныгытып чыккач.

— Юк,— диде Кылый бик мөһим эш хакында әйткән кебек.— Мин сиңа ышана алмыйм.

— Әй, үзеңнең намусың...— Аксак йөрәк белән кул селтәде.

— Алтын янында беркемнең дә намусы калмый,— диде Кылый, бик табигый нәрсәне әйткән кебек.

— Ә алла? — Никитич тегеләрнең динле булуларына төрттерде.

— Адәмдәге нәфсе алла белән дә санашмый,— дип, Кылый кыска саплы көрәгенә тотынды.

Аксак белән Петя ком юарга керештеләр. Кылый һаман карулашты: Аксак алтын бөртекләрен авызына йотып, эченә җыеп барачак, дип мыгырданды. Петяны кисәтте: ул күз буа, чамала, аң бул, диде. Аксак үзен түбәнәйтүгә әллә ни исе китмичә, тегеңә ачу белән кул селтәде.

Иң элек чишмә суын ташлар белән буып, кечкенә шарлавык ясадылар. Тачкада ком килде. Ул көрән-яшькелт төстә иде. Кантарсыз. Арада вак яшькелт ташлары бар. Беренче иләктән аларны җыеп читкә ташлыйсың. Платон һәрбер каты кантар кисәген кулы аша уздыра. Тегеләрнең моңа ачулары да килә иде. Платон бу мәсьәләдә чигенми, мыгырдауларын колак яныннан уздыра.

Комлы лотокны селки-селки юарга туры килә. Өстәге ике иләк аша ком тиз үтә, әмма иләк астындагы сукнода шактый тоткарлана. Аннан үткәч, иң астагы икенче сукнога дуенланып утыра.

Аксакның куллары гаять көчле. Петя манма тиргә батты. Лотокны аның уңаена селкетмәсәң, шундый этеп җибәрә, чүгәләгән җирдән артка мәтәлеп китәсең. Аксак дәшеп тормый, бары хәрәкәт кенә итә.

Өйлә узганчы баш күтәрми эшләделәр. Арыгач, лотокны чирәмгә куеп, иләкләрне алдылар, сукнога утырган ялтыравык бөртекләрне чүплиләр. Платон пинцетын Аксакка бирде, аның бармаклары вак нәрсәләрне тота алмый икән. Бөртекләрнең кайсы элпә кебек юка, арада бодай чаклылары да чыккалый. Барысын да калай банкага сала баралар. Кылый учак тергезеп җибәрде. Сукноларны кат-кат тырнадылар. Ялтыравык бөртекләр җыелган банкага Платон бер колбадан берничә тамчы терекөмеш тамызды һәм банканы утка куйды. Теге ялтыравыклар

терекөмеш белән реакциягә керсә — алтын, кермәсә, гади металл була. Бераздан Платон пинцет белән алып банканы ак кәгазь өстенә аударды. Эрбет чикләвеге чаклы бер сары-яшькелт шарчык тәгәрәп төште. Никитич үлчәвен алып тез өстенә куйды һәм пинцет белән хәрәкәт итте. «Утыз җиде грамм»,— диде ул ясалма шатланган сыман. Тегеләрнең ризасызлыклары кыяфәтләренә чыкты.

— Үзегез алып килдегез бит? — Никитич йомшак итеп тегеләрнең җаена ятып сөйләшә иде.

— Әнә, Кылый сүзен тыңлагач соң...— диде Аксак, юан итеп төргән бакча тәмәкесе төтәтә-төтәтә.

— Син, ачәрвах, шушы төшне әйттең бит...— Кылый һәрвакыттагыча кырын торган килеш ачуланып дәште. Петя аларның сүзен бүлде:

— Кем инде чит кешеләрне әйбәт җиргә алып килсен? — диде кинаяләп. Тегеләр әрепләшүдән туктадылар. Петя дөресне әйтеп биргән иде.

Икенче көнне Платон, гадәтенчә, укмашкан комны, ташларны учында тикшереп уздыра иде, ничектер бер кисәкне кире төшермәде. Аны алдына куеп, лупа белән җентекләп карарга тотынды. Балчыктан, комнан чистарткач, моның тоташ бер токым икәне күренде. Токым шактый авыр булса кирәк. Формасы — дүрт әстерхан чикләвеге бергә тоташып үскән тәлгәшне хәтерләтә иде. Старательләрнең күзләре янды. Аксак токымны кулына алып, үлчәгән кебек итеп торды.

— Самородок булмагае,— диде, тәҗрибәле белгеч кебек.

Платон бер сүз эндәшми үз эшендә булды. Токымны бик озак пәке белән чистартты, аннары банкага салды, аңа терекөмеш кушты. Уттан озак тотмый алды һәм банканы аударгач кәгазь өстенә шарчык тәгәрәп килеп төште. Шлак та шактый коелды. Кайсыдыр «ух» дип куйды.

Үлчәүдә токым өч йөз сиксән грамм тартты.

— Бүлешү тиешле! — диде Кылый, тизрәк үз өлешен сирмәп калырга омтылгандай.

— Юк, самородок — тапкан кешенеке! — дип, Аксак телен шартлатып куйды. Аның үртәлгәнлеге, эче сызлавы йөзенә чыкты.

— Әй, ачәрвах, ни сөйлисең! — Кылыйның тавышында катгый кыҗрау ишетелде. Алар тагы ырылдашып, гаугалашып китә яздылар.— Бергә таптык, димәк, уртак!

— Дурак, үзең белән тиңләмә, ул бит укыган, галим. Ә укыган кеше — чукынган кеше. Иманы юк! — Аксак Платонның аңына, җанына тукынды.

— Йә, шауламагыз,— диде Никитич тыныч кына.— Тапшыргач, акчасын тигез бүләрбез.

— Анда очсыз алалар, давай, граммын илледән сатып бирәм,— дип куйды Кылый. Аксак та төсе белән аның ниятенә кушылуын белгертте.

— Юк, самородок бүленми,— диде Никитич, характерын күрсәтергә теләп. Тегеләрнең тынычлыклары беткәнлеге һәм эчке борчылулары төсләренә, күзләренә чыккан иде.

Самородок ак кәгазьгә төрелеп, аерым чехолга салынды һәм, бүтән токымнардан аерып, күн сумкага урнаштырылды.

Яфрак, чыбыклар өстенә тезелеп яттылар. Аксак белән Кылый, уйсыз кешеләр шикелле, бик тиз гырлый башладылар. Никитич борчылды, эченә пошаман төште. Әллә кара базарда гына саттырыргамы? Бермәбер артык бирәләр. Ләкин кемгә ышанасың? Болар, алырлар да, коерыкларын да күрсәтмәсләр?

Тиле, ничек шуны белми торам, Шайтановка әйтергә кирәк! Ул рәтен белә. Аны акыллы санап, киңәш иткәнне дә бик ярата.

Шул уй белән йокыга китте. Капчыгын баш астына куеп яткан иде. Төнлә башы аска таба чүмәлгәнгә уянды, йокы аралаш тигезләмәкче булды. Ләкин кинәт арттан муен тамырына бик каты итеп китереп суктылар, күзеннән ялкын чаткысы күренде, кулы берни тотмас булды.

Кырыйда гына кемнеңдер ах-ух килгән киеренке авазы колагына керде. Бер минуттан барысын кара дөм каплады.

Никитич икенче көнне йөзен кояш кыздырганга уянды. Күзләрен көчкә генә ача алды. Бер мәл үзе белән ни булганын аңларга тырышты. Һәм миенә шул китереп сукты. Старательләр самородокны алып качканнар!.. Күзенә Петяның башы чалынды, яңагы тоташ канга каткан, үзе гыжлап сулыш ала иде. Ул аны көч-хәл белән исенә китерде.

Алар озак терелделәр. Петяның чигәсенә каты сукканнар, бер күзенә ак төште, колагы начарланып калды. Никитичка да нык эләккән. Сульяк җилкә сөяге чатнаган иде. Ул озак авырды, барыбер төзәлеп җитмәде. Сул кул гарипләнебрәк калды... Әмма бу яман нәрсәнең бер уңай ягы да килеп чыкты. Сугыш башлангач, мобилизация комиссияләре икесенә дә ак билет бирде. Сугышның беренче айларында ук аларны шул Сара станциясендәге практик-тикшеренү базасына күчерделәр. Күп галимнәр гаиләләрен алып килде. Ачлык хәвефеннән шунда котылып калдылар. Ә кырык биштә — янә Мәскәүдәге нефть-тикшеренү лабораториясендә. Платон Никитичның материаллары тау-тау. Диссертация яз, дип кыстыйлар иде. Шул исәп белән, ул журналга зур материал бирде. Ләкин баш өстендә кара болытлар пәйда булды. Генетикларны тар-мар итеп ташладылар. Кара көннәр башланды.

Платон Никитичның «Нефтяное хозяйство» журналында нефть генезисына карата зур гына мәкаләсе басылып чыккан иде. Күпмедер вакыттан шуны тикшерү оештырдылар. Платон Никитич үз артында ниндидер сәламәт булмаган ыгы-зыгы барганын тиресе белән дигәндәй сизеп яши иде. Чөнки, беләсең, тычкан таяк белән йөри торган заман. Иртәгә синең белән ни буласына бернинди ышаныч юк. Эчеңә чумган килеш үз эшеңне эшләп йөрисең. Хезмәттәшең белән бары эш турында гына бер-ике сүз алышасың. Ул синнән шикләнә, син аңардан сагаясың.

Лаборатория галимнәре, препараторлар, ассистентлар җыелган иде. Президиумда — институттан берничә туз һәм иң уртада — райком вәкиле. Ул кара зәңгәрсу кительдән, киң, ирләрчә күркәм чырайлы, урта яшьләрдәге кеше. Зур-зур галимнәр аңа килеп, түбәнчелек белән исәнләшәләр, ялагайланалар. Менә аның алдына җыелышта чыгыш ясаячак иптәшләрнең исемлеген куйдылар. Ул, кулына карандаш тотып, укый башлады. Менә бер фамилиягә минус куйды, ә икенчесенә плюс билгесе төшерде. Тәҗрибәдән белә: югары партия вәкиле утырган җыелышта һәр чыгыш ясаучы политик капитал эшләп калырга тырышачак. Кемгә ул капиталны эшләргә бирергә, кемгә бирмәскә — аның кулында. Шул гадәткә кергән: кешене иң якын дус галимнәреннән, шәкертләреннән тәнкыйть иттерәләр. Бирегә дә шул алымны куллану сизелде.

Платонның дусты саналган галим Н.га сүз бирелде. Бик мөлаем йөзле, киң күкрәкле, текә, биек маңгайлы, бар кыяфәтеннән хәерхаһлык, яхшылык нурланып тора иде. Юк, бу начар сүз әйтә алмас, шул тикле нурлы йөзле адәм авызыннан кара сүзләр чыкмас төсле иде. Ләкин нәрсә ишетә ул:

— Бу мәкалә мине аполитичный булуы, иптәш Сталин диалектикасын фәндә куллана белмәве белән шаккатырды. Без ни күрәбез, иптәшләр? Без шуны күрәбез, галим бөек Сталин тәгълиматын белми, үзләштермәгән, шуңа күрә адым саен сөрлегә. Буржуаз галимнәрнең фикерләрен яклый, җөпли. Буржуазмы, түгелме икәнен аера белми. Буржуазия тарафдары дәрәҗәсенә хәтле түбән тәгәри... «Нефтяное хозяйство» мондый буталчык мәкаләгә урын биреп, идеологик хата ясаган. Мәкалә безнең арада череп таркалган рухлы галим барлыгын күрсәтә, безгә уяу булу кирәклеген искәртә. Бөек Сталин тәгълиматын корал итеп, без мондый аумакай позицияләрне фаш итәргә, сафларыбызны чиста тотарга тиешбез...

Платон үзенең колакларына ышанмыйча тыңлый. Исенә төшерә: ашап-эчеп утырганда бу галим гел башкача сөйли иде бит. Фән өчен

сәясәт һич кирәк түгел, дип купме тапкыр тукынганы бар. Хәер, бу галим генәме, барыбыз да үзара шулай сөйләшәбез. Ә трибунага менгәч, бөтенләй икенче төрле сайрыйбыз. Тылсымлы нәрсә ул трибуна. Кешене, җанны икегә бүлә торган, икейөзләнергә мәҗбүр итә торган нәрсә. Трибунага менү белән адәм баласы эчендә ни барын, ни уйлаганын сөйләми, ә нәрсә таләп ителә — шуны такылдарга тотына. Трибуна безнең ике төрле тормыш белән, ягъни «двойная бухгалтерия» белән яшәвебезне ачык күрсәтеп тора. Сәясәт кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне кешелексез иттерә. Фәнгә бернигә сәләтсез ертлачлар, башсызлар үтеп керүгә юл ача. Сәләтсез галимнәрнең бер-берсен сатуын, бер-берсенә дошманлыгын тудыра.

Икенче галим сөйли башлаган икән. Бу яшь, күптән түгел күтәрелгән кеше. Бик фәкыйрьлек белән укыды. Аның шундый икәнен сизеп, Платон аны үзләренә еш чакыра һәм ашатып-эчертеп җибәрә иде.

— Мин иптәш Никитичны аңламыйм,— дип башлады ул бик тирән хәлиткеч фикер әйткән кыяфәттә. Моңарда ярарга тырышу, ясалмалык нык тышка бәреп тора иде.— Нефть төрле газларның зур басым астында, тимер окисьлары кушылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Моны бөек рус галиме Менделеев ачкан. Никитич, шушы фикер белән килешеп бетмичә, төрле буржуаз тәгълиматларга табына, аларны яклый. Мәсьәләне бутый һәм үзе дә бутала. Чөнки галимнең остазыбыз бөек Сталин тәгълиматлары белән коралланган төпле үлчәве, кыйбласы юк. Ул сукыр хәлендә. Сукырларча, буржуаз тәгълимат баткагына барып чума. Студентларның аңын буржуаз фикерләр белән агулауга кадәр барып җитә! Юк, яшьләрне буржуаз рух белән агуларга бирмәбез!..

Шулчак реплика яңгырады, алгы рәтләрдән: «Долой, андый галимне!» — дигән тавышлар ишетелде. Райком кешесе сүз кыстырды: «Иптәшләр дөрес реагировать итәләр!» — диде һәм аңа дәррәү кул чаптылар. Райком кешесенең күңеле булганлыгы әллә каян сизелеп тора иде. Аның кәефе килгәнне күреп, президиумдагыларга да җан кереп китте.

«Күсәк» кушаматлы бер галим сәламәсе трибунага менде. Хәер, галим дисәң, хәтере калыр дигәндәй, бик сантый, надан адәм иде ул. Һәр җыелышта, берәрсен кыйнарга кирәк булса, аны чыгаралар. Аның хакында ямьсез сүз йөри: бу бик талантлы бер галим белән дуслашкан, бер бүлмәдә бергә яшәгәннәр, эч серләрен бүлешкәннәр. Бервакыт төнлә килеп, тегене алып киткәннәр, ә бу аның бастырырга әзерләгән фәнни хезмәтен үзенә алган. Чөнки бүлмәдә беркем дә юк бит. Шаһитлар юк. Тегенең башын бетергәч, бу шул язмаларны үзенеке итеп бастыра һәм диссертация яклый... Бу хәл чынга бик охшый, чөнки шул вакыттан бирле аның бер генә мәкалә дә бастырганы булмады. Бу инде кызып сөйли. Чөнки аның башка козыре юк.

— Партиясез фән була алмый,— диде ул һәм гаять яңа, мөһим фикер әйткән төстә ияген чөеп куйды.— Партиялелек төп инструмент, аннан башка бер ачыш та ясап булмый фәндә...

— Ньютон партиялелек кулланмаган, күп ачышлар ясаган,— дип аваз салды Платон Никитич, бу кешегә чиксез ачуы кубып. Ни хикмәттер, үзеннән әхлакый түбәннәр сине тәнкыйтьли башласа, җеннәрең кузгала инде. Һич кабул итеп булмый, эчкә бары үт ачысы гына тула.

— Ә сез бүлдермәгез! — дип, җыелышны алып баручы озын карандашы белән графинга суккалап алды. Хәсрәт оратор ишетмәмешкә салышты, язганыннан аерылырга курыкты... Тагы берничә галим шактый каты талкыдылар. Бу җыелышта аларга очко эшләп калырга кирәк иде.

Хәзер Платон Никитич үзен-үзе фаш итеп чыгарга, тәүбә итәргә тиеш.

— Мин, иптәшләр, ялгышларымны таныйм,— дип башлады ул.— Партия тәнкыйте минем күзләремне ачты, мин әлегәчә томан эчендә йөзгәнмен. Тәнкыйть урынлы, соңга калмаган. Ялгыш юлда булуымны минә иптәшләрнең принципиаль тәнкыйтеннән соң гына төшенә

башладым... Барча иптәшләргә рәхмәт әйтәм...— Ул шабыр тиргә батты, маңгаеннан борчак-борчак тир тып-тып итеп кәгазьгә тамганы ишетелә. Бу тир каушаудан да түгел, ә үзенең ялган сөйләвенә оялудан иде. Тизрәк бер адым артка чигенеп, урынына чүмәште.

Райком вәкиле сүз алды. Ул остарып беткән, җелекләргә үтәрлек итеп такылдый. Хәлләрне шундый куркыныч итеп тасвирлый ки, баш өстендә болытлар куера, каракучкыллана сыман тоела. Шул кара болытлар эченнән яшен чаткысы кылычтай ялтырап чыгар да менә-менә хәзер... Гаебе булмаса да, билгеле бер моментта кеше үзен гаепле итеп сизә башлый. Гүя нәкъ аның өстенә ниндидер көч ыжгырып, ярсып килә, шул минутта таптап-изеп китәчәк. Һәр тыңлаучыда шундый тоем барлыкка килә. Ирексездән бөрешеп, кечерәеп каласың һәм урындык култыксасына шатырдап ябышасың. «Безнең тирә-ягыбызны дошманнар чолгап алган. Безне үтерергә сагалап, почмакка посып торалар. Җай чыгу белән юк итеп ташлаячаклар...» Сөйли-сөйли шулай куркыныч туа. Кешеләр тынып калган, алар өстендә кара шом канат җилпи. Һәрберсенең эченә курку төшкән һәм гипнозлаган кебек иткән... Оратор бик хәтәр яный торган итеп сүзен тәмамлый. Зал сулыш ала башлый.

Җыелыш беткәч, кешеләр ничектер курка-өркә генә таралалар. Эчләрендә оялап өлгергән курку аларны юашландырган. Шәхесләрен йөгәнләгән, мин-минлекләрен бетергән. Алар буйсынучан, күндәм, һәр нәрсәгә риза булырга әзер хәлгә килгәннәр. Курку бик көчле нәрсә бит. Адәм баласы белән курку идарә итә, диләр. Кешеләр моны танырга теләмиләр, янәсе, алар куркаклар бистәсеннән түгел. Ә теге яки бу адым ясаганда бар эшне курку яки курыкмау хәл итә.

Платон Никитичка беркем дә иярмәде, әнә шулай кинәт дус-ишләре аны ташладылар. Ярар, таныш хәл. Теге елларда халык дошманы дип гаепләнгәннәр янына барырга, кул бирергә ул да шүрләгән иде бит. Менә хәзер үзенә килеп төште. Нинди авыр булуын хәзер генә аңлады.

Ул, яраланган җәнлек үз өненә ашыккандай, авыру сеңелесе өенә таба атлый. Уйлары башында умарта күче кебек гөжли. Кайсынадыр тотынып, ныгытып уйларга, бу хәлне аңларга кирәк иде. Ә ул һаман нәрсәгәдер өмет торгызып маташа. Элеккечә үзен-үзе алдаларга тели, ниндидер өмет калганына үзен ышандырмакчы итә. Шуның аркасында башына күпме тукмак төште. Акыл иңмәсә дә иңми икән. Сәясәт белән бәйләнгән эштә бернинди өметкә урын булмый. Ул кайчы кебек кисә дә ыргыта. Бетте. Бу бит яңа нәрсә түгел. Нинди талантлы галимнәр күз алдында яндылар бит. Әллә кая юкка чыктылар. Син генә бүтәнчәмени?

Тагы шунсы җанны үрти: бу фаш итү җыелышында бер кеше дә практик тормыш өчен файдасы тиярдәй сүз сөйләми. Чынында үзе нәрсә уйлаганын тышка чыгармый. Барысы да өстән төшкән фәрманча гына чыгыш ясый, ә асылда гел ялган сүз сөйли. Шушындый коллектив төстә алдашу ни өчен кирәк? Аның мәгънәсе ни? Менә мин тәүбә иттем, тәнкыйтьне дөрес дип таныдым. Мин дә чеп-чи ялган сөйләдем. Мин бу фаш итү җыелышын коточкыч гаделсезлек дип карыйм. Тәнкыйть сүзләренең тамчысы да дөрес түгел. Фән мәнфәгатьләре бөтенләй куелмый, читләтеп үтелә. Мин дә, бүтәннәр дә үз башын кайгыртып сөйли.

Күпме кеше бушка, бер файдасызга лыгырдады, энергия сарыф итте. Әллә ничаклы нервы түкте, ә нәтиҗә — нуль. Аек акыл хөкем сөргән бер генә җирдә дә мондый хәлнең булуы мөмкин түгел. Биш пар казанлы электр станциясе бушка янып торсын, имеш. Ә ил буенча күпме шундый җыелышлар уздырыла бит. Әллә ничә турбиналы электр станциясе җилгә эшли дигән сүз! Ничек бездә җитешлек булсын, ничек кешеләргә нормаль тормыш тәэмин ителсен. Кая гына барып төртелмә, кытлыкка килеп бәреләсең. Үзебезне үзебез шундый хәлгә төшерәбез. Нигә һәр эшнең практик ягы һәм нәтиҗәсе уйланмый? Гаҗәп! Тормыш бит практик эштән тора. Һәр нәрсәнең үлчәве бары бер генә: файда — зарар! Һәр кешенең бәясе — файдалы яки зарарлы булырга тиеш. Юкса тормыш

алга бармаячак. Кем соң дөньяны алга илтә торган файда — зарар үлчәвеннән безне мәхрүм итеп, безгә ялган үлчәү китереп такты?..

Икенче көнне Платон Никитичны эшеннән азат итү турында приказ эленгән иде.

Бераз вакыт ни тере, ни үле түгел килеш үтте. Беркем ярдәм итә алмый иде. Ул бер-ике инстанциягә йөреп карады, бернинди нәтиҗә чыкмады. Батып баручы кеше саламга да тотына, ди. Бу да нәкъ шулай иде.

Шулай да Платон Никитичка бер эш тәкъдим иттеләр. Ерак Көньяк Урал даласында институтның практика базасы бар, Сара станциясендә. Җәй көне практика үтәргә теләгән студентларны шунда алып баралар. Платон сугышка кадәр һәм сугыш вакытында анда күп эшләде. Ул база таркалу хәлендә икән. Менә шуны торгызырга, киңәйтергә диган күрсәтмә бар... Бу инде үзенә күрә сөрген иде. Монысы әле сәдакәсе дип әйтергә була, һәрхәлдә, кулга алыну түгел... Иртәгә җыенып юлга чыгарга ниятләп, ул көенә-сөенә Старая Вражкадагы фатирына кайтты. Ишеккә килсә, ни күрә ул, тышкы якта аның чемоданы тора. Нигә чыгардылар икән, дип, ишекне шакыса, эчтән хуҗа хатынның чәрелдек тавышы ишетелде. «Платон, хәзер үк кач! — диде куркулы елаган аваз. — Ярты сәгать элек кенә сине кулга алырга милиция килде. Кач! Өйгә тентү ясап чыгып киттеләр. Озакламый тагы киләчәкләр, тизрәк югал! Мине кулга алуларын теләмәсәң, шәһәрдән чыгып кит! Өченче көн төнлә Чайкиннарны алып киткәннәрен ишеттең бит! Алла хакы өчен тизрәк ычкын моннан! Югал, юкса безне дә, үзеңне дә харап итәсең... Кирәк-яракларың чемоданда...»

Платон ышанырга да, ышанмаска да белми, әле бая гына, иртәгә приказ алып китәрсең, диделәр... Багана кебек катып калды. Провокация хәзер гадәти хәл. Хатынның истерикалы чәрелдәвенә чыдарлык түгел иде. Ничектер үзен Платоннан тизрәк аерасы килгән сыман булды. Шайтан, фәнни сотрудник Чайкиннарның төнлә алынуларын ишеткәч, бик курыктылар алар. Хатынның паникага бирелүе нигезсез түгел. Ахрысы, тизрәк сызарга кирәк.

Ул, чемоданын күтәргән килеш, караңгы урам буйлап атлады. Кая барырга, нишләргә? Барып сыенырлык бер ышанычлы зат юк. Ул институтта күрде, белде: янына килергә, исәнләшергә куркалар. Күрмәмешкә салынып үтеп китәләр. Шайтан алгыры, нәрсәгә бу тамаша? Сеңлесе дә аны гел телә: тәкәббер хәерче, идеалист, үз фикереңне дәгъвалап маташасың, тиле! Безнең шартларда беркемнең дә үз фикере була алмый, ди.

Нинди максат белән эшләнә бу тамаша? Фәнне чистарту өченме? Бу рәвешле чистара алмый ул. Баш миендә туган фикерләрне әйтмәскә мәҗбүр итеп була. Мәҗбүр итү, көчләү юлы белән уйлауны тыю мөмкинме? Мине җәзалап, фикеремне бетерделәр, ди. Ләкин икенче кеше башында ул фикерләр барыбер уяна бит. Ә персонально һәр кешене дә җәзалап бетереп буламы? Булыр, булыр, большевиклар эшли алмаган бер эш тә юк.

Безнең хөкүмәт әллә нинди читтән килгән подпольный хөкүмәт кебек. Барча эшне астан, яшертен эшли. Юньле хөкүмәт үз кешеләрен шулай эзәрлекләр идеме? Юк, әллә нәрсә бу, берни аңлап булмый. Хөкүмәтнең үз халкына каршы сугыш алып баруы мөмкин микәнни?

...Чырае качкан Платон Никитич, тәмам өнсез калган килеш, минем бүлмәгә килеп керде. Шыпырт тавыш белән хәлен аңлатты. Бик курыккан, һаман ишеккә башын бора, бармаклары әйбер тота алмый, дерелдиләр. Сине дә калдырмаслар, исән чакта бирелдән сызыйк, дип, миңа карады ул. Мин дә үз өстемдә болытлар куерганын аңа әйттем. Диамат мәсьәләсендә. Моны ул белә иде. Без аның белән диамат турында күп бәхәсләштек. Материя беренчелме, аңмы? Миңа аң беренчел булып

тоела, хәзер дә шулай. Фикеремне үзгәртә алмыйм. Минем аң шулай корылган, ахрысы. Ялганларга күңел бармый. Ә ул чакта диамат укытучысы мине имтиханда өч мәртәбә кире борды. Шулай да мин үземнең фикерне алга сөреп, исбатлап маташтым: «Менә дәфтәр, мин әйтәм, әнә икенче дәфтәр. Алар бер-берсен белмиләр. Аңым булмаса, мин дә дәфтәр турында белмәс идем. Аң булмаса, материя дә булмый...» Укытучы: «Аң булмаса да, материя бар, ул — объектив чынбарлык»,— дип тагы исемә төшерә. «Аннан тыш чынбарлык була алмый, үлгән кешегә нинди чынбарлык булсын!?» «Объектив чынбарлык аңнан тыш яши!» Мин: «Юк, аңнан тыш бары алла гына булуы мөмкин?» — дидем. Укытучы кинәт кайнап чыкты, өстәлгә китереп сукты: «Вон! Син халык дошманы!» — дип кычкырды һәм үзе аудиториядән чыгып китте.

Шул көнне, штат кыскартылды дип, мине эшкә кертмәделәр. Мине анда Платон Никитич урнаштырган иде. Платон Никитич колагыма гына әйтә: «Башта эштән чыгаралар, аннан алалар, әйдә, җыен...» Мин тиз-тиз чемоданымны тутырдым. Никитич тагы пышылдый: «Мин карьерамны сезнең Сара станциясендә эшләп башлаган идем, хәзер тагы шул якка юнәлик, анда качар-посар урыннар күп».

Без, бик шыпырт булырга тырышып, төн уртасында тулай торактан чыгып киттек. Көч-хәл белән Свердловскига билет юнәтеп, транзит поездга утыра алдык.

...Без Мәскәүдән качып киткәч, үзебезнең Сара станциясенә кайтмадык. Анда Никитичны таныйлар иде. Без, тәвәккәлләп, алтмыш чакрым төньяк-көнчыгышкарак булган Мукаев руднигына бардык. Бирелә «Нефтеразведка» тресты оешканлыгын ишеткән идек. Никитичның «Нефтяное хозяйство» журналында чыккан мәкаләләрен беләләр икән. Баш геолог ярдәмчесе итеп эшкә алдылар. Миңа да эш табылды. Ике катлы таш бинада тулай торак. Икебезгә бер бүлмә бирделәр. Кайнар су белән җылытыла, гомуми кухнясы бар.

Күп тә үтми, мин унынчыны бергә тәмамлаган кызны очраттым. Зария исемле, райкомда эшли икән. Фронтта булган. Без уртак тел таптык, һәм мин, күп уйлап тормыйча, Зария янына күчтем.

Никитич биредә күңелендә яшеренеп яткан фикерләрен чыгара башлады. Чөнки иркенлек сиздe. Нефть генезисы турында ике төрле караш бар иде. Беренчесе: нефть органик булмаган җисемнәрнең тимер окисы белән реакциягә керүеннән барлыкка килгән, дигән фикер. Моны Менделеев әйтеп калдырган. Рәсми даирәдә шушы фикер канунлашкан. Икенчесе: нефть бары тик органик матдәләрдән килеп чыккан, дигән караш. Бу караш буржуаз һәм марксистик түгел дип санала һәм катгый тыела, эзәрлекләнә иде. Тагы шундый хикмәте бар: органик булмаган теория буенча теләсә кайсы җирдән нефть, газ чыгарга тиеш. Ә органик генезисы буенча исә бары аерым специфик урыннарда гына нефть, газ ятмалары була. Никитичның эзләнү-тикшеренүләре һәм гамәли күрсәткечләре органик генезисны дәлилиләр. Ул, әнә шул органик ягына авышып, тыелган булса да, шуның белән әвәрә килә башлады.

Трестта ике бригада җир бораулау белән шөгыльләнә. Берсе җирне бары дүрт йөз метрга гына бораулап төшә. Анализлар ала. Аларны «секретлы» диләр. Уран, кобальт, алтын эзлиләр, ди. Геологик картаны Никитич төзеп бирә. Ул фараз иткән ике җирдә эзләгән нәрсәләрен тапканнар. Никитич бернигә дә дәгъва белдермәде. Әмма шул уңайдан дәртләнеп органик генезисны нигезли торган бик төпле дәлилләр тупланган зур мәкалә язды. Трест начальнигы Шайтанов бик абруйлы, көчле кеше иде. Мәскәүгә главкага барышлый мәкаләне алып китте. Һәм аны «Нефтяное хозяйство» журналында бастырып чыгаруга ирешә.

Әмма байтак вакыт үткәч, ни күрәбез? Бер килмәсә килми бит. «Правда»да сөлгe буе мәкалә. Никитичның язмаларын тар-мар итеп ташлаган. Буржуаз теорияне космополит дип атаган. Политик ышанычсызлык тамгасы салган. Бәла өстенә бәла, Никитичка хәерхаh Шайтанов-

ны Бөгелмәгә күчерделәр. Шмарев үзе чакыртып алган, диделәр. Аңлашыла инде, Никитичны кыса башладылар. Бу уңышсызлыкны ул аеруча каты кичерде. Кинәттән сизелерлек картайды. Битараф булып китте. Эчендә авыруы булуын да яшерде. Врачка күренмәде. Еш кына кан төкерә иде. Бөтенләй чыгарып атмадылар, аңа лабораториядә генә эшләргә рөхсәт иттеләр.

Буровой эшләре нәтиҗә бирми иде. Өч-дүрт ай газапланып, җирне мең сигез йөз метрга тишеп төшәләр. Скважинадан су чыга. Инде ике ел буе шундый уңышсызлык. Платон Никитичның тау геометриясе алымнары белән исәпләп чыгарган берничә өметле урыны бар иде. Шайтанов гаиләсен алырга кайткач, Никитич аңа гозерен әйтте. Ул трест башлыгы белән сөйләште һәм эшне хәл итте. Җитәкчеләр Никитич күрсәткән мәйданда борауларга, егерме биш метр төшкән саен забойдан токым үрнәкләре алып барырга килештеләр. Бу трест өчен дә кабат бәхет сынап карау иде.

Бораулый башладылар. Өч смена эшли. Утыздан артык кеше. Токым үрнәкләрен кәрзингә тутырабыз, буровой атына салып өйгә ташыйбыз. Көне-төне токымнарны беренче эшкәртү эше белән мәшгульбез: авырлык таблицасы аша уздыру, коэфициентларны билгеләү, микроскопик үзенчәлеген, электр үткәрүчәнлеген, башка параметрларын билгелибез. Барча мәгълүматлар аста нефть барлыгына ишарәли. Шуңа без нииндидер пионерларча күтәренкелек белән эшлибез, йөрәкләр ашкынып тибә.

Ләкин, хәерченең итәгенә ипи куйсаң, аны карга алып китә, ди. Бораулау бригадиры итеп икенче кешене куйдылар. Бу — Тартакиев дигән бик тупас адәм булып чыкты. Без яңа токым кыйпылчыклары алырга килгәч:

— Юк, токым алып булмый, бетте! — диде, бик кырт кисеп. ·

Никитич та, мин дә берни аңлый алмыйбыз, әсәрешкән күзләр белән тик текәлеп торабыз.

— Шаяртмыйм, чынын әйтәм, нигә шаккаттыгыз? — Ул чак сизелерлек зәһәр елмайды. — Токым бүтән булмаячак!

— Ни сәбәптән?

— Токым алып вакыт уздыру планда каралмаган.

— Туктале, сез нидер бутыйсыз кебек, Шайтанов бит...

— Шайтановның биредә берниндн катнашы юк! — диде Тартакиев, безне түбәнәйтә һәм җәлли торган төстә.

— Шалишь, Шайтанов әйтте, главка аша планга керттердем, диде.

— Шайтановка ышансаң... Бернинди главка да, план да юк. Просто Бозылыкта гостиницада бергә эчеп ятканнар. Атна буе. Шайтанов бай. Безнең контор директоры Калинковны сыйлаган да сыйлаган. Сүз арасында теләгән белдергәндер. Исерек баштан Калинков вәгъдә иткән. Исереккә диңгез тубыктан.

— Юк, карале, ничек була соң бу? Шайтанов безне алдаганмыни?

— Шайтанов бик гайрәтле авантюрист, ул алланың үзен төп башына утырта, — диде Тартакиев безнең беркатлылыктан көлгән тавыш белән.

Никитич авызын ачкан килеш таш булып катты, мин дә шундый халәттә идем.

— Бу мөмкин түгел, шаяртмагыз, иптәш Тартакиев, — дип куйдым мин, үземне кулга алып.

Ләкин Тартакиев таш кыядай нык торды:

— Без монда үзебезнең план буенча борауларга килдек. Шайтановның бер катнашы да юк. Шушы тирәләрдә берничә разведка скважинасы бораулаячакбыз. Кышка бөтен контора биредә күчә...

Ул, безнең белән эшне бетергән кыяфәттә, үзенең кәгазьләренә йотылды. Без, дип, җә, дип әйтерлек, каршы килерлек, сүз көрәштерерлек хәлдә түгел идек инде. Тартакиев әйткән хәбәрләр безнең баш миләренә бик каты сукты. Шул килеш без, ишек төбендә бераз таптанып тордык та, чыгып киттек.

Платон Никитич конторга Калинков янына барып кайтырга мәҗбүр булды. Ул әйткән: «Мин Тартакиевтан үтендем, ул токым алып бирергә вәгъдә итте»,— дигән. Никитич: «Калинков эчкәнгә, нигә мин чиләним, дип әйтә Тартакиев»,— дигәч, теге бик каты ачуланган, пыр тузган. «Эштән алам мин аны!» — дип янаган... Шайтанов белән иптәшләрчә сөйләшкән идек, юк, план хакында берни белмим, дип әйткән. Шушы көннәрдә буровойга үзем барам, дигән...

Шулай тынычландырып җибәргән. Ләкин күпме көтсәк тә, Калинков күренмәде. Тартакиев исә һаман үзенекен тукыды. Кем безнә алдый, һич белерлек түгел. Ни өчен шулай итәләр, анысы да аңлашылмый.

Никитич бик каты борчуга калды. Нишләргә? Сихерләнгән түгәрәккә килеп эләккән шикелле. Бу буталчыклыктан чыгу юлы күренми. Йөрәкләр әрни. Хәзер иң кирәкле һәм төрле көтелмәгән рудаларга бай катламны бораулыйлар. Чыдап булмады, Тартакиевның кайтып киткәнен чамаладым да мостик астына скважина тамагына үрмәләп кердем һәм измә белән чыккан токым ярчыкларын җыйдым. Ул көнне измә бик сыек иде. Токымнар рафинад шикелле эреләр, тикшерергә яраклыклар булды.

Без шуларны өйрәндек, тикшердек. Ләкин күңел үртәлеп ярсый: ни өчен безне Шайтанов алдады икән, дип, һаман ачуланабыз, тынычлана алмыйбыз. Ни өчен Тартакиев безне санга сукмый? Аның өчен моның ни файдасы бар? Безгә каршы төшү аның шәхси интересы була алмый? Димәк... Юк, шәхси файдасыз булмый. Скважинаны тизрәк бораулап бетерү һәм премия алу — шәхси файда түгелмени?

Без өч көн саен буровойга киләбез. Әмма бушка гына. Тартакиев безне штык белән каршы ала.

— Хөрәсәннәр, тагы комачауларга килдегезме? — ди-ди, ачы, мыскыллы сүзләр белән каршылый. Культбудка баскычында тәмәке тартып утыра. Соры кепкасы кырыеннан сары чәчләре тузгып чыккан.

— Нигә син безгә үчләнәсең әле, ә? — Никитич ипле генә, тегенең йон ягына сыпырган тавыш белән, килешергә теләп сөйләнә. Эшне шаяруга бормакчы итә: — Безнең гаебебез юк. Синең кебек үк эш башкаручылар. Ләкин син безгә эшләргә бирмисең, шуның белән илгә зыян китерәсең...

— Һи-и, зыян, имеш,— дип мыскыллавын йөзенә чыгара ул.— Чын зыян — менә бу скважина. Чөнки монда нефть юк. Миллион сум җилгә. Нефтьнең исе дә булмаячак!

— Яла, яла! — дип, кинәт кайнап чыга Никитич.— Биредән нефть чыгачак!

— Китап корты! Син ни беләсең! Һи-и! — Тартакиев тагы да түбәнсетә торган тавыш белән әйтә.— Уйлап чыгарган идеяң сине утырткан. Нефть миграциясенең юлы биредән түгел, төньяктанрак уза. Гөмбә баш!

— Нефть юк дисең, алайса нигә бурить итәсең? — Никитич бераз тынычлана башлады, тавышы тигезләнде.

— Нигәме? Менә синең кебек тизәк башлар кушканга күрә!

— Ни өчен биредә нефть булмаска тиеш?

— Тизәк баш, берни аера алмыйсың, ә? Хәзер чын урынына ялган йөри...— Ул, ачу белән тәмәкесен җиргә ташлап, аны табаны белән басып сүндерде дә, кулын өметсез селтәде. Бар нәрсәдән бизгән, өметен өзгән кайгылы кыяфәткә кереп, буровойга таба атлады.

Без озак бер-беребезгә сүз куша алмыйча кайттык. Бу зобани Тартакиев нигә безгә шулай каршы төшә, нигә биредә нефть юк, дип тукына? Моның артында ни ята? Тартакиевны кемдер безгә каршы котыртып тора кебек тоела иде.

Ике ай дигәндә бораулаучылар тиешле горизонтка төшеп җиттеләр... Скважина тамагында берничә нефтьче басып тора. Без дә шунда. Әллә каян Тартакиев пәйда булды. Ул — көндәгечә түгел, кызу хәрәкәтле, тавышлы иде, салганлыгы сизелеп тора. Менә скважинадан пар сыман исле нәрсә күтәрелде, аннары саргылт су голт-голт килергә тотынды.

һәрберебез учларына су алды, иснәде, учын-учка ышкыды. Суда майның әсәрмәте дә сизелми иде.

— Тизәк баш, мин сиңа ни әйттем. Шарлатан! — дип, Тартакиев учларын бер-берсенә ышкып торган Никитич янына килде. Йөзендә ачу, мыскыллау иде.— Фәлән-мать, кая нефть, ә? Кая, тап! — Ул, капылт килеп, куш учына пычрак суны алды да Никитичның чыраена чәпәде.

— Нишлисең син, сволочь! — дип акырып куйдым мин. Тартакиевны ярсытырга шул җитте, Никитичка тибеп җибәрде, миңа килә башлаган иде, кулымдагы чиләк белән селтәндем. Ул чигенде.

Никитич, битен-күзен сөртә-сөртә, китеп бара. Мин аңа барып тотындым. Барысы да бетте! Нинди коточкыч алдану! Җәһәннәм упкынына тәгәрәү! Никитич аяк атлавын тоймый, күзе күрми кебек иде. Без лабораториягә кайтып аудык. Сөйләшеп булмый иде. Никитичның йөзе үлек төсендә. Үзе ах-ух килеп авыр сулый.

Зария мине алырга керде. Утынга барырга машина тапкан икән. Киту уңайсыз булса да, мәҗбүр идем.

Кайтуга йөрәк, нидер сизенгәндәй, лабораториягә этәрде. Нәрсә бу? Һич күзләремә ышанмыйм. Никитич идәндә аунап ята, ирен кырыйларыннан кызыл кан сызыгы агып төшкән. Пульсенә ябыштым, анда бернинди өн юк иде. Өстәлдә пробирка. Тукта, ниндидер сыеклык. Иснәп карыйм, цианистый калий... Нишләргә белми, дер-дер басып торам. Никитичның аксыл йөзендә, күз чокырларында әчке елмаюга охшаш ниндидер чалым бар. Гүя, барысы да шулай тәмамлануга ул канәгать кебек иде.

Озакламый Зарияне Уфага күчерделәр. Минем өчен дә әйбәт булды. Институтны читтән торып тәмамладым.

Бераз вакыттан тагы Зариягә тагылып, Бөгелмәгә килеп урнаштым... Уфадан туган җирләргә бер кайткан чакта теге скважина белән кызыксындым. Нефть биреп ята иде... Шунда теге хәлне Тартакиевнең юри оештырган булуын, коточкыч мәкерен аңладым.

— Никитичның да бәхете булмаган икән...— дип нәтиҗә ясады Андрей Казан.

## VI

Иртән вахталарны озатып бетергәч, Тугаев, эш кәгазьләрен алып, үзенең качып эшли торган почмагына барып утыра. Бу — аулаграк җирдә, техничкалар бүлмәсе. Шуның бер ягын шкафлар белән бүлеп алган. Өстәл, урындык куелган. Биредә телефон юк, шунысы шәп. Бу почмакны җыештыручы һәм бухгалтердан башка беркем белми. Үзе тыныч, рәхәтләнеп эшкә чумасың. Аны биредә беркем бүлдерми. Әмма бүген бераз башкачарак булды. Җыештыручы хатын декретка китә икән. Үз урынына калырга кеше алып килгән. Юашлыгы йөзенә чыккан авыл хатыны. Бер сүз русча белми, ди. Тугаев, җитәкче кеше татарча сөйләшергә тиеш түгел, дип саный. Этикага туры килми, русны хөрмәт итмәү була, янәсе. Ул хатынга сорауны да урысча бирде. Декретка китә торганы тәрҗемә итте. Авыл хатыны сөйләде: ирем эчә торган булып чыкты, диде, исереп кайта да кулын озайта. Берсендә чыдамадым, әйберләремне төйнәп алдым да качып киттем. Әтиләргә кайтырга гарьләндем, шулай шәһәргә килдем...

— Бала-чагагыз булмадымыни?

— Өч яшьлек балам анда калды. Мин баламны барыбер ул исеректән урлап алып китәчәкмен. Сыенып почмагым гына булсын...— Хатын качырып кына башын артка борып, күз яшьләрен сөртеп алды. Тугаев, кешеләрне җәлләп бик күп мәртәбәләр төп башына утырганын онытмаса да, кырыслыгын киметте, гаризасына: «Принять на работу, предоставить комнату в бараке!» — дип резолюция салды. Хатыннар, яктырып, тиз-тиз

чыгып киттеләр. Тугаев башында: берәр кешене җәлләп хәленә керсәң, үзеңә бәла генә була, күпме сынаганым бар, дигән уйлар чагылып китте. Эш кәгазьләрен алдына салгач, барысы онытылды, шуларга чумды. Ләкин бераздан кадрлар бүлеге мөдире Харлампиева килеп керде. Ул, яше белән кан көрәшеп, киенеп-ясанып йөрүчән хатын. Кулында тегe гариза иде.

— Баракта бүлмә юк бит, Алмаз Борисович! — диде ул кызылга буялган калын иреннәрен бөгә-бөгә.

— Резервтагыны бирергә туры килә,— дип ипле, йомшак кына әйтте директор.

— Ай-йай, өстегезгә күп аласыз. Горкомнан кеше җибәрсәләр, кая куярбыз, ни дип әйтербез?

— Миңа сылтарсыз, барыгыз да чиста булып калырга теләгәч...— Тугаев маңгай астыннан гына аңа карады. Харлампиева конторның барометры иде. Аның сиңа карата мөгамәләсеннән өстәгеләрнең синең хакта ничек уйлауларын чамаларга була. Соңгы вакытларда Харлампиева Тугаевның кайбер хәрәкәт-эшләренә каршы килгәли башлады. Димәк, өстә миңа карата «һава үзгәргән». Моны икеләнми әйтергә мөмкин. Узган ел Тугаевны горкомга алалар дигән сүз йөргәндә, ничек кенә бөтерелмәде аның тирәсендә! Тугаев уңайсызланып кала иде. Ә менә моннан бернничә ай элек кинәт мөнәсәбәте үзгәрде. Утлы ялкыннан карлы бозга әйләнде. Тугаевның эш кәгазьләренә салган резолюцияләрен кире кага, аны либерализмда гаепләргә генә тора.

Харлампиева бөтен кыяфәте белән ризасызлыгын белдереп чыгып киткәч, Тугаев бераз пошаманга төшеп уйланды. Нәрсә булды икән тагы? Шайтан алгыры, гел нәрсәдәндер шүрләп торырга туры килә. Хәер, төкерергә, вак-төяккә дикъкать итмәскә кирәк. Менә бүген горкомга барасы бар, шунда нәрсә булса да беленер. Горкомны ярата ул. Аның биек ишекләрен ачып кергәндә, коридорларыннан атлаганда үзеңне үсеп киткән кебек тоясың. Тәнгә, мускулларга ниндидер дәрт тула, хыяллар канатланып китә. Бигрәк тә хатыны аңа еш тукый: синең урының горкомда, эшчеләр белән тарткалаша торган җирдә түгел, ди-ди, ымсындыргыч оеткы салып тора. Шуның тәэсирендә ул үзе дә: «Әллә мин горкомда эшләмәслекме?» — дип хыялга чумып ала. Чөнки начальниклар белән эшчеләр — ягъни чүкеч белән сандал арасында эшләү бик авыр.Ританың бар хыялы — Тугаевны горкомда итеп күрү. Чөнки аның барча туганнары Әлмәттә, Бөгелмәдә кайсы — горкомда, кайсы — горсоветта, кайсы берләшмәдә дәрәҗәле урын билиләр. Үз ирен дә Рита бары дәрәҗәле итеп кенә күрергә тели. Аның төп максаты Тугаевны югарыга омтылдыру гына. Тугаев, табигате белән бик үк теләмәсә дә, хатынының күңелен кайтармас өчен тырыша. Дәрәҗәгә омтылу дәрте аның үзенә дә керде, эчке этәреш бирә торган яшерен көч булып төйнәлде шикелле.

Адәм балалары нәфселе, бер-берсеннән көнләшеп шашына.

Киңәшмәдән Тугаевның эченә пошаман төшеп кайтты. Горкомның бүлек мөдире аның белән салкын исәнләште, битараф сөйләште. Карашын читкә ала, күзләр очрашуыннан кача сыман иде. «Бу ни хикмәт, нәрсә булды тагы?» — дигән хафалы уй Тугаевның миен чәнчеп үтте. Мөдир әле кайчан гына очрашкан саен әйтә иде: Тугаев, сине горкомга алабыз, промышленность бүлегебез йомшак, тарта алмый, энергичный иптәш кирәк, дип әйтә, өметләндерә иде. Тугаев аңа ышана, эченнән генә сөенә иде. Кара, күрә беләләр, таный беләләр эшчән кешене, дип үзенчә горурлана иде. Болай горурлануы нигезсез түгел. Таркау, һаман артта өстерәлә торган бораулау конторасындагы эшләрне рәткә салуга ирешкте. Бригадалардагы кадрлар тотрыклыланды, летуннар әзәйде. Тәртип ныгый төште. Иң мөһиме: планны үтәүгә ирешәләр, һәрбер нәрсә берберсенә ялганган бит. План үтәлгәч, эшчеләргә премияләр була башлады. Бу нәрсәдә Тугаевның хезмәте күп булды. Ул, күп көч салып, борауларга перспективасы зур була торган участоклар алуга ирешкте.

Геология трестында бер иптәше бар иде. Бөгелмәдә хатыны белән аерылышып, яңа шәһәргә — Акташка күчте. Еш очрашалар, очрашкан саен иптәш бүтәннәр өчен сер булган нәрсәләрне Тугаевка өйрәтә иде. Шуның өстенә, местком, партком, бер булып, эчүчелеккә каршы көрәшне катгый куйдылар. Вахта алдыннан врач тикшерүе үткәрелә. Әз генә шик булдымы, эшче буровойга кертелми. Прогул языла. Социалистик ярышны бик нык тәгаенләштерергә кирәк булды. Ярыш бик формаль нәрсәләргә корылган, нәтиҗәсен билгеләү дә үтә беркатлы, эшчеләрне кызыксындырырлык түгел иде. Тагы бик күп чаралар. Шулардан һәм бүтән хәлләрдән чыгып, Тугаев үзен эшне оештыра һәм кирәкле дәрәҗәдә алып барырга сәләтле итеп танытты. Аның эшен Берләшмә таный, горком да әйбәт бәяли иде. Тугаевның бораулау конторасы алдынгылар исәбендә йөри. Һәм алдынгылык даимилеге белән Тугаевның да абруен күтәрә иде. Шул хәлләрне исәпкә алып, ул горком мөдиренең, очрашкан саен: сине горкомга алабыз, дигән сүзләрен хаклы һәм нигезле дип санады. Һәм шуңа күрә мөдирнең өметләндерүләрен чынга алды. Ул башта горкомда бик күп буш сүз, ялган сөйләргә туры килер, моны минем хаклык белән программаланган табигатем күтәрә алмас, дигән фикердә торды. Анда күтәрсәләр, озак та үтми сөртенермен, ычкынганымны сизми дә калырмын, ди-ди,Ританың кысуына каршы төшә иде. Ләкин тормыш хәлләре үзгәрә. Шуңа карап, кешедәге фикерләр-уйлар да үзгәрә. Тора-бара аның элеккеге теләр-теләмәс настроениесе үз көченә ышану, горкомда эшләргә хаклы булуына инану белән алышынды. Һәркем нинди дәрәҗәгә ирешү теләге белән яши бит.

Ә мөдирнең бүген аңардан йөз качыруы Тугаевны тәмам аптырашта калдырды. Горкомга барганда ул һаман: кичә мөдирнең кәефе булмагандыр, бүген яктырып сөйләшер, дип өметләнә. Һәм көн саен канатлы өметенең бер канаты сынып кайта. Нидән бу кискен үзгәреш? Нинди гаебем бар икән? Һәм ул күңеленнән элеккеге һәм хәзерге гөнаһларын санап карый. Аның өстеннән горкомга берничә анонимка яздылар. Тик берсе дә йөз процентка расланмады. Әлбәттә, кайбер вак-төяк кимчелекләр дөрес күрсәтелгән иде. Кимчелекләрсез бер генә гамәл дә бармый. Бүген бар ул кимчелекләр, иртәгә-берсекөнгә аның кайберләре бетерелә. Эштәге вак-төяк кимчелекләрдән һич тә арыныйм димә. Алар гомерлек диярлек. Кеше ихтыярыннан тормыйлар. Безнең системадан киләләр. Каршы көрәшеп булмый, үзгәртергә ярамый.

Чүп өстенә чүмәлә, дигәндәй, геология хезмәте күрсәтмәләрен бораулаучылар кулланмыйлар, шуңа аварияга дучар булалар дип, нигезләп, теге бәлане бөтенләй үзләре өстеннән төшергән язуны Байкин берләшмәгә җибәргән. Тугаев шул дәгъвага аңлатма-җавап язды. Ул үзенең бораулаучыларын яклады. Авария геология хезмәтенең халтура булуы аркасында килеп чыгуын исбат итте. Бораулаучыларның гаебе юк, чөнки алар геологик сукыр рәвештә җир астына керергә мәҗбүрләр.

Шул нигездә ике ведомство арасында конфликт чыкты. Аварияга бүтән каршылыклар да өстәлде. Тугаев таләбе буенча берләшмә башлыгы геология бүлегенә бик каты рекламация язып җибәрде. Бер нөсхәсен парткомнарына адреслады. Үз нәүбәтләрендә геологлар да авыз йомып калмадылар. Бораулау конторын гаепләп язган кәгазьне горкомга юллаганнар.

Бүген горкомның промышленность бүлеге мөдире дошманлашучы якларның икесен бергә чакырткан иде. Ягъни, «очная ставка»га. Кыяфәтеннән күренә, бу эшне ул бик әһәмиятле итеп саный һәм үзен шундый катлаулы эшләрне башкарырга сәләтле полководец итеп тоя сыман иде. Ул зур ике тумбалы өстәл артында утыра, алдында — ачылып куелган папкалар. Гаеплеләрне «Т» хәрефе формасындагы өстәлгә каракаршы утыртты. Байкинга бу хәл бер дә ошамады, нишләп ул безгә шул тикле малайсытып карый, дигән уй килде аңа. Тугаев исә тыштан берни белгертмәде, гаепле елмайган төстә, үзен сабыр булырга этән күндерен утыра.

— Ну, футбол матчын башлыйбызмы? — диде мөдир, тапкыр сүз таба алуына масайган төстәрәк.— Кем беренче булып тупны капкага суга, ә?

Мөдир, өстәгеләргә охшарга тырышып, халыкчан, гади булып күренергә ярата иде. Гомумән, горкомдагы мөдирләр Беренче өлгесенә бик нык ияреләр. Кием-салымны әйткән дә юк, сөйләшү рәвешенә кадәр охшарга азапланалар иде.

Болар, сүз берләшкәндәй, авызларына су кабып утыралар. Шикаять язганнарына эчтән генә үкенәләр шикелле. «Нигә дәшмиләр, бу нинди санламау?» — дип уйлый мөдир һәм матур йөзенә эчтән ачуы килә башлау билгеләре чыга. Байкин түзми, телгә килә:

— Кәгазьләрдә әйтеләсе әйтелгән бит...— Аңа мөдирнең үзен зурга куеп, боларны түбәнсетә торган кыяфәте ошамый иде. Шуңа сүзен каты гына итеп әйтте. Шуннан мөдирнең каты күзләре Тугаевка кадалды. Тугаев аның үз кул астындагы кеше, шуңа тәкәллеф саклап тормый, дорфа гына эндәшә:

— Нигә син тәнкыйтьне кабул итәргә теләмисең, ә? Кәперәясең? — Мөдир русча сүзләрне дөрес әйтергә азапланып сөйли. Сүз азакларын ялгыш бетерсә дә, үзенең хаклы булуын бик нык тоя. Горком бервакытта да хаксыз була алмый, дигән караш мөдиргә дә, әле бу үзара карулашучыларга да сеңгән.— Борын чөясең? — Мөдирнең соңгы сүзләре Тугаевның авырткан җиренә тиде, эчтән каршы тору дулкыны күтәрелде, ләкин ул үзен тыйды. Чөнки барча эшләр мөдирдән тора, теге яки бу хакта аның бер сүзе хәлиткеч була. Бер ымы белән язмышыңны теге яки бу якка авыштыра ала ул.

— Син шулай тел-теш тидермәслекмени? Ә? — диде мөдир кинаяле тавыш белән. Тугаев тыныч булырга тырышып, сабыр гына әйтте:

— Геологлар хаклы түгел! — Ул мөдирнең йөзенә карады, ачуын күбәйтмәдем микән, дип курка иде. Һәр әйткәнгә буйсынучан, бераз гына куштанланасы иткән кыяфәт белән башын алга таба игәләп-игәләп алды. Мөдир белән араны суындырасы килми иде. «Геологлар хаклы түгел!» — дигәнгә Байкин тыныч карады. Хикмәт бит инструментлар җитмәүдә, запчастьлар булмауда. Мөдир шул мәсьәләгә конкрет якын килми, чөнки үз өстенә җаваплылык алырга теләмәгәнлеге сизелә иде. Мөдирнең юк эшне бар итүчән кеше икәнен, бернәрсәне йә теге, йә бу якка хәл итмәвен аңлап алгач, үз ягын якларга, исбатларга гайрәте кайтты. Мөдир өчен эшне җайга салу, нәрсә беләндер ярдәм итү түгел, ә гаепләне табып, җәза бирү мөһим кебек иде.

— Юк, геологлар хаклы! — дип, мөдир өстәл өстендәге папкага учы белән шап итеп сугып алды. Ачуы килүдән борын яфраклары дерелдәп куйды, керфекләре керпе энәләре шикелле тырпайдылар. Тугаевны талкырга күптән җыенган булган, ахрысы. Менә хәзер шуңа бик нигезле сәбәп чыкты...— Тәнкыйтьне өнәмәвеңне без элек тә белә идек,— дип чынлап ачуланырга тотынды ул.— Квартал планың өзелү алдында тора. Шуның нәтиҗәсе бу. Эшчеләр арасында политик-масса эшләре алып барылмый. Парторг, понимаете ли, сыер тизәге, синең кубызга бии. Бер местком Холодец дөрес линия алып бара. Эштә конкрет политик җитәкчелек сизелмәү аркасында чатаклыклар килеп чыга. Контор директоры партия йогынтысын инкарь итеп, үз авторитетын өстен куярга омтыла. Кыш көне район газетасы директорны күккә күтәреп язды. Анда директор үзен «геройчик» итеп күрсәтүгә кадәр барып җитә, понимаете ли...

Мөдир Тугаевның шәхесенә кагылып алды, хәтер калдырырлык сүзләр әйтте. Билгеле, горком һәрчак хаклы. Гел хаксыз булган чакта да ул хаклы санала. Ә бит мөдир теге газетадагы зарисовка турында бик нахак сүзләр сөйли. Ул мәкаләгә Тугаевның катнашы юк. Редакция кешесе үзе инша кылып бастырган аны. Дөрес, конторга килеп сөйләшеп утырган иде утыруын...

Мөдир аның өстенә күпме нахаклар яудырса да, Тугаев дәшми генә буена сеңдереп утыра иде. Һаман да бер сүз — мөдирнең ачуын китерүдән курку. Бәлки, тора-бара Тугаевка карата аның мөнәсәбәте үзгәрер? Ниндидер өмет үз хакын хаклаудан тыя аны. Сәяси климат алмашынып һәм Тугаевны горкомга алырлар. Шуңа күрә барча талкуларга түзәргә кирәк. Иелгән башны кылыч кисми. Әйдә, мөдир аны пычракка салып таптасын, әйдә, ул җинсен, кинәнсен... Җүләр, җиңдем, дияр, акыллы, юл бирдем, дип әйтер, ди.

Мөдир, Тугаевны шактый талкыгач, ачулы тонын йомшарта төшеп әйтте:

— Ярый, бар, эшлә! Болай борын чөймә, кара аны!

Тугаев белән Байкин горкомнан бергә чыктылар. Гаепле кешеләр төсле, бер-берсеннән карашларын яшерәләр иде. Алар Фрунзе проспекты буйлап түбән таба атлыйлар. Проспект гаҗәп матур. Киң полосага каен, юкә, тирәк агачлары утыртылган. Алар бик шәп, куе булып үсеп киткәннәр. Чын урман диярсең.

— Нишләп ул сиңа бик кадала? — дип аваз салды Байкин. Ул, минем аркада Тугаевка эләкте, дигән нәтиҗә чыгарып, хәзер үкенеп бара иде. Тугаев аның сүзләренә җилкәләрен генә селкетеп җавап бирде. Байкинга ачуы килгәнлеге шул җилкә селкетүләрендә нык кына сизелеп китте.

— Әгәр болай булырын белгән булсам...— дип Байкин тагы сүз башлаган иде, Тугаев кулын кырт селтәп:

— Ташла! — диде һәм аны күрергә теләмәгән кебек бара башлады. Аның чырае эчке уйларга бирелүдән чытылган, сөмсере коелган, битендә җыерчыклар күбәйгән иде.

Проспект беткән җирдә юллар аерыла иде, туктадылар, бер-береңә нидер әйтергә кирәк бит, әмма горурлыклары тота, дәшмиләр. Байкин тагы горурлыгын ертып чыкты.

— Сиңа анда ниндидер тенденциоз караш бар шикелле,— дип, Тугаевка күтәрелеп карады.

— Ничек тенденция? — Тугаев кинәт уянып киткәндәй күзләрен зур ачып, юлдашына төбәлде. Эчтән ул нәкъ шул хакта баш ваткан һәм Байкин нәкъ өстенә баскан иде. Әмма Тугаев кинәт үзен кулга алгандай итте, сагайды, тегенең ихласлыгына ышанасы килмәде.

— Юк, юк, ул болай гына, тәнкыйть итми ярамый бит инде. Урыны шундый...— Тугаев бу хакта сүз озайтырга теләми кебек иде. Мөдир турында начар фикер ычкындырудан сагая.

— Мөдирне элек бераз белә идем, кара, хәзер ничек үзгәргән, ә? Танырлык түгел кешене! Әйе, номенклатурага эләктеме, кеше йөз сиксән градуска үзгәрә. Шулай тиештер, ахрысы. Өстәгеләр белән түбәндә торучылар арасы шактый зур шул...

— Йә, йә, мине провоцировать итмә! — диде Тугаев ачу белән һәм саубуллашмыйча да китеп барды.

Эш сәгате чыкмаган иде әле, ул Н-поселокка юнәлде. Конторлары шунда. Аны көтеп утыралар икән. Местком Холодец фатир исемлеген тагы карарга, чиратны тәгаенләүне куйган. Кәеф начарлыгын белгертергә, эшкә күчерергә һич ярамый, бу намуссызлык булыр иде. Шуңа Тугаев ясалма елмаеп, йөзенә юрамалый дәрт чыгарып, утырышка керде. Директор үзенең кул астындагыларга һәрчак әйбәт настроениеле булырга тиеш. Җанында мыраулый-мыраулый күңелсезлекләр тырмашса да, белгертергә ярамый. Юкса, башкарыла торган эшкә тәэсир итүе мөмкин.

Холодец үз эшен җиренә җиткереп, яратып эшли. Ул хезмәттән, тормыштан тәм таба, фатирга мохтаҗлар исемлеген гадел итеп төзегән. Һәрхәлдә, Тугаев исемлектә нинди дә булса исәпкә алмый калган кеше күрмәде. Бу нәрсә шулай килешенгәч, тагы да четерекле мәсьәләгә күчелде. Хикмәт шунда, конторга бер фатир бүленгән, шуны кемгә бирүне хәл итәргә кирәк. Ике кандидатура бар, диде Холодец, ягымлы йөзе белән киңәштәшләренең әле берсенә, әле икенчесенә күз ташлап

алып. Аның бу хәрәкәтендә ниндидер икеләнүгә охшаш нәрсә чагылып китте. Моны бүтәннәр абайламады, әмма, Холодецны бераз өйрәнгән кеше буларак, Тугаев чамалады. Әллә астан гына бирер нәрсә маташтырырга уйлыймы? Холодец матур сөйли белә, теле белән үзенә карата. Хәер, кыяфәте дә аның бик мәһабәт: ирләрчә киң маңгайлы, калын кашлы, төз, калын борынлы, киң иякле. Үзе ак күлмәктән, кара галстуктан. Ләкин шушы чибәр кешенең тешкә тия торган бер ягы бар: ул һәркемгә ялагайлана. Үзеннән өстә торганнарга ләббәйкә булып, сагыз кебек сылана иде. Тугаев башта ук аның шул ягын өнәмәде. Ул аңа бик ялагайланды, тик Тугаев һич әһәмият итмәде. Күрмәмешкә салышты. Мин андый нәрсәгә чиертмим бит, дигән мәгънәдә ишарәләде. Холодец җәнлектәй бик сизгер иде, тиз аңлады. Тугаевка сиздереп куштанланмый башлады. Әмма Холодецның ертлач, ялагай булуының конторга файдасы да тигәли иде. Ул бүтәннәр таба алмаган нәрсәләрне җир астыннан айкап чыгара. Мәсәлән, дефицит путевкаларны ничектер астан кулга төшерә. Тик ул дефицитларны дәрәҗәлеләргә бирү ягын карый. Горкомда, Холодецны дөрес линия алып бара дип, Тугаевка үрнәк итеп куйдылар. Аны мактаган бүлек мөдиренә дә Холодец Сочига путевка юнәтеп бирмәдеме икән? Булмас димә...

Холодец ике кандидатураның да мәгълүматларын әйтте. Кирамов — өч баласы, хатыны белән — баракта бер бүлмәдә яши. Бүлмә пар белән җылытыла. Буровой эшчесе. Эшендә мактыйлар, алтын куллы, диләр. Ләкин шул уңай сыйфатларын бетереп ташлый торган кимчелеге бар: ул эчкәли. Быел гына айныткычтан ике тапкыр язу килде. Ике тапкыр местком утырышында тикшерелде. Эчмим, дип сүз бирде, сүзе тукран тәүбәсе булып чыкты. Менә үз бәхетенә үзе аяк чала. Нишләтәсең аны? Мин йөрәгем белән аңа квартир бирү ягында, әмма аңым әйтә: мөмкин түгел, ярамый, ди. Квартира бирсәк, эчкән өчен бүләкләү була. Аны шулай исемләячәкләр. Эчүчелек белән көрәшмисез, дип, болай да колак итен ашап бетерделәр. Юк, «Чаян»га эләгү безгә килешмәс. Безнең намус чиста, кеше үзе бәхетле буласы килми икән, нигә аңа көчләп бәхет бирергә? Юк, әхлакый яктан да дөрес түгел.

Аның сүзе беткәч, бераз тын булып алды. Әңгәмәгә парторг кушылды. Ул тулысы белән Холодец фикерләрен җөпләде. Соңгы вакытларда ул гел шулай эшли иде. Җилнең кай яктан искәнен борыны яхшы сизә, ахрысы. Тугаевның директор буларак абруе кими барганны чамаларга өлгергән. Горкомда кем «котироваться» ителгәнен, кемнең ителмәгәнен шәйли бит ул. Тагы икенче срокка партком булып калырга тели ул һәм шуна күрә ис тоя торган борынын бик сизгер тота. Эштә күбрәк Холодец белән киңәш-табыш итүчән булып китте. Элек, Тугаевны горкомга алалар икән, дигән сүзләр йөргәндә аның янында ничек бөтерелә иде. Бер алдына, бер артына төшә иде.

Беркетмә язучы бухгалтер хатын Холодец сүзеннән чыга торган түгел. Фатир Кирамовка тәтеми, ычкына бит, дип борчылды Тугаев. Холодец тагы Кирамов өстенә кара күләгәләр өя башлаган иде, ул аны кискен генә бүлдерде һәм тегенең әйбәт якларын тезәргә керешә.

— Намуслы эшче, өч баласы бар, хатыны да эшли. Ә эчүен без аның тәрбияләргә тиеш. Мин аны беләм, Кирамов йомшак холыклы кеше. Өченче ел без аны орден белән бүләкләү исемлегенә керткән идек. Ләкин шул моментта айныткычтан язу килеп төште. Горкомда исемен шунда ук сыздылар. Соңыннан Кирамов белән сөйләштем. Акыллы, реалист кеше. Теге вакытта аны бер иптәше сыйлаган булган. Юри шулай иттергән ул, сволочь, ди Кирамов, хәзер генә галошка утыртуын төшенеп. Бүтән алай булмам, дигән иде. Квартира бирергә иткәч, тагы әүвәлгесенә охшаш хәл килеп чыккан. Монысында да ниндидер астыртын кул уйнамый микән? Фатир хаклы рәвештә аңа тиеш!

— Эчүчелекне бүләклибезмени? — диде Холодец шырпылы тавыш белән.

— Без аңа җәза бирергә тиеш,— дип, аның сүзен куәтләде парторг. Бухгалтер хатын аның белән килешүен чыраена чыгарып белгертте.

— Бирмәсәк, балаларга җәза була бит, шуны исәпкә алмыйсызмыни? Юк, ярамый, иптәшләр! Өлкәннәр кимчелеге өчен балалар газап чигәргә тиеш түгел...— Тугаев утырдашлары йөзенә караштырып алды. Берсе дә аның фикерләре белән килешми иде. Моны йөзләре, күзләре әйтеп тора. Менә гел шулай. Тугаевның фикерләре әйләнештә йөри торган кагыйдәгә күпчак туры килеп бетми. Тугаев бу хәлне үзе бик үткен кичерә иде. Ни өчен мин шулай соң, ни өчен минем фикерем күпчелекнекенә туры килми? Миндә аңга буйсынмаган һәр гаделсезлекне артык тою бар, ахрысы. Шул харап итә мине. Шуңа күп вакыт эчендәге фикерен тышка чыгармый калырга мәҗбүр була. Бүген кычкырып торган гаделсезлеккә юл куела, дәшми калу мөмкин түгел.

— Балалары газап чиксә, без гаепле түгел бит,— дип, Холодец тагы тәгәрмәчкә таяк тыкты.— Эчмәсен иде, балаларын кайгыртсын иде.

— Юк, без балаларны җәзалыйбыз, дигән логикага таяна алмыйбыз,— дип куйды парторг, нindидер җиңүле хаклылык үзе ягында булган төстә.

— Чөнки синең өч бала белән бер бүлмәле баракта яшәп караганың юк,— диде Тугаев, ачуы килә башлап.

— Әгәр эчүчегә бирсәк, барча тәрбия эшен бозабыз, Алмаз Борисович! — Холодец бик эшлекле кыяфәтле, сүзләренең кире кагылмаслыгына шундый нык ышанган төстә иде. Парторг ияк кагып, аның сүзләренә пичәт суккан кебек итте. Соңгы вакытларда ул бик кыюланып китте әле. Үзе болай юаш холыклы кеше. Әмма нindидер җеп белән кайдадыр тоташкан шикелле. Шул җептән тартсалар, юашлыгы да бетә, кешеләргә бик каты бәреләә. Элек месткомда эшләгәндә шәһәр партактивында ялкынлы чыгыш ясый, Беренчене күккә чөя. Менә без Беренче кебек булсак, аның шикелле риясыз эшләсәк, коммунизмны тиз якынайтыр идек. Беренче үзе биштән торып барча төзелеш объектларын карап чыга, якындагы буровойларга барып килә. Аңа беркем дә шыттырган информация бирә алмый. Шунда ук артына утырта... Уралов шулай мактады Беренчене һәм теләгенә ирешге. Күп тә үтми, аны парторг итеп күтәрделәр. Әмма ул тыйнак булды, масаймады. Тугаевка таяна, аның киңәшен тота торган иде. Ләкин менә хәзер ни сәбәптәндер бик кыюланды. Тугаев белән дә бик санашмый башлады. Шушы хәл Тугаевның эчен бик пошыра иде. «Нәрсә булды, нигә шундый кискен үзгәреш?» — дигән сораулар белән җаны бәргәләнә. Әйбәт кенә барганда арадан нindидер кара мәче үтте шикелле. Теге «Кара мәче» турындагы популяр җырдагы кебек: «Не повезет, если черный кот дорогу перейдет». Тугаев үзе тарафыннан ярамаслык бер эш тә эшләмәде. Юк, хәтерләми. Нindидер эчке өнәмәү тоенләнеп килә. Әллә парторг белән директор арасында каршылык нормаль хәлме? Элеккеге парторг Фомичев бик демократ кеше иде. Безнең аның белән фикерләр гел туры килде. Эшләргә күпкә җиңел булды. Ул миңа тулысынча ышана, мин — аңа. Низагсыз эшләдек, нинди әйбәт иде. Фомичев бер дә карьерага омтылмады. Кешеләрне эшенә карап бәяләргә тырышты. Уралов исә яшь, билгеле, аңа карьера кирәк. Хатыны да шул хакта игәүләп тора, диләр. Ничек дәрәҗәгә күтәрелү хәйләләрен өйрәтеп тора, ди, имеш. Миңа да Рита акыл биреп кенә тора бит. Ни дип бүтәннәрнең хатыннары шул әмәлне кулланмаска тиеш? Ирен дәрәҗәле итәсе килү һәр хатынның канында инде.

— Юк, без эчкечелекне бүләкли алмыйбыз, бу — партия установкасына каршы килү була. Моның өчен баштан сыйпамаслар! — Уралов: җитәр, бу хакта ике төрле фикер булуы мөмкин түгел, дигән төстә сөйли иде.

— Партия белән спекулировать итмә! — диде Тугаев, тәмам эчтән кайный башлап. Парторгның борын яфраклары агарды, иреннәре шәмәхәләнде.

— Ә син үз өстеңә күпне аласың,— дип тавышын күтәрә төште.— Билең каймыгуы мөмкин.

— Зато син җилкәңә берни алырга теләмисең, карьерама сугар дип шыр җибәрәсең...

— Синең эчкечене яклавың тикмәгә түгел, үзең дә юрган астында салгалыйсың булыр...

Аларның тәмсезләнешен Холодец бетерергә ашыкты. Кулларын ике якка болгый-болгый, туктагыз, дигән хәрәкәт ясап, ызгышны сүндерергә тырышты.

Әгәр хәзер парторгка үз тиене белән кайтарсаң, талашып китәргә туры килер иде. Тугаев үзен тыеп калды. Нахак сүзләр күтәрергә үзен өйрәткән иде инде. Холодец тизрәк икенче кандидатура турында сөйли башлады. Миннекаев — алдынгы эшче. Үзе, хатыны, җитеп килгән малае белән баракта бер бүлмәдә яшиләр. Хатыны елый, җиткән егет белән бер почмакта торуы бик читен, ди. Бу бик аңлашыла, шуңа күрә Миннекаевнең яшәү шартларын нормальләштерергә кирәк. Фикерләрегез ничек, иптәшләр? Интернациональ семья, моны исәпкә алмыйча мөмкин түгел...— Холодец, үзенең хаклы һәм гадел хөкем йөртүенә бик ышанган төстә, иптәшләрен күздән кичерде. Тугаевтан башкалар аның белән теләктәшләр иде.

— Бирергә кирәк, лаек — диде парторг, ничектер Тугаевка каршы киләсе килеп эшләгән сыман.

— Минемчә, аңа квартир бирергә зарурилык юк. Кирамовка — зарури, чөнки балалары кечкенә...— Тугаев юри бик тыныч, үтә җитди тавыш белән әйтте. Тавыш күтәрү көчсезлекне, ышанычсызлыкны белгертер, дип уйлый иде.

— Ягъни интернациональлекне чутка кертмисең, ә? — диде Холодец гасабиланып. Ул һәр кечкенә детальгә политик күзлектән караучан. Моны үзенә кәсеп итеп алган, чөнки шактый төшемле нәрсә. Гаделсезлеккә төкерә ул, әгәр политикага мач килә икән, иң гаделсез хәл дә гадел итеп кабул ителә. Бу Холодец иҗат иткән нәрсә түгел, ә гамәлдәге тәртип шулай.

— Рус кызына өйләнү генә интернациональлек була алмый һәм фатир алыр өчен дә нигез түгел!..— Тугаев дипломатларча салкын кан белән сөйләде.

— Юк, бу халыклар дуслыгы, нигә интернациональ булмасын! — Парторг, үзенең сәяси мәсьәләдә сизгер булырга кирәклеген исенә төшергәндәй, алга таба башын суза төшеп әйтеп куйды.

— Нинди дуслык? — дип, Тугаев үртәлгәнлеген сиздереп әйтергә мәҗбүр булды.— Миннекаев ничә тапкыр хатыны белән сугышып телгә керде. Өченче ел хатыны гаризасы белән профсоюз җыелышына куелды. Үзара сугышып тору интернациональлек буламыни?

— Ни өчен сугышалар? Бүлмәдә урын тарлыктан,— диде бухгалтер хатын, аны-моны абайлап бетмичә.

— Алайга китсә, Кирамовның да хатыны ирен эчә дип елап килгәләде,— дип, Холодец тизрәк Тугаев дәлилләрен ега торган каршы дәлилләр китерергә ашыкты.— Аны да әллә ничә тапкыр тикшердек. Хәзер зарплатасын хатыны килеп ала, үзенә ышаныч юк...

Тугаев, балалар интересы барыннан өстен булырга тиеш, диде. Миннекаевның шартлары түзәрлек... Кирамовның хәле мөшкел. Ләкин Холодец һәм парторг аны тыңламыйлар иде. Бәхәсләшү кычкырышуга әйләнә башлады. Холодец утырышны япты.

Бераз соңрак Тугаев местком утырышы карарына кул куймады. Холодец мин-минлекле кеше, бик ачуланды, күгәренде-бүртенде, янаулы ишарәләр ясап, чыгып китте. Тугаев уйлады: бу ертлач барыбер үз дигәненә ирешәчәк, юкка гына каршы килдем, ахрысы...

Шулай булып чыкты. Холодец ярдәмендә Миннекаев әллә нинди белешмәләр юнәткән. Имеш, малаенда туберкулез башлангычы бар,

нервылары какшаган. Андый авыруларны изоляциялиләр, дип язылган инструкциядә. Менә ни өчен Миннекаевка фатир бирү зарури.

Тугаев барыбер үз фикереннән чигенмәде, местком карары белән килешмәгәнлеген белдерде. Кешене хезмәте, эше буенча бәяләмәү бик күп әшәкелекләр тудыра: җайлашучылар, ялагайлар, жуликлар барысы да әнә шул гаделсезлектән килеп чыга. Яхшы эшләгән бәяләнми, ә тәлинкә ялаучыга хөррият. Холодец горкомга йөрде, анда үзенә теләктәшләр тапты.

Пневма ачкычлар табу өчен Тугаевны командировкага җибәрделәр. Шул вакытта квартираны Миннекаевка биргәннәр. Кирамов, моны ишеткәч, шактый төшереп килеп, конторада тавышланып йөргән. Холодец аңардан качкан. Ике көн конторада күренмәгән. Кирамов сөйләнгән: Холодецның малае яңа гына врач булып эшли башлаган. Шуңарда дәваланганмы, юкмы, Миннекаев яшь врач турында өлкә газетасына мактап язып җибәргән. Мәкаләне бастырып чыгарганнар. Холодец Миннекаевка рәхмәт әйтеп, кулын кысккан. Һәм үзе дә аңа булышкан. Менә нәрсәдә хикмәт. Шулай да миңа Миннекаев бер дә ошамый, чөнки ул үз туган милләтеннән йөз чөергән була. Үзенә файдалы булган өчен генә! Һәр милләт иясе теге яки бу файданы исәпләп, үз милләтеннән баш тартса, нәрсә килеп чыгар иде? Юк, минемчә, милләтне шәхси файдаң бәрабәренә алыштырырга ярамый. Каныңны алыштыра алмыйсың, барыбер үз милләтең каны белән тереклек итәсең. Ә бәлки зур, өстенлек итүче милләткә көчү балалар өчен әйбәтрәктер? Андыйлар, балалары турында кайгыртып, өстен милләт ягына авышканнардыр? Милләт кайгысы урынын баш кайгысы ала. Зур милләт мәдәниятле булса, нацменнарны шундый хәлләргә куярга тиеш түгелдер бәлки.

Боларны Тугаевка Рита сөйләде. Конторда булган хәлләрне «чыбыксыз телефон» аша аңа җиткереп торалар иде. Яңа шәһәр зур түгел, биредә күпләр бер-берсен беләләр.

Кайтуга күңелсезлек көтеп торган: конторга БХССтан ревизия килгән иде. Ни өчен, ни сәбәптән? Нindидер сигналлар булган, имеш. Тугаев берләшмәгә чапты. Начальник Тугаевка хәерхаһ иде, кайгырган төстә сөйләнде: безнең катнаш юк, горком, диде түшәмгә бармагы белән төртеп күрсәтеп. Ул горкомнан уза алмаячак, билгеле. Беләсең, диде бераз тынып торганнан соң, без сине саклау ягында. Әгәр сәяси мотивлар нигезендә булса, бигайбә, яклап булмаячак...

Берләшмә бинасыннан чыкканда, Тугаев үз эчендә кузгалган ачудан төкерде: менә, бер гаебең булмаса да, ничек куркасың, шайтан алгыры. Үз-үзенә ачуы килде... Әйе, теләсәләр, әллә нинди юк гаепне бар итеп, өстенә өяләр. Беркем сине яклый алмый. Утыртып куюлары да мөмкин.

Ул, кайтканда, үз өстендәге гөнаһ саналырдай хәлләрне күңеленнән барлый башлады. Авыз тутырып әйтерлек, намуска тиярлек гөнаһлар юк шикелле. Әмма гамәл мәҗбүр иткәнгә эшләнгән, кагыйдәдән чыккан нәрсәләр бар. Мәсәлән, җиде-сигез җыештыручы штаты хисабында ике помбур тотарга туры килә. Иртән медицина тикшерүен үтмәүчеләр була. Үзен-үзе белмичә кичтән сәрхүшләнә дә, иртән — махмыр. Менә шундый «бракованный»лар урынына шунда ук запас бурильщикны куясың. Һәр контор моны шулай эшли. Тик бу законга сыймый. Моңа бәйләнәләр. Тагы нәрсә? Бу кварталда план тулмас, ахрысы. Бер-бер артлы аварияләргә юлыктык. Запчастьлар үз вакытында килмәде. Гаеп бездән түгел, әмма җаваплылык безнең башка төшә. Берни дә эшләр хәл юк. Шулай корылган. Тәртипләр гаебе өчен дә кешеләр җавап бирә. Тәртип-законнар барча эш барышына җайланмаган, сыгылмалы түгел. Бик кирәкле детальләр исәпкә алынмаган. Гамәли эшнең бар ягын нигезли алмыйлар. Ә безгә төрле хәлләрдән чыгу өчен хәйләләргә, алдашырга туры килә. Тәртипләрнең гамәли эш барышына ярап бетмәвең һәр эштә күрергә мөмкин. Икенче төрле итеп әйткәндә хәйлә, алдашу тәртип-законнарның үзләренә үк салынган...

Башында рәнжүле уй бөтерелә: «Сәяси мотивлар аркасында булса, бигайбә...» Башлык аны яклый алмавын алдан ук әйтә. Нигә моңа кимсенергә? Аның урынында үзең әллә ышыклый алыр идеңме? Юк, әлбәттә, шулай булгач, нигә бүтәнне гаепләргә? Ихласлыгын хәерхаһ итеп кабул итәргә тиешсең.

Ревизиягә булышчылар итеп гади эшчеләрдән вахтадан буш Фаизов белән Алкинны алганнар. Хәер, Алкин үзе инициатива күрсәткән, ялда булса да, конторга килеп, местком документларын тикшереп утыра. Холодец турында тыныч кына сөйли алмый ул, аны яшерен жулик дип атый.

Тугаев ихатаның аргы башында гаражлар артында гына Зәй Фаизов белән очрашты. Шыпырт кына сөйләштеләр. Зәй икейөзлеләнә белми, шулай да рус кешесеннән курка торган чалымы сизелә. Әллә бала чактан куркытып калдырганнар, әллә Уралда хезмәт батальонында берәр хәл булган?

Зәйдә бераз үзенә зур, катлаулы эш йөкләгәннән борын күтәрү бар сыман. Бу — аның татарлыгы иде. Тугаев сорауларына теләмичә генә җавап кайтара. «Син нәрсә? — диде Тугаев аңа ачуланып карап.— Хәтерең начарландымы?» Үзе эчтән уйланды: «Адәм баласы кемнеңдер эше үзеннән торганны белсә, шунда ук үзгәрә, үзен зурга саный башлый... Менә бит Зәйгә игелегем тигәләде, ә ул рәтләп сөйләшергә дә теләмәгән шикелле».

— Алмаз Борисович, ревизия башлыгы кисәтте, җитәкчеләргә берни әйтмәгез, диде.— Зәйнең битләренә алсулык тибеп чыкты. Ул маңгаен учы белән ышкырга тотынды.

— Өркәк икәнеңне чамалый идем...— Тугаев, кулын селтәп, китә башлады. Зәй аның җиңенә тотынды һәм сөйләп китте:— Мин бер хәлне сезне аклап сөйли башласам, син директордан куркасың, дип авызны яба ревизор хатыннар. Әллә нинди үчле, һәр нәрсәгә бәйләнәләр. — Списать ителгән «Волга» машинасы булган, шуны кемгәдер очсыз бәя белән саткансыз? — диде Зәй җитдиләнеп.

— Аны Холодец маташтырды бугай.

— Юк, анда сезнең имза, Алмаз Борисович. «Эш срогы чыккан «Волга» машинасын ГАИ учетыннан төшерергә һәм халыкка сатарга». Имза сезнеке.

— Шайтан белсен, һич хәтерли алмыйм... Тагы?

— Бүзәев дигән кеше штатсыз урында эшли?

— Аны горком безгә тыкты, нәрсә беләндер «янган» булган.

— Конторда эшләмәүче ике инженер ярты ставка акча алып яталар: Сибгатуллин, Тимәшев.

— Алар горкомда утыралар, үзләре шулай эшләделәр. Безгә бит чынында горком баш. Тагы?

— Больничныйларны тикшерделәр. Больницага барып. Травмалар күп булган, берсенә дә акт төзелмәгән. Яшерелгән...

— Акт төзесәң, премияне кисәләр, эшчеләр үзләре теләмиләр. Бу хәл бездә генә түгел, заводларда да шулай...

Алар гараж алдына чыктылар, Зәй конторга таба атлады. «Син алай шүрләмә ул хатыннардан, кыю бул, «мин рабочий класс» дип күкрәк сук!» — ди-ди, дәртләндерде аны Тугаев. Әллә каян гына ялт итеп Холодец килеп чыкты. Аның йөзендә бернинди борчылу, пошыну ише нәрсә сизелми. Күз карашларында канәгатьлек, сөенечкә охшашлык чаткылар чамалана иде.

Тугаев аңардан теге исәптән чыгарылган «Волга» турында сораша башлады. Имеш, аны минем боерык белән кемгәдер биргәнбез, шулаймы? Имеш, ул машина, әрь-яңа булмаса да, яртылаш та тузып җитмәгән булган? Чын бәясе биш меңлек машинаны 916 сумга сатканбыз? Мин нишләптер берни хәтерләмим?..— Ул Холодецка карады, тегенең йөзе кинәт дәһшәтләнде, калын кашлары җыерылып маңгаена менде. Кыяфәтенә авырыксыну да чыкты.

— Куркырлык эш юк,— диде Холодец тагы элеккеге ягымлылыгы белән яктырып.— Без аны горкомның тәэминат бүлегендәге Кирюшинга саттык. Барысы да законно. Хакын машина магазинында техниклар куйды. Без ни монда?— Ул кулларын ике якка җәеп алды.

— Нигә «Без» дисең, мин ул нәрсәне белмим... Виктор Михайлович, мине бутама син!— Тугаев тегенә төбәлде, уңайсызланыр, дип уйлаган иде, ә Холодец көлеп җибәрде. Тугаевның йөзе караңгыланып китте.

— Тукта, әллә син чынлапмы?— Холодец көлүдән кинәт җитди төскә керде.

— Син ул «Волга»ны металлоломга гына яраклы дидең шикелле? Шуңа кул куйганмындыр. Димәк, алдагансың?

— Алмаз Борисович,— диде Холодец хатын-кызлар өчен генә тотыла торган йомшак, килешүчән тавыш белән.— Мин аны Кирюшинга сатарга ниятләгәнне әйттем. Син хупладың, чөнки горком кешесе, бик кирәкле зат...

— Минем яхшылыктан явызларча файдалангансың, Виктор Михайлович!

— Ялгышасың, Алмаз Борисович, мин контор өчен тырыштым. Инструментлар белән тәэмин ителү әйбәт булгач, квартал планын күпме алдан үтәдек. Күпме премия алдык! Кирюшинның хәерхаһ кулы аркасында. Үзегезгә бу мәгълүм. Без — аңа, ул — безгә. Хәрәкәт иттерә торган көч шул бит! Айдан төшмәгәнсездер, шәт!— Холодецның йөзе кызарып бүртенде, бугаз тамырлары туктаусыз хәрәкәтләнә иде.

— Нәрсә син Кирюшинны купайтасың? Мин күпме чаптым, бүтәннәр... Мине галошка утырту өчен эшләгәнсең син моны!

— Сез мине рәнҗетәсез, Алмаз Борисович!— дип, карлыккан тавыш белән гыжылдады Холодец. Тугаев та тәмам самавыр кебек кайнап чыккан иде, тыелып кала алмады, эчендә җыелып килгән нәрсәләрен чыгарды.

— Күптән сизеп йөрим миңа баз казуыңны, тик...

— Бу кадәр сукырдырсың, дип уйламый идем. Сезгә хөрмәт белән караганымны һәркем белә. Юк...

— Тыштан син бик итагатьле. Ә астан ниндидер этлек эшләвеңне сизгәләдем, әмма дәшмәдем. Син «Волга» өчен үзең җавап бир, миңа сылама. Үзең мәтәштергәнсең...

— Алай булмый ул, Алмаз Борисович, кәгазьләрдә сезнең имза, так что...

— Имзаны подделать итеп булмыймыни? Синең кулдан килә торган эш... Әллә... Мөнә намуслылык күрсәт, җаваплылыкны үз өстеңә ал да бетер! Ә? Синдә берни дә булмаячак. Үзем яклап калырмын!..

— Сатулашасызмы? Шуның өчен миңа нәрсә?— дип, Холодец күз aклары белән карады. Йөзендә кызыксыну чаткылары иде. Тугаев аның йөзенә карап, айнып киткән кебек булды, үзенең кирәкмәс сүзләр җибәргәнен, дипломатик чалымын югалтып, ялгыш юлга кереп киткәнен шәйләп алды. Ләкин чигенергә соң иде. Мәгънәсез булса да, фикерне дәвам итте:

— Сезне бездән алдыруны куймаячакмын...

— Хе-хе-хе!— дип, тиенкы гына зәһәр кеткелдәде Холодец, ияген учы белән сыпыра-сыпыра.— Сез берни дә сизмисезме? Үзегезнең тәгәрәвегез ихтимал бит! Үз башыгыз турында кайгыртасы урында...

— Беләм, беләм,— дип бүлдерде аны Тугаев.— Син ул «Волга» белән махсус рәвештә миңа компромат әзерләгәнсең! Ну сиңа шулай кушканнардыр, билгеле?..

— Миңа беркем дә кушмады, нахак сөйләмәгез, олы башыгызны кече итеп. Мин эш өчен, контор өчен тырыштым. Тик моны үз җилкәмә генә ала алмыйм.

— Аңлашылды, син моны әшәке максат белән явызлык өчен эшләгәнсең. Бәлки алар сиңа директор урынын вәгъдә иткәннәрдер? Ә?—

Тугаев, артык нервыланудан, кулындагы ниндидер чыбыкны үзе дә белештерми шарт-шорт сындыргалады. Холодец, үзен тиз кулга ала белә торган кеше буларак, болай тәмсезләнешү берни дә бирмәгәнлеген тойды һәм әйтте:

— Сез хәзер бик ярсыган, киеренке настроениедә,— диде юмалаган, үтенгән һәм үзенең акыл өстенлеген белгерткән төстә. Шуңа сөйләшүне дәвам итмик! Әйе... Тынычлангач, уйлангач, мөнәсәбәтләрне ачыкларбыз...

— Монда ачыкланды инде, артыгы белән...— Тугаев кулын өстән аска таба кинәт селтәде дә борылды һәм машинасы торган төшкә китте. Ул ерактагы бер буровойга барырга тиеш иде. Өч-дүрт көн инде әзер буровойны тапшыра алмыйча азаплаиалар...

Актив киңәшмәсендә Тугаевка артык озак утырырга туры килде. Лекция сөйләргә Гатыев үзе килгән иде. Ул өлкә комитетының икенче секретаре булып эшләде, аннары нигәдер Верховный Совет президиумына куйдылар. Милли мәсьәләләрне хәл итә, диләр. Чыннан да, лекция-чыгышларында ул шул мәсьәләгә кагылмыйча үтми. Солтангалиевкә тибеп уза, аның коерыклары чит илләрдә «Азатлык» радиосы тирәсендә тупланып, шуннан котырган этләр кебек советларга өреп яталар, ди. Татарстан турында да төрле уйдырмалар тараталар, рус халкы белән татар халкы арасына үчлек сибәләр.

Гатыев сөйләгәндә шәбәя, гайрәтләнә. Алдында яткан кәгазьләргә карамый. Эре бөртекле ялбыр чәчләре киң маңгаеның ике ягына салынып төшә, ул аларны бер кулы белән артка сыпырып куя. Юан, таза битләре майлаган кебек елтырый. Ул чын ир чырайлы, көче ташып тора торган ягымлы кеше. Кулыннан килгән кадәр бүтәннәргә ярдәмчел дә, диләр... Тугаевның танышы, нефтьчеләр тормышын өйрәнеп, роман язарга йөргән, очраган саен эчәргә акча сораучы Акчуриннның Гатыев турында төрле нәрсәләр сөйләгәне бар. Имеш, бирегә еш килүенең сәбәбе — райкомда эшләүче яшь, чибәр хатын белән чирттерә икән. Нәчәлниклар өчен генә тотылган аулак урман буена салынган кунакханәдә кәеф-сафа корып ята. Ягъни-мәсәлән, зур эшләр өчен рухи заряд ала. Моны гаеп итеп сөйләмиләр. Киресенчә, бик хәерхаһ әйтәләр. Чөнки Гатыевның хатыны үзеннән шактый өлкән, бетерешкән карчык. Бер елны «Васильево» санаториясендә Тугаевка туры килгәннәр иде. Ул гаҗәпкә калды: Гатыев солыда гына торган яшь ат кебек, ә хатыны талкынган киндер көлтәседәй иде. Алар аерым йортта яшәделәр. Гатыевны көн аралаш дигәндәй эшеннән машина килеп алып китә. Бер-ике көн югалып тора да, аннан тагы пәйда була иде. Шунысы кызык, алар ризыкланырга гомуми залга түгел, ә ашханә артындагы аерым бүлмәгә киләләр иде. Номенклатура кешеләренең интим эшләре генә түгел, ашау-эчүләре дә аерым, ят күзләрдән яшерен. «Нәрсә генә ашыйлар икән? Һәр адәмдә шул бер ашказаны бит»,— дип уйлап куя иде Тугаев.

Гатыевның Акчуринга да файдасы тигән. Ниндидер китабын Мәскәүдә чыгарырга булышкан. Ул, гомумән, кешеләргә хәерхаһлыгын югалтып бетермәгән. Акланып төрмәдән кайткан язучыларга ярдәм кулы сузудан курыкмаган. Аны кыю кеше, диләр. Һәрхәлдә, шкурник түгел. Күп еллар Сталин зинданында газап чигеп могҗиза белән исән калган олуг бер шагыйрьнең китабын главлит җибәрми, чыгармый икән. Теге Гатыев янына барган һәм каршына утырган килеш елаган. Китабымны чыгармау — мине физик үтерү, әйдә, үтерегез инде, дигән... Гатыев главлит белән кискен сөйләшкән. Тегеләр әйткән, Гатыев, үз өстеңә күп аласың, дигәннәр. Кисәткәннәр. Әмма ул өркеп калмаган, китапны үз җаваплылыгына алып чыгарган. Шул китапны куштан язучылар, төрмә лирикасы дип, Гатыевка каршы сөйләп йөргәннәр...

Гатыев, гадәтенчә, чыгышын бүлеп, мәзәк сибәргә керешә.

— Райкомда партиягә керүче берәүне раслыйлар икән. Секретарь тегеңә сорау бирә: «Капитал»ны кем язган?» — ди. Теге әйтә икән: «Юк,

мин язмадым»,— дип. «Алайса кем?» — дип ачуланган секретарь һәм бюро члены, НКВД лейтенантына ымлаган: «Барыгыз, кем язганны ачыклагыз»,— дигән. Лейтенант тегенә ияге белән генә: «Әйдә, атла»,— дип, аны алып чыгып киткән. Бераздан кергәннәр, лейтенант әйткән: «Мәсьәләне ачыкладык, ул язган»,— дигән. Секретарь расланучыга төбәлгән: «Әйе, мин яздым»,— дигән теге гаепле кеше сыман... Бу, иптәшләр, коммунистлардан көлү өчен чыгарылган. Сезнең арада андыйлар юктыр, дип уйлыйм. Моны безнең идеологик дошманнар тарата. Лондонда советларга каршы ике том анекдот чыккан. Безгә һәр төштә уяу булмыйча һич ярамый. Менә Төркиядә турыдан-туры татарларга караган китап бастырганнар. Диверсион характерда. Татарстан турында күп уйдырма хәлләр бирелгән. Имеш, татар халкының милек байлыгын талыйлар. Әгәр Татарстанда чыгарыла торган нефтьнең бер проценты гына җирле халыкка калдырылса, кешеләр алтын тәңкәләр өстеннән йөрерләр, дворец кебек биналарда яшәрләр иде, янәсе. Әмма Советлар аларга берни дә бирмиләр, мөлкәтләрен бушка алып бетерәләр, имеш... Бу бит чеп-чи уйдырма, иптәшләр! Безне зәһәр куралмаучылык, явызлык рухында язылган. Шушы эштә Али Акыш һәм башка сатлык җаннар аеруча дошманлык белән тырышалар. Эчләренә җыелган агуларын корал итәләр. Рус белән татарны маңгайга-маңгай бәрелештерергә телиләр. Рус халкы белән татар халкының мәңге дуслык мөнәсәбәтләренә чөй какмакчы булалар. Ләкин дошманнар юкка көчәнәләр. Без бөек рус халкының карусыз дуслык мөнәсәбәтен һәрчак тоеп яшибез һәм аны бервакытта да истән чыгармыйбыз...

Ул, салынып төшкән чәчләрен өскә сыпырды да, бик демократ булып, елмая-елмая, тагы анекдот сөйли башлады...

Тугаев уйланды: «Нигә ул боларны безгә сөйли икән? Татарстан җиренең байлыгын бушка алып бетерәләр дигән уй кешеләр башында туа күрмәсен, дипме? Туа калса, ул фикерләрне алдан ук реакцион, дошмани дип белдерү өченме? Әллә арада үз җирен, милкен кайгырткан милли хисле кешеләр бармы? Белмим, андый затлар табылыр микән. Руслар сүз арасында: татарлар күндәм халык, дип әйтәләр. Тиешсез җиргә борын сузмыйлар. Татарга эш бир, кулына гармун тоттыр. Тамагы тук булмаса да, гармуны белән моңаеп туеныр...

Ә бит уйлап карасаң, Гатыев уйдырма дип әйткән нәрсәләрдә шактый гына хаклык бар икән. Чөнки бездә чыгарыла торган нефть «Дружба» магистраль үткәргеч аша Европага — демократик дәүләтләргә агызыла. Менә ничәмә еллар инде. Әйтергә кирәк, бик тә очсыз бәягә. Прәме шалкан бәясенә. Бик зур гаделсезлек бу! Моны чит илләрдә, безнең җитәкчеләрнең авантюризмы, дип язалар. Без сугышта җиңгән ил, әмма җиңелгән илләрдән күпкә ярлы яшибез. Байлык чит илләргә китеп исраф була. Системаны терәтеп тору өчен җиребезнең хәләл байлыгы сарыф ителә. Безнең табигый байлыклар кими бара, ә теге дәүләтләр баеганнан байый. Ә безнең җир асты байлыгыбыз мәңгелек түгел бит. Киләчәктә без бернисез калырбызмыни? Безнең балалар, оныклар нишләр? Аларның хәләл өлеше бетерелә булып чыга түгелме соң?..

Тугаев, үз уйларыннан үзе куркып, як-ягына каранып алды. Ике ягында утырган кешеләр икесе дә галстуклы күкрәкләренә ияқләрен терәп, мыштым гына черем итәләр иде.

Икенче көнне горкомның промышленность бүлеге мөдире чылтыратты. Беренче сүзеннән үк талкырга тотынды. Теге «Волга» мәсьәләсе аңа барып җиткән икән.

— Ну, син, Тугаев, яхшы булырга яратасың да, ә? Дәүләт хисабына, билгеле. Начар гадәт бу. Коммунист исеменә тап төшерә синең бу очсызлы демократлыгың. Бу юлы үз кесәңне әйләндерергә туры килмәгәе.

— Мин белмим. Холодец эшләгән аны,— дип, Тугаев көчкә бер сүз кыстырды. Мөдир аны тыңларга да теләмәде.

— Беләбез без, стрелочникка сылтауны,— диде, зәһәр ишарәле тавыш белән.

— Ә стрелочник чынлап гаепле булса, нишләргә?

— Чамала, үз өстеңә күп аласың. Без сине элек тә кисәттек. Син гел очсыз авторитет казанырга тырышасың. Ярамый бит алай!

— Сезгә берничек тә ярап булмый,— диде Тугаев ачуы ташый башлап. Башында бик каты сүзләр бер-берсен эртешә-төртешә чыгарга итәләр. Ләкин ул үзен тыя алды. Әйтәсе килгәне шул иде: «Алтынчы контор директоры Байтимеров ике «Волга»ны исәптән төшереп әрмәннәргә саткан, аны сез ачуланмыйсыз, чөнки ул сезнең янга барганда портфеленә коньяк тыгып бара. Сез жулик кешене яратасыз, ә гадел эшләгәнне өнәмисез!..» Ярый әле тыелдым, дип сөенеп уйлады ул соңыннан. Ник дисәң, мөдир вакчыл, үч алучан адәм иде.

Аһ-ваһ итеп, тәэминат инженеры килеп керде. Йөзенә карарлык түгел, сөмсере коелган.

— Теге торбаларны тагы безгә бирмәделәр,— дип, өмете беткән кыяфәттә урындыкка чүмәште.— Шул Байтимеровка китте. Мин складтан алырга торганда завка горкомнан әйттеләр. Бетте! Шуннан горкомга чаптым. Мөдир әйтә: «Юк,— ди,— чылтыратмадым»,— ди. Күзен дә йоммый. Ышанмыйча булмый бит. Склад завына барып ябыштым. Ул әйтә: «Чылтыратты, чылтыратты, боерды,— ди.— Мин аңардан уза алмыйм,— дип, үземә ябышты. Кемгә ышанырга? Болай эшләп булмый, Алмаз Борисович. Юк!

— Әйе, күңелсез хәл!—дип уфтанды Тугаев. Моны берләшмә начальнигына әйтмәкче булды. Чылтыратты. Төрепкәне алучы булмады, берәр киңәшмә-фәләндер инде.

— Инде нишлибез, Алмаз Борисович? Нигә безне шулай кыерсыталар?

— Нәрсә өчендер безне җәза объектына әйләндерделәр, белмим...— Тугаев авыр сулады, аның киң җилкәләре кыймылдап куйды.

Алар озак уйланып утырдылар, бәладән чыгу әмәлен таба алмадылар.

Өйгә эленке-салынкы, үртәлүле җан белән кайтылды. Ниятләгән эшеңне эшли алмаганга үртәлеп, күңелгә әллә каян әче үт ага иде. Шайтан алгыры, күпме чыдарга мөмкин? Хәер, безнең эш шундый инде, моңа зарланырга ярамый.

Өйдә берәү дә юк. Ул ишек төбендә үк өстен алыштырды. Юынгычта юынып чыкты. Кухняда чәй куеп җибәрде, суыткычтан ашамлыклар алып, өстәлгә тезде. Ишек шакыганга барып ачса, Рита керен килә. Күзләре яшьләнеп кызарган, битләре буйлап яшь эзләре сызылып төшкән. «Нәрсә булды тагы?»—диде Тугаев, әллә ни исе китмичә генә. «Юк, берни дә юк»,— дип, Рита өстен алыштырды да йокы бүлмәсенә юнәлде. «Чәй эчмисеңмени?»—дигәнгә бары кулын гына селтәде. Алмаз аны юатырга омтылмады. Рита төчеләнүне, юмалауны бер дә өнәми иде. Алмаз да ялынырга тормый. Ул аны иркәләп өйрәтмәде. Рита тагы да ныграк горурлыгын саклый. Алмаз кәефе килеп песиемли башласа, йә-йә, төчеләнмә, дип читкә этәрә. Әмма хатынның бик кирәк моменты була бу, тик Рита синең хәлеңне аңламый, аңларга да теләми, отыры киреләнә. Кочагына якын җибәрми. Алмаз ачуланып лыгырдый-лыгырдый кире чигенә. Кайбер ялагай ирләр кебек, үзен түбәнәйтер дәрәҗәгә төшми. Эчтән үзен тыя-тыя, аерым диванга барып ята. Ул озак кына йоклый алмый, әйләнә-тулгана, диван пружиналары шатыр-шотыр килә. Рита шуны ишетеп ята, әмма иренең хәленә керергә теләми. Бу бик зур мәнсезлек, билгеле. Шундый чакларда Алмаз фронтта контрразведка шартлары таләп иткәнгә мәҗбүри кушылган Зарияне бик җанлы итеп хәтерендә терелтә. Менә ул чын хатын иде ичмаса! Аның хатын-кыз-

лыгын, назлылыгын Алмаз һич оныта алмый. Рита назы Зария назын томалый, бетерә алмады. Киресенчә, Зария назын күңелдә тирәнәйттеренә. Ритадан канәгать булмаган чакларда Зария назы күңелдә ниндидер бер сызлау булып сулкылдый башлый. Нишләптер бу хис хәзергә чаклы бетми. Рита шуны бетерә алмый. Нигә шулайдыр инде. Зария яшь иде, дәртле, бер ым белән аңлый иде. Мин дә яшь идем. Зария минем беренче хатын-кыз иде. Бәлки, шуңарга мәңге җуелмаслык булып йөрәктә калгандыр... Рита белән тәмсезләнешкәндә аеруча сагындыра, йөрәкне сызып-сызып үтә ул.

Пәриләшкән төннең иртәгесен чәй эчкәндә, кашын-күзен җимереп утырган Алмазга Рита акланырга тотына.

— Мин врач буларак шулай эшлим, сине саклыйм, согыңны эчеп бетермим. Син, дурак, шуңа үпкәлисең. Аңламыйсың. Беләм мин юләр хатыннарны, төнлә ирләрен талыйлар, аларның актык сокларын суыралар. Шулай ирләрен эштән чыгаралар, иртә картайталар. Кырык яшьтә андыйларның ирләре алтмыштагы кебек — арка бөкрәйгән, күзе чекрәйгән була. Ә мин сине саклыйм, әнә син кырыкта булсаң да, утызны гына бирерлек.

Иртән шулай сөйләнсә дә, эштән кайтканда тагы елаудан күзләре шешенгән була. Соңгы вакытта иртән дә сөйләнми иде инде. Чәй дә эчеп тормыйча, соңга калам, ди-ди, әштер-өштер чыгып чаба. Ике атналап вакыт узды.Ританың куркыныч сызыгы үткән иде. Алмазны үзе чакырып алып янына яткырды. Тойгылар бер-берсен уяттылар, кузгаттылар. Тәндә дулкын булып кузгалып, бер-берсенә каршы барып, чарпалыштылар. Шуның тәэсирендә икесенең дә кәефләре бер ритмга көйләнде. Күңелдәге юшкыннар эреп, юылып төшкән шикелле булды. Җанда булган иң ихлас сүзләргә юл әрчелде кебек. Алар үзләреннән-үзләре телдән агыла башлады. Ике җанның берләшү, серләшү һәм сафлану моменты иде бу. Иң изге мизгел. Рита башын мендәрдә килеш Алмаз башына китереп кысты да пышылдап сөйләргә тотынды. Тәмам чишелде:

— Минем кайгырып-борчылып, ни эшләргә белми, үземне югалтып йөрүләрем тикмәгә булмады, — диде. — Ике таза гәүдәле орган кешесе, мине ялгыз бүлмәгә алып кереп, сорау алдылар. Көн саен диярлек сәгатьтән артык тоттылар. Бу хакта беркемгә дә белгертмәскә, бигрәк тә сиңа сиздермәскә имза куйдырдылар. Бик каты янадылар. Әмма мин бу серне синнән яшерә алмыйм, Алмаз, юк, мөмкин түгел. Син бит үзең дә смершта эшләгән кеше, болар синең өчен бернинди сер түгел. Мин әйтмәсәм дә, барыбер сизәр идең, белер идең. Тик арабызда стена хасыйл булыр иде. Шулай бит?.. — Рита бераз тынып торды.

— Әйе, дөрес, Рита, — диде Алмаз аны хуплап. Рита дәвам итте:

— Орган кешеләре: «Теге австрияклар белән нигә аралаштыгыз, ниләр сөйләштегез?» — дип төпченделәр. Һаман шул хакта казындылар. Мин барысын да сөйләп бирдем. Ни хакында сүз барганын да бәйнәбәйнә тездем. Аларны аерым сүзне ничек дип әйтүләренә, вак детальләргә чаклы кызыксындыра иде. Тугаев безнең нефть серләрен аңа ычкындырмадымы икән, дигән шик аларга тынгы бирми. Мин сөйлим, алар ышанмыйлар. Менә бәла...

— Ышанмау аларның төп профессиясе! — диде Алмаз.

— Шуннан юмаларга тотындылар, — дип дәвам итте хатын, авыр сулыш алып. — Без Тугаевны горком өчен әзерлибез, шуңа күрә аның эчен-тышын белергә тиешбез. Бу аңлашыла торгандыр һәм сорау уятмыйдыр бит, ди. Менә син безгә аның ни сөйләшкәннәрен җиткереп тор, безгә ярдәм ит. Ватанга ярдәм итүең шул булыр. Ватанга ярдәм итүдән баш тартмыйсыңдыр, шәт, ә? — дип туп-туры күзгә тегеп төбәлә. Карашыннан тәнемдә «мурашкалар» йөгереште, аркам буйлап салкынлык чиркандырып узды. Ватанга булышырга риза, әмма иремә шымчылык итүдән ходай сакласын. Үтерсәгез дә булмый, мин әйтәм...

— Нигә риза булмадың, юләр! — дип, Алмаз аның сүзен бүлде.

— Син әйтәсеңме моны, Алмаз! —Ританың гаҗәпләнүе хәттин ашты.— Мин исә, сизенерсең дә мине ташларсың, дип курыктым.

— Нәрсә ул кадәрле, әллә бер без генәме?

— Ничек инде, Алмаз, шаяртасыңмы соң?

— Тормыш шулай таләп иткәч, адәм баласы нишли алсын?! Беркем дә барыштан өстен була алмый... Гамәл мәҗбүр иткәч, кешеләр әллә нинди әшәкелекләрне дә тайчынмый эшлиләр.

— Юк, Алмаз, аңламыйм, аңларга теләмим! — Рита өстенә япкан юрганны ачу белән алып атты. Ике учын йөзенә каплады да сулкылдарга тотынды. Урамнан төшкән электр яктылыгында аның бармакларында алтын йөзекләр чагылып-чагылып китә. Йөзекле бармаклары арасыннан күз яшьләре саркып акканы күренеп кала иде. Бер дә ләпшәрмәгән, резин туп шикелле тыгыз булып тәртеп торган күкрәк алмалары тагы хисләрне кабындыра, аны кирәкле һәм сөекле итә. Карасана, Алмаз үзе белән янәшә яшәгән, аның белән гомерен, мәхәббәтен бүлешкән кешесен белмичәрәк йөргән икән. Рита кайбер сыйфатлары белән бераз эгоист булса да, намус мәсьәләсендә нык йөрәкле икән.

Шушы ихлас сөйләшү-ачылулардан соң Алмаз үзенә ни өчен басым ясауларының, кыерсытуларының сәбәбен аңлагандай булды. Әйе, бу ревизияләр, финанста казынулары барысы да сәяси ышанычны югалтудан гына, дигән фикер төйнәде ул... һәм хәтеренә австрияклар килде.

## VII

Нефтьчеләрнең яңа Акташ шәһәре элеккеге Пичмән авылы урынына төзелә иде. Уртасыннан кечкенә чишмә суы агып торган яссы үзән сузылган. Үзән аша дамба салынган. Каршыда тәбәнәк тау тезмәләре китә. Таулар куе урман белән капланган. Шушы урман кишәрлекләрен шәһәр паркы итеп җиһазлаганнар. Цементтан катырып сыннар, беседкалар, концертлар өчен гөмбәзле аркалар эшләнгән. Эскәмияләр тезгәннәр. Бу төш Тартакиев өчен изге бер урынга әйләнде. Бирегә ул кызы Фирүзә белән очрашырга килә. Аерылган хатыны кызны әтисе белән күрештерми, бик усал рәвештә тыя иде. Ә кыз исә бик күрергә ашкынып тора. Кайчагында әнисеннән кача алса, шушы өсте козырек шикелле эшләнгән гөмбәз янына килә. Тартакиев, кызы белән легаль аралашу хокукы таләп итеп, судка мөрәҗәгать иткән иде. Ләкин файдасы тимәде.

Аерылган ирнең үз баласына бернинди хокукы да юк икән. Барысы да хатыннарга бирелгән. Әмма алиментны шәп каералар. Балага акча түләп барасың, тик аның үзен күреп сөйләшергә хокукың юк. Ул хокук хатын рөхсәт итсә була, ә рөхсәт итмәсә, булмый. Менә шулай яшерен очрашырга туры килә. Закон ата белән бала арасына киртә куйган. Ул киртәне яшерен хәйлә кулланып кына үтә аласың.

Бүген Фирүзә озаклады. Башка вакытта алдан килә торган иде. Теге карчыганың тырнакларыннан ычкына алмый, ахрысы. Әйе, кызның килә алмаган чаклары да була. Тартакиев көтә-көтә дә, булмады, ахрысы, дип, башын иеп, дөньясын каргый-каргый кайтып китә.

Мир Тартакиев, папиросын кабызды да, аерылган ирләрнең үз балалары белән качып очрашуларын күзәтеп утыра башлады. Әнә безнең берләшмәдә эшләүче Фәләхов җитеп килә торган улы белән очраша. Икесенең дә йөзләрендә югалып калганлык, гаҗизлек. Сүзләре ябышмый, ахрысы. Әти кеше борчыла, кулларын болгый, нәрсәдер исбат итәргә тырыша. Малай әнисе ягына авышкан күренә. Качып килмәгән, әнисе аны махсус җибәргән, шпион итеп. Малай шул роленә үзен туры китерә алмыйча борчыла булыр.

Тегендәрәк Җир шарын кулларына күтәргән сыннар янында хәвефсезлек инженеры, балигъ, формалашып җиткән кызы белән күрешә.

Бер-берләрен нинди сагынышканнар. Кыз гел көлеп кенә тора. Гүя аны кием эченнән кемдер кытыклый диярсең. Инженер нигә аерылганнарын сөйләп торган иде. Хатыны искиткеч модница булган. Идиотизмга кадәр. Ә мода коточкыч нәрсә. Шул канына сеңгән хатын бик хәтәргә әйләнә. Баласың, ирен оныта. Мода артыннан гына чаба. Күзенә ак-кара күренми. Мода һава кебек бик еш алмашынып тора. Модный күлмәк тектереп җиткерергә өлгерми, яңа мода килеп башына суга. Ах, итәкне янача тар һәм ерыклы итеп тегү модасы чыккан. Барысына да акча кирәк. Ә акчаның кайчан җиткәне бар. Хатын бар эш хакын яңа модага тотып бетерә, ашарга-эчәргә берни калмый. Ул акчаны ала, әмма ризык әзерләми. Эштән кайтам, кабарга берни юк. Әбәдкә дә акча бирми. Нишләргә? Кычкырыш арты кычкырыш. Хатын-кызны җиңеп буламыни? Модага бирелгән хатынны аек акылга китерү мөмкин эш түгел икән. Мода наркотик шикелле икән, валлаһи. Төп сәбәпкә бүтән сәбәпләр дә өстәлде. Финалы менә шул. Миңа үчегүдән кызны минем белән көрәштерми. Шуңардан ниндидер ләззәт таба шикелле. Адәм затының эчендә явызлыклар бик күп әле.

Ә без Шакирә белән ни сәбәпле аерылдык. Әйтсәң, кеше ышанмас, сөйләргә оят. Ул детдомда тәрбияләнгән. Шактый сансыз иде. Үзенең хатынлыгын күрсәтер өчен, мин-минлеген текәндерергә теләп, эчәсең, дип бәйләнде. Чынлап та еш кына эчелә. Кыш көне бигрәк. Салкында катып-туңып эшлисең. Салкын җелеккә үтә. Шунда аракы эчмәсәң, икенче көнне больничный алырга туры килә. Тәнең кайнар, борының тыгылган. Бюллетень белән маташып йөрү егет эше түгел. Шуңа бер кырлы стаканны тутырып саласың һәм вәссәләм. Иртән өр-яңа кеше, томау да төшмәгән. Эчемлек барысын сыпырып ташлаган. Ләкин, Шакирә нык бәйләнә башлагач, салуны киметергә мәҗбүр булдым. Кыз туды. Гаилә бәхете килде. Бәхет рәхәтен тоярга өлгермәдек, Шакирәдә әллә нинди дәрт котырды. Баланы да юньләп карамый, минем дә бары зарплатам һәм ирлегем генә аны кызыксындыра. Мин командировкада чакта ужымга кергәләгәне ишетелде... Нишләргә? Кызым гүзәл булып үсеп килә. Йөрәктән өзелеп төшкән җанлы кисәк. Ничек аннан башка яшәү мөмкин булсын, ди. Мин түздем, чыдадым. Мине эштә күтәрергә тиешләр иде. Шуның өчен дә түздем. Мораль якка нык әһәмият бирәләр. Әмма минем урынга бер жуликны күтәрделәр. Шуңа бик нык гарьләндем, тагы шешәгә тартыла башладым. Хатынга да ачу килде. Минем абруйны үзенең кәнтәйлеге белән төшереп бетерде. Арт якка йомшак хатынның ирен ничек дәрәҗәле урынга куйсыннар? Шуннан соң аерылудан башка хәл калмады...

Минем хатыннан бәхет булмады, шайтан алгыры, дип Мир үзенекен уйлады: беренче хатын белән дә бер дә юктан гына кычкырышып, үпкәләшелә иде. Ул укытучы, өстәвенә үз-үзенә бик ышанган, тәкәббер. Бер дә санга сукмады, чөнки мин нефтьтә бригадир булсам да, барыбер кара эшче. Һаман мине түбәнсетә торган хәрәкәтләр ясый, минем кара җилкә булуга ишарәләүдән туктамый. Моны ул ниндидер үчлек рәхәтлеге тоеп эшли иде. Мин гел аның кәефенә генә ярашып торырга тиеш. Аны иркәләргә, алиһәләргә бурычлы. Шулай итмәсәң, янына да яткырмый. Кем булган ул тикле аның аяклары астында дорожка кебек сузылырга? Мин бит аннан ким эшләмим, ким алмыйм? Хатын үзен зурга куеп, мине начар билгеләренә укыган, класста икенче елын утыручы үтә тәртипсез укучы итеп күрә иде. Түбәнсетү белән мине сындырып, үзенең күзенә карап: нәрсә боерасыз? — дип торучыга әйләндерергә теләде. Аның үзен бик югары тотуына каршы миндәге тискәрелек, тупаслык баш күтәрә. Шунда аңладым, мин буйсынуны күтәрә алмыйм икән. Ә бит начальникларның һәр боерыгына ләббәйкәләнеп, аларны янып үтәү миңа бик рәхәт була. Ә хатын ихтыярына бөгелә алмыйм, шабаш. Ахырда баланы алып, әниләренә китте. Алты ай ярым торганнан соң, аерылышуны кузгатты... Хәзер генә аңладым, мин ахмак кире булганмын. Ничек тә

үз-үземне әз-әзләп җиңеп, хатын ихтыярына тапшырылырга тиешле булган. Акыллылар шулай эшлиләр. Һәм эшләрендә уңышка ирешәләр. Дәрәҗәгә күтәргәндә шарт бар, ди: хатынына буйсынамы, юкмы. Минем кандидатура шул шартка төртелеп егылды, күтәрмәделәр. Ә хатынга буйсыну һәрьяктан әйбәт нәрсә. Андый гаиләләр тыныч, тигез яшиләр. Ирләре эчми, чөнки хатыннарыннан куркалар. Мин тәҗрибәдән беләм, бик ахмак булганмын. Зиһен җитмәгән. Әмма үкенүемне йомшарта торган бер нәрсә бар: хатын үзе акыллылардан түгел иде. Мин әйткәнне колагына элми, бүтәннәр ни әйтсә, шуны чынга ала. Шуның буенча эш йөртә. Шул йомшаклыгын белеп алып, аны миңа каршы зәһәрләнеп котырттылар. Аңа әйтәләр: син акыллы, чибәр, үзең культуралы, югары белемле, нигә шул тупас шимпанзе белән гомереңне заяга уздырасың. Бәхетең юк бит, ә син бәхетле булырга лаеклы. Үз өлешеңне җиргә күмәсең. Аерыл һәм бәхетне озак та үтми табарсың... Әмма аерылгач, өмет иткән бәхет юк та юк. Асат кына бәхет тотырып куйганнар, ди сиңа! Шактый вакытлар үтә. Бәхетнең шәүләсе дә шәйләнми. Менә шул чакта хатын уйлана. Элеккегеләр исенә төшә. Мин нинди уйсыз, беркатлы булганмын, ди ул үз-үзенә. Үз бәхетемне үзем аңламаганмын. «Подругаларым» ничек мине адаштырганнар. Моны көнчелектән генә эшләгәннәр. Үзләренең бәхете китек булгач, мине дә үзләре төсле булсын, дигәннәр...

Күзәтүем буенча, гаиләләрне читтән тәкәллефсез катнашып җимерәләр. Ни өчен эшләнә бу? Җимерүдә тычкы көчләр катнаша. Әллә хөкүмәткә шулай файдалымы? Һич аңлап бетерер хәл юк бу тормышны... Элек әйбәт иде, кечкенә калибрлы начальник ни боерса, шуны йөз процент берсүзсез үтәп торалар. Ә хәзер һәркем үз фикерен әйтә, пешмәгән башы белән эшкә тыгыла. Эш эшлисе урында бер-береңнең хаклыхаксызлыгын исбат итеп көч түгелә. Бу бик начар. Эш ул телдәрләнүне яратмый, эшләгәнне ярата. Телдәрләнү судан май язу кебек өметсез нәрсә. Эш урынын сүз ала, менә нәрсә фаҗига. Ну бездә сөйләргә яраталар да соң! Ул җыелышлар — йа Хода, күпме вакытны әрәм итә! Кечкенә бер конкрет эш тә мең җыелыштан файдалырак, валлаһи! Кайчан моны аңларлар, кайчан реаль аң керер? Өстәгеләр тәмам идеология белән миңгерәүләнеп беткәннәр. Реаль фикер йөртүгә сәләтсезләр. Түбән баскычта торучы, барча материаль байлыкны тир түгеп тудыручылар хакында бөтенләй уйламыйлар. Колхозда эшләүчеләр, эшчеләр турында кайгыртмыйлар. Ә сөйлиләр, язалар: партиянең эшче-крестьяннарны хәстәрләүдән башка бүтән интереслары юк, имеш! Нинди ялган, икейөзләнү. Чит илләргә ай саен әллә ничә миллиард китә, ди. Барысы да халык байлыгы. Халыкның авызыннан өзеп, читләргә бирәләр. Шул хәзинәне колхоз авылларына җибәрсәләр, нинди яхшы булыр иде! Юк, уйлыйсы килми, йөрәкне генә бетерә бу абсурд нәрсәләр...

Тартакиев урыныннан кузгалды, булмады, ахрысы. Фирүзә теге карчыганың тырнакларыннан ычкына алмады. Боегып, өметен өзеп, башын игән килеш, әкрен генә парктан чыгу юлыннан атлады. Ни булды икән, әллә имтиханын бирә алмадымы? Кичә ул физиканы тапшырырга тиеш иде. Мин ярдәм итә алмадым. Беркөн вопросник белән утырган идек. Анда Фирүзә унөч билетка җаваплар биреп чыкты. Дөресрәге, физика курсын миңа аңлатты. Тыңлап торучыга сөйләү хәтердә калдыра, ди.

Ишегалдына кергәч, Тартакиев адымнарын тизләтте. Подъезд төбендә озын эскәмиядә гайбәтче хатын-кыз утыра. Алар һәркемнең сөяген авызларында «юалар» иде. Тартакиев башын читкән борып, илтифатсызлык күрсәтеп узып китте.

Подъезд баскычыннан менгәндә ни күрсен, Фирүзә төшеп килә. Менә бәхет.

— Ачкычыңны югалттыңмы әллә? — дип туктады ул, кызына сөеп караган килеш.

— Әни ачкычны сумкамнан урлаган. Сорарга курыктым, — диде Фирүзә бер баскыч түбән атлап һәм этисенең муеныннан ике куллап кочып

алды. Ул кулларын сузып кочты, чөнки биек булып тулышып торган күкрәкләрен әтисенә тигерергә уңайсызлана иде.

— Имтиханыңны ничек бирдең?

— Нормально, дүртлегә...

— Ничек ычкындың?

— Әни янына бер дядка килде. Олы якта диванда утыралар иде, кердем дә киногa барырга акча сорадым. Дядка ашыга-ашыга акча чыгарып бирде. Әни тыярга базмады...

Алар ишекне ачып керделәр. Әти кеше өс-башын алыштыра, ә Фирүзә исә, кухняга узып, алъяпкыч бәйләде, кичке чәй әзерләргә керешге. Тартакиевның башы күккә тигән иде: Фирүзә керүгә бүлмәгә әллә нинди җылы яктылык тулды, сорылык бетте. Сулыш алуы иркенәйгән, бүлмә киңәйгән шикелле иде. Зиһен дә ачылган, баштагы томаннар юкка чыккан. Әллә бу туган баланнан гына килүе мөмкин булган рәхәтлек микән? Ике туган җан кара-каршы утырып чәй эчәләр. Тартакиев, кызын уңайсызламас өчен, аңа текәлеп карарга курка. Ул алма кебек пешкән, каны уйный башлаган. Әнисе янында бозылып китмәгәе. Начар үрнәк бик йогышлы. Бигрәк тә менә шушындый яшьтә куркыныч. Кыз томанлы яшьлек чорына кергән, аңа акыл түгел, хисләр баш.

— Әти, мин өйгә кайтмас идем,— дип куйды Фирүзә, күптәнге ниятен белгерткәндәй җитди төстә. Тавышы әти кешенең йөрәгенә май булып ягыла, шундый ягымлы, нурлы.

— И-и кызым, пожалысты гына,— диде әти кеше шатланып. Ләкин бу теләкнең тормышка ашуына шикләнгәнен белдереп, йөзендәге нурлар кинәт сүнде. Кызы әтисенең реаль уйлавын абайламады.

— Әни янында дядкалар эчәләр, шаулыйлар. Дәрес хәзерләргә һич мөмкинлек юк. Кухняда идәндә йоклыйм?

— Беләм, кызым. Минем исемнән судка шулай дип язып бирик әле. Әниеңнең нервы авыруы икәнен дә әйтергә кирәк...

— Әни скандал кубармасмы?

— Закон синең якта. Балигъ булгач, ата-ананың кайсында телисең, шунда яшисең.

— Квартира мәсьәләсе Сездә җайлыракмы әллә?

—...Иң башта бирегә пропискага керергә кирәк.

— Мин бүтән анда кайтмыйм, шушында калам,— дип, Фирүзә әтисенә текәлде. Аның карашында әтисен әти итеп кенә түгел, ә ир-ат итеп карау бар иде кебек. Әтисе, сөенеп, елмайды.

Чәйдән соң Фирүзәгә урын әзерләргә керештеләр. Стена буендагы шифоньерны бүлмәнең нәкъ уртасына ипе белән куйдылар. Икенче шифоньерны икенче стенага терәтеп, тегесе турына китерделәр. Ике шифоньер арасындагы ачыклыкка пәрдә элделәр. Бер диван белән өстәл тәрәзә ягында калды, икенче диван — караңгы якта. Тәрәзә ягында Фирүзәгә бик җайлы урын барлыкка килде. Көндез якты, кич белән өстәл лампасы бар. Әтисенә караңгы як бик уңай. Көне буе эштә, кичтән кайта да диванга ава. Эштә тәмам эт булып, мунчалаланып бетә ул.

— Дальше укырга исәплисеңме, кызым?— ул уку-укымауны кызның үз ихтыярына куйган төсле әйтте. Әмма Фирүзәне җилкәләп булса да укытырга ниятли иде.

— Бер ел эшлим,— диде кыз, әтисе алдында баскан килеш ике кулы белән чәч толымын баш артына төйни-төйни.— Эш стажы белән үтү ышанычлырак. Син миңа җайлы эш табарсың бит.

— И-и, эшнең бер дигәнен табам, кызым...— Әти кеше кызының акылына, аек фикер йөртүенә сокланды. Ничек төпле уй йөртә.

— Быел бәхет сынап карамыйсыңмы соң?

— Ансын уйлармын әле,— дип Фирүзә, әтисенең ятарга әзерләнүен күреп, үз ягына чыкты. Өстәл лампасын яндырып, дәресләренә утырды.

Тартакиев диванга сузылды. Ул иртә ятырга, иртә торырга өйрәнгән. Бүгенге көненең бәхетле тәмамлануына канәгать булып, йокы балына

чума башлады. Өйдә бер туган җан булу нинди рәхәт икән. Китек дөнья тулыланып киткән кебек тоелды. Ни хикмәт, синең дөньяң бервакытта та түгәрәк булып торганы юк. Кай төшедер һаман китек була...

Төн урталары узган иде шикелле, бик каты ишек дөбердәткәнгә Тартакиев уянып китте. Нәрсә бу? Ялгышып дөбердәтәләрме? Бер мәл аңгы-миңге булып торды да ишеккә таба атлады. Ишекнең теге ягында Шакирәнең чәрелдек зәһәр тавышы колак барабанына килеп бәрелде. Тартакиев барысын аңлап, фикерен җыеп өлгерде.

— Мин сиңа ишек ачмыйм! — диде ныклы итеп.

— Гражданин Тартакиев, ишекне ачыгыз! — дигән калын ирләр тавышы ишетелде. Ул боерыклы тавыш иде. Тартакиев утны кабызып, ишекнең келәләрен ычкындырды. Күзе-башы тонган Шакирә артында милиция лейтенанты басып тора иде. Тартакиевкә җиткергәннәр иде инде, бу лейтенант — Шакирәнең йөргән кешесе, ди.

— Син нәрсә хулиганланасың, Тартакиев? — дип тотынды лейтенант киңчә борын тишекләрен кабартып, йөзеннән ачу чаткылары чәчә-чәчә. — Унбиш суткага утырасың киләме әллә? — Аны бик тиз оформить итәрбез!

— Баланы миңа каршы котырта, — дип чәрелдәде Шакирә, әллә нинди пыяла ватылгандагы тешкә тия торган тавыш белән.

— Фирүзә синең белән яшәргә теләми, — диде Тартакиев, тавышын калын чыгарып. Аның калын кашлары җыерылган, йөзе дәһшәтле тартылган. Бер учы белән йөрәк турын ышкыштыра. — Аңа имтиханга әзерләнергә кирәк. Ә син өеңне фәхешханәгә әйләндергәнсең. Оят кирәк әз генә! Балаңа нинди үрнәк күрсәтәсең?

— Ә син аны ачка кибектерерсең. Бер тиен өчен чукына торган кеше бит син! — ди-ди ысылдый Шакирә, сулышына буыла-буыла. — Синең белән бер хатын-кыз да яши алмый. Бер сум бирсәң, шуңа отчет аласың син! Шуңа теге хатының да тормаган! Фирүзә, әйдә!

— Юк, Фирүзәгә дәрес хәзерләргә кирәк, аңлыйсыңмы шуны, җен хатыны! — дип кычкырды Тартакиев. — Мин аны сиңа бирмим!

— Гражданин Тартакиев, тәртипне бозмагыз! Суд кызны әнисендә калдырган. — Милиционер алгарак атлады. Теге яктан Фирүзәнең тузган чәчле тубалдай башы күренде.

— Фирүзә, әйдә! — диде Шакирә тавышын юмакайландырып. Тартакиев кул ишарәләре белән Шакирәне куа иде.

— Яз шуңа протокол, нишләп мәлҗерәдең! — дип кычкырды Шакирә лейтенантка. Тегенең бер дә моңа исе китмәгән кебек иде.

— Сез гаделлек урнаштырырга куелган, ә үзегез гаделсезлеккә булышасыз! — диде Тартакиев лейтенантка төбәп. Әмма ул бу сүзләргә дә битараф калды. Теге яктан сумка тоткан Фирүзә чыкты. Ул әтисенә карады. Тартакиев, «китмә», дигән ым какты. Шулчак Шакирә атылып килде дә кызның кулыннан эләктерде. Ниндидер сүгенү сүзләре әйтә-әйтә кызны өстерәп диярлек алып чыгып китте. Лейтенант зур эш башкарган кыяфәт белән аларга иярде.

Алар киткәч, Тартакиев, диванга утырып, башын ике учына алып, уйга калды. Менә яңа гына түгәрәкләнгән рухын тагын китеп төшерделәр. Рәхәтләнеп бер көн яшәргә дә бирмәделәр! Авызын корт чаккыры! Ни өчен миңа шундый җәза?! Мин риясыз эшлим, үземне кызганмыйм. Ил байлыгын ишәйтүдә үземнән физик өлеш кертәм. Ә миннән көн-төн эшләп тапкан кечкенә генә бәхетемне каерып алалар? Нинди гаебем бар соң минем? Нигә мине болай газаплыйлар. Дөньяңны тир түгеп түгәрәклисең, шунда ук бер почмагын китеп төшерәләр...

Зәй һич уйламаган-көтмәгән җирдән хастаханәгә килеп эләкте. Сөйләсәң, адәм ышанмас хәл. Барысы да бертуган абыйсы Гайса аркасында булды.

Теге, үтерелгән Сәлим абыйсы, чыбык очы гына булса да, бик туган җанлы иде. Ул Зәйне педучилищега урнаштырды. Матди ярдәм күрсәтте. Зәй аңа күңеленнән бик зур бурычлы булып калды. Ә бертуган Гайса абыйсы Әлмәттә өйләнде дә туганлыкны бөтенләй онытты. Хатынның төпсез чоңгылына батты. Хатыны Дөрия бик зәһәр нәрсә булып чыкты. Акны-караны белми мал җыя, Гайсаны ике сменада эшләтә. Үзе дә ике җирдә эшли. Коточкыч комсыз, саран булып киттеләр. Чик-чама белмиләр. Инәйгә бер кап чәй бирмәс өчен пыр тузып талашалар. Гайса хатынына әсир шикелле буйсынган. Аңардан рөхсәтсез борыла да алмый. Гайса вышка-монтажда тракторчы булып эшли иде. Шефка алган колхозга ярдәмгә өч трактор җибәргәннәр. Берсендә — Гайса. Көрт басып киткән басудан фермага трослар белән салам эскертләре тарттырып алып кайтканнар. Рәис килгәч сыйлаган, эш эшләнгәч, тагы өстәгән. Инде ярты төн. Китәргә дип кабиналарга утырганнар. Гайса, алга чыгар өчен, кызурак тизлектә икенче трактор янынннан үтә. Нәкъ шул вакытта тракторчы ни өчендер җиргә сикереп төшә һәм Гайса тракторы трослары эләгәнгә ике аягы да эләгә, икесе дә тубыктан өстән шартлап сына. Шул көнне операция ясаганда үлә. Гайсаны судка куялар. Гайса — райсовет депутаты, утыртмыйлар, мәрхүмнең балаларына түләп торырга ясыйлар. Тик каршы як риза түгел, Гайсаны утыртырга йөриләр. Менә шул чакта Дөрия күз яшен түгә-түгә мәрхүмнең хатынына бара. Күз яшь берни бирми, алтын-көмеш, затлы мехлар белән көйләп, бераз җайга китерә. Хатын йомшап, әнә бурамны житкереп бирегез, дип ычкындыра. Дөрия, Гайса моңа бик сөенәләр. Гайсаның кулы эш белә. Булышырга Зәйгә әйтмәскә булалар. Чөнки күптән түгел генә бик каты кычкырышып, дошманлашканнар иде. Әниләренә ярдәм итмәгәнгә, Дөриянең чамасыз гуҗлыгы аркасында. Ләкин Зәй бәлане ишетеп үзе килде. Эшли башладылар. Гайса сөйләшми. Ике бертуган, әмма аларны арадагы хатын бер-берсенә дошман ясаган. Читен булса да эшлиләр. Менә ишек көчәкләрен утырттылар. Наять кенә булды. Зәй, тәрәзә кәчәгенә үлчәп, борыс кисеп алды. Гайса икенчесен киртләргә кереште. Кинәт артта мылтык шартлаган тавыш ишетелде һәм бер үк вакытта Зәй аягына нәрсә беләндер сукканнарын тойды. Ботын капшап карады, учына кан буялганын күрде. Шунда ук хәле китеп, идәнгә чүмәште... Гайса тәрәзәдән башын тыкты, мылтыгын сындырып, көпшәдән гильзы алып торучы малайны күреп алды. Ул абзарга кача иде. Бишенче класста укучы малай. Котырткannardыр, күрәсең, сиңа берни дә булмый, дигәннәрдер...

Һәр начарның бер уңай ягы да чыга дигәндәй, бу хәлдән соң мәрхүмнең туганнары Гайсаны утырту өчен йөрүдән туктадылар. Үзләренең дә артлары пычранган иде.

Больницага Дөрия килгәли. Бәла аны Зәй белән мөнәсәбәт урнаштырырга мәҗбүр итте. Бәла аңа нык суккан булса кирәк. Болай да эчендәге зәһәре йөзенә чыгып күксел булып йөри торган хатын тәмам чырага калган. Ләкин тышын алыштырса да, эче шул килеш. Эшнең уңайга борылуын, бәланең бетүгә баруын белгәч, ул тагы элеккеге зәһәрлек белән агуын чәчә башлады. Килә дә Зәйләрнең нәселен мыскыл итә-итә сүгә: пешкән шалкан, төшеп калганнар, ди, бәхетсез туганнар. Бәла сезнең башыгыздан гына йөри...

Шайтан алгыры, бөтен планнар җимерелде бит әле! Нишләргә? Моның өчен больничный әз түлиләр. «Бытовая травма» пунктына кертәләр. Ничек производство травмасы итәргә? Йөрсәң булыр иде, әмма кем булышсын. Ә алга планнар шәп иде: Зәй армиядән кайткач та Минзәлә педучилищесына барып, өзелгән укуын торгызды һәм экстренно имтиханнар биреп, диплом алган иде. Ул юл белән китмәде. Фатир өчен, эш хакы яхшы төшкәнгә күрә, буровойга керде. Эшли-эшли аңлады, аның өчен бу авыр йөк иде. Ә сәламәтлеге шәптән түгел. Еш чирли. Бер чире бетсә, икенчесе төртеп чыга. Ахрысы, геналардан киләдер. Әтисе эчкече иде. Андыйлардан таза орлык булмый, диләр. Әмма алга карап

яшәргә кирәк. Укыйсы килеп һәм кара көнгә кирәгер дип, Зәй кыш көне пединститутка заочно укырга керде. Рамилә баланы Казан больницасына алып киткәндә, икесе киңәштеләр. Зәй заочниклар ялын, җай килсә, үзенекен дә алып, Казанга бара. Рамиләләрнең өйләре иркен, шунда рәхәтләнеп бераз торыр... Хәзер бары да бетте, җилгә очты. Күпме сынаганы бар, алдан план корырга һәм аны кемгә булса да әйтергә ярамый. Барыбер чынга ашмый.

Кечкенә генә юанычы бар: яра куркыныч түгел. Мылтык куян ядрәләре белән корылган булган. Шулай да бер сеңерне зарарлаган, аякны бөгеп булмый. Аңа шин куеп бәйләделәр, үзенә култык таяклары тоттырдылар.

Инде тагы бер читен нәрсә: бу хәлне ничек итеп Рамиләгә язарга? Әллә бөтенләй белгертмәскәме? Рамиләне куркытмаска иде. Әйтмәсәң, берәр хәйлә тапсаң, барыбер беленер инде ул. Тик дөресен генә язарга мөмкин түгел. Баланың хәле ничектер бит.

Иллә дә йөрәкне кисеп тора торган хәл: ул да булса, Рамиләнең зиһенсезлеге, мәгънә белмәве. Врачлар ни әйтсә, шуңа тулысы белән ышана ул. Акыллы кеше барын да чынга аламы? Бер врач бер төрле әйтсә, икенче врач шул ук авыруга икенче диагноз куя. Врачлар дәвалап гарипләндергән балалар азмыни?! Һәр очракта ана бик зирәк һәм сизгер булырга тиешле. Үз баласын ана һәр врачтан яхшырак тоярга тиеш. Менә шул нәрсә Рамиләдә юк инде. Килешми торган дарулар биреп, баланың организмына зыян китерерләр.

Әллә шушы килеш Казанга китәргәме? Юк, мөмкин түгел. Рамиләнең туганнарына гарип-гораба булып күренү уңайсыз.

Зәй һавага чыккалый башлады. Соры пижам чалбарының бер балагын кия, икенче балакны җөй эзеннән сүтеп шинга җайлап куя да, әйдә, ике кәстил белән титак-титак. Ишек алды иркен. Бу — Әлмәттәге шифаханә шәһәрчегенең бер почмагы. Өч-дүрт катлы коробка-корпуслар, лаборатория-дәвалану биналары тезелеп киткән. Ихатада шактый күп юкә агачлары, койма кырыйлары буйлап сәрби куаклары күренә. Авырулар һава сулап утырыр өчен түбәле, як-яклары ачык лавкалар, озын эскәмияләр. Савыга башлаганнар өстәлдә чалт-чолт домино сугалар. Зәй койма буендагы аулаграк эскәмиягә барып чүмәште. Хәзер як-ягына күз салырга була. Ихата коймасына терәлеп үк икенче ихатаның биек коймасы сузыла икән. Койма өстенә өч рәт чәнечкеле тимерчыбык җибәрелгән. Нинди «секретный объект» икән бу? Ихата эчендә өч катлы ике бина.

Зәй икенче көнне белде: чәнечкеле тимерчыбык артында психбольница икән. Ычкынган авыруларны, армиягә бармас өчен симуляциягә бирелгән никрутларны шунда китерәләр, ди. Армиягә бармас өчен авыруга сабышу нормаль түгеллекне күрсәтәдер шул. Ник куркалар икән солдатка барудан? Ахмаклар! Армиягә китәргә ашкынып торырга кирәк. Армия дисциплина мәктәбе бит ул. Чын егет кеше армия үтүне үзе өчен дәрәҗә санарга тиеш. Бәлки аларны, Вьетнамга җибәрәләр, дип куркыткannнардыр. Шундый сүзләр йөргән иде.

Кичке аш алдыннан соры халат кигән өч мужик Зәй эскәмиясенең артына чирәмгә килеп утырды. Күчтәнәчкә бер шешә «Неру» килгән, шуны өчкә бүлеп эчә башладылар. Өчесе дә имән муенлы, тазалар, яшь ягыннан кырыктан узганнар кебек. Башларына китте, ахрысы, сүзләре хатын-кыз тирәсендә әйләнә башлады.

— Хатын йокыга бик каты,— диде берсе кет-кет көлгән итеп.— Кочакка алганны да сизми, һаман гыр-гыр...

— Ну инде әйтерсең син, әкият?

— Сораган бар, әллә берни дә сизмисеңме, дип. Юк, сизәм, әзрәк, ди, ләкин уяна алмыйм, ди.

— Бик йончылган буладыр эштә?

— Юк, тегүдә ул, закройщик.

— Үзе шундый тоймастыр ул. Андыйларның холыклары әйбәт була.

— Әйе, дөрес, холкы әйбәт. Салып кайтсаң да, мыгырдамый, игәми. Тыймый...

— Тыючы булмаса, салырга омтылмыйсың да, ә?

— Тыю бит каршы тору теләген уята. Тарихтан укыганым бар: бәрәңгене халыкка мәҗбүр итеп керткәннәр. Ә французлар киресенчә эшләгәннәр. Хөкүмәт бер участокка бәрәңге чәчтергән дә шуңа сакчылар куйган. Сак куелгач, димәк, бу әйбәт нәрсә, һәм кешеләр участоктан бәрәңгене урлый башлаганнар. Урлап табылган әйбер тәмле дә була бит әле... Әнә шулай бернинди мәҗбүрсез таралган бәрәңге...

— Урлап табылган тәмле була дигәннән әйтәм, качырып кына берәр хатын белән якынлык кылсаң, шул нигәдер татлырак тоела, шайтан алгыры!

— Шуңамы, кайбер ирләр чит хатыннар белән шуры-муры килергә омтылалар? Азуданмы, әллә берәр сере бармы?

— Азудан, билгеле. Кайбер хатын үзе аздыра. Әгәр ире бүтәннәргә карый икән, моңа хатын виноват!

— Юк, хатын гаепле түгел, ир-ат үзе!

— Нигә үз хатыны белән генә канәгать булып тормый соң ул?

— Нигә дисеңме? Ир-атның табигате шундый, ахры, аңа төрле «аш» кирәк!

— Әйтмәсәң дә, әнә, төклетураны күзәтеп торганым бар — әллә ничә чәчкәгә куна, бер дә туймый, әллә ничә чәчкәне серкәләндерә.

— Ну, сез ир-атның азуын-тузуын табигать белән акламагыз. Төклетура инстинкт белән генә яши, инстинкт колы. Ә адәм заты аңлы, үз эшенә бәя бирә ала. Шуңа күрә адәм үзенең инстинкт тойгыларын җиңәргә тиеш.

— Җиңә алмасаң, ә? Ансат кына җиңеп булмый бит аны! Һе!

Берсе тагы тозлырак итеп әйтте дә, көлешә-көлешә кузгалып, бинага таба юнәлделәр. Нинди бәндәләр булды болар, дип уйланды Зәй, һәм бертөрле дә нәтиҗә чыгара алмады. Кешеләрнең милли билгеләре бердәйләшеп беткән, ахрысы?

Зәй төнлә күргән төшләренә әһәмият итә башлаган иде. Бары да шул бала турында кайгырудан, борчылудан инде. Бүген нинди төш күрдем соң әле, дип хәтерен җигеп маташты. Ә-ә, бүген үзләренең ишек алды ап-ак кар белән капланган итеп күрде. Ак кар начар булмаска тиеш инде. Моны баланың эшләре терелүгә таба барылган дип юрарга мөмкин. Шулай гына була күрсәче! Бала — бәгырь кисәге, дип юкка гына әйтмиләр икән. Менә бүтен уң күз кабагым тарта. Нәрсә булыр икән. Уң күзем тартса, нниндидер күңелсезлек килә торган иде. Тагы нәрсә булды икән? Мөгаен фатир исемлегеннән артка чигергәннәрдер. Анда астан яшертен генә хәрәкәт бара. Күп эшләр астан качырып эшләнә. Хөкүмәт төп эшләрне кешеләрдән качырып башкара. Ә газета-радиолар — бары халык күзенә төтен җибәрү өчен. Төтен пәрдәсе артында әнә Вьетнамда безнең хисапка сугыш алып баралар. Без, эшчеләр тир түгеп тапкан байлыкны әллә нинди максат өчен исраф итәләр. Ә үзебезнең балаларны дәваларга дару юк, яраны бәйләргә бинт җитми...

Зәй, утыра-утыра арып, эскәмиягә сузылып яткан иде. Күршеләре Зәйгә: менә сезнең Акташ шәһәре турында язганнар, дип, өлкә газетасы тоттырдылар. Ул торып утырды да укый башлады. Карале, бу суд тикшерүчесе Ефимов турында бит! Ничек аны хур итеп язганнар... Ефимов белән соңгы очрашу Зәй күңелендә ачы төер булып калган иде. Эш шунда, Ефимов Сәлим абыйсының «Дело»сы дәлилләр табылмау сәбәпле ябыла, туктатыла, диде. Ничек инде кеше үтерүчене эзләүдән, тикшерүдән туктарга?.. Мин синең хисләрне аңлыйм, дип куйды Ефимов калын тавыш белән, без эзләүдә барча чараларны кулланып бетердек... Әйе, мин сиңа бер версия әйткән идем, абыеңның Беренче белән бергә укулары турында. Ә син, сволочь, шуны тиешле җиргә җиткергәнсең! Шымчы икәнсең син, юха елан! Бар, вон отсюда!.. «Сез ялгышасыз,

Ефимов дәдәй!» — дип кенә әйтә алды Зәй, чөнки аның күзләре тонган, куллары дер-дер килеп өстәлгә бәргәләнәләр иде. Кыяфәте белән берни аңлашырлык түгел. Зәй тиз-тиз чыгып сызу ягын карады.

Ә газетада Ефимовның уллыкка алган малаен ничек итеп колониягә озатуы турында язылган. Ул ятимне Зәйнең дә күргәне булды. Әллә нинди ач күзле иде ул. Чынлап та, тамагын туйдырмаганнар, ди. Ефимовның хатыны бар азык-төлекне бикләп китә икән. Малайга ашарга калдырмый. Ул ач килеш каңгырып йөри. Ефимовның эшләгән җиренә баргалый. Анда да әллә ни таммый. Хатын эш хакын кырып-себереп алып бетерә. Малай өйдән вак-төяк әйберләр чәлдереп саткалый. Аны хатын кыйный. Берсендә малай хатынның алтын йөзеген күпмегәдер ычкындыра. Өйдә тавыш-гауга куба. Ефимов хатын таләбе буенча танышлык белән милиция аша малай өстеннән кәгазьләр әзерли һәм аны колониягә җибәрә... Үзләре тәрбиягә алганнар һәм, комсыз гуҗлыкларына бирелеп, баланы җинаять юлына этәргәннәр. Хәер, бу бернинди җинаять түгел, ә бары гаилә эше генә. Гаиләдә кала торган нәрсә. Ефимов, эш урыныннан файдаланып, шуны җинаять эше итеп күрсәтә. Законлылык, гаделлек сагында тора торган кеше үзе законны үз шәхси мәнфәгате өчен боза... Газета хәбәрчесе Ефимовны бик каты тәнкыйтьләп һәм хурлап яза. Мөгаен, аны урыныннан төшерерләр...

Зәй эскәмиягә шинле аягын җайлап, тагы сузылып ятты. Яра авыртмый, көн тымызык җылы, җан гына тыныч түгел. Җанны нидер кылчык кебек кырып, эчне пошырып тора. Алга ниятләгән хәлләрнең җимерелүеннән, шушындый адәм көлкесенә калудан инде. Моны Рамиләгә язсаң да, барыбер аңламаячак. Уф-уф, уф-у-у-у!.. Ята торгач, ул черем итеп киткән. Якынлашкан аяк тавышына уянып, күзләрен ачты. Кояш офык артына киткән, горизонт буйлап ахак кызыл тасма сузылган иде.

— Әллә Зәй инде? — дигән тавышка ул башын күтәрде. Алдында Алкин басып тора иде. Буй-буй сары сызыклы пижамнан, йөзе бик таушалган, яңакларын дуңгыз шитинасын хәтерләткән саргылт төк каплаган, авыз кырыйларына тирән сызыклар уелган. Тик күзләре генә тере көйри, ясалмарак, егетләрчә булырга тырыша. Ул иң элек тартырга сорады. Папирос, шырпы тоткан бармаклары дерелдиләр иде. Берни әйтмичә, карашын читкәрәк алып, папирос көйрәтте. Сөйләшсә тартуның тәме китәр, дип уйлаган төсле. Берне бетереп, икенче папироска ут элдергәч кенә Алкин Зәйгә таба борылды. Зәйнең чырае-кыяфәте сорау белән тулган иде.

— Мин әнә тегеннән,— диде Алкин чәнечкеле тимерчыбыклы биек коймага ияге белән ымлап.— Психушка. «Смирительная рубашка» дигәнне ишеткәнең бармы? Тар гына бер ящикка кертеп бастыралар һәм сине резин беләкле резин йодрыклар кыйнарга тотына. Нәкъ кеше кыйнаган кебек башка бик каты ора. Чын ычкынган кеше шул резин кулларга каршы сугыша башлый. Ә ычкынмаган адәм моның хикмәтен тиз төшенә һәм чүгәли дә тик кенә тора. Теге резин кыйнаучы сине берни эшләтә алмый. Кешенең ычкынганмы, түгелме икәнен әнә шулай беләләр... Ничек килеп эләктең дисең инде син? Сөйләргә озын, тик әйтмичә дә булмый...— Папиросын тиз-тиз суырып бетерде дә, Алкин яңасын шуңардан кабызды, төпчеген ыргытты.

— Теге атна башында I-поселок клубында нефтьчеләр җыелышы булды. Сөләйнефть белән Акташнефть арасындагы социалистик ярышның барышы һәм эштәге кимчелекләр турында фикер алыштылар. Мин дә чыгып, үз фикерләремне әйттем. Алга барырга комачау итә торган бюрократик киртәләр турында каты гына сүзләр ычкынды. Местком рәисенең тәгәрмәчкә таяк тыга торган эшләрен тездем. Ул, сволочь, контораның иске «Волга»сын списать иттереп, юк кына бәягә горком кешесенә саткан. Тугаев, торып, справка бирде, мин белмәдем, бу эшкә катнашым юк, диде. Холодец президиумда бүртенеп, карасына коелып утырды, ләкин әйткәннәрне кире какмады. Квартира бүлгәндә ясаган

махинацияләреннән бер-ике фактны әйттем. Сәяхны миңа каршы, мине Сәяхка өстерүен үз башымнан кичкәнне сөйләдем. Зал гөж килеп торды. Холодец күпләрнең саруын кайната бит. Әмма өстә тереге бар, берни дә эшләтә алмыйсың. Тик шушы затны горкомга күчерәләр икән, дип сөйлиләр дигәч, зал тагы гөжләп алды. Сөйләү белән мавыкканмын, карасам: Холодец президиумда юк, кай арададыр чыгып сызган... Ярар. Икенче көнне гел таныш түгел эшчеләр килеп, минем кулны кысалар: «Ну шәп әйттең, молодец! — диләр.— Холодецның бераз кикриге шиңәр, бик узынган иде»,— дип, җилкәдән кагалар. Мине сыраханәгә алып кереп, сыйларга тотындылар. Әле берсе килеп минем кружкага йөз грамм сала, әле икенчесе. Шулай шактый гына булган. Өйгә кайтсам, хатын өермә күтәрә. Балаларга сөт, ипи алырга акча юк, ә син лыкынып йөрисең! Фәлән дә, фәсмәтән. Үземнән тиен дә тотмадым дип әйтәм, юк, туктамый. Бер кизәнгән идем, өйдән чыгып чапты...

Мин верандага чыгып, диванга яттым. Төн уртасында ике милиционер, бер врач килеп... Менә шул Холодец тәренең кулы. Ул «теге»ләр белән тыгыз бәйләнгән, шуңа бернидән дә курыкмый...

— Шул тикле үк булыр микән?

— Холодец кулы гына! Хатын аңа жалоба белән барган...

— Холодец бит кай кешеләргә яхшылык та эшли?

— Абруй яулар өчен, показуха гына! Тыштан яхшылык иткән итә, ә астан буйый...

— Дөрес, ул шактый жулик кеше инде,— дип килеште Зәй.

— Үзең жулик дип хак әйтәсең, алайса нигә Холодецка тәлинкә тотасың?

— Тормыш бит, дуңгызга да жизни дип әйтерсең, ди.

— Жуликка елышасың икән, димәк, үзеңдә дә шундый хирыслык бар.— Алкинның тавышында өстен чыгу, җиңүлек чагылып китте. Шушы чалымы аны төрле җәнҗалларга катышырга этәрә иде шикелле. Бу аның шәхесенең нигезендә ята торган бер сыйфат, Алкин аңы белән шуны төшенеп җитмәгән күренә.

— Квартир мәсьәләсендә ярдәм итмәсме дигәннең эше инде,— диде Зәй.— Тормыш жуликның артын яларга мәҗбүр иткәч, нишлим? — Аның тавышы калтыранып килде дә өзелде. Күзләренә ачы яшь тулган иде. Түләнмәгән күз яшьләре! Әмма бик тиз үзен кулга алды. Алкин аның бу халәтенә бөтенләй әһәмият итмәде кебек.

— Без авызга су кабып торган саен жуликлар узына. Безнә санга сукмый, түбәнәйтә. Курыксак, алар канат җәя...

— Менә син кыюланып дөреслекне әйткәнсең, ә нәтиҗә нәрсә?

— Алай төрттерергә ашыкма,— ди-ди Алкин, төтенен авызыннан алка-алка чыгара. Тәмәкедән туя башлады, ахрысы.— Мин дөреслекне халык алдында ачып салдым. Халык ничек шатланды, хуплады. Ярар, соңы минем өчен начар булсын ди. Тик мин артта яралы эттәй шыңшымадым. Менә синең ише дер калтырап, үз астына кәк итеп йөрүчеләр күп булганга безне басымчак итәләр дә. Син итегең ялаган Холодец нишли? Бервакыт гөмбәгә коллектив белән баргач, Соня Валеевна ачылды. Колагыма гына пышылдады. Холодец аңа акча биргән дә әйткән, Алкинны юешләнгәнче эчер дә үзеңдә кундыр, дигән. Ышанасыңмы? Сонядан хәзер сорасаң да танымас. Әнә бит, Холодец хатын белән минем араны тәмам бозар өчен ниләр эшли, жулик! Ә минем, хатын-кыз ачып ятса да, исем китми. Юк! Дөрес, эчемлеккә йомшак ягым бар...

— Шуның аркасында харап итмәсәләр, дим...

— Хәлемә кереп сөйлисең, рәхмәт,— дип куйды Алкин. Кашлары җыерылган, борын яфраклары әллә ничек читләшүле, карашын читкәрәк ала. Хәер, Алкинның күзләреннән, карашыннан берни дә чамалап булмый. Ул импульслы кеше. Кинәт кенә сиңа хәерхаһ һәм дус кебек була һәм шулай ук капылт кына дошмани карый башлый. Бик тиз кызып, әтәчләнеп ала, һәм тиз генә сүрелеп, әйбәт тыныч кешегә әйләнә. Аңарда

Зәй аңлап бетерми торган нәрсәдер бар. Конкрет җентекләсәң, һәр адәмдә аңлашылмый торган нокталарны табарга була... Алкин, уйга калып торды да, әйтте:

— Тугаев сиңа ничек карый? — Үзе карашын ике бармак арасында көйрәүче папиросына төбәгән. Зәй өчен бу көтелмәгән сорау иде, ул аптырап калды, уйларын туплады. Соңгы вакытларда Тугаевның аңа карата үзгәрүен сизә ул. Фатир исемлеген тикшергәндә дә аның чиратын арткарак чигергән, дигән сүзләр колакка керде. Әллә гайбәт, әллә чын, һич белер хәл юк.

— Каян беләсең, бүген болай, иртәгә тегеләй... — диде Зәй икеле-микеле. Бу чыннан да шулай иде, ул алдамый иде. Үзе, нәрсәгә Алкин моның белән кызыксына икән, дип, уйлап куйды.

— Тукта, син ничек бирегә, Әлмәт бульнисына эләктең? — дип бита-раф кына сорап куйды Алкин. Зәй бер-ике сүз белән генә сөйләп бирде. Ләкин тегеanы юньләп тыңламады да шикелле. Ул үз кайгысына чумган, шуның тырнагыннан ычкына алмый төсле иде.

— Син озакламый чыгасыңдыр? — диде Алкин, яңак очында мускул-лар тартышты. Зәй ым какты.

— Мине психушкадан коткару турында Тугаевка әйт! — Алкин ниндидер өметсез хәрәкәт белән төпчегән атты. — Тиешле җиргә шалтыра-тып, мине юлласын. Ә? Хатын ыжламас, беләм.

— Дисеңме? Тугаев шүрләмәсме икән соң? Горкомга алалар дигәч, ул кызыл авызланып китте? Моңа баш тыгармы?

— Холодецны горкомга үткәрмәү аның мәнфәгатендә бит.

— Шул кәрткә уйнамакчы итәсеңме? Ай-һай, Тугаев ул уенга керерме икән? — Зәй Алкинга хәерхаһ булса да, аның хәзерге хәленә бераз ышанып бетмәү аша карый иде. Чөнки Алкинда батырлык, хаклык өчен көрәшүче япмасына төренергә омтылу чалымы бар. Биредә хикмәт бер Холодецны тәнкыйтьләү генә сәбәп булмаска тиеш. Егет барысын да әйтеп бетерми кебек. Аның холык-фигылендә корбан романтикасы да чамалана иде. Шуңа күрә бик ышандырасы килми.

— Син аңа әйтеп кара, — Алкин. — Үзең алынмассың инде?

— Мин — нуль, Тугаевка әйтермен. Ә кем тота сине чыгармыйча?

— Врачлар, сакчы әзмәверләр...

— Син бит нормаль кеше!

— Бар нормаль икәнеңне исбатлап кара! Минем ишеләр байтак. Әнә Бишмунчадан бер укытучы. Мәктәпләрен русчага әйләндергәнгә каршы чыккан. Роно мөдире белән якага-яка килгәннәр. Мөдир ничектер сигнал биргән, моны шунда ук алып киткәннәр.

— Неужели шундый әшәкелек эшлиләр? — Зәй хәзер генә мәсьәләнең катлаулы булуын аңлый башлады. Бу «житейский» гына хәлләр түгел икән. Аның эченнән, өшетеп, салкын бер сызып үтеп китте. Куркуын ничек тә яшерергә маташып, ул чыраена хәерхаһлык нурлары чыгарды.

— Кыйгырма, Назыйр, бер җае чыгар әле! — диде үзенең Алкинны йоларга йөри алмаячагына ачуы килеп һәм үртәлеп. Алкин, шул нәрсәне сизенгән кебек, кулындагы «Беломор» пачкасын куенына яшерде дә кузгалды. Сизсәләр, эш харап, «смирительная»ны кигерерләр... Ул, бөге-лә-сыгыла, тиз-тиз сәрби куаклары арасына кереп китте. Анда үтә торган койма ярыгы бар иде... Алкинны җәлләү хисе Зәйнең йөрәген чеметеп, әчеттереп алды. Күкрәк туры чәнчеп торды. Зәй үзен-үзе тиргәде: нишләргә инде бу йомшак күңел белән? Мәлҗери дә төшә. Хисләр бит бары үзеңне генә ашый. Аларның беркемгә дә файдасы юк. Мин Алкинга ничек ярдәм итә алыйм, ди? Биредә сәясәт катнашкан булырга охшый. Каһәр сәясәт кешеләр арасын боза, кайберәүләрне бәхетсез итә. Мин Алкинны йоларга тавыш куптарып маташсам, өстә моны исәпкә алачаклар һәм миңа фатир мәсьәләсе тагы һавада асылынып калачак. Моңа мин гаеп-лемени? Әй, син куян йөрәк, дип әйтүчеләр булыр. Ләкин минем авыру балам бар, ул бар нәрсәдән кадерле. Миңа таш ыргытырга теләүчеләр әйдә ыргыта бирсеннәр...

Тугаев та бу эшкә катнашмау ягын караячак. Ул бик нык үзгәрде. Элеккеге «демократлыгы», егетлеге юкка чыкты. Башта ул сабыр, ярдәмчел, түзем холыклы иде. Хәзер исә бер сүздән шырпы кебек кабынып китә. Андрей Андреич та моны белә. Ул Тугаевның хәзерге холкын үзенчә шәрехли: Тугаев карьера ярышы агымына эләкте. Ә җинәр, ирешер өчен мөмкинлекләре күп түгел. Эштә уңган, булдыклы булу гына җитми, сәяси капитал да кирәк. Әнә шул ягы сыек. Хатыны Рита исә, бернигә карамыйча, аны дәрәҗә өчен көрәшергә каулый. Каулый гына түгел, хатын-кыз байлыклары белән көне-төне камчылый...

Ниһаять, Зәйнең эшләгән җиреннән килделәр. Конторның местком әһеле Кәкүшев һәм Сәях. Карасана, Сәяхка нормаль кеше кыяфәте кергән ләбаса: муены йомрыланган, яңак-битләренә ит кунган, элек зәңгәр тамырлар тулган була иде. Эчүне ташлау кешене бөтенләй икенче итә шул. Кыяфәтеннән сизелә, аңа хәзер ышанып карыйлар. Бүтәннәрнең сиңа ышануы инде ул бик зур нәрсә. Җанга яшәү канәгатьлеге бирә ул... Кәкүшев конторда күптән түгел пәйда булган кеше. Зәй аны әз белә. Аппаратта эт каешына әйләнгәнлеге сизелә. Авызы-борыны алга чыгып, яңаклары кырт эчкә баткан, шуңа бераз төлкене хәтерләтә. Ләкин үзендә төлке хәйләсе юк кебек.

— Әллә син Вьетнамда булдыңмы? — диде ул кәстилләрне күреп. Үзе кет-кет көлде, юка иренле авызы колакларына җитә язды. — Сине анда, бер тол хатын янына барган икән, малае әнисен көнләп мылтыктан аткан да яралаган, дип мәш киләләр.

— Тычканга үлем, мәчегә көлке, — диде Зәй, кәефе китүен белгертеп. Кәкүшевнең иреннәре колаклары яныннан үз урынына җыелды. Шуннан ул хәл-әхвәлне сорашырга кереште. Сәях та, хәерхаһланып, сүзгә кушылды. Зәй үзенең хәле алга баруын, озакламый чыгарга исәпләвен сөйләде. Шуңа ялгап, больничный мәсьәләсе хөртиерәк, диде. Яра производство травмасына керми икән. Нишләргә?.. Ул Кәкүшевнең кылын тартып карый иде. Сәях та Кәкүшевнең саргылт-көрән йөзенә төбәлгән. Әмма Кәкүшев сүзне икенчегә бора, мәзәк сөйләргә тотына: хирург ашказанына операция ясый. Эш бетте дигәндә генә, авыруның йөзенә иелә дә пышылдый: «Гафу үтенәм, сезнең эчтә пенцитым онытылып калган. Тагын туры килә инде... э-э-э?» «Нишләмәк кирәк соң, — дигән авыру, көчкә-көчкә телен әйләндереп. — Ни, теге, минем корсак тиресенә сәдәфләр генә куеп чыгып булмасмы?» Кәкүшев кыска гына көлеп куйды. Зәй белән Сәях аңа кушылмадылар. Зәй сүзне тагы больничныйга китереп чыгарды. Производство травмасы дип куелса, больничныйга әйбәт түләнә... Әмма Кәкүшев аның сүзләренә нигәдер әһәмият итми. Сүзне бүтән нәрсәгә күчерә. Холодецтан шүрлиме, әллә ярдәмчел түгелме? Юк, Холодецның гаебе булмаска тиеш. Холодец үзе ярдәмчел кеше. Ләкин кешесенә карап булыша. Әллә нинди җайлар таба белә. Аның коерыгын беркем тота алмый. Шунлыктан Холодец халык арасында абруйлы. Аның ярдәмчеллеген риялы, «показ»ной дип әйтүчеләр дә бар. Махинацияләрен белгәннәр аны артында жулик дип атыйлар. Ләкин жулик диючеләр дә, тормыш кыскач, аңа килеп йөз суы түгәләр.

Зәй бер сүз арасында Назыйрны искә төшерде:

— Алкин әнә теге чәнечкеле тимерчыбык эчендә, психушкада. Аны йолып алырга иде. Тугаев белән сөйләшеп карамассыңмы? Ә?

— Тартар теленнән табар, ди. Начальникларның саруын бик кайната иде, — дип куйды Сәях.

— Син нәрсә, Сәях? — диде бик аптыраган чырай белән Зәй. — Нигә Алкинны өнәмисең? Ул бит хаклык өчен көрәшә?

— Тешли торган эткә йә сөяк, йә таяк, ди.

— Үзеңне дә месткомда тикшергәндә ничә тапкыр яклады, ә син аны яратмыйсың. Ничек аңларга моны?

— Алкин артык күп белә, — диде Кәкүшев. — Тавыкның әтәч булып кычкыруы, җитәкчеләргә, әлбәттә, ошамый.

— Тәнкыйть иткән өчен психушкага ябу кебек килеп чыга түгелме?

— Санчастька хатыны шалтыраткан, диләр.— Кәкүшев ничектер моңардан читләшергә теләгән төстә әйтте. Әллә шуңа сүзләре ышандырмый иде.

— Нишләп хатыны булсын?— дип шикләнде Зәй.

— Һәй, аның хатыны явыз,— диде Сәях.— Алкинның әйткәне бар, мине хатын төрмәгә утыртырга тели дип...— Ул өметсез кыяфәттә кулын селтәде. Зәй тагы аптырашта калды. Алкин аңа, мине бирегә кертүдә Холодец кулы уйнады, дип елаган иде. Юк, бу хакта Кәкүшевкә сүз ычкындырырга ярамас... Зәй, эчтән шулай уйлап алды да, әйтмәде. Алкинны жәлләде, аны йолып алу хакында тагы Кәкүшевкә сүз катты. Ул безнең эшче, ә тәнкыйть кирәк нәрсә, шунсыз алга барып булмый бит, диде. Иптәшебезгә авыр вакытта ярдәм кулы сузарга бурычлыбыз...

— Аны Холодец юллап йөри башлады инде,— диде Кәкүшев.— Горкомга чылтыратты...

— Чынлапмы?— Зәй әнә гаҗәпләнде.— Һай, Виктор Михайлович, ә?

— Мине дә милициядән коткарганы бар аның,— дип куәтләде Сәях.

Алар тынып, уйланып калдылар. Аннары Сәях буровойдагы бер хәлне сөйләп торды... Сменаны кабул итеп алдык, мин тормозда. Маклаков белән чуваш Тачиван булышалар, насосны, изменә кайгырталар. Забой мең дүрт йөз метрда. Су белән бораулыйбыз. Кул белән тоям, забойда нидер булды, турбабур калтырый, әллә берәр клапаны тыгылдымы? Уйларга өлгермәдем, насос эчәгесеннән нечкә агынты фантаны китереп бәрде. Әгәр миңа тисә, кисә иде. Што син, 72 атмосфер! Тачиван насосны сүндерде. Колоннаны күтәрәбез. Әмма кыскан, бирми, ярый әле Тартакиев килеп җитте. Барыбызны куып чыгарды да, дизельләрне соңгы көченә эшләтеп, суыртып маташты. Юк, булмый гына. Шуннан бер фляга химик көчле реагент ясап салдык. Аның токымга тәэсир итүен бераз көтәргә кирәк. План яна. Тартакиев читлеккә ябылган арыслан кебек әрле-бирле йөренә. Борчыла. Өстәвенә геология лабораториясе өчен токым аласы бар. Аерым долото белән. Әнә ул, крокодил башы кебек, идәндә тешен ыржайтып ята. Ике шорошкасы кырылып төшкән. Тартакиев лом алды да бүтән шорошкаларны да ватты. Юкса, ремонтка алмыйлар, шуның белән эшләргә кушалар. Бүген яңа долото китерергә тиешләр, диде. Ул моны алга исәпләп эшләгән икән. Чөнки токым алу белән мәшәләнсәк, план бөтенләй яначак. Безгә теләсә нинди юл белән проходка гына булсын. Акча да, премия дә шуңардан. Токым алу безгә шул тикле комачау итә, Тартакиев тиредән чыгарлык булып ачулана. Безгә аны Тугаевның өстәгеләргә ярарга тырышуы аркасында гына тактылар, ди. Имеш, ул булдыклы, гуманлы директор. Очкосы аңа була, ә без шуның өчен көне-төне җәфа чик! Анасын сатыйм!.. Реагентның файдасы тиде: Тартакиев бик зур осталык белән долотоны суырып алырга ирешә. Колоннаны күтәрдек. Күтәрү илле алты операция. Яңа долото борып, колоннаны төшерәбез. Сәгать унберләр, вакыт күп узды. Тартакиев тагы нервылана, кабалана. Шул мәл күперчектә Байкинның күзлекле йөзе күренде. Тартакиев кәефсезлеген белгертеп аяк кагып кына исәнләште. Токым алып булмады, долото «прихват»ка эләкте, ватылды, диде. Аягы белән төртеп күрсәтте. «Яңа долото алып килергә тиеш идең, булдымы?»— дип сорады. Байкин, юк дип, баш селкеде һәм кинәт йөзе бүртенде, авыз кырыйларына ачу сызыклары чыкты. Ватык долотоны иелеп, җентекләп карады.

— Ничек, токым бер дә алмадыгызмыни?— Байкин мастерга якын ук килде. Ул Тартакиевнең нindидер хәйләсен фаш итәргә җыенган төсле иде.

— Әйтәм бит, аварияга юлыктык дип...

— Син, гадәтенчә, нәрсәдер бөгештерәсең?!— Байкинның иреннәре дер-дер селкенгәли иде. Нык борчылганы күренә. Тартакиев шиттагы шкафтан буровой журналын алды, аңа кыстырган геологик картаны

тартып чыгарды һәм Байкин каршына китереп битләрен ачып суз-ды.

— Менә бу сезнең эш — тоташ халтура! — диде каты гына. — Без кичә ике «прихват»ка, ике «убылу»га очрадык. Кая алар? Бу карта безгә күз, кисәтү булырга тиеш. Ә карта үзе сукыр. Аңа берни төшерелмәгән. Без сукыр килеш капкынга барып эләгәбез! Мәтәштерәсең, имеш! Без эш эшлибез, ә сез чабата кайтарып, акча алып ятасыз! — Тартакиев картаны бөкләп урынына ташлады.

— Син боларны миңа үч итеп эшлисең, — диде Байкин, мастерның сүзләренә туры җавaптан качып. — Сизәм мин, кемдер миңа этлек эшләргә котырта сине! Әйе, әйе! Теге вакытта да шулай булды, безне күп интектердең. Син шул вакытта җаныңны иблискә саткан идең. Иблис диктовкасы белән Платон Никитичны соңгы чиккә җиткердең. Хәзер дә...

— Юк, мин синең белән сөйләшмим! — дип Тартакиев китә башлады, ләкин Байкин аны җиңеннән тотып туктатты. Тартакиев, кинаяле ачы елмайган рәвештә йөзен җыерып, тыңлап тора башлады. Ярар, тормыш механизмын белмәүче бу адәм белән нишлисең инде, дигән төсле иде.

— Элеккегечә сиңа бар нәрсә рөхсәт ителә дип уйлама, хәзер замана башка. Беләбез, иманын иблискә закладка салганнар үзләрен дөнья кендеге итеп тоталар. Ләкин әүвәлге замашкаларыңны ташла! Иблискә дә чара табарлар! Син Платон Никитичның башына җиттең, берни булмады, әмма минем баш белән шаярма!

— Синең башың арт сөртергә дә кирәк түгел, Байкин! Без эш турында сөйләшәбез, ә син әллә нәрсәләр фантазировать итәсең... — Тартакиев як-ягына каранып алды, безгә эшләгез, дип ым какты һәм, Байкинга иелә биреп, сүзен дәвам итте.

— Мин дә беләм сине, син аристократ, ялкау-хөрәсән, эшеңне булдыра алмыйсың, шуны сүзләр, демагогия белән капларга азапланасың. Янәсе син честный, гаделлекле...

— Син намуссыз, ертлач, бер тамчы гаделлек юк синдә! — диде Байкин, карлыккан тавыш белән кычкыра биреп.

— Ну, син намуслы, ди, әйтик. Нигә син намуслы булгач, үзеңнең бурычыңны үтәмисең? Эшеңне эшләмисең, халтура белән шөгыльләнәсең? — Тартакиевның йөзенә җиңүле кинаяя сызыклары чыкты.

— Кешеләрне ничек тә түбәнәйтү — синең яратканың шул!

Тартакиев, аның сүзләрен ишетмәгәндәй, үзенекен тукыды.

— Кая эшең? Эш күрсәт! Миңа синең намусың нәрсәгә? Намус проходка бирми! Бездән көн дә проходка таләп итәләр! Намус түгел!

— Барча эшең хәрәмләшүгә көйләнгән, алдау-йолдау белән бара, чөнки синең намусың юк! — Байкин кызганыч, көчсез төстә ысылдый иде.

— Ялкауның намусы тизәк ул! — дип Тартакиев кискен итеп кул селтәде дә күперчек буйлап китеп барды...

Иптәшләре киткәч, Зәй тагы уйга калды. Ничек булып чыга соң? Холодец Алкинны юллап йөри башлаган, имеш. Алкин исә психушкага эләгүен аңардан гына күрә? Хәлләр нинди тиз үзгәрә һәм шуңа карап кешеләр дә бүтәнгә әйләнә.

Парторг Уралов командировкага китте. Шул тикле дә шатланыр икән! Хәер, аңлашыла, хатыны бик усал нәрсә. Ураловны тота да яңаклый. Тугаев, үзе күрмәсә, ышанмас иде. Уралов ничектер киңәшмәдән әбәдкә аны үзләренә алып керде. Хатыны өйдә иде, карасына коелып каршылады. Шулай да чәй әзерләде. Колбаса белән бәрәңге кыздырган. Дымык кына әбәтләп утырганда, хатын Ураловныңниндидер сүзенә бәйләнде. Элгәләшеп киттеләр. Хатын сикереп торды да иренең яңакларына чалт-чолт сугып алды һәм теге якка кереп китте. Ә Уралов исәрләрчә көләргә тотынды. Кулларын чәбәкли-чәбәкли көлә... Мин булсам ачуланыр идем, дип уйлады Тугаев. Ә Уралов көлә, характеры нинди шәп икән, дип аңа сокланды ул.

Ураловтан башка эш, мәшәкать бермә-бер күбәйде. Партбюро әгъзасы икәнсең, син барсын да башкарырга тиешсең. Партия функциясендә формализм бик көчле. Иң теңкәгә тигәне — горкомга чакыралар. Кай көнне икешәр мәртәбә. Карышу мөмкин түгел, ул төп штаб, стратегия һәм тактика шунда эшләнә. Һәр эшкә, хәлгә, вакыйгага, кешеләргә бәя бирелә.

Менә Тугаев калын ырмаулы күзлек кигән идеология мөдире каршында утыра. Мөдирнең чырае рәсми-кырыс, шул рәсмилектән бер тамчы да читкә чыкмый ул.

— Холодец моннан ике ай элек командировкага барган иде,— дип, Тугаев контора хәлләрен бәян итә башлый.— Әйе, кунакханәдә эчеп-исереп скандал чыгарган, кулын озайткан. Милициядән язу килде. Җыелышка куймакчы булабыз?..

— Юк, җыелышка куймагыз,— диде мөдир исе китмәүчән төстә.— Мин үзем аның белән сөйләшермен.

— Милициягә ничек җавап язарга?

— Чара күрелде, дип.

— Нигә Холодецка карата шундый ташлама?

— Аның пычрак якларын әлегә чыгармыйбыз. Әгәр ул безнең сүзне тотмый башласа, без аңа начар эшләрен ачып күрсәтербез! Хәзергә йомыгыз!

— Холодецның милициягә эләгүе турында сүз халыкка таралып өлгергән.

— Барысы да гайбәт сүз дияргә!

— Фактны юкка чыгарабызмыни?

— Бу хакта сорамыйлар. Үзең аңларга тиеш.

— Ярар, бер факт ялганга чыгарылды. Хуш, аннары: без буровой дизелисты Камаловка квартира бирергә булган идек, сез аны исемлектән сызгансыз? Хатыны, баласы авырулар?..

— Ул безнең кеше түгел. Аннары теле озын. Өстәгеләргә карата чәнечкеле сүзләр әйтә. Горкомны джунгли дип атый. Юк, бераз акылга утырсын әле...

— Соң, «Маугли»не карап әйтәдер, юмор белән. Анда да джунглинең үз власте, үз хөкеме турында сөйләнә шикелле.

— Ни булса да, үз авызыннан чыккан сүзгә үзе җавап бирергә тиеш!

— Положениесе авыр, бер сүз өчен инде?.. Ну, ярар, ә Халитованы фатир исемлегеннән нигә төшердегез?

— Русларны яратмый, аларга каршы сүз озайта!

— Барактагы күршесе исерек урыс аны төрлечә мыскыл итә. Шул кешегә җирәнеп каравын русларны өнәмәү дип бәяләргәме?

— Без рус халкына хөрмәт белән карарга тиешбез. Әгәр руслар булмаса, татарлар бер-берсе белән суешып бетәрләр иде...— Мөдир боларны әйткәндә тагы да җитдиләнгән кебек булды. Тугаев ни дияргә белми аптырап калды. Башында зиһене чуалды. Неужели татарлар шундыйлар икән? Әллә мине сынар өчен юри әйтәме? Горкомда һәрвакыт сыныйлар. Адым саен, һәр сүзеңне кырык бизмәнгә салалар. Биредә шундый атмосфера тудырылган.

— Беренче кварталда бурильщик Фаизов проходкадан рекорд куйган иде. Шул хакта үзебезнең газетага, өлкәнекенә дә зарисовка бирергә кирәк дип уйлыйбыз?— диде Тугаев бик өметләнгән төстә һәм мөдиргә төбәлде.

— Юк, ярамый,— дип, мөдир бераз уңайсызланып, өстәлендәге язу приборларын рәтләргә керește.— Чөнки ул милли хисен бетермәгән...

— Ә Гайнанов?

— Ул да безгә скептик карый.

— Кемне тәкъдим итәсез соң?

— Буровой эшчесе Кафуров турында язарга кирәк...

— Аны бит теге ни... бик әләкче, тегендә барып барысын да сата, дип сөйлиләр? Мораль яктан да: әтисен үзенең квартирына кертмәгән...

— Ансы аның шәхси эше. Без аңа катнашмыйбыз. Ул безне өни, русларны да ярата...

— Сәер, димәк, булган фактны юк дип, чын түгел дип әйтәбез, ә Кафуров очрагында, булмаганны, ялганны чын, бар дип бәялибез?— Тугаев бу сүзләрне әйткәндә мөдирнең күз аклары тәгәрәште, чыраена кара дәһшәт чыкты.

— Син минем телгә басма, горком ничек куша, шулай эшлә! Юкса...— Аның муен тирәсе хәтәр селкенде. Тугаев ялгыш сүз ычкындыруына гафу үтенде! Шуның белән сүз беткән кебек булды. Мөдир Тугаевны җибәрде.

Чыгу белән Тугаев «уф» дип куйды. Әле генә сөйләнгән нәрсәләр аның башына сыймый сыман иде. Хәер, ул мондый механизмны күптән белә. Үзе дә система механизмында эшләде. Гаҗәпләнерлек берни дә юк. Ләкин съездан соң механизм яхшы якка үзгәргәндер, дип уйлап йөри иде. Баксаң, бар нәрсә дә нәкъ элеккегечә икән... Уф! Дөнья без дигәнчә генә бармый шул...

## VIII

Андрей Казан бүлеккә килгән сигналларны тикшерергә Акташ шәһәренең поселокларына барды. Һәрбер яңа шәһәрдә башта поселоклар төзелә. Беренче поселокта яшьләрне никахлаштыру белән шөгыльләнгән мулланы табып сөйләште. Баракта никах укытып гаилә корган кыз белән егет янына кереп чыкты. Иске Писмән поселогында подпольный поп балаларны чукындырып ята икән, ләкин аны очрата алмады. Әллә чынлап та идән астына качкан?

Ул кайтып кергәндә апасы өйдә иде. Чәй хәстәрләп йөри. Андрей ал якта өс-башын алыштырды да тизрәк кухняга ашыкты. Алар апалы-энеле һәр эшне бергәләп башкарырга тырышалар иде. Андрей кайчак керләрне дә үзе чиләктә кайнатып уа, чөнки апасы мыгырдана, йөзенә нәфрәт чыгара. Ул моны максат белән эшли. Андрейны, өйләнеп үз тормышыңны корырга вакыт, дигән уйга китермәкче була. Аны күзле-башлы итәсе килә. Белгән хатын-кызлар да димләп карады. Тик Андрейның берсенә дә күңеле ятмый. Җанында нәрсәдер үлгән, беткән. Барысына да шул әшәке зиндан гаепле. Ул беркемгә дә ышана алмый! Бу мәсьәләгә тормыштагы башка ваклыклар килеп кушыла һәм апа белән эне арасыннан кара мәче дә узгалый. Апасы эндәшми-сөйләшми йөри. Өйдәге бу тынлык җанга аеруча авыр булып төшә.

Өстәлгә таба белән көнбагыш маенда кыздырылган бәрәңге, ипи, суган турап куйдылар. Яшел чәйнек тимер челтәр түгәрәк өстенә менеп утырды. Ипи белән бәрәңге капкаларга керештеләр. Башта сүз һәрвакыттагыча ашамлык әйберләренең хакы турында барды. Узган атнада базарга ит бик күп кергән. Бөгелмә тирәсендә бүтән шәһәрләр юк, шуңа бирәдә ит юнь була. Өстәвенә, бойний да эч-баш чыгара. Аңа чират була булуын, шулай да кайчак сиңа да тиеп куя.

Анна сүзне янә гаилә тормышына, ир-атка хатын җәмгате кирәклегенә иләп кенә китереп чыгарды.

— Әгәр өйләнсәм, синең белән минем арага кеше керә,— диде Андрей, чынаяк чокырларына чәй агызып.— Хатын ягына авышырмын, дип куркам. Юкка гына хатыннарны юха димиләр. Ул безне дошманлаштырыр. Син шуны телисеңмени?

— Әллә берәр апа белән эненең дус яшәгәнен күргәнең бармы? Без болай да... Ә ир һәм хатын бер-берсен хөрмәт итеп, дус яши ала. Чөнки аларны балалар бәйли.

— Гауглашып яшәгәне дә җитәрлек.

— Болай безнең нәсел корый,— диде Анна, энесенә житди карап.— Ә Ленинградтагы малаең әнисе фамилиясен йөртә. Синең малаймы соң ул?

— Минекедер инде, миннән алимент алып торгач...— дип, Андрей сүзне икенче эзгә төшерәсе итте. Акташтан яңа җиләк вареньесы алып кайткан иде, шуны ачып, апасы алдына куйды. Элеккеге гаилә, малай темасына керәсе килми, анда тоташ җәрәхәтләр. Тирән чи яралар әле дә җанны борчып, әрнетеп торалар иде.

— Быел җиләк-җимеш елы, иген уңышы зур булмас, диләр картлар,— ди-ди, Анна, калак белән варенье капкалап, чәй эчәргә тотынды. Җыерчыклары булса да, беленмәгән түгәрәк тулы битенә һәм соры җете күзләренә канәгатьлек нурлары чыкты. Сүз, бүтән нәрсәгә күчеп, дәвам итте. Аннары тагы үзеннән-үзе элеккеге эзенә килеп төште. Анна хатын-кызга ир-атсыз берни түгел, диде киң маңгаена төшкән салам төсле эре бөртекле чәч чылгыен артка сыпырып. Ә ир-атка хатын-кыздан башка бик яман. Физиологик яктан алганда да...

— Өйләнеп бередә калудан куркам,— диде Андрей, бик саллы сәбәп белән апасын сүзсез итмәкче булып. Әмма апасының иреннәре кинaя белән бөгелгәләнде.

— Һаман иллюзиядән арына алмыйсың, ә?— дип куйды төртмәле тон белән.— Китапны күп укыйсың. Әйе. Әти әйтә торган иде, Россиядә революция китапны күп укудан килеп чыкты, дип. Китапта идеал тормыш сурәтләнә. Ә гамәл кырыс, рәхимсез. Художество әсәрләре кешене адаштыралар гына... Кайтырга тагы отказ килде бит.

— Менә син кайтып урнашсаң, миңа да Ленинградка рөхсәт итәрләр...

— Бу астма белән анда бик тиз ычкынырмын. Мине вакытыннан алда җиргә күммәкче буласыңмы?— Аннаның йөзе житдиләнеп китте, битләреннән ачуы килә башлау шәүләсе узды.

— Ну, Анна, нәрсәгә борасың? Анда зур белгечләр, чит ил дарулары...

— Бередәге кояшлы тау һавасын берни дә алыштыра алмый. Өченче ел Ленинградтан ничек кайтып егылганымны күрдең бит. Ун көнгә дә чыдый алмадым, буылып үлә яздым. Юк, юк, кайту турында миңа бүтән әйтмә!— Аннаның карары нык һәм кире чигенмәслек төстә яңгырады. Андрей исә бу ныклыкның сәбәпләре ни дип уйлый: Анна бер хатыны өметсез авыру бик яхшы кеше белән таныш, әллә шуңа исәп тотамы? Белмәссең кеше йөрәгендә нәрсә ятканын...

Аннага туган шәһәре Ленинградка кайтырга рөхсәт итәләр. Дөрес, башта өч-дүрт ел коммуналкада интегергә туры киләчәк. Алар яшәгән йорттан кирпеч өемнәре генә калган икән. Әмма рөхсәт булса да, Анна анда кайта алмый, сәламәтлегем кыйбат, ди. Ә Андрейдан һаман Гулаг клеймәсе алынмаган, Ленинградка пропискага кертмиләр. Шулай да ул һаман туган шәһәренә омтыла. Анда гомер юлы да бүтән эздән агып китәр төсле тоела иде.

Андрейның уйлары бүтәнгә күчте. Ул, Акташта күргән яңалыкны Аннага сөйләргәме, юкмы, дип уйлана иде. Анда аяктан егарлык хәл кичерде бит. Һаман моңа тулысы белән ышанып житә алмый әле. Әмма күз хәтере аны алдамады шикелле. Эш шунда, Андрей төрмәдә үзен кыйнаган, сорау алганда сугып беләгеи имгәткән тикшерүче кешене очратты һәм танып калды. Аның исем-фамилиясе — Холодец Виктор Михайлович. Бу адәм Андрейның һәр күзәнәгенә кереп, пичәтләнеп сеңгән. Очраткач, Андрей чак исен җуймый калды, бик каты итеп баш миенә суккандай хис итте. Күп уйланып йөрде, хәзер бу хакта Аннага белгертми ярамавын аңлады. Һәм бер-ике сүз белән сөйләп бирде.

— Кит инде! Әллә күзеңә генә күрендеме?— дип, Аннаның күзләре аларып маңгаена менде, гаҗәпләнүдән кашыгын өстәлгә куеп, энесенә төбәлде.

— Юк, өченче тапкыр очратуым,— диде Андрей ныклы итеп.— Башта үзем дә ышанмадым, зиһенем чуаладыр, дип шикләндем. Хәзер төгәл ул икәнен белдем...

— Әйе, аңлашыла,— дип куйды Анна моңсуланып.— Яңа җиргә төрле әтрәк-әләмне тутыралар. Сөйләделәр, авылда элек түрә булып, кешеләрне эзәрлекләгән, таш капчыкка утырткан бәндәләрне шәһәргә качыралар икән... Шәһәрдә бит кешеләр бер-берсен яхшы белмиләр...

— Органнар үз палачларын ким-хур итми...— Андрей, өметен өзгән төскә кереп, тирән уфтанды. Кашыгын куйды да өстәл артыннан кузгалды һәм идән буенча йөренергә тотынды.

— Эчемдә үртәлү, үч ачысы, нишләргә?— диде ул, башына җиз энәләр тезеп чыккандай күренгән эре бөртек чәчләрен сыпырып.— Әллә милициягә язып бирергәме?

— Дурак, дурак,— дип кулын селтәде Анна ачуы килеп.— Үзеңне тагы харап иттерәсең киләмени? Карга күзен карга чукымый...

— Заман үзгәрде бит, так что...

— Тышкы яктан гына, косметика бары. Эчке яктан бөтенесе элеккечә калды. Һе! Һаман акыл керми диген, ә? Әнә Мәскәүдә журналист хатынкызны кулга алганнар. Чехословакларны яклап язган, ди.

— Әйе, «Голос» тапшырган иде. Соң, нишләргә? Бер яңагына суксалар, икенчесен куяргамы?

— Иң хәвефсезе шул. Артыңны кысып кына утыр. Үзеңә тимиләр икән, шыбырдама!

— Юк, Алмаз Борисович белән киңәшеп карарга кирәк. Кеше үзе кылган әшәкелекләре өчен җавап тотарга тиеш!

— Һаман да шул идиотизмың тышка бәреп чыга. Булырсың икән! Алмаз Борисович соңгы вакытларда үзеңнән качып йөри. Ахмак түгел ул синең эшләреңә катнашырга?

— Әйе, соңгы вакытларда Алмаз карьера комарына йотылды,— дип куйды Андрей йомшак итеп. Кешене артында яманлаудан ул бик сагая иде.

— Яхшы адәм белән палачны аерып булмый хәзер, төшенәсеңме?— диде Анна, энесенең иллюзияләр тырнагыннан ычкына алмавына рәнҗегәндәй тавыш белән.— Палачның да кемгәдер яхшылык эшләве мөмкин. Яхшы адәмнең исә кайвакыт начар эш кылуы ихтимал...— Анна торып, портфеленә дәреслекләр, әсбаплар тутыра башлады. Эшенә соңга калуы ихтимал иде.

— Үзем җыештырырмын, юармын,— диде Андрей, аның сәгатенә еш-еш карап алгалавын күреп. Ул, шырпы газета кисәге тотып, ваннадагы титанны кабызырга кереп китте. Анна исә, элгечтән плащын эләктереп, ишеккә ашыкты.

Табак-савытларны юганда Андрейның уйлары шул Холодец дигән бәндә тирәсендә бөтерелде. Нинди җылы җирне тапкан, иблис! Яхшы фатирда яшидер, әйбәт урын билидер. Ләкин ничек итеп аңа үземнең барлыгымны белдерергә? Кылган әшәкелекләрен исенә төшерсен иде, сволочь! Әмма моңардан ни мәгънә? Мин бит аны берни эшләтә алмыйм? Өстеннән язып бирсәң дә, аңа бернинди чара күрмәячәкләр. Менә шулай явызлыкка җәза бирелми. Җәмгыять өчен бу коточкыч нәрсә, бу хәл аны эчтән җимерә. Ник дисәң, җәмгыятьтә һәр нәрсә бер-берсенә бәйләнгән, тоташ савыт кебек...

Шул мәлдә ишек шакыдылар. Рая икән, яктырып, мөлаем елмаяелмая керә, алгы тешләренең алтынлы булуы йөзен тагы да матурайта шикелле иде. Ул китапханәдә эшли, Андрейга сораган китапларын китерә килгән. Дефицит. Андыйларны Андрейга бирмиләр, Рая үземә дип яздырып ала да яшереп кенә китерә. Юл өсте, кертеп чыгыйм, дидем дип, Рая нигәдер аклана. Андрей бер-бер нәрсәдә шикләнмәсен дигәндәй итә. Чөнки Андрейның четерекле холык-фигылен чамалап алган, күрәсең... Андрей хатынны үз ягына алып чыгып, диванга утыртты.

Рая китапларны сумкасыннан бушатты. Менә бәйрәм! Андрей, заем откан шикелле, шатлыгын эчтән тыя-тыя китапларның әле берсен, әле икенчесен ачып карый. Ләкин иң кирәкле китаплар булмаган икән. Андрейның эчке шатлыгы бетә, йөзенә гадәттәге моңсулыгы чыга. Шулай да сер бирмәс өчен елмая, Раяга шаян сүзләр әйтә, көлдерә. Кулын тотып, шаярып, үзенә таба тарта, китапларны читкә алып куеп, янына ук шуыша. Рая (ул татар хатыны Рәхилә, исемен руслар әйтергә җайсыз булганга шулай йөртә) бик аппетитны кузгата торган хатын, күкрәкләре тыгыз булып төртәйгәннәр, тар юбкасы юан ботларының зиһенне таратырлык йомры, тазалыгын белгертеп тора. Андрей учын хатынның биленнән шудырды һәм, әллә шуңардан тамырларында каны кайнаранып, тәне буйлап йөгерә башлады. Ниндидер эчке дәрте кузгалды, дулкындай тышка чыгарга омтылып, баш мие тамырларына суккалый иде. Раяны үзенә таба тарта, ботларына үрелә, хатын чырык-чырык көлә дә көлә, гүя кытыгы килгәннән шулай итә. Андрей кыюрак хәрәкәт ясады. Рая торып басты, Андрейның кулларын читкә этәрә, үзе юньләп каршылык күрсәтми. Каяндыр Аннаның яраткан эте Тимка килеп җитте, Раяның аягын тешләргә борынын сузды. Рая, курыкмаса да, кыланып ах иткән булды. Андрей, кызышкан халәттә, белештермичә Тимкага каты гына тибеп җибәрде. Тимка чинап туп шикелле идән буйлап тәгәрәде. Ул торып, тагы чиный-чиный диванга таба ыргылды, Андрей тагы тибеп очырды. Үзе һаман Раяны диванга екмакчы булып тырыша. Рая юри бирешми, һаман шыркылдый. «Татар көрәше», ди-ди, үзе дә шаярта иде. Тимка, әллә хуҗасына ярдәм итәм дип белеп, һаман Раяның аягын тешләргә ыргыла. «Этеңне тый!» — диде Рая. Шуннан соң гына Андрей Тимканы тотып алды да ваннага ябып куйды. Ул борылып килгәндә Рая китәргә җыенгандай сумкасын карый иде. Андрей аның биленнән кысып тотты да диванга екты. Бу юлы хатын каршылык та күрсәтмәде. Аның гадәте — башта карышкан булып, үзенең очсыз түгеллеген расларга тырышу иде. Раяның шоколад төсле ботлары Андрейның барча түземен бетерде...

Аннары алар бераз тын гына яттылар һәм бераздан торып утырдылар. Рая тиз-тиз төзәтенде. Ашыгыч эше барлыгын әйтеп, сумкасын кулына алды. Ул нигәдер бик боегып, нәүмизләнеп калган иде. Андрей аның хәлен сорашып тормады, ихтыярсыз гына елмайган итеп һәм шуның белән рәхмәтен белдереп, ишектән озатып калды.

Аны кинәт нигәдер тирән бер эч пошу биләп алды. Җанын сулыксулык китереп, эче поша башлады. Күкрәк турын тыгызлап авырттыра. Баш исә кургаш коеп тутыргандай авырайган. Түмәргә әйләнгән. Бер фикер чагылып китәргә дә чама калмаган. Нишләп бу болай? Хатын-кыз белән якынлык кылгач, рәхәтлек тоялар, ә минем нигәдер эчем пошарга тотына? Ярату булмагангамы? Мин ярата алмыйм, ахрысы? Шул зиндан касәфәте инде? Әмма эчтәге дәрт үзенекен таләп итә. Яратасыңмы, яратмыйсыңмы, аңа барыбер. Ул эчке таләп аңга да буйсынмый, ярату, яратмавыңны уйлап маташмый. Аңа бары җенси якынлык булсын. Ярату әллә хыялыйлар тарафыннан уйлап чыгарылган бер нәрсәме? Юк, кайбер кешеләрдә ярату хисе бар һәм көчле булырга тиеш.

Ул, эче пошуын берничек тә җиңә алмагач, үзенең өстәле артына килеп утырды, эш кәгазьләрен актарырга керешә. Башкарган эшләре турында бүлек мөдиренә кыскача гына отчет язып бирергә тиеш иде.

Иске Писмәндә ул балаларны яшерен генә чукындыру белән шөгыльләнүче бер рус карты янында булды. Өстеннән сигнал килгән иде. Карт совхозда төнге каравылда тора икән. Көндезләрен буш. Зур гына алты почмаклы өйнең кече ягында онысы белән икесе утыралар иде. Онысы өстәл башында дәрес әзерли, карт күзлеген киеп газета укый. Инспекторның тикшерергә килгәненә бер дә исе китмәде. «Әллә рөхсәте бармы?» — дип икеләнде Андрей. Һәм ипле генә, ачу китермәслек итеп сорады:

— Кем рөхсәт итте?

Карт, газетын куймыйча гына, күзлеге өстеннән Андрейга кызыксынып карады. Аның нинди зат булуын чамаларга теләде һәм үзенчә ниндидер фикергә килгән төстә:

— Алла рөхсәт итте,— диде һәм, бу җавап Андрейда нинди тәэсир тудырыр дигән төсле, күзен алмый текәлеп катты. Ансат җавап, дип уйлады Андрей эчтән, бар гаепне аллага сылтау яки шайтан өстенә аудару. Әллә адәм заты җаваплылыкны үз җилкәсеннән төшереп тору өчен алла белән шайтанны уйлап чыгарганмы?

— Бер хатын сезнең өстән жалоба язган,— дип, Андрей кара сумкасыннан амбар кенәгәсе чыгарды. Шуны актарып бер бит кәгазь алды.— Чукындырганда балага салкын тигән, үпкәсе шешкән, врачлар көчкә үлемнән коткарганнар. Әгәр бала үлсә...

— Юк, үлми,— дип, газетын өстәлгә куйды карт, йөзенә җитдилек чалымнары чыкты. Аның мыегы сакалы белән бергә тоташкан, авызының кай төштәрәк икәнен төк чылгыйлары кыймылдаудан чамалыйсың.— Мин фәкать эссе мунчада җылы су белән эш итәм. Әгәр хатын үзе юбалгы икән...

— Бу үзегезнең дин канунын бозу түгелме соң?— Андрей попның ялганын тотарга итә иде.

— Ә дин ул тормышка яраширга тиеш!

— Еванглиедә андый катехезис юк шикелле?

— Аның каравы, агымга каршы бармаска диелгән.

— Ә үзегез менә агымга каршы барып, балаларны чукындырасыз, ә?

— Хәзерге барыш ул, иптәш, антихрист тәртипләренә корылган. Кешеләрдә иман юк, шуңа күрә кешеләр бер-берсен күралмыйлар, брат белән брат дошман, адәмнәр һәртөрле түбәнлек белән килешәләр, үзләре гуҗлар, фахишәлеккә омтылалар. Бер-берсенә яхшылык эшләргә куркалар... Бер кеше икенче якын кешесенә дә ышанмый... Православныйлардан кайберәүләр әнә шул әшәкелекләрне күреп, үз җилкәләрендә татып, балаларына иман иңдерергә телиләр. Әшәкелекләр эшләп яшәмәсеннәр, диләр. Моның өчен сөенергә кирәк иде, рәхмәт әйтергә, ә миңа штраф салалар?.. Яхшылыкка начарлык белән кайтару антихристлар эше генә...

— Мин салмыйм штрафны, закон сала!— диде Андрей, картның сүзләрендә хаклык күреп. Әллә мине сынар өчен шулай сөйлиме? Мин киләчәкне белеп, картны әзерләп куйганнармы? Ярый әле аның фикерләрен хуплый торган ымнар йөземә чыкмады шикелле? Әйтәм җирле, карт сөйләгәндә миңа бик нык төбәлеп — күзләре белән кадалып торды? Юк, берни дә сизмәде кебек? Әмма карт шайтан дөрес сөйли бит: хәзер адәм зат коточкыч нәфесле, хөсетле. Якын кешеләр бер-берсенең үлгәнен көтеп яшиләр. Дуслар бер-берсенә чокыр казыйлар. Берсе өстеннән икенчесенә өстәгеләргә сигнал бирәләр... Моңа соң антихрист кына гаеплеме? Картка шулай уйлау файдалы, билгеле. Ләкин барча начарлык, әшәкелекне антихрист-дәҗҗалдан күрү бик балаларча фикер йөртү булыр иде. Кешеләрнең бер-берсенә дошман караштa булуларының сәбәпләре тирәндәрәк ята булса кирәк...

Бераздан Андрей яңа шәһәрнең Пархоменко урамындагы оныгын чукындырган хатын янында утыра иде. Бик яхшы ике бүлмәле фатир. Хатын да шактый зыялы күренә. Андрейны башта ул газ төнлекләре тикшереп йөрүче пожар инспекторы дип белде. Аңлашкач, хатынның йөзе берьюлы караңгыланып китте. Сер бирмЗәс өчен иреннәре белән генә елмайган булды. Аннары гозерләнергә керешге:

— Зинһар, кызым белән киявемә җиткерә күрмәгез, алар белмиләр. Мин аларга әйтми генә эшләдем. Бары мин гаепле. Алар берни сизмиләр. Икесе дә Якутиядә җаваплы эштә. Икесе дә партийныйлар. Зинһар!..— Хатын тәмам каушаган кебек иде, учы белән биек түшләрен сыпыра, чебен куган шикелле, кулларын йөзе алдында бутый.

Нишләгәнен үзе дә аңлап житми сыман, хәрәкәтләре аңына буйсынмый, ахрысы.

— Менә жалоба язганнар бит,— дип, Андрей хатынның еламсырап такмаклавын бүлде.

— Юк, булмас!— диде хатын, кинәт уен туплагандай тынып. Андрей амбар кенәгәсен ачты, аннан бер бит кәгазь алып, хатынга сузды. Шунда гына үзенең ялгышуын аңлады. Шикаятьне ул иясенә күрсәтергә тиеш түгел иде. Мөдир аны бу хакта ничә мәртәбәләр кисәтте. Һаман эчендәге ялганлый, икейөзлеләнә алмавы сизмәстән бәрә дә чыга, шайтан. Эш интересы өчен дә ялганга бара алмый. Тәмам интегеп бетте инде үзе белән...

— Баладан яздырганнар,— дип, хатын кәгазьне Андрейга сузды. Йөзендә таркаулык, нинди дер гоман итү галәмәте бар иде.

— Зинһар, киявем белән кызымны буямагыз,— ди-ди сөйләнде хатын кулларын бутый-бутый.— Күпме штраф түләтсәгез дә риза!!

— Аллага ышанасызмыни?— Андрей хатынны сынар өчен генә шулай әйтте. Үзе өчен, кешеләр ни өчен алланы яд итәләр икән дигән мәсьәләне ачыклыйсы килә. Аллага табынуда теге дөньядагы җәзадан курку ятамы? Әллә башка берәр серме?

— Ышанмый ни, имансыз ничек яшәмәк кирәк?— диде хатын, ничектер сүрәнләнеп.— Аллага да ышанмаган кеше бәндәгә ышана аламыни?!

Андрей үзе аллага да, муллага да ышанмый иде. Кайтканда һаман шул хакта уйланды. Кешеләр теге дөньядагы җәзадан куркып кына ышаналармы, әллә тагы биредә берәр тылсым бармы? Алла һәркемнең рухында-җанында, диләр динчеләр. Моны ничек аңларга? Адәм баласы теге яки бу эшкә алынганда рухындагы шул алланы — ягъни иманны тыңларга тиеш, ә үзенең эгоизмын, нәфесен түгел. Шул иман кушканча эшләсә, башкаларга да, үзенә дә әйбәт булачак. Ягъни рухындагы алланы тыңлау — намусыңны тыңлау, намус кушканча эшләү була түгелме соң?

Ышанмыйча иман — «вера» була алмыйдыр инде? Ләкин дин сүзсез, һичбер шикләнүсез ышануны таләп итә. Ышан — бетте, сәбәбен, нигезен төпченмә! Коръән дә сүзсез, каршылыксыз, дәлилсез ышануны таләп итә. Исламның нигезе дә сүзсез ышануга корылган. Ышан, әмма, нигә, ни өчен, ни сәбәпле, дип сорама. Бездә социализмда эксплуатация юк дигәнгә сүзсез ышануны таләп итәләр. Ни өчен барча диннәр дә сүзсез, сукырларча ышануны куялар? Нәрсәдән бу? Табигать серләрен азагына чаклы танып-белү мөмкин түгел дигәннән чыгыпмы? Әллә сукырларча ышану шәхеснең үзе өчен кирәкме? Үземнән беләм, ихлас шикләнүләрсез ышана алган кеше бәхетле ул. Мин шул ихлас күңелдән ышана алмыйм, шуңа бәхетем дә юктыр.

Ул алла дигән миф шәхесне космос чалымнары белән бәйли торган бер нәрсәме? Бу миф адәм затының төрле табигать катастрофаларыннан куркуы нәтиҗәсе түгелме? Куркудан, җан саклаудан туган нәрсә булуы мөмкин бит! Без, җир адәмнәре булу белән бергә, күк штатында да торабыз, без — күкнең дә җан ияләре.

Яшьләргә никах уку белән шөгыльләнүче самозванец мулланы эзләп барганда һаман шул уйлар бөтерелде. Мулла яңа шәһәрдән өстәрәк урнашкан Подлесный поселогында иде. Үз йортлары белән торалар, уртача тормышлылар күренә. Мулла дигәнең кыска гына ак сакаллы, җыерчыклар ермачлап бетергән мөлаем йөзле татар карты икән. Ул Андрейдан шүрләп киткән шикелле булды. Аңа утырырга артсыз урындык сузганда, кулыннан ычкынып идәнгә тәгәрәде, шуның белән мәшәләнгәндә түбәтәе төшеп китте. Андрей картка татарчалап дәште. Көн дә татар сөйләшләре тыңлап йөри торгач, болай әйбәт кенә сукалый икән. Дөрес акцент бар барын. Татарча сүздән картның каушавы беткәндәй булды.

— Нәрсә, шикаять язганнармы?— диде ул Андрейның ник килгәнен төшенгәч, бик нык канәгатьсез төстә.— Һәр адымны барлап торалар, шабаш! Бәдрәфкә чыкканыңны да теркәп баралар, ахрысы? Кешеләр берсен-берсе күзәтеп кенә йөриләр. Ай-йай, кая китте бу дөнья?! Уф, уф, шулай тиештер инде, болай гына әйтүем!— Ул башын зур-зур учларына алып торды да, кулларын төшереп, Андрейга текәлде.

— Нәфсегезне тыярга кирәк, абзый,— диде Андрей ныклы гына итеп.

— Нинди нәфсе,— диде абзый, кулын алга таба селкеп.— Сорап килгәч, гозерен үтәми калалмаганнан гына! Нәрсә инде бу, берәрсенә яхшылык эшләсәң, үзеңә зарар килә?! Әллә нинди эт тәртибе! Уф! Уф!— Абзый тагы башын ике учы белән тотып куйды. Үзе зарланды да зарланды. Ул сәяси зарлана иде, шуңа күрә Андрей үзе дә шүрли калды. Абзыйның безнең тәртипләргә төрттерүен ишетмәмешкә, белмәмешкә салышты. Амбар кенәгәсенә бер-ике сүз яздырып алды да, абзыйны тыңлап сәяси гөнаһка батудан шүрләп, тизрәк чыгып сызу ягын карады.

Никах укыткан яшьләр Дон урамы чатындагы баракта кечкенә бер бүлмәдә иде. Яңа гына эштән кайтканнар. Буяуга, акбурга каткан комбинезоннарына караганда маляр булсалар кирәк. Алар бик күңелсез-җансызлар иде. Эштә тәмам алҗып беткәннәр, ахрысы. Андрейның ни сәбәп белән йөрүен ишеткәч, бөтенләй йөзләре йомылды.

— Дингә ышанасызмыни?— дип, Андрей бик ипле, хәерхаһ тавыш белән сорап куйды. Шуны да уйлады: болар намуслы, риясыз эшчеләр, матди байлык тудыручылар, андыйларга зур хөрмәт, кадер булырга тиеш. Әмма юк шул, юк.

— Тагы нәрсәгә ышанасың?— диде хатын, шактый тын торганнан соң. Ул түгәрәк битле, күкселләнгән иренле, арыган күзле иде. Яшь булса да эштә алҗу аны карт итеп күрсәтә.— Фатир өчен өйләнешкәнче әле ирем стройкада кара эштә йөрде. Алдадылар. Авыргач ЖКУга урам чистартучы булды, пычрак җыйды. Алдадылар. Бераз терелгән кебек булгач, кирпеч заводына керде, тагы авыр эштә эшләде. Фатир вәгъдә итеп эшләттеләр дә бирмәделәр. Тагы алдадылар...

Авыр тынлык урнашты. Урындыкта утыручы Андрей аяклары белән кыбырсып куйды.

— Кем чаккан безне?— дип, ир өмете беткән йомык йөзен күтәрде. Аның авыр карашыннан Андрейның ояты кузгалды, бик уңайсыз булып китте.

— Ярар, мин сигнал расланмады дип язармын,— диде ул, кузгала башлап. Амбар кенәгәсен ачып, хатын алдына куйды һәм каләм тоттырды. «Инспектор булды» дип яздырды да, тизрәк кенәгәне тартып алды. Ашыга-ашыга чыгып та китте.

Менә хәзер шул кәгазьләрне кабат күздән кичереп утыра. Тукта, бер-берсенә охшаганрак почерклар күзенә чалынып китте. Андрей тоткалы лупасын кулына алды, күзенә ышанып җитми иде. Почеркларны җентекләбрәк карарга тотынды. Тикшергән саен гаҗәпләнүе арта барды. Нәрсә бу? Поп әллә оныгыннан яздырып, оныгын чукындырган хатын өстеннән «сигнал биргәнме? Кит, кит, күзем, зиһенем саташа торгандыр? Нужәли, бу тагын нәрсә? Поп өстеннән язылган почерк кенәгәгә теге хатын язган почерк белән бер. Йа хода! Нинди әкәмәт бу? Юк, күзләрем алдамый, дүрт-биш кат почеркларны чагыштырдым. Фу, шайтан, маңгайга тир бәреп чыкты. Ярар, тынычланыйм әле. Фикерне бер җиргә туплап уйларга кирәк. Ни өчен поп үзе чукындырган баланың туганнары өстеннән «сигнал» биргән? Бу бит бернинди логикага сыймый? Оныгын чукындырган хатынның поп өстеннән язып җибәрүен дә аек акыл кабул итә алмый. Ни сәбәпле яза ул бу нәрсәне? Үзенең бу ярамаган эшен властьлар каршында ничек тә акларга теләпме? Кайсы яктан гына китереп карасаң да, бу хәлләрне аңлап та, аңлатып та булмый. Бирегә кемнәрнеңдер кулы катышкан булырга тиеш. Бу нинди иблис корган эксперимент? Хәер, нигә мин гаҗәпләнәм әле? Төрмәдә күргәннәреңне

хәтерендә китер. Анда бер тәрилкә баланда хакына зэк, үзенең иптәше өстеннән органнар ни кушса, шуны язып бирә иде. Ачлык, кытлык яман нәрсә. Поптан һәм теге хатыннан аерым-аерым безгә ярдәм ит, дип үтенгәннәрдер, куркытканнардыр һәм нәрсә булса берәр файда вәгъдә иткәннәрдер. Адәм заты йомшак...

Йа хода, әллә мин ычкына башладыммы, валлаһи! Теге мулла үзе никах укыган яшьләр өстеннән язган бит? Үзе, кешеләр берсен-берсе күзәтү белән шөгыльләнәләр, дип зарланып маташты? Ә карасаң нинди икейөзле икән! Менә сиңа изге зат. Теге яшьләр аның нинди кара эчле икәнен чамалаганнардыр шул. Яшьләр үзләре исә чиста кала алганнар. Мулла өстеннән язган сигнал теге маляр хатын кулы түгел! Яшәсен тормыш! Яшәсен намуслылар!

Юк, мин нәрсәнедер аңлап бетермим, ахрысы. Бәлки, бу зарури хәлдер? Мин бит бары үз каланчамда торып кына фикер йөртәм. Мондый фикер һәрчак диярлек берьяклы була. Тәгаен шулай. Мин ул механизм серләренә кермәскә тиешмендер? Белмәү бит бик күп бәлаләрдән коткара. Һаман шул каһәр төшкән гаделлек таләп итү шундый каршылыклар чытырманына китереп кертә мине! Үзем аңлыйм, югыйсә, һәр эштә гаделлек таләбе кую ахмаклык. Сиңа гаделлек кебек булса, икенче кешегә аның гаделсезлек булуы мөмкин. Гаделлек мәсьәләсе минустан плюскә, плюстан минуска бик тиз күчүчән...

Ул көнне Андрей соңга калып кайтты. Ишекне ачып керүгә, Анна кухнядан башын сузып: «Бездә кунак бар»,— диде шыпырт кына серле тавыш белән. Андрей, кем килде икән, дип уйлап өлгермәде, эчкәре бүлмә ишеге ачылды һәм зур күзлекле, биек маңгайлы, таррак күкрәкле таза гына бер егет аңа таба атлады. Килеп җитәрәк түгәрәк битләрендә һәм күзлек эчендәге күзләрендә берни белгертмичә:

— Папа!— диде, Андрейга кулын сузды. Әмма Андрей югалып, каушап киткән кебек булды, күзләре зур булып ачылдылар, күз аклары елык-елык килде. Ул үзенең улы Юрийны көчкә-көчкә таныды һәм кинәт йөзенә кара коелды. Күкрәк эченнән ачумы, рәнҗүме йөрәген ачыттырып күтәрелде, тәне буенча пешерә торган кайнар нәрсә йөри башлады. Йөзе хәтәр чытылды, кашлары җимерелде, иреннәре күгәрде. Ул аягын ботинкалардан ашык-пошык бушатты да, гәүдәсен турайтты һәм, Юрийга дөмерынып караган төстәге кыяфәт белән, Анна бүлмәсенә ашыкты. Үзе дә сизмәстән куллары калтырый, зәңгәрсу резина төсенә кергән иреннәре дерелдиләр иде. «Нигә мин болай?— дип, үз-үзенә гаҗәпләнгәне миендә чагылып узды.— Әллә кире борылыргамы, кеше төсле исәнләшергәме?»— дигән икенче уй да җанын борчып тилпенде. Ләкин кире борылырга аяклары тартмады. Эчтән нәрсәдер тота иде. Хәтер калу рәнҗүме, теге вакытта үзенә яра салганны ихлас йөрәк оныта алмыймы? Әллә бу бары дәрәҗәңне төшерәсе килмәү кирелегеме? Юк, әле вакыт узмаган, борылырга да сузган кулын учка алырга? Әмма мин-минлеге карыша, аяклары тышаулагандай итә... Ахырда ул, кинәт авырып киткәндәй, ах-ух уфтанып, диванга барып утырды. Башын ике учына алды... Моннан күп еллар элек булган хәлләр ап-ачык күз алдына килеп басты.

Эвакуациядән Ленинградка кайтып көчкә-көчкә тернәкләнеп килгән чак. Андрей кечке мәктәптә тарих укытучысы булып эшли. Диссертациясенә материаллар тупларга хыяллана. Ләкин соңгы вакытта артында чыш-пыш сөйләшкән авазлар колагына чалына иде. Хатын белән мөнәсәбәтләр начарланды. Ул — юкка-барга бәйләнеп, ачуны китерүчән, һәрдаим диярлек кәефне бозучан, акча әз эшлисең, ди-ди, намуска тиючән булып китте. Хәтта ашау-эчүдән аера башлады. Андрей моның тикмәгә булмавын аңлап, сагайды. Нәрсәдер берәр әшәкелек көтеп йөрде.

Һәм бер төн уртасында ишек шакыдылар. Хатыны, улы эчке бүлмәдә йоклый иде. Ишекне Андрей ачты. Анда ике милиционер басып тора. Алар елт кына эчкә уздылар һәм ордер күрсәттеләр. Андрей бераз исенә килә алмый торды, телдән калды. Тегеләр ым белән ашыктырдылар.

Андрей караңгы бүлмәдән арка капчыгы табып, шуңа кирәк-ярак салгалады. Ыгы-зыгы тавышка эчке бүлмә ишеге ачылды, бусагада хатыны һәм улының башлары калкынды. Андрей өстенә-башына киеп, биштәрен җилкәсенә элгән килеш аларга саубуллашырга дип карады. Шулчак Юрий алга чыкты һәм, Андрейга кулы белән төртеп күрсәтеп:

— Ул халык дошманы, мин аңардан баш тартам!— дип кычкырып җибәрде. Ул арада милиционерлар Андрейны икесе ике яктан төрткәләп алып чыгып киттеләр.

Шул чагында йөрәгенә кадалган шырпы хәзер дә сызлап тора. Күпме еллардан бирле авырта, һаман да беткәне юк. Анасы, укытучысы өйрәткәндер, ди-ди, улын акларга, аны каты хөкем итмәскә үгетли, төрле дәлилләр китерә. Тик барыбер улы ясаган яра йөрәгендә һич тә төзәлми. Эх, онытып булсын иде! Оныта ала торган кешеләр нинди бәхетлеләр! Улына булган рәнҗү-әрнүле яралар һич төзәлмәгән икән. Гаҗәп. Менә үзен күрүгә барысы да яңардылар. Күңелне, җанны ачыттырып әрнетәләр. Чыдар хәл юк. Нәрсә бу? Ник мин шундый һәрчак газап чигә торган кеше икән? Нормаль түгел бит бу! Йә, Юрий белән күрешсәм, әз генә сөйләшеп торсам, нәрсә булыр иде? Әллә берәр җирем кимер идеме соң?

Аптыраган Анна бүлмәгә килеп керде. Төсендә гаҗәпләнү, ачуы килгән чалымнар иде.

— Андрей, нәрсә кыланасың тагы, бу ни эш бу?— дип шелтәләргә тотынды ул.— Балаң алдында оят түгелме? Ә? Әти, дип каян кадәр килгән бит? Ә?

— Булдыра алмыйм, Анна, хет үтер!— Андрей учы белән йөрәк турын сыпыра ук башлады. Апасы аны да җәлләп куйды, шулай да улы белән сөйләшергә кыстады. Бу бит үзең өчен кирәк, ди-ди үгетли, ялвара иде.

— Ул бала башы белән теге вакытта синә яра ясаган, ә хәзер син аның йөрәген яралыйсыңмы?

— Аның йөрәге өчен кайгырма, Анна! Аларның йөрәге урынында — таш!

— Юрийга моны ничек дип аңлатыйм? Ниндидер өмет белән килгән бит ул?

— Авырый, эпилепсиясе кузгалып тора диген...

— Бу чаклы булырсың икән, үз бәхетеңне үзең кисәсең?!— диде Анна, ах-ух килде дә чыкты. Аннары аның Юрийга кичкелек ашарга кухняга алып кергәне ишетелде. Табын янында күбрәк Анна сөйли иде. Ләкин сүзләрен бу бүлмәдә аерып булмый. Бу хәлгә Юрийның кәефе киткән дә Анна шуны көйләп, турылап маташамы? Мин Юрийдан берни көтмим, өмет итмим. Аңарда туганлык хисләре юктыр да. Әгәр кайдадыр тирәндә яшеренеп калган булса, аны барыбер чокып алып ташлаячаклар. Туганлык хисләреннән мин мәхрүм ителгән, мин аңа лаек түгел. Туганлык җепләре өзелеп беткән. Аларны торгызып булмаячак. Туганлык җепләре үрелсә дә, бары тышкы яктан гына. Нәләт заман, үз улым белән шул тышкы туганлык өчен мин хәзер икейөзлеләнергә, ялганларга тиешме? Ул дә әтисе белән формаль туганлыкны кайтару өчен үзен-үзе алдауга барырга мәҗбүр.

Тукта, мин үземнең бу мәгънәсезлегемне аңларга маташам түгелме? Шайтан алгыры, эшләремне, бәлки гөнаһларымны аклый торган миндә «двойник» барлыкка килгән бит! Әйе, Юрийга үч тоту да ахмаклык шикелле. Ләкин шул ахмаклык аша атлап чыгып булмый. Юрий файдасына тагы шул хакыйкать тә бар: ул вакытта беркемне дә сындырмыйча калдырмадылар. Әллә нинди гаять көчле намуслы, принципиаль затлар бар иде. Барысы да сындылар, сынмаган берәү дә калмады. Адәм баласы ачлык белән җәзалауга чыдый алмый. Җан саклау үлчәвенә салганда намус, патриотлык, егетлек чүп нәрсә була да бетә...

Кухня якта тавышлар куерды. Анна Юрийга нәрсәдер тукый шикелле. Тегесе каршы төшә. Анна акыл сату буенча белгеч инде. Үз һөнәренә һәрчак тугры кала.

Ул арада Анна Юрийны ияртеп, бу якка чыкты. Утны яндырды да Юрийга өстәл артындагы урынны ымлады. Үзе кара такта янына баскан укытучы кебек торды. Андрей, уңайсызланып, кашын-йөзен җимерде, кысылган күз ярыкларыннан караган килеш, аякларын идәнгә төшереп утырды. Ул Юрийга каш астыннан күз кырыйлары белән сирпеп алды. Тегенең тәкәббер бүртенгән, үзен генә хаклы санаган чалымнарын кыяфәтеннән чамалады. Очрашасы, сөйләшәсе килмәвенең дөрес булуын, сиземләве алдамавын шәйләп, сөенечкә охшаш хис кичерде.

— Андрей, син олы була бел,— дип, юмалый торган тавыш белән тезде Анна.— Юрий тормышын әтисен сатудан башлады дип һич үртәлмә. Галим Милашкин малаен беләсең бит. Әтисен алгач, мәктәптә: «Юк, минем әти халык дошманы түгел!»— дип кычкырып йөргән. Алып киткәләр үзен. Шунда бетте. Әтисе кайтты. Син Юрийның шул үсмер кебек булуын теләр идеңме?

— Юк, билгеле!— диде Андрей, иреннәрен көчкә кыймылдатып.

— Шулай булгач, син Юрийны гафу ит! Ул тынычланып яшәсен. Үзеңә дә әйбәт булып китәр, чын, чын! Кичерү ул көчлелекне, яхшы күңелле булуны күрсәтә...— Ул Андрейга дәресен үзләштермәгән укучысына юнәлешне чамалый торган сорауга җавап көткән кебек текәлде. Андрей ияген күкрәгенә терәгән, дәшми. Бераздан әз генә башын калкытты.

— Гафу итү өчен кешечә хисләр кирәк, ә миндә ул юк! Тагы икейөзләнергә, маска кияргәме? Юк!

— Ялгышасың, Андрей,— диде Анна, энесенә таба бөгелә төшеп.— Улыңа, миңа яхшылык эшлә! Бүтәнгә яхшылык эшләми торып, адәм баласы яхшырмый.

— Булмый, Анна, көчләмә! Җанымда үт ачысы, әрнү... Барысы да минә монда яна, кайный...— Ул йодрыгы белән күкрәгенә дөп-дөп суккалап алды. Күзләреннән битләре буйлап күз яшьләре тәгәрәде... Шул мәл Юрий урындыгында кыбырсып куйды һәм телгә килде:

— Әни гел әйтә иде,— диде ул кытыршы, бераз калтыранган тавыш белән.— Әтиең начар әдәм дип. Димәк, минем баш тартуым нигезсез булмаган?

— Юра, тукта, нәрсә сөйлисең!— дип, Анна кулы белән кире тибәрү хәрәкәте ясады.— Ул сиңа җан биргән кеше! Син бит инде күптән балигъ булган. Ничек әзрәк оялмыйсың!— Аннаның ачудан тавышы күкле-яшелле булып чыга иде.

— Нормаль әдәмме, руслар татарларга карата каты чаралар куллана дип, үз башын утка тыга, йә? Нәрсәгә кирәк сиңа ул гололобыйлар? Шушы ахмаклыгың өчен әнидән, миннән үзең гафу үтенергә тиеш! Менә, Анна Андреевна, хөкем итегез!— Юрий бармагы белән күзлеген борыны өстенәрәк этеп куйды.

— Юрий, акылыңа кил!— ди-ди үрсәләнде Анна.— Ник әтиеңне газаплыйсың? Йа хода!

— Бар бәхетсезлек аңардан башланган. Нигә ул безнең хакта уйламаган? Аның аркасында күпме газап чиктек! Әти икән, нигә ул мине санга сукмый?— Юрий үзенең өстенлеген, хаклылыгын тойгандай, ияген горур гына күтәреп куйды.

— Йа, хода, үзең сакла, ата белән бала бер-берсен үтерергә кизәнәләр! Нинди иблис котырта моны! Йа хода!— Анна учы белән маңгаен тотып идән буенча йөренде.

— Җитәр, Анна, карганып йөрәкне өзмә!— дип ялварды Андрей көчсез, сүнгән тавыш белән.

— Юк, Анна Андреевна, мин аның мине гафу итүен теләмим! Противно! Бетте!— Юрий ярсулы кайнар рәвештә кычкырып җибәрде һәм нindидер өмет калдырмый торган кырыс кыяфәткә керде дә бүлмәдән чыгып китте.

— Юрий, ахмакланма, бер үкенерсең!— диде тавышын күтәреп Анна аның артыннан. Ул ике кулын өметсез җәеп җибәрде дә, гаҗизләнеп, нишләргә белмичә тәрәзә янагына барып башын сөяде. Аннары башын як-якка чайкап алды. Андрейга карады. Шыпырт гаепле тавыш белән: «Әйдә, син бит чәй эчмәдең?»— диде, ничектер тыңлаусыз баланы юмалаган шикелле. Андрей кул гына селтәде. Анна ияген кага-кага чиксез гаҗәпләнү һәм рәнҗү белгертеп, кухняга юнәлде. Андрей, күлмәгенең түш кесәсендә генә йөртә торган даруын алып тел астына салды да, утны сүндереп, диванга сузылды. Йөрәге күкрәк эченнән атылып чыгардай булып тибә һәм кинәт дертләп, авыртып куя. Менә ничек инфаркт алалар икән, дигән уй килә аңа.

Юрийның татарларга карата хөкүмәт политикасының гаделсез булуын ник әйттең, ник сәясәткә борын тыктың, ә татарлар үзеңне якладымы соң?— ди-ди җикеренүе һәм шул нигездә, барысына да син гаепле, үзең бездән гафу үтенергә тиеш, дигәнендә ниндидер хаклык бар бит, шайтан алгыры!.. Нишләргә соң, нишләргә?— Һаман мин гаепле. Юрий мохитне, заманны исәпкә алмый. Заманны бит сайлап алып булмый. Нәрсәгә татарларны якладым, үзем дә белмим. Аңлы рәвештә түгел. Юлымда шундый ситуациягә очраганмын, шул гына. Минем җанда гаделлекне ярату бик көчле. Нинди генә эшкә тотынсам да, шул нәрсә төртә дә чыга, хәерсез. Һәм мине бер бәлагә төшерми калмый. Минем табигатькә тумыштан шул нәрсә салынган, программаланган, ахрысы. Корьәндә бит, кешенең күрәчәге ләүхел-мәхфүздә язылып куелган була, күрәчәген күрми адәм гүргә керми, ди. Җанымдагы хаклылыкны ярату хисе миннән көчлерәк күрәсең. Уф! Уф!

Юк, кем гаепле, кем гаепсез икәнен тәгаен генә белеп булмый. Уйлый башласаң, очына чыга алмыйсың. Тылсымлы түгәрәк шикелле. Әмма Юрийны гафу итсәм дә, тынычлану килми. Кылыч ярасы төзәлә, тел ярасы төзәлми, диләр. Хак шул. Кичерәм дип әйтсәм дә, бары сүзләр генә, тыштан гына. Эчтә нәрсәдер кала.

Әнә Холодецның да рәнҗетү, мыскыл итүләрен оныта алмыйм. Мин ул хәлләрне истән чыгарырга тиеш тә түгел. Үземне таптаган, гарипләндергән кешегә бернинди җавап кайтара алмыйм. Чөнки хокукым юк. Моннан да аянычлырак хәл булуы мөмкинме? Сине яңакласыннар, синең кыйнаучыга кизәнергә дә хокукың булмасын! Йодрыкларыңны йомарлап, тешеңне кысып, эчеңә үт ачысы саудырып тереклек итәргә тиешсең. Төрмәдә бер зэк әйтә иде: «Бездә кешене рәнҗетү түләүсез, бетереп ташлау бушлай. Һәм адәмне үтергән өчен дә бернинди җәза юк! Бары да түләүсез!»— дия иде. Холодец мине кыйнап гарипләндерде, ә бер зыян күрмәде. Киресенчә, бераздан чинын күтәрделәр.

Ярар, артык фаҗига ясамыйк әле. Яшәргә кирәк бит. Тик Холодецны кояш яктысына чыгарырга иде. Әмма мөмкин эшме? Анна сизенгәнчә, үземне тагы гаепләп ташламасларммы? Барысы да алар кулында бит? Холодец, билгеле, органда эшләмәсә дә, барыбер аларга хезмәт итә. Пенсиягә чыккач та агент булып калалар. Үлгәнче штаттан төшермиләр, ди...

Бәрәч, яктыра башлаган икән, дип, Андрей торды һәм бик шыпырт кына киенде, тавыш-тынсыз гына ишеккә барды, ботинкаларын аягына элде. Тынын кысып, бик сак кына ишектән подъездга чыкты. Баскычтан песи кебек йомшак, пружиналы атлап төште. Урамда гына күкрәгеп киереп, иркен сулап җибәрде.

Иң элек ул базарга таба атлады. Юлы шуннан үтә иде. Базар инде җыела башлаган. Арбалардагы киндер капчыкларда дуңгыз балалары шырыйлап кычкыра. Шул исенә төште: капчыкта дуңгыз баласы, ялгыз булса гына, әнә шулай шәрран яра икән. Икәү, өчәү бергә булсалар, кычкырмыйлар, бары мыркылдап кына яталар, ди.

Базарда руслар, татарлар, чуашлар. Татарлар бер-берсе белән кычкырып исәнләшәләр:

— Ни хәлләр?
— Хәлләр шабаш, бизде җанаш.
— Кайгырма, аша табаш...
Руслар, яшь марҗалар да шаян телле. Нәрсәдер сатулашалар:
— Ни бәя?
— Фәлән хак.
— Ну-у, зәңгәр күзләрең өченме бәяне югары куясың? Ә?
— Минем зәңгәр күзләрем өчен кыйбатрак та түлиләр!— дип көлеп куя марҗа, калын күкрәкләрен дулкынландырып.
— Безнең авылныкы булсаң, син миңа бушка гына килер идең! Жәл, жәл!— Берничә яшьрәкләр шаркылдыйлар. Кыз да аларга кушылып көлә.
Аңа бүген иртүк Акташка барырга кирәк иде. Кичә кичтән эш кәгазьләрен алып, беренче рейс белән китәргә әзерләнеп кайткан иде. Акташта тагы бер самозванец поп пәйда булган. Шуны тикшереп кайтырга кирәк. Аннары Тугаев янына сугылырга исәп. Бу Холодец имансыз белән нишләргә инде? Әллә Анна киңәшен тотаргамы? Нужәли шул тикле канлы эшләр өчен җавап тотучылар булмас? Белмим. Теләсәң нишлә?! Юк, барыбер Алмазны күрергә кирәк!

Тугаевны горкомга чакырдылар. Вахталарны озатып бетереп, яшерен бүлмәсенә алып керергә эшләрен сайлап утыра иде, чылтыраттылар. Алмаз бераз зиһенен җыеп торды, горком һәрчак шүрләтеп җибәрә, үзеңнең булган яки булмаган гөнаһларыңны барларга мәҗбүр итә. Тагы нәрсә булды икән, нинди төймәдән дөя ясарлар икән, дигән уйлар башта чагылып китә. Үткәндәге эшләреңне кайда кемгә нәрсә дип әйткәнеңне хәтерләргә көчәнәсең. Әллә хатын минем хакта берәр ярамаган сүз ычкындырдымы? Менә шулай үзеңнең астыңны, өстеңне тикшерәсең. Горкомда бары елмаеп, канәгать булган төс белән йөрергә тиешсең. Төксе чырай, димәк, властьны яратып бетермисең. Шулай гына бәяләнә. Нindидер мөдир ярдәмчесе сиңа мәгънәсез замечание ясаса да, син каршы әйтергә, хаклыкны ачарга хокуксыз. Әз генә каршы төшсәң, беттең: тегенең чырае кара коела, иреннәре кысыла, тавышы кырыслана. Үзе берни сиздермәскә итә, барысын эченә салып куя.
Сөйләшкәндә кемнең нинди икәне кайчак беленеп китә. Мөдирләр үзләреннән акыллырак фикер йөрткән кешене күтәрә алмыйлар. Акыллырак сүзләр ычкындырсаң, бер-ике сүзен аста калдырсаң, шәхси дошманына әйләнәсең. Шуның өчен эт каешына әйләнгән адәмнәр биредәгеләр белән үзен түбәнгәрәк куеп сөйләшә. Ахмаграк булып күренергә тырыша, үзенең аңгыралыгы белән мөдирне көлдерә алса — бу инде уңыш. Карьераңа берни дә янамый, тыныч кына урын билисең.
Шушы нәрсәләрне белеп, эчтән җирәнеп, кире кагып йөрсә дә, Тугаев горкомга күтәрелергә яшерен генә омтыла иде. Горкомда эшкә алсалар, аңа тагы да югарырак китәргә юллар ачылыр шикелле тоела. Биредә ул кешеләргә нинди дә булса файдалы эш эшләми калмас иде. Кешеләрнең тормышын җиңеләйтүчән эшләрне властьтан башка эшләп булмый. Мәсәлән, авылның як-ягында унлаган газ факеллары көн-төн бушка янып тора. Күпме байлык җилгә оча. Әмма шул газны авыл йортларына кертергә рөхсәт итмиләр. Ә бит горком бу эшкә алынса, мәсьәләне югарыда утыручыларга кабыргасы белән куйса, нәрсәдер эшләми калмаслар иде? Юк, кыймылдамыйлар. Беренчедән, куркалар, урыннары өчен калтырап, ләббәйкәлек итәләр. Горкомга күчерсәләр, ул да шулай бюрократлашыр иде микән? Һәрхәлдә, урын өчен шыр җибәреп эшләмәс иде. Дөресне ялганга чыгарып, ялганны чын итеп игълан итүләргә каршы ташланыр иде.
Мөдир Алмазны канәгать, тук һәм астыртын серле йөз белән каршы алды. Нәрсәгә канәгать икән бу? Миңа яхшы хәбәр җиткерәме, файдалы берәр нәрсә әйтәме? Әллә конкрет бер эш табылганга чыраенда яктылык

җәелгәнме?.. Мөдир Алмазга утырырга кушты, үзе басып торган килеш, аңа калын гына конверт сузды. Конверт ачылган, язылган битләр чыгып тора. «Менә танышып чык»,— диде һәм, зур шкафыннан ниндидер катыргы алып, ишеккә юнәлде.

Куш дәфтәр битенең эч ягын тутырып язган бу нәрсәне Алмаз күз йөртеп кызу гына укыган итте. Берни дә аңламады. Аннан һәр сүзен төгәл таный-таный әкренләп, туктап-туктап укыды. Бераз төшенгәндәй булды. Бу аның үзе турында анонимка иде. Кинәт аркасына, тамырларына кайнар кан йөгерде. Ни өчен бу? Нинди әшәке зат аны пычратырга җөрьәт иткән? Бу бит бер гаепсез кешегә кара ягу. Кемнең кулы уйнаган монда? Яңа шәһәрдә аның үткәнен беркем дә белми иде?

Бик эшлекле кыяфәт белән мөдир килеп керде. Өстәл артына утырды да Алмазга төбәлде. Күзләрендә кызыксыну, кеше газабын күзәтәсе килү уты көйри сыман иде.

— Ну, нәрсә әйтәсез?— Эчендәге кызыксынуы мөдирнең бөтен тулы битле тук чыраена сизелерлек булып чыкты. Бу нәрсәдер белә, ләкин әйтмәячәк, дигән уй чагылып китте Алмазда.

— Монда минем биографияне язганнар,— диде Алмаз уйчан һәм сүрән генә. Тавышы да бераз калтыраулы, тигезсез чыкты.— Сугыш азагында мин «смерш»та хезмәт иттем. Көнчыгыш Пруссиядә. Анда хәл бик катлаулы иде. Абвер күп агентлар калдырып киткән.

— Өйләнгәнсең, хатының, балаң булган, шулаймы?— Мөдирнең йөзендә яктылык күбәеп китте. Ә Алмазның җаны уч төбендә. Ике якта ике чигә тамырлары колак барабаннарына дөп-дөп суга, хәтта мөдиргә ишетелә сыман. Алмазның уч төпләре тирләде. Үзе дә сизмәстән, кулъяулыгын чыгарып, бармакларын сөрткәләп алды.

— Юк, алай ук дип әйтеп булмый,— дип, Алмаз мөдиргә карады. Аның сүзләрен чынга аламы, юкмы? Мөдир эчке елмаюын белгертеп аны тыңлый, әмма ул әйткәннәрне чынга алмый кебек иде.

— Ул хәл безнең хезмәт спецификасы белән бәйләнгән иде. Командирыбыз майор Зимин мине, бер кыз белән өйләнешергә теләгән яшьләр итеп, кононик янына җибәрде... Колоникка, абвер калдырган агент, дигән шик төшкән иде...

— Шуннан?

— Без, билгеле, кононик каршында егет белән кыз булып уйнап, кононикның кылын тартып карарга тиеш идек. Һәм без шул эшне башкардык та... Вазыйфа. Аны аңлатуы кыен...— Алмаз бүтәнчә эчкә керергә теләми иде. Анда сөйләргә ярамый торган нәрсәләр байтак. Интим мөнәсәбәтләрне сүзгә әйләндерү дә уңайсыз. Аларны сөйләп тә булмый. Ә мөдирнең күзләре һаман кызыксыну белән очкынлана. Ничектер Алмаз үз хәлен мәченең тычкан белән уйнавына охшатты. Мәче тычканны җибәрә дә кинәт барып өстенә баса, җибәреп тора да кинәт ыргылып, янә тырнакларына эләктерә...

— Әйе, тагы?

— Нечкәлекләрен хәтерләп булмый инде, күпме еллар узган... Алмаз мөдиргә ялварган йөз белән карады. Тегенең һаман кызыксынуы кимемәгән иде.— Нәрсәгә соң бу?— диде ул эчендә кайнаган ачуын көчкә тыеп.

— Нәрсәгә, нәрсәгә?— диде мөдир кәефе китеп. Йөзе шунда ук кырыс сызыклар белән тулды.— Менә интересный хәлләр ачыла. Без белеп торырга тиеш...

— Минем хатыным да, балам да булганы юк! Әшәке яла бу!— диде Алмаз ныклы, ышанычлы итеп. Ләкин мөдиргә бу берниндн тәэсир итмәде. Ул аның сүзләренә баягыча ышанып җитми иде.

— Да-да,— дип куйды мөдир уфтанып, Алмаз хәленә кергән сыманрак итеп.— Күңелсез нәрсә, сине горкомга алырга дигән «мнение» йөргәндә генә. «Үзе» ишетсә, тагын йөзен чытачак инде...

— Без бит приказ үтәдек!— диде Алмаз, тавышын күтәрә төшеп ипле генә.— Әллә бу ялага ышанасызмы?

Аңа җавап итеп, мөдир җилкәләрен генә селкетеп куйды, карашын читкә алды.

— Вообше, тәгаенләп аңлатма язарсың, кәнителе булмасын,— диде мөдир һәм хатны алырга кулын сузды... Алмаз аңа конвертны бирде дә, тагы нидер сорарга итеп, карап торды.

— Бу нәрсәгә соң?— диде тагы бер кат.

— Курыкма, иптәш Тугаев,— дип, мөдир аны сизелерлек тынычландырырга теләгәндәй итте.— Аңлатма яз, бәлки шуның белән вәссәләм булыр?..— Ул шуның белән сүз беттене аңлатып, өстәл тартмаларын ача, актара башлады. Алмаз ни әйтергә белми ык-мык итеп торды да, теге башын күтәрмәгәч, ишеккә таба китте.

Чыккач ул үзен кыйнап ташланган кебек хәлсез сизде. Аяк буыннары, куллары шул тикле арыганнар, гәүдәне көчкә-көчкә тоталар. Аяклар менә егылам, менә егылам дип атлыйлар. Юк, болай булмый, барысы өстенә башым да үземнеке түгел. Баш тартмасы эчендә ми сулкылдап-сулкылдап куя кебек. Атлаганда сыек әйбердәй ми куышлыгының кырыйларына бәрелеп киткәнен тоясың... Күзләре беркемне күрми иде. Шулай да зиһененең ниндидер почмагы эшли икән. Ул Фрунзе проспектына утырткан куаклыклар арасына таба атлады. Анда эскәмияләр бар иде. Беренче очраганына килеп лып итеп утырды. Исерек кешедәй чак артка чайкалып китмәде, эскәмиянең кырыйларына куллары шытырдап ябышты. Теге анонимкадагы, «Баласын, хатынын ташлаган», дигән сүзләр аны тәмам үтерде, шушы хәлгә төшерде. «Бала» дигән сүз йөрәгенә шырпы булып кадалды. Нужәли бала булды икән? Моны Рита белсә, минут саен искә төшереп, күзне ачырмас. Шайтан алгыры, була дигәндә артын бора, менә шушы инде. Күтәрелеп килгәндә генә ничек итеп тәгәрмәчкә таяк тыгалар. Мин түзәрмен, әмма Ритага бик каты зарбы булачак. Аның бөгелеп төшүе мөмкин. Ул мине дәрәҗәгә күтәрер өчен гомере буе тырышты, корбаннарга барды. Туганнары башка шәһәрләрдә югары урыннарда. Башта Рита мине туганнарына күрсәтергә читенсенде. Директор булып, күп акча да аны канәгатьләндермәде. Дәрәҗәне акчадан өстен күрде. Һаман горком кешеләре, аларның хатыннарыннан көнчелеге ярсыды. Хәзер нишләр инде, ул якка юл ябылды дигән сүз.

Тукта, фикер читкә китте. Әйе, кем язарга мөмкин бу әшәке нәрсәне? Мин бу яланы ничек итеп кире кага алам. Барысын да инкарь итепме? Ә ничек, ни рәвешле? Безнең Зария белән разведкага йөрүләрне белгән кеше язган моны? Без кононик янына берничә мәртәбә визит ясадык. Безне көтмәгәндә аердылар. Мине йокыдан төртеп уяттылар да приказ әйттеләр. Зария тагы да иртәрәк каядыр киткән. Саубуллашып та булмады. Бер сәгатьтән мин Молдовиягә оча торган самолетта идем.

Каян килеп чыгарга мөмкин бу нәрсә? Берничә вакыттан миңа Зариянең һәлак булуын сөйләделәр. Юк, бу яктан һөҗүм була алмый. Әллә «смерш»тан котылып калган берәрсе терелеп калыкканмы? Алай дисәң, мин үзебезнекеләргә булган операцияләрнең берсендә дә катнашмадым. Бер абвер агентларын ачыклау буенча эшләдек. Минем ролем латыш кешесе булу иде, минем төс-битемне тач латыш, диләр иде. Юк, зарбының бу флангтан булуы бик шикле. Әллә Ритага дошман кеше моны казып чыгарганмы? Рита үзен бик горур тотарга ярата, әллә шул бәйсез булырга омтылган горурлыгы бәла дәшеп китердеме? Булмас димә. Кечкенә шәһәрдә начальник хатыннары бер-берсеннән бик көнләшәләр һәм бер-берсенең гайбәтен сатарга да яраталар. Хәзер Рита алдында нәрсә дип акланырга?

Карасана, нишләп әле мин начар эш кылган кеше кебек уйлап утырам? Мин бит берninди хилаф эш эшләмәдем, минем тамчы да гаебем юк бит! Юк, булмаганны бер диндар адәм шикелле үз өстемдә тоярга әзер. Тьфү! Куркып яшәүдән бу, горком өрәгеннән йөрәгең алынып торудан...

Алмаз, үзен-үзе ясалма дәртләндереп, урыныннан кузгалды. Чуалган фикерләре бер киләпкә кергән, караңгы җирләре ачыклана төшкән иде.

Кайтса, Рита алгы якта елап утыра. Телефон өстәлендә ачык хат ята. Алмаз аны конвертыннан таныды. Аңа да җиткергәннәр икән. Ярый, кырыйдан ишетүгә караганда болай әйбәтрәк.

— Нәрсә булды?— диде кайгыртып Алмаз, гәрчә хикмәт нидә булганын яхшы белсә дә.

— Әнә синең мәгъшукаң турында язганнар...— Ул сүзен әйтеп бетерә алмады, елагына буылып төште:— Ый-ый...

— Горкомга да язганнар,— диде Алмаз, дәртлелеген сүндермичә.— Бу язуда бер хаклык юк, барысы уйдырма, кара яла! Минем юлны кисү өчен. Һәм синең юлны да!

— Хатының, balaң булган...— Рита Алмазның сүзләрен гел ишетмәгән кебек һаман шул яңа тәэсиреннән ычкына алмый иде.

— Әйтәм бит, берни дә юк! Неужели миңа ышанмыйсың? Синең белән минем арага чөй какмакчы булалар...— Алмаз ясалма җанланып, өстен чишенде, кулын юып, кухняга үтте. Колбаса белән кыздырылган бәрәңгене, чәйнекне газга утыртты. Өстәлгә ашамлыклар тезде. Буфет шкафыннан коньяк алып, тиз генә бер рюмканы авызына чөңкәйтте. Икенчесен Ритага дип тутырып куйды. Кыланган була инде, янәсе, бу ирен бик ярата, аңа гына карап тора, үтә тугрылыклы. Уйлана-уйлана үзе суына, аек акылына кайта ул. Тирән кичерешләр аңа хас түгел шикелле... Әмма хатын-кыз төпсез тоба ул. Барча нәрсәне үзенә суыра торган бүрәнкә кебек, тормыш кебек. Чөнки хатын-кыз үзе тормыш бит! Алмаз чәй әзерләде, кыздырылган бәрәңгене табасы белән өстәлгә куйды. Булкилар турады. Ләкин Ритага дәшмәде. Үзе әйбәтләп кенә ашарга тотынды. Кичерешләрдән нык кына ачыгылган икән. Юк, Ритага сүз катмаска кирәк.

Байтак шулай тынып торганнан соң, ниһаять, Рита кузгалды. Күзләрен бармак кырыйлары белән сөртә-сөртә, халат изүен биек күкрәкләренә яба-яба өстәлнең теге башына килеп бөкшәебрәк чүмәште. Ярыйсы гына бетерешкән төстә иде.

— Фронтта хатының булган инде, яшермә,— дип куйды ул, рәнҗегән кыяфәттә, шул ук вакытта аңа карата бераз йомшаган сыман итеп.— Чөнки ул частьта офицерның пэпэжесы булмый мөмкин түгел. Анда хатын-кызлар да хезмәт иткән. Ир-ат үзе янындагы хатын-кызга тими каламы? Хатын-кыз корыч булса да, барыбер ул аны сындыра... Ә балаң? Ә? Ә?— диде Рита янә кырысланган кыяфәткә кереп, ләкин тамагына төер утырды да тавышы кысылды, өзелде. Ул тирән кайгыра алмый, бу тышкы горурлыгы һәм хурлыгы чагылышы гына, ахры. Алмаз бернинди гаепне дә өстенә алырга теләми. Служба приказын үтәп эшләгән эшкә нишләп гаепле булсын ул. Бирелә барысын да инкарь итү тактикасын тоту ярашлы. Сөйлиләр: коммуналкада бер хатын ирен күршедәге ялгыз хатын өстеннән өстерәп төшергән. Ир исә, юк, берни булмады, дип барысын инкарь итә икән. Һәм шулай хатынын ышандырган, ди... Алмаз да аңлашуны бүтән юнәлешкәрәк авыштыра иде.

— Әйтәм бит, барысы да уйдырма!— диде.— Безне аермакчы булалар! Арага чөй кагалар! Төшенәсеңме?— Ул рюмканы аңа табарак этте.— Эч тә тынычлан! Миңа ышанмыйсың, ә ялага...— Кулын өметсез селтәп куйды.

— Димәк, мин беренче хатының түгел? Ә?—Ританың борыны лышык-лышык килде.

— Аның ни әһәмияте бар?!— Алмазның матур арпа кашлары җыерылып тырпайды, күрән йөзе агарыбрак киткәндәй булды. Аның кызып киткәнлеге сизелерлек иде.— Сине арт сан кызыксындырамыни? Единоличник! Мә, мине ашап бетер! Шуны телисеңме? Әх, егетләр. Бу яланың мине бетерүен, чабып барганда аяк чалып, егып салуы хакында уйласаң иде ичмаса! Донос миңа гына түгел, сиңа да суга бит?

— Хатының булган икән!— диде хатын, аның сөйләгәннәреннән нәтиҗә чыгарган сыман һәм ирен үчекләгән шикеллерәк итеп.

— Тьфү! Сине һаман арт сан кызыксындыра! Арт мәсьәләсендә әллә йомышый төшкәнсең инде?— Алмаз тыныч тонга күчте. Тавыш күтәрепРитаны ышандырып булмый, ул аны оялтмакчы иде.

— Булмаганны ничек язалар соң? Утсыз төтен чыкмый...

— Аңа егерме еллап узган, шул вакыт эчендә уты булса беленми калмас иде?

— Нигә хәзер генә беленгән?

— Менә аек эзгә төшә башлады! Әйдә, эч!— Алмаз рюмканы аның кулына тоттырды. Рита ихтыярсыздан иренең сүзен тыңлады. Тиз генә эчеп куйды. Закуска капмады. Бит урталарына беленер-беленмәс кенә сыек алсулык тибеп чыкты. Төсендә, йөз сызыкларында бераз тынычлана башлау чалымнары сизелгәндәй иде. Димәк, ул ирен аңлау ягына борыла бара. Шуны ычкындырмас өчен, Алмаз чын кайгысын Ритага түгәсе килгәндәй әйтте:

— Кем язуы мөмкин моны? Син бит минем «смерш»та хезмәт иткәнне белә идең. Әллә синнән ычкындымы?

— Анда ниләр эшләгәнне белми идем, син сөйләмәдең бит? Әллә миңа ышанмыйсыңмы?—Ританың озын керфекләре лепердәп-лепердәп куйды, күз кабагына яртылаш яшеренгән күзләренең агы елтырап китте.

— Үзеңә йөз процент ышанмыйсыңмы? Мин, мәсәлән, үземә алай ук ышанып җитмим,— диде Алмаз һәм тагы өметсез уфтанды. Алар, бер-берсенә туры карарга курыккандай, карашларын читкәрәк алып, тирән уйга калдылар. Алмаз башын күтәрми генә әйтте:

— Хәер, кем язуының әллә ни әһәмияте юк. Пычратып ташладылар. Ничек шул карадан арынырга, менә мәсьәлә...

Тагы уйга чумып торды да:

— Ул караны өстән юып төшереп булмаячак!— дип авыр сулады.

— Нигә булмасын, тоташ яла, дисең бит?— диде Рита, гаҗәпсенгән төстә.

— Ышанмаслар. Ышанган кебек кенә итәрләр... Мине тикшергәндә берәрсе реплика ташлый: фронтта аның хатыны, баласы булган, имеш, ди. Һәм бетте, язмыш түбәнгә төшә дә китә. Аны беркем туктата алмый. Иң фаҗигасе аның шунда...

— Ну син күпертәсең инде, арттырасың!— диде Рита катгый төстә, ул иренең ялгыш эшкә кереп китүен һәрвакыт диярлек каты гына кисәтә торган иде. Чөнки Алмаз күп нәрсәне йөрәк-хис белән кабул итүчән. Күп кенә уңышсызлыкларына шул салкын канлы була белмәү сәбәп була иде.

Алмаз аны бик таркау тыңлады, чөнки башы үзенеке кебек түгел, колак эчләре белән гөжләп тора иде. Ул авыр сукрана, уфтана башын ике учы белән тотып, үз ягына чыгып китте. Ничек аңлатма язарга инде, дип кайгыра иде. Аңа хәзер иң элек әз генә черем итеп алырга кирәк. Тән дә утын ярган кешенеке кебек ватылган, башның бөтенләй рәте киткән. Ул йокы даруы эчте дә диванына ятты.

Күпмедер вакыттан соң ул уянып китте. Башы сафланган кебек, ярсыган нервылары бераз тынычланган, чуалган уйлар да үз урыннарына кунаклаганнар шикелле иде. Йокы искиткеч дәва шул, дип уйлап куйды ул. Әмма баягы борчу тагы күңелен били башлады. Шайтан алгыры, бер генә көн дә кешечә тыныч яшәп булмый. Менә юк җирдән әллә нәрсә казып чыгардылар. Ничек итеп аңлатып язарга? Шәрехләргә кирәкмәс, пунктирлап төп хәлләрне тезеп чыгарга да, вәссәләм. Тирәнгә китсәң, шикне генә зурайтуың бар. Эх, әз генә дә ялганлый белмим бит ичмаса. Берәү булса, барысын тотып инкарь итәр иде дә бетерер иде. Ярый, үткән эзләрдән хәтер белән йөреп карыйк, мать якасына.

*Ахыры бар.*

# ШИГЪРИЯТ



**Гамил Афзал**

## Хәтер көне

Ак сакаллы ил агасы әйтер:
— Тарих юлларында абынгач,
Үткән гомер белән калган хәтер
Сатып алыйм дисәң табылмас.

Казан күкләрендә ак болыт ла,
Мәскәү күкләрендә күк болыт.
Ил өстенә золым, җәбер килде
Күк болытлар кебек күп булып.

Ачы язмыш язган безгә тәкъдир,
Имансызлык, хыянәт өчен дә—
Сөембикә үксеп елаган җир
Сафа Гәрәй кабере өстендә.

Шушы җиргә тезлән, дога укы,
Киләчәккә үтеп барышта,
Күзләреннән китсен гамьсез йокы,
Күз яше дә ачы, язмыш та.

Хәтер көне, хәтерлә син, дөнья,
Канга баткан Идел үзәнен,
Мескен булып торган биш йөз елда
Тәкъдир безне ничек изгәнен.

Офыкларың тулы кара болыт,
Утлар-сулар кичкән арслан,
Сулышларың чыга сөрем булып
Эчеңдәге кайгы-сагыштан.

Басып алучының бите ыштыр,
Эче тулы агу, мәкер, хәйлә.

Былтыр кысылганга быел кычкыр,
Тавышың бар чакта кычкыр, әйдә!

Елга булып шушы җиргә сеңгән
Татар милләтенең күз яше.
Чәчәк атып яшәгән дә сүнгән
Мәскәү тәхетенең көндәше.

Денсезләргә бөтен нәрсә сатлык,
Ил намусы синең иңсәдә,
Йөрәгеңдә булсын изге сафлык,
Кырык Иблис каршы килсә дә!

Урам тулы өелеп мәет яткан,
Сугыш кыры булган бу урам.
Ил намусын саклап уклар аткан
Бабаларың белән горурлан!

## Театрда

Көрәш вә дәрт, акыл вә хис, горур караш, бөек сүзләр...
Серле утлар кабынган кич, затлы кием, сылу йөзләр.

Һәр пышылдау, һәр елмаю тирән мәгънә тулы монда,
Саф мәхәббәт, усал мәкер чәбәләнгән кызык дөнья.

Матур җырлый, матур көлә мәхәббәт тә, хыянәт тә,
Ак Фәрештә, Кара Елан хәрәкәттә, һәлакәттә.

Сәмум исте, давыл узды, күкләр күкрәп, җаннар тетрәп.
Нәфрәт белән каннар кызды, ялкын белән тулды күкрәк...

Халык китте, утлар сүнде, тынып калды бу кичәләр...
Ак Фәрештә, Кара Елан бергә утырып чәй эчәләр.

Ак Фәрештә белән Кара Елан
Бер өстәлгә утырып чәй эчтеләр,
Җәфалана торгач тулды план,
Дөнья хәлләренә керештеләр.

— Сабировлар яңа фатир алган.
— Безгә чират җитми, аларга бар...
— Тигез хокук дигәннәре ялган,
— Кая таба бара бу дөньялар...

— Шекспиргә аңа рәхәт булган,
Язган-сызган, умырып акча алган,
Менә мин утыз ел Кара Елан,
Сәхнәдә дә, тормышта да ялган...

## Гөлмәрфута

Яшь чирәмдә вак-вак атлап йөрисең дә,
Мыек чыккан егетләрнең күзе синдә,
Нәзкәй билләреңне бөгеп бардың суга,
Кайсы чорда яшәдең син, Гөлмәрфута?

Авыл кызы, үзең эшчән, үзең чибәр,
Кара бөдрә чәчләреңне тарап җибәр,
Кем сокланмас алма битле кара кашка,
Ниләр килеп, ниләр китми япь-яшь башка!

Агач сука басу сөргән заманнарда,
Даның киткән Уфаларга, Казаннарга,
Суга бардың, судан кайттың, Гөлмәрфута,
Су юлыннан килеп кердең безнең чорга.

Урак белән арыш урдың, Гөлмәрфута,
Тезеп-тезеп зурат куйдың, Гөлмәрфута,
Күл өстендә аккош кебек йөзеп кенә,
Чорлар аша килеп кердең безнең җырга.

Рәхмәт сиңа, мәңге яше, Гөлмәрфута!

## Завод кызына

Яшьлек елларыма урап кайтам
Сары яфрак койган күзләремдә.
Зәңгәр күзле, сылу завод кызы
Сынап карый кара күзләремә.

Син карама миңа өмет итеп,
Мин барыбер юньле кияү булмам,
Мине татлы сүз газабы көтә,
Шигырь иле дигән кара урман.

Ул урманда кошлар сайрап торыр,
Пәйгамбәрләр көтәр үгетләргә,
Анда Җәллад балта кайрап торыр,
Минем кебек чибәр егетләргә.

## Кызык заман

Әй кызык заманда яшәдек:
Алданып, таланып, дәшмәдек,
Симерде уйнаш та әшнәлек.

Әй кызык заманда яшибез:
Азатлык уятты халыкны,
Иманлы йолдызлар калыкты.

Әй кызык заманда яшибез:
Бәйгегә, көрәшкә без әзер,
Көнлекче булмыйча кемгәдер.

Әй кызык заманда яшибез:
Җыелдык, шауладык, гөрләдек,
Өметләр уятты бергәлек.

Әй кызык заманда яшибез:
Айкала, чайкала дөньялар,
Кайнаган төшендә без дә бар.

Әй кызык заманда яшибез:
Безгә дә елмайды пәйгамбәр,
Ватаным өстендә күк зәңгәр...

## Шәп халыклар

Рәсәй акчасының хурлыгына
Ачу, оят белән җан сызлана.
Иң акыллы, бөек культуралы,
Шәп халыклар идек бу дөньяда.

Шәраб эчә-эчә мие түнгән,
Берсен-берсе сүгә һәр дивана.
Бөек Дәүләт дигән даны сүнгән,
Болганчык су кебек еллар ага.

* * *

Бик әз генә мөстәкыйльлек татып,
Иң акыллы шигырь язар вакыт,

Язылмый гына шул бер сүз дә,
Нинди булыр уңыш бу көздә?

Нинди булыр көзге үзгәрешләр,
Юлбашчылар, җитәкчеләр нишләр?

Елмаеп һәм матур сүзләр сөйләп,
Алып китмәсләрме артка сөйрәп?

Һай, күңелләр тулы борчулар,
«Акча җитми» дигән чыр-чулар.

## Онытма

Балтыйк суларында йөзәсеңме,
Сахалинда балык сөзәсеңме,
Чиләбедә чуен коясыңмы,

Хәтта бозлы, салкын котыпта
Туган якларыңны онытма!

Бик боексаң, чык та япан кырга,
Туган якларыңның җырын җырла:
Галиябану сылуым иркәм, диген,
Озакламый кайтып җитәм, диген,
Хәтта бозлы, салкын котыпта,
Татар икәнеңне онытма!

* * *

Оҗмах бакчасыдай илдә туып,
Тозын ашап золым-җәбернең,
Кулларыңны күкрәгеңә куеп,
Кайларда ятасың, кадерлем!

Үтеп чыкмас кара урмандыр, һәй,
Төз наратлар карап торгандыр,
Хуш, бәхил бул, адәм баласы, дип,
Бозлы җилләр дога кылгандыр...

* * *

*Вакытында җирне селкеттек...*
Г. Тукай.

Заманында җирне селкеткәнбез,
Күңелле булгандыр «селкетү»,
Аннан ары артка киткәнбез дә,
Сарыклар булганбыз бер көтү.

Үзгәрергә сәбәп булгандыр ул,
Кимсенергә сылтау булгандыр —
Тарих төпкелендә томандыр ул,
Офыклары — кара урмандыр...

## Хәзерге «демократлар»га

Трибунадан акыллы сүз кычкыр,
Шәп пәйгамбәр диеп уйласыннар,
Күзләр усал сезнең, битләр — ыштыр,
Канатсыз лачыннар.

Сүз уйнашын уйнаучылар зирәк:
Матур яшәгәннәр патшалар,
Дача кирәк, мерседеслар кирәк,
Власть тирәсендә акча бар...

## Милли хис

Тормышның караңгы почмагы
Яктырды, балкыды син килгәч,
Кабынды мәгънәләр учагы,
Кемнәрнең йөрәге җилкенмәс!
Уянды «Без» дигән горурлык,
Дөньяның барышын борырлык.

* * *

Мактанып йөрмәдең, тыйнак син,
Өметсез шайтаннан ерак син.

Сиңа да һай-һаулап эт өрде,
Синең дә «Мин»нәрең мең төрле.

Шәм тотып барырга кирәк син,
Тынгысыз җаннарга терәк син.

## Бабай әйтә

Бабай әйтә: — Чәчтек, урдык,
Арыш, бодай, борчак инде.
Илле ел сугышсыз тордык,
Тагын йөз ел торсак иде!

Сөеп иссен сахра җиле,
Иген үскән офыкларда.
Курыкмый яшәсә иде
Балалар да, оныклар да!

* * *

Кая барганыңны белер-белмәс,
Башың иеп йөрдең иләс-миләс.

Күп иснәдең төтен һәм газ исен,
Чәчәк исен бөркетеп җилләр иссен.

Нигә сиңа бу ясалма аксым,
Үз кануны белән сулар аксын!

## Болытлар таралгач

Башлары әйләнеп алкыштан,
Юлбашчы агайлар ялгышкан,

Ышанып ялагай куштанга,
Тәкәббер мин-минлек кушканда.

Болытлар таралгач таң белән,
Без моны аңладык аң белән:
Һавалы, мәкерле дан белән,
Тарихлар язылган кан белән...

## Җавап

Миндә егетлек юк инде,
Сабыйлык та картлык.
Сәяси жулик булганчы,
Сабыйлыгым артык.

Җырласаң да, еласаң да,
Барыбер үтә еллар.
Барыбыздан да акыллы
Хуҗа Насретдин бар.

## Сәяси төш

Мин төшемдә шәп сарайда торам,
Кесәләрем тулы алтын-көмеш,
Патшабикә миңа гашыйк булган,
Зар-интизар булып тора, имеш.

Шат елмаеп әйтә чибәр ханым:
— Революция ясый күрмә, җаным,
Герой булып йөрү ямьледер дә,
Тик азагы матур бетми аның...

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



**Тәлгат Галиуллин**

# КИЯҮ

хикәя

Бу юлы да бәла, көтүдән артта калган сарыкны ботарлаган бүре төсле Сәгыйрне көтмәгәндә, уйламаганда каптырды. Әйе шул, капылт чыгып котырынган бураннан соң туган тынлык озакка бармый икән...

Ике бүлмәле фатирының йозагын ачканда ул картларча шактый мәтәште. Ачкычын тишегенә туры китерә алмый интектеме, әллә күңеле нидер сизенеп, юри суздымы вакытны — кистереп әйтү кыен.

Буялган агач идәндә чүп-чар, чүпрәк-чапрак ауный. Тентүчеләр булган яисә караклар нәрсәдер эзләгән, диярсең. Гадәттә, ашыгу дигән төшенчәне бөтенләй белмәгән ир выжт итеп өстәл янына үтте. Шакмаклы кәгазь битенең читенә ике генә җөмлә төшерелгән: «Сәгыйр, рәнҗеп калма, безнең арттан килмә, оныт! Кызым белән бөтенләйгә авылыбызга кайтып киттек. Әсма».

Язуны кулына алды да, лып итеп аксыл тышлы иске диванга сеңде. Күз аллары караңгыланды, күңеле болганды, миен хәвефле уйлар каплады. Димәк, ул янәдән карт буйдак булып калды. Икенче хатыны да ташлап китте. Иртә уңмаган кич уңмас, ди шул халык. Бәхетсезлек беренче өйләнүдән башланды.

...Мәзәк кенә булды аның гаилә башлыгы дигән югары дәрәҗәне алуы. Аксубай ягында туып-үскән мишәр малаен хәрби хезмәткә Украинага, төп-төгәле, Львов шәһәренә җибәрделәр... Унҗиденчесен тутырганчы район үзәгеннән узмаган үсмер өчен барысы да кызык иде биредә. Һич кенә дә авыл тормышына охшамаган кырыс тәртибе, ефрейтор, сержантларның әфисәрләрдән дә хәтәр кыланып, борынны иләм чөеп йөрүләре, сүтелә-җыела торган автоматлары, тимер кашык, кружкалары — һәммәсе аның өчен үзгә бер яшәеш, яңалык иде. Казармалар янында ук парк,

---

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН (1938) — *әдәби тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы, профессор, күпләгән китаплар авторы. Казанда яши.*

спорт мәйданчыгы, менә дигән клуб чекерәеп тора. Юллары бөлеш табасының асты кебек тигез, такыр. Аны асфальт диләр икән.

Иртә торып, соң ятырга өйрәнгән, иркә шәһәр тормышы белән бозылмаган авыл егетенә тәртипкә күнегүе артык кыен булмады. Әмма яшьлеген терлек абзарында, утын әзерләп һәм печән чабып үткәргән Сәгыйр спорт уеннарын кыен үзләштерде. Турникта тартылуын, боргалануын, йөгерүен, акрынлап җиңде. Тик коңгырт күн белән тышланган, җитмәсә җене сөймәгән хайван исеме белән «кәҗә» дип аталган нәрсәне сикереп чыга алмыйча иза чикте. Илләм йөгереп килә, гәүдәсен куллары белән этеп җибәрә һәм... шып итеп «кәҗә»нең биленә утыра. Әйтерсең лә анда ат ияре тора. Яшьли шунда уйнап үскән, өреп тутырылган футбол тубыдай беләкле хохол малайлары җиргә ятып көлә. Аларга ни.

— Татарин ишәк дип белә аны. Шуңа атланып базарга йөрергә өйрәнгән инде ул, нишләсен.

Татарстан халкының ишәк дигән хайванны Хуҗа Насретдин турындагы фильмнарда гына күрүен аңлатып буламыни ул тинтәкләргә. Урта Азия халкы да һәм татар, башкорт, чуваш, ар, мукшы да — алар өчен барысы да бер милләт шул.

Җансыз, йонсыз, шәрә «кәҗә» Сәгыйрнең шәхси дошманына, тик барыбер баш бирергә тиешле Памир пигына әйләнде.

Сирәк эләккән ял мизгелләрендә, солдатлар әниләренә, сөйгән ярларына хат язарга утыргач яисә ләчтит сатарга керешкәч, Сәгыйр шыпырт кына урамга чыгып китә. Максаты: «кәҗә»не җиңү. «Җаныем, бәгырем, сикертеп чыгар сыртыңнан. Ыштан артыннан тартып утыртма инде, житте», — дип бисмилласын кат-кат әйтеп, янәдән уңышсыз тәҗрибәләр ясый.

Ләкин чит як «кәҗә»се аның догаларын кабул итми, мөселман баласының хәленә керми. Магнит тыкканнар диярсең эченә!

Сәгыйрнең җене котыра башлады. «Адәм хуры, кеше күзенә ничек чалынырсың. Орчык хәтле үзбәк малайлары ялт иттереп сикереп чыга. Төп төз басып, ачу китереп, кулларын бот буйлап сузып куярга да өлгерә... Ә мин — пешмәгән, старшина дөрес әйтә, ясалып бетмәгән».

Егет ераккa ук китеп, җан-фәрманга йөгереп, куллары белән бар куәтенә этеп, тегенең өстеннән ялт итеп үтте бу юлы һәм коры җиргә йөзе белән барып кадалды. Күккә баксаң — күк ерак, җиргә егылсаң, туфрагы каты икән шул бу якларның. Борыныннан шарлап кан китте.

Дөньяда тылсым булуга ышанырга туры килде шул көнне. Кемнеңдер йомшак, көчле кулы аны беләгеннән тотып, аякка бастырды. Бакса: янында чуар спорт костюмы кигән илаһи бер кыз елмаеп тора. Каян килеп чыккан ул? Тирә-юньдә адәм заты юк иде кебек.

— Әллә егылдың инде, солдатик. Авырттымы? Тешләрең исәнме?

Егет телсез калды. Күзләре кызның битен бизәгән елмаюлы чокырчыкларга, тулы иреннәргә, коңгырт чәчләргә текәлде. Гомерендә беренче тапкыр мондый гүзәллекне күрүе иде Сәгыйрнең.

— Юк, — дигән булды, ниһаять, егет, шаяртуны аңламыйча.

Изге җан, фәрештә аңа кечкенә ап-ак кульяулыгын сузды.

Егет чүпрәкне кулында изгәләгән, борынына якынлаштырган арада, кыз кискен карарга килеп, карышырга урын калдырмаслык итеп:

— Әйдәгез, безнең өйгә кереп юынып алыйк! Старшинагыз күргәләгәнче авариянең эзләрен юкка чыгарыйк.

Сөйләшеп киттеләр. Сүз — кешене таныштыру өчен ярaтылган нәрсә, кыз — Светлана исемле икән. Физкультура техникумын бетергән, хәзер мәдәният сараенда тренер булып эшли. Солдат казармалары янындагы өч катлы кирпеч йортта гына икән фәрештәнең торган җире.

— Әни, бу чибәр солдатик борынын канаткан, юынып алсын әле.

Урысчасына караганда, әткәйнең якташы булырга охшый.

Кызның әнисе Феоктиста Петровна кунакны ихластан кабул итте, тәмле вареньe белән чәй эчерде. Көтмәгәндә, уйламаганда шактыйга

сузылды кунаклы уйнап утыру. Кичке энгердә шап-шап атлап, уртача буйлы, таза, базык буйлы, киң битле ир килеп керде. Җилкәсендә олы бер йолдыз.

Әфисәр белән очрашкан солдатның беренче хисе курку була. «Губага (гауптвахтага) озатмагае»,— дип уйлап алды Сәгыйр дә.

Майор абый Светаның әтисе икән, тумышы, чыгышы, килеше белән Себер татары булып чыкты. Башка командирлар кебек тырт-пыртланмыйча, егет белән иплəп, малае белән фикерләшкән сыман сөйләште күрше батальон хуҗасы.

Кешенең сынына, дәрәҗәсенә карап кына аның үткәнен белеп булмый. Биктимер агайның тормышы да үзе бер укылмаган китап икән. Язмыш аны, боз арасында калган бүрәнәне сыткан төсле, шактый талкыган, изгән...

Ул Омск өлкәсендәге бик борынгы бер татар авылында туган. Әтиәнисен хәтерләми. Гражданнар сугышы вакытында — Колчак баскынчакларымы, кызыл зәхмәтләрме — хәзер ул хәтлесен берәү дә әйтә алмый, әтисе мулланы һәм абыстайны да атып китәләр. Биктимер балалар йортында үсә, Суворов мәктәбен тәмамлагач, Казанның танк училищесында белем ала. Сугышта катнаша.

Гел күченеп йөрешле чегән тормышына, көпчәк өстенә ияләшеп беткән инде ул. Оренбург өлкәсендә хезмәт иткәндә өйләнә, беренче балалары — малайлары үлә, кызы исә Казагыстанда хезмәт иткәндә туа.

Кызык хәл: майор әүлия идеме, әллә оста оештыручы булып чыктымы, алла белсен, әмма шул көнне үк, ул кунак егетенә, алтын тешләрен елтыратып, шаярткан булып, «кияү» дип эндәште. Раска чыкты тәки шаяртуы. Өйдә Феоктиста Петровнаның бәхәссез хуҗа булуы күренепсизелеп тора. Ишекне-түрне бер итеп, зил-зилә кебек йөри. Сүзгә колак салып, юнәлеш бирергә дә өлгерә.

Сәгыйр үзе дә Светлана белән очрашуны көтеп кенә торды. Ә бер мәлне паркта сәрхүшләнеп йөргәндә, егет бар булган, авылдан килгән запас кыюлыгын җыеп, кызны барган җиреннән туктатып, үз ягына борып, кулларын биленә салды. Яңакка сылар дип өреккән иде егет, киресенчә булды: тегесе, шуны гына көткәндәй, гәүдәсен йомшартты, өлгергән чиядәй кызыл иреннәрен Сәгыйргә сузды. Егет калтырана-калтырана кызның иреннәренә «ябышты». Тәненә рәхәт калтырану йөгерде.

Дөресен әйткәндә, беренче үбешүе түгел иде аның. Авыл кызларының иреннәреннән, битләреннән, борыннарыннан авыз иткәләгәне бар иде. Тик ул кыргыйларны рәхәтләнеп иркәләп булмый, бөтен тәмен бетереп, сугыша, чеметә, тырный, тарткалаша башлыйлар. Ә шәһәр кызлары башка камырдан ясалган икән шул... Әнә үзе суырып-суырып үбә, кочаклый, аркадан, җилкәдән, муеннан сөя...

Татар кешесе матур сүзләр әйтергә ояла. Табигате шундыйрак аның. Шулай да Сәгыйр «нинди матур син, назлы син, мин сине яратам»... кебек сүзләрне күңеленнән кысып чыгара алды. Артыгына көче дә, хыялы да җитмәде.

Сәгыйргә казармада да мөнәсәбәт үзгәреп куйды. Аны бәдрәф чистартуга, кухняга эшкә билгеләми башладылар. Бу шәфкать нурын булачак бабасы оештырганны егет соңрак кына абайлады. Света белән урамнарда, бакчаларда күренгәли башлагач, бервакыт аны көпә-көндез, таныш булмаган ике «кабих» туктатты. Берсе каршыга басты, икенчесе янга чыкты.

— Сүз бар,— диде алда торганы, дорфа гына итеп. Икенчесе аяк астына китереп тондырды. Әмма Сәгыйр аякта калды һәм читкә сикерергә өлгерде. Бүтәнчә сукмадылар.

— Света янында башка күренмә. Безнең кадр ул. Килмешәк солдат өчен карап үстермәдек без аны. Үзеңә үпкәлә, яшисең килмәсә...

Тагын нәрсәләрдер әйтеп, янап, тәмләп көлештеләр дә, ашыкмыйча гына китеп бардылар.

Артык кыю кеше булмаса да (ни әйтсәң дә, чит-ят җир), Сәгыйрне кыз янына йөрүдән туктата алырлык көч юк иде дөньяда. Күнеле гел шунда тартты, аяклар гел шул якка сөйрәде.

Егет үзен тукмап ташларга җыенуларын берәүгә дә әйтмәде. Дөрес, бу юлы борыны канамады. Әмма гарьләнде. Данлыклы совет армиясе солдаты үзен ике мужиктан кыйнатып торсын инде! Тузга язмаганны.

Бума елан җылы куенга керү юлын яхшы белә. Кыз аны яратуы, авылда яшәргә, татарча өйрәнергә риза булуы турында туктаусыз искә төшереп торды. Хуҗалар да егетне бик яраттылар. Тыйнаклыгы, оялчан елмаюы, дөньяга сабыйларча каравы, солдат боткасыннан туйган булса да, бик аз ашавы өчен яраттылармы шунда... Әллә җыйнак кыяфәте хуш килдеме? Сәгыйрне артык матур дип, килеш-килбәте шәп дип кемнедер ышандыруы кыен. Махсус белеме дә юк. Бар гыйлем байлыгы — авыл урта мәктәбе.

Ә кызның аңа җылы мөнәсәбәте турында әйтеп торасы да юк. Бусаганы узуга, әнисе алдында ук, аның муенына сарыла, шашып-шашып иркәләргә, битен, иреннәрен үбәргә тотына. Үз эченә бикләнгән, авыл әхлагында тәрбия алган Сәгыйр әүвәл бик оялды, тартынды, әмма иләсләнде, ә аннан күнекте. Бәлки, шулай тиештер. Адәм баласы иркәләүгә тиз иялэшә бит. Һич гаепсезгә аяк астына сугуга гына өйрәнүе кыен.

— Әнкәй, карале, Сагирчикның күзләре нәкъ грек аллаларыныкы кебек икән,— дип, егетне тәрәзә ягына борып куя кыз җиңеннән тарткалап.

Бу чагыштыруның мактаумы, әллә көлүме икәнен аңламый әле ул. Әмма күңелендә кала. Алла хәтле алланың күзе иләмсез була алмастыр, дип уйлый.

Соңрак, шәһәр уртасында Зевска куелган һәйкәл янында үрә катып озак матавыкланды Сәгыйр. Алга чыгып торган, төссез, вә ләкин мәгънәле, ышанычлы, мәгърур иде грек алласының күзләре. Бармаклары белән үз күзләрен дә капшап карады. Охшашлык тапты. Светланага рәхмәтле иде егет.

Өйләнешүләре сәеррәк булды. Танышуларына ике ай булганда, бергә яшәп киттеләр.

Җылы тойгылар, матур, килешле сүзләр кыз ягыннан иңде.

— Бу бәхетле мизгелләр мәңгелек булсын иде, җаным, без гомерлеккә бергә булырга тиеш,— диде кыз, үбешеп туйгач.

— Кстати, бүген төшемдә газиз әниеңне, әниебезне күрдем. Ул безнең мәхәббәтне хуплады.

Көтеп-көтеп тә Сәгыйр авызыннан «а» ягына да, «б» хәрефе тарафына да җылы сүз чыкмагач, кыз томанлырак әйтелгән кинаяләренә ачыклык кертергә булды.

— Гомерлек юлдашым бул, Сагирчик. Өйләнешик! Мин сине бәхетле итәрмен. Пар күгәрчендәй гөрләшеп яшәрбез.

Сүз дә юк, Сәгыйр кызны үлепләр ярата. Татарча ләм-мим бер сүз белмәсә дә, яртылаш безнең халык каны гөрли бит үзендә. Бик рәхәт аның белән. Вакытның узганын сизми дә каласың. Әмма шундук өйләнү, солдаттан никахлы хатын белән кайтып төшү — егетнең башында тәмам укмашып, тәгаенләнеп беткән фикер түгел иде. Чөнки язылышуны ул олы нәрсә дип саный.

— Өйләнү — уен эш түгел. Без әле бер-беребезне бик аз беләбез. Службаны бетерәсе... Югары белем алу хыялым да бар...— дигән булды егет.

— Соң! Мин берсенә дә каршы түгел, күгәрченем. Син укырсың, мин эшләрмен. Һәркөнне кочагымны җәеп, елмаеп каршы алырмын.

— Мин биредә кала алмыйм. Татарстанга кайтырга исәбем. Анда минем әни, абыйларым.

— Мин синең белән, Сагирчик, җәһәннәмгә китәргә дә риза. Туйдым казармалардан, гарык булдым солдафоннардан. Китәбез булгач, китәбез!

Кызның әти-әнисен ташлап, мәми авыз авыл малаена ияреп, билгесезлеккә чыгып китәргә риза булуын чын сөюгә юраган Сәгыйр томаулы борын кебек йомшый барды. Мәгәр аның инде төмен татып өлгермәгән ирекне тиз генә югалтасы килмәве дә табигый иде. Гаилә йөгенә бер җигелсәң, тәртәне ташлап чыгу килешми.

Сүз шул тирәгә җитеп, түмгәккә төртелгәч, ачык ишекле күрше бүлмәдән ата кеше килеп чыкты. Гафу мазар юк.

— Сәгыйр, мин сине үлгән улым кебек якын иттем. Син озак яшә. Һәм яшәрсең дә. Биредә хатын-кыз бик аз. Хөрмәне өзеп кабарга теләүчеләр, кызымның артыннан сөйрәлүчеләр бинаһая (ул аны урысча до...дип әйтте). Эшсезлектән үзләрен кая куярга белмәгән ырдыктай ирләрнең шәһәрчектә бик күп икәнен онытма. Ә мин Светушкамның синең белән булуын, кияүгә татар егетенә чыгуын телим. Ә инде өйләнергә ниятең булмаса, эч пошырып йөрмә. Бу бусаганы үз аягы белән атлап кереп, кәҗә кебек чыгып киткәннәр булгалады, дустым.

Тагын шул каһәр суккан «кәҗә» дип уйлап та өлгермәде Сәгыйр, Биктимер ага бәхәсле мәсьәләне хәрбиләрчә чишеп тә куйды.

— Тәк. Теге атна ахырында туйларбыз. Әзерләнү, аш-су якларын үз өстемә алам. Башка тарафлардан да кайгы-хәсрәт күрмәссең,— дип вәгазь сөйләп ташлады булачак бабасы.

Шактый төшереп алганлыгы сизелә иде аның. Шунда егетне акылын җуйган бала хәленә калдырган бер хәл булды. Майор, сөйләшүеннән кинәт туктап, Сәгыйргә якын ук килде дә, саллы кулын өстәл артында боегып, куркынып утырган мәхбүснең баш түбәсенә куйды. Турсайган күзләрен хатынының тәресе торган почмакка кадады:

— Хәзер минем кул аша бөтен тәнемнең, нәселемнең биокуәте, Гумилевча әйтсәм, пассионарлык көче синә күчә. Сизәсеңме, тәнең чемердиме? Каның сикерәме, нерв күзәнәкләрең чытырдыймы? Дөрләп янсын!.. Бу, кияү, шәрыкъ фәлсәфәсе буенча, рухи якынлыкка ирешү була. Көчем хан нәселе белән туганлашуың бу, энем...

Егетнең гәүдәсе хәлсезләнеп, салынып төште, зиһенен гасырлар эңгере каплады. Тәкъдирдән узып булмый икән. Ул кияү булырга риза иде.

Беренче март көне килде. Һава җылы, гөрләвекләр ага, тамчылар тама, кояш кышкы йокыдан сулыккан битләрне иркәли, тәнгә тормыш, яшәү дәрте сеңдерә. Ә Биктимер агай фатирында дус-иш туйлап ята. Сәгыйрнең әтисе сугыштан кайтмаган иде. Әнисе, абыйлары килә алмадылар. Бәлки, егерме яшьлек малайның телеграммасын җитдигә дә алмаганнардыр. Шау-шулы мәҗлестә кияү ягыннан Сәгыйр үзе генә булды.

Төн уртасында кунаклар таралышты, яшьләрнең үзләрен генә калдырып, ата-ана иптәшләренә киттеләр.

Зөфаф киченда ни-нәрсә эшләргә һәм үзеңне ничек тотарга икәнлекне егет ишетеп, укып аз-маз гына чамалый иде. Бит әле авыл ирләре, дөнья күргән солдатлар сөйләгәнне ыржаеп тыңлап тору бер хәл... Ә монда... Авылда рәхәт ул. Мунчага озатып куялар да, бетте-китте. Ә анда эссе, караңгы... Чишенмичә юынып булмый.

Югары әхлаклы, суфый татар әдәбияты яшьләрне бу тормышка әзерләми. Мәктәптә дә сыйнфый көрәшкә багышланган, ярлы-ябаганы күтәргән, дошманны фаш иткән әсәрләр генә өйрәнелә. Ә хатынның беренче төндә үк сыйнфый дошман була алмый ич инде.

Сәгыйр хуҗаларча кыйланып, күлмәген, майкасын еракка атып бәрде. Светланасы үзен чишендерергә бирмичә интектерде. Егет буталды, калтыранды, ахыр чалбарын салырга оныткан булып чыкты.

Иренең халәтен аңлаган кәләше инициативаны үз кулына алды, назлады, иркәләде. Сәгыйр өчен дөнья, түшәм, идән, тәрәзә томан эчендә

калды. Зиһененең бер кырыена «кирәк түгел, авырттырасың... ашыкма» кебек татлы сүзләр генә эләгеп калды. Чынында егет һушын, зиһенен югалтты. Бәхет оҗмахында тоныкк күзеннән очкыннар чәчелде.

Иртән уяныл, сөеклесе башын беләгенә салгач кына, хатын-кыз белән йоклауның никадәр рәхәт булуы турында уйлап алды. Солдатның хәтер капчыгында бу ләззәткә тиңләшә алырлык чагыштыру табылмады.

Алдагы тормышларында да Сәгыйр хатынының тәнен яратып яшәде. Мәгәр кадерлесенең женси осталыгын, маһирлыгын, тәҗрибәсен тиешенчә бәяли алмады. Хатыны ятакта ни кыланса да, шулай булырга тиеш дип фараз кылды.

Фани дөнья әшәкелегеннән хәбәрдар булмаган авыл малае бәгырькәенең чәчәк таҗы күптән ачылган икәнлеген аңышмый калды. Күпер башында тәкә сөзештермәгән, әтәч сугыштырмаган чит-ят кешеләрнең үзен ни өчен кыйнап ташларга омтылуларын да аңламады бахыр.

Аннан соңгы вакыйгалар Сәгыйргә бөтенләй аңлашылмады. Яшьләр йокы бүлмәсеннән аш өстәле янына чыккач, кызның әнисе олы гәүдәсе өчен ифрат җитезлек белән бүлмәгә үтеп, тиз генә урынны җыештырды, астагы киндер җәймәне таза, кыска беләгенә салып, урамга алып чыгып, керләр элә торган зур бауга салындырып куйды. Җәймәне уртасына җәелгән кызыл зур тап бизи иде. Әйтерсең лә өстендә кара тавык суйганнар. Чүпрәк көне буена рейхстаг түбәсендәге әләм төсле, җиңү билгесе булып җилфердәп торды. Биктимер ага батальонын да шул тирәдән честь бирдереп уздырган, дип сөйләнде усал телләр.

Сала баласы, үгез кебек, тик күзен челәйтеп тора кызыл тамга каршында. Светлана дустанә генә аңлатып бирде:

— Әни моны шик-шөбһәгә, гайбәт-тыкшынуга урын калдырмас өчен эшли. Үзем кияүгә чыккач та, шулай элеп куйган идем, ди.

Кызның әтисе динен, телен оныткан мөртәт булса да, кендекне төен белән бәйләп кую дигәндә эшне коры тотты. Хәрби шәһәрчекнең үз ЗАГСы бар икән. Чират-фәлән юк. Яшьләрне шунда алып төшеп, паспортларына тиешле мөһерләр суктырды. Әфисәрләр тәртип ярата.

Загрединова, шулай итеп, Шарифуллина булып китте. Атасының исеме дә күптәннән бирле Биктимердән Бориска әйләндерелгән икән инде.

Солдатикның соравына кызның җавабы әзер:

— Детдом баласы бит ул. Исемен үзгәртмәгән булса, әни аңа кияүгә дә чыкмаган булыр иде. Барыбер түгелмени...

Тәртәгә кертсәң, кәҗә дә ат кебек кешни, диләр.

Соңрак абыйлары «кыз идеме соң хет», дип бәйләнгәч, «белмим тагын, простыня кып-кызыл иде» дип җавап бирә торган булды.

Олы тормыш өчен адәм баласы диңгездәге бер йомычка гына, бөтереп ала да, ярга китереп ташлый. Баллы, татлы көннәр үтеп китте. Киләчәкне билгеләү вакыты җитте.

Сәгыйр гомерендә беренче тапкыр күңел җәрәхәте алды. Беркөнне казармадан хәләл җефете янына барганда, янәдән үзенә суккан шайтан күсеֆләрә очрады. Таныды. Тегеләр бәйләнеп маташмадылар.

— Татарин Пышку отхватил,— дип артыннан көлеп кенә калдылар.

Мопассан «пышкаларыннан», женси бозыклыктан хәбәрдар булмаган ир, һәрхәлдә, колагына иңгән бу сүзләрне бәхетеннән көнләшү, кызыгу дип юрады. Үзләренә тәтемәгәч...

Мужиклар хаклы. Аның Светушкасы гәүдәсе-сыны белән бик тә, бик тә «пышная», теләсә кайсы ирне аңгы-миңгә китерерлек. Күлмәк изүен борчып торган, чүпрәле камыр кебек күпереп өскә калыккан тулы, ак күкрәкләрен аласыңмы... Җилкәләре дисеңме... һәммәсе туфрактан чыгып, язгы кояшка чекерәйгән йомран башлары кеби күтәрелеп тора. Туктаусыз сыйпыйсы, иркәлисе килә үзләрен. Билдән түбәнрәк өлешләре, өлгергән кабаклардай артка чыгып, эмсендереп, күңелне кытыклап тора. Төз, матур аякларда калган комсыз карашларны санап бетергесезләр...

Шул мизгелдә аның башына шук фикер төште. Хатынының уйнап торган арт саннарын, хәрәкәтчән гәүдәсен туган авылы пожаркасы янында җыелган ирләргә күрсәтәсе иде. Аларның мул гәүдәле, бигрәк тә су тулы көянтәле чиләкләр белән яннарыннан узып киткәндә хатыннарны ничек эмсенеп, сагыш тулы ач күзләр белән озатып калуларын хәтерли. Малай чакның хәтере «тырнаклы» була. Бер нәрсәне дә онытмый.

Сәгыйрнең хәләл җефетен шуларга күрсәтеп, тамак төпләренә төелгән төкерекләренә тыгылдырасы килде. Матур тәпиләрен песи кебек йомшак итеп куя белүләрен дә онытасы түгел. Куе чәчле башны ап-ак муен, үз бәясен белеп, горур йөртә. Тойгылы иреннәре, очы мендәрле бармаклары да «пышная» сүзен тәфсилләп тора.

Дөрес, елтыр күзләренең төсен билгеләве кыен. Иртән алар күгелҗем, шунда ук кырыйларына карасу төсмер йөгерә, кичен исә яшел сурәт өстенлек ала... Хуҗасының кәеф сихәтләренә карап үзгәрә күзләре.

Әйе, Света күп яктан килгән. Әмма табигать матурлык үрнәген иҗат итүдә күрелмәгән яңалык ачмаган. Сискәндерерлек түгел аның хатыны. Килешле гәүдәне битнең артык җәенке, иркен, тулы булуы бозып тора. Әтисе нәселе җиңгән. Аксубай якларында «чәпәк бит» диләр андыйларны. Агымсу басмасында салкын керне тәпәли торган, асты шома агачтан чыккан сүз.

Соң, егетем, һәр ягы спай, кәртинкәдән төшкәндәй гүзәл булса, ул сиңа тәтер идеме? Авызыңны, телеңне ял иттереп, шул хакта башың белән уйлап кара!

Менә синең кай җиреңә дә, нәрсәңә кызыкты икән әфисәрнең йөрәк парәсе? Уен «кәҗә»се янында адәм хуры иткән боламыклыгың мәхәббәт хисен дөрләтеп җибәрдеме күңелендә? Үзеңә кара да, аңа бак! Аерманы сизәсеңме?

Егет, бабасы өендәге коридор көзгесе каршысына басып, үзенең төс-кыяфәтенә игътибар күрсәтүне кирәк тапты. Уртача биеклек, татар өчен бик үк табигый булмаган саргылт-аксыл чәч, тар, ияктә бөтенләй гаип булган чырай, зур маңгайдан тамырланган туры кылыч борын, иреннәре эчкә бөгелеп кергән җыйнак авыз. Сакал-мыек рәтләп үсми торган иркә тире. Алга чыгып торган соры «алла» күзләре...

Ямьсез, шөкәтсез зат дип үк бәяләргә җөрьәт итмәсә дә, үзен бик ошатмады Сәгыйр. Хыялында хатыны белән янәшә куеп карады үзен. Чагыштыру аның файдасына чыкмый. Кем соң аның гомерлек юлдашы?.. Тагын шул сораулар аның миенә кырмавык кебек ябышты. Алардан коткарырлык көч юк иде сыман дөньяда.

Нигә дип мине сайлады икән бу кызый гомерлек юлдашы итеп? Татар булганы өченме? Әтисенең йогынтысы җиңдеме? Берни аңламый. Әтеге юньсезләрнең «безнең кадр», «пышная» кебек сүзләрен ничек аңларга?

Чынында, язган ризык кебек тешен сындырып, үз ихтыяры белән куенына сеңгән кызны ул белми диярлек. Ничек үскән ул, егерме өч яшенә кадәрге вакытын кайларда үткәргән, яраткан кешесе булганмы? Бу хәтлесе егет өчен чытырманлы кара урман. Әлеге темага әти-әнисе дә кагылмый. Сораша башласаң, Василь Быков партизаннары кебек, үлем элмәгенә муеннарын тыгарлар, әмма серне чишмәсләр.

Көнбатыш Украинаның яшелчәгә, җиләк-җимешкә, иткә бай җирендә хатын-кыз Набоков Лолиталары төсле иртә өлгерә. Җенси хис тәндә, мидә мәңгелек туңлыкта гомер итүчеләр белән чагыштырганда күп алдан уяна. Шифалы кояш нуры, кыска җиңле күлмәктән, кара майкадан йөргән ирләр, унөч-ундүрт яшьлек җилкенчәкләрне иләм-миләс китерә, диварга сикертә.

Хәрби гаиләләрдә әхлак дигән нәрсә дә Аксубай ягының үткән елгы сумаласы кебек катып калмаган. Һәркем аны үзе өчен янәдән яза. Табигате сораганча, хиресе таләп иткәнчә...

Җиденче сыйныфта укыганда Светаның борын асты кибә — ул буяна, бизәнә, табигый ки, өлкәнрәк егет-җиләннәр белән дә йөри башлый.

Ә бу якта очрашу кимендә иреннәрең кара күмергә әйләнгәнче үбешүне тәкъдир итә.

Икенче елны кызны техникумга тапшыралар. Мәктәп белән хушлашкан бала үзен бәйсез, мөстәкыйль, балигъ дип саный башлый. Тәннең аерым урыннарын ачу җаен күрә. Сүз байлыгын урам теле исәбенә яңарта, бизи.

Куакта пешә, өлгерә килгән тәлгәш бу шөгыльдә тәҗрибәле сунарчылар күзенә чалына. Кызны кулга төшерү юнәлешендә кискен хәрәкәтләр башлана. Ир-атның өлгерлеге, булганлыгы шунда сынала. Кем беренче?

Кичәләрнең берсендә аны хатын-кыз сөю өчен махсус үстертелгәндәй таза, чибәр ир биергә чакыра. Күзләреннән нур көлтәсе балкый. Иреннәре дымлы, ияген икегә бүлгән матур чокыры кызның маңгаена сибелгән кыска чәчләрен кытыклый. Кечкенә матур кул олы, таза учта эри, юкка чыга.

Кавалерның тавышы сөт өсте кебек куе, ягымлы, әллә каян, йөрәк түреннән күтәрелә. Кыз аның ихтыярына буйсына. Җитмәсә, сүзләре нинди ягымлы, җөмләләре төзек, мәгънәләре йөрәккә, җанга сылана. «Синең кебек матур кызның әле бу мәйданга аяк басканы, бәхетле иткәне юк иде, мөмкин булса синең аяк эзләреңне үбәр идем»,— дип әллә ниләр сөйләп бетерә. Тик хатыны белән ике баласы турында гына ләм-мим бер сүз ычкындырмый ул.

— Тәнең синең затлы бәрхет кебек, шуны үзең беләсеңме? Бәйләнчек егетләрең әйткәне бармы?

— Мондый күзләр, билләр, аяклар үзен хөрмәт иткән теләсә кайсы рәссамның, фотога төшерүченең хыялы булырлык. Син шуны шәйлисеңме?

Өенә озатып куйды. Култыктан тотудан узмады. Шундый тәртипле кешеләр дә була икән дөньяда!

Аның белән ничек ресторанга бармыйсың ди инде, иплән чакыра белгәч. Львовның иң матур кызлары андый ир белән болгар шәрабен тәмләп утыруны, бергә биюне үзләре өчен бәхет санар иде.

Рестораннан чыккач, егет өенә кереп чыгарга тәкъдим итте. Бер кызык әйбер генә күрсәтәм дә, озатып куям, ди. Анда шампанский эчәләр. Светаның башы әйләнә, гәүдәсе тыңламас була. Карышырлык хәле калмый.

Иртән бер бүлмәле шыксыз фатирның хуҗасы кайтып керә. Кызылга аракы кушып, Светаның матурлыгы шәрәфенә баш төзәтәләр.

Кызны алып килгән чибәр ир шыпырт кына чыгып тая. Кунак кыз хуҗага мирас булып кала. Ул тынлы оркестрда уйный, хатыны ташлап киткән буйдак икән. Теленә шайтан төкергән, тегесе кебек үк, туктаусыз сөйләнүен белә:

— Бу һөнәргә сине дөнья күргән өлкәннәр өйрәтергә тиеш. Син әле безгә рәхмәтләр укырсың.

Ә куллары тик тормый. Кызга киенергә бирмичә, көне буе үз янында тота... Бу очрашулардан Светаның күңелендә, тәнендә ләззәттән бигрәк, авырту һәм җирәнү хисе генә калса да, Биктимер аганың бердәнбере инде бу бозрадан чыга алмый. Ихтыяры сына, һәрнәрсәгә кул селтәп карау рухы җиңә.

Шуннан инде ике дус, аларның таныш-белешләре, кыздан рөхсәт алып та тормастан, теләсә кая тотып аннан файдаланалар. Яңа, кызыклы хәяткә үзе дә өйрәнә кызый.

Әнисе сизенә. Дөресе, беренче кунып кайткач ук, аяк балтырларында ир-ат комсызлыгының эзләрен — кара тапларны күреп ала ул.

— Аквариум күрсәтергә алып кердеме егетең, кызым?

Әнисенең кыек атып, туры тидерүеннән югалып калган Света «Әйе шул, каян беләсең?» — дип кенә сорый ала.

— Аквариумы бармы соң өендә? Балыклары безнекеннән матурракмы?
— Юк. Пыяла савыты да, чурты да юк өендә.
— Алтын балыгын күрсәттеме соң? — дип сораганын сизми дә кала газиз ана.
Кыз белән ана арасында тулы ышану, сердәшлек, дуслык яши иде. Кеше кемгәдер ышанмыйча яши алмый ич. Ялганларга өлгерергә дә вакыт кирәк бит әле.
— Әйе, әнием. Анысы булды. Хәтта икене күрсәттеләр.
— Хәерлегә булсын. Атаң ишетә күрмәсен. Сугып үтерер.
Ана, көрсенеп, чыгып китте. Замана үзгә, буын башка, Львов Оренбург түгел, ә ир-атның хатын-кызга куйган тозаклары шул ук калган икән. Берни үзгәрми. Элек тә шулай булган, тагын да шулай булыр, күрәсең.
Заманында үзе дә шул ук «тизләтелгән» юлны үткән Феоктиста Петровна бердәнберенең яшьли ялгышуыннан фаҗига ясамады. «Яшәп кал, кызым, кемгә эләгәсең әле, кадереңне белерлек кешегә тап булсаң ярый ла», — дип, күңеленнән хуплады, элек медсестра булып эшләвенең кызына ярдәме аз тимәде.
Оҗмах алмасын тәмләргә теләүчеләр җитәрлек булса да, Светлананы гомерлеккә юлдаш итәргә ыжгырып торучылар офыкта бик күренми иде.
Ир-ат халкы, хатын-кыздан аермалы буларак, сер саклый белми. Җиңүе белән мактанасы, үзен күтәребрәк куясы килә. Имеш-мимешләр хәрби шәһәрчек буйлап төн пәрие төсле йөри. Ата колагына да ирешә бу хәвефле хәбәр. Кызның хурлыклы тәварихын белмәгән, ишетмәгән кешегә кияүгә сылап, черек тамырдан йолкып алып, бөтенләй башка төбәккә озатырга кирәк, дигән иманга килә кырыс холыклы ата кеше.
Шобага Сәгыйргә чыга. Майор аны уенчык «кәҗә» белән булышканда күреп ала. Мокытлык күз алдында. Үҗәтлеге дә бар. Татар кавеменнән булуын да хуплый Биктимер ага. Карарны күңеленә ныклап беркетеп, кызын спорт мәйданчыгына тулы инструкция биреп чыгара ул. Бу мәсьәләдә хуҗабикә дә ашатучысының ихтыярына каршы килмәде. Хатын-кыз күпме генә тилерсә дә, ахыр чиктә барыбер кияүгә чыгасы, бала табасы бит.
Күзе рәтләп ачылмаган Сәгыйрнең кияү булып төшүе әнә шулайрак булды. Этне дә кешегә дуслыктан түгел, бүрегә дошманлыктан йортка ияләшкән, диләр.
Кызның башкача хуты калмаган, аңа срочно кияү кирәк иде.
Өйләнү — тары бәлеше ашау гына түгел икән шул. Рәхәте артыннан агач таякка таянып, михнәте, ачы хәсрәте килеп җитә икән.
Бергә тора башлауның икенче атнасында ук, Сәгыйр кебек ифрат тыныч кешене дә тетрәндергән хәл булды.
Ул казармада кунарга тиеш иде. Өч пачка тәмәкегә бер солдатны үз урынына яллады да, сикерә-йөгерә сөеклесе янына йөгерде. Ә хатыны кунарга кайтмады.
Шул төнне Сәгыйр саташып, спорт мәйданчыгында үзенә бил бирмәгән оятсыз «кәҗә»не төшендә күрде. Каһәр суккан нәрсә, ыржаеп, мыскыл итеп караватъ янында тора. Сыртында ике мөгезле ияр! Ни юрарга да белмичә, пошаманга калып уянды егет.
Матуры иртә белән генә бусаганы атлап керде дә, берни булмагандай каударланмыйча, ирен кочаклап үпкәндәй итте дә, такылдарга керешге:
— Спортзалны ташлап китеп булмады. Охранник эшкә чыкмады. Сволочь!
Сәгыйрнең өмете җәрәхәтләнде. Ялгыз үткәргән төне гомер игәве булып калды, йөрәгенә ырпы кадалды.
Холкы тыйнак, басынкы булу сәбәпле, мин-минлекне булдыра алмаган кебек, күтәрелеп бәрелә дә, тузынып дулый да алмады егет. Ярсынып ләгънәт оруы, каргавы, ачыргалануы — барысы да үзендә кал-

ды. Шулай да бер нәтиҗә ясады: «Мин — хатын-кыз күрмәгән аңгыра солдат — әрсез кыз һәм ничарасыз ата-ана капкынына эләктем бугай. Өсте каплаган пыяла савыттагы үрмәкүч көнендә калдым».

Кичен спорт мәйданчыгына барып, уенчык «кәҗә»не кочаклап, туйганчы җылады, аңа йөрәген ачты Сәгыйр. Япа-ялгыз солдатның ышаныр кешесе дә, йөрәген ачардай дусты да юк иде. «Кәҗә» исә тыңлый белә, кешеләрдән аермалы буларак, серне ятларга чәчми.

Биктимер агай бу бәхәскә катышып вакланмады. Ул яшьләрне тизрәк Сәгыйрнең туган якларына озату хәстәрен күрде.

Феоктиста Петровна өчен гаепле кеше кияү балакай булып чыкты:

— Сөйгән хатынының вак-төяк кимчелекләрен кичерә белмәгән ир аның олуг мәхәббәтенә лаек була алмас. Гыйшыклар юлы — мәрхәмәт һәм шәфкать юлы,— диде ул серле тантана белән.

Сәгыйр шул көннән тагын да басынкы, күндәм булып калды.

Ярый әле хезмәт срогы тәмамланды. Хатыны белән туган авылына, әнисе, абыйлары янына кереп чыкты да, пожарка янында кәрт суккан ирләргә дә байлыгын күрсәтеп тормастан, Казанга чыгып китте, ерак туганнары ярдәмендә хәрби заводка эшче булып урнашты. Тулай торактан бүлмә бирделәр үзләренә. Икенче елны читтән торып укырга керде.

Хатыны да тик ятмады. Бер-бер артлы ике малай китерде. Ике арада бәхәс чыкмасын дип, дөнья күләм таралган исемнәр куштылар үзләренә. Олысы Карл булды. Икенчесе шул чорда ярым-йорты зыялылар арасында модага кергән атны алды: Ромео. Исем кушарга мулланы да, попны да чакырып торуның кирәге булмады.

Йорт хуҗасыннан аена ике тапкыр эш хакы, квартал һәм ел ахырларында өстәмә акчаны алып кайтып, тулысы белән хатынга тапшыру, шук малайларны әүвәл бакчага, аннан мәктәпкә илтү һәм фатир артыннан армый-талмый йөрү генә таләп ителде. Калганын агым хәл итте. Менә дигән фатирлары, кием-салымнары, җиһазлары — һәммәсе дә үз җае белән килә торды.

Мәгәр татар рухында авылда тәрбия алган Сәгыйр шул елларда жиде тәмугъ утларын күрде. Эш шунда: ул үзе татар халык җырларын, моңын, көен өзелеп ярата. Светага рок музыка, очкынлы, ялкынлы негр биюе кирәк.

Сәгыйрнең кайнар токмачны телен яндыра-яндыра, өрә-өрә ашап, тезгә тезне терәп, туган телендә гөрләшеп утырасы килә. Байконурда туган ханымның исә камыр салырга, бәлеш, гөбәдия димим, гадәти шулпа пешерергә дә теләге юк. Әзер кәтлиткә өйрәнгән кеше башка тормышка күнегә алмый икән шул.

Кара кофе янында, затлы бармагыннан төтен чыгарып, фәлсәфә сатып утыруны ярата төшә ул. Күңеленә хуш దуслары да, якыннары да табылды. Ә эш аты Сәгыйр һаман да «солдатик» булып калды. Татар кешесе мондый тормышны «ни ылтара, ни пылтара», ди.

Хатыны да, балалары да Сәгыйрнең туган телен өйрәнергә теләмәде. Аңа ихтыяҗ да юк иде ул чорда. Урыс теле үзенә галәм күләмендә аралашу чарасы булуны дәгъва иткән, совет халкы дигән гыйфрит милләт ясау дәверендә үсте малайлары.

— Синең телең үзләштерү өчен коточкыч авыр. Әнә инглиз, немец, латин кебек телләрне җиңел өйрәнеп була,— дип туп тәгәрәтте хатыны, шул телләрне белгән кеше кебек.

— Сезнең ул «лар», «ләр»нең серенә төшенгәнче, кытай тамгаларын ятлау җиңелрәк.

Кыскасы, Сәгыйрнең «җәннәт фирдәвесе» аның өчен генә үз телен сындырырга теләмәде.

Яшь хуҗа үз-үзенә бикләнде. Эштән арып-талып кайтканда, кухняда җилләр уласа да, хатыны чит-ял кешеләр белән ихахайлап утырса да, исе китмәде, тавыш чыгармады. Тәрбияви эшнең файдасыз икәнен аңларга аны Львовта ук өйрәтеп җибәргәннәр иде инде.

Тышкы кыяфәте, йөреше дә үзгәрде. Кышкы киеме аның өстендә чөйгә элеп куйган шикелле асылынып тора. Баш, гәүдә, куллар селкенми, хәрәкәтсез. Тик аяклар гына берәм-берәм алга алып куела. Җилсез көнне агач атлый диярсең.

Сәгыйрнең озынча чыраена һәрвакыт тыенкы сагыш тулы хуҗа булса, кешеләр белән аралашуында битараф салкынлык чоңгылы — җиңүче.

Учак ягып бозны эретеп була, ә Биктимер аганың бердәнбер киявен эретерлек көч юк иде кебек дөньяда. Әйтерсең лә рухындагы, йөрәгендәге, җелегендәге яшәү дәртен көчле суырткыч белән тартып алганнар. Уйлары да тонык су кебек аның.

Кадим мәдрәсә шәкерте кебек, ходай тәгалә билгеләгән язмышына баш иеп яши бирде Сәгыйр.

Хатыны туктаусыз битәрләвен белде:

— Тормыш күңелсез. Яшьлегемне үтмәс пычак белән суйдың.

— Син шулай дип уйлыйсыңмы?..— дип кенә сорый торган булды хуҗа әрнүле тавыш белән.

— Синең аркада иртә картайдым. Тәнемнең матурлыгы узды да китте бала карап, сине көйләп. Рәхәтен дә күрми калдым... Гомеремне, алсу матурлыгымны син бозауга әрәм иттем. Хәтта матур сүзләргә дә туендыра алмадың...

Ханым әсәрләнеп, эчке тетрәнү белән сөйли. Ә Сәгыйр аны аңламый, бөтенләй җавапсыз калмас өчен шул ук яраткан җөмләсен кабатлый:

— Син шулай дип уйлыйсыңмы...

Сәгыйр бу ләмкәне Идел бурлаклары үрнәгендә, йөк аты төсле, зарланмыйча гомере буена тартыр иде, әлбәттә. Ике баланы ташлап кая талпынасың. Тик язмышның кызыл кары Феоктиста Петровнаның хаты рәвешендә көтмәгәндә килеп төште. Ул үз туганнары янына Оренбург өлкәсенә күчеп китүе, торак ягыннан авыр хәлдә калуы турында язган. Эзоп теленә күчеп тормыйча гына, кызының квартирасын алыштырып, анасы белән кушылу мөмкинлеге булуны искәрткән. Шуның өстенә, олы малайлары бабасы юлыннан китеп, Балашово хәрби уку йортына укырга кергән иде. Аңа да якын булачаклар икән.

Чыннан да, Светаның анасы җылы якта берүзе торып калган иде. Ә Биктимер ага, юлдан язган кызын ачык авыз татар малаена сылагач, озак яшәмәде, фани дөньяны ташлап китте. Ни сәбәптәндер, бердәнбер кыз атасын күмәргә кайта алмады, «эчеп үлгәндер» дигән диагноз кую белән чикләнде.

Сәгыйр бабасын кызганды, рухы өчен мәчеткә барып сәдака өләште. Биктимер ага үзен бәхетле язмышлы кешегә санап яшәде. «Ап-ак беләкле, зур күзле, олы артлы хатыным бар, ни кирәк миңа тагын»,— дип, Сәгыйр алдында мактанырга ярата иде. Һәркем бәхетне үзенчә аңлый шул. Хатынының сүзеннән чыкмый. Китап укымый, марка җыймый. Милләте турында ул үзе бөтенләй уйламаса да, аның язмышыннан хәбәрдар булмаса да, чираттагы дәрәҗәне биргәндә, өстә утырган түрәләр анкетаның бишенче бүлеге турында онытмадылар. Шуңа күрә училищеда аңардан начаррак укыган башка халык әһелләре генерал, һич югында полковник булып исән калдылар, ә ул майор дәрәҗәсендә җан тәслим кылды. Яраткан хатынын да ярык тагарак янында калдырды.

Рухи дөньясы, тәрбиясе бөтенләй башка булган үз кызын да ул авыл малаена сылап, үзе шуны аңлап җитмичә, тәртәдән дуга ясап, икесен дә бәхетсезлек упкынына ташлады.

Сәгыйр бишенче катта, күгәрченнәр оясы астында, ләхет кебек тар «хрущевка»да яшәп калды. Буйдак тормыш ләззәтен татып карады да, тиз туйды. Светасы белән яшәгәндә төшләрендә күргән ирекнең, бәйсезлекнең аңа һич кирәге юк, буйсынып, баш бөгеп, тез чүгеп яшәү җиңелрәк икән ләбаса. Ул — зур диңгездә идарәсен югалткан кораб хәлендә калды.

Ә туган ягында ипле генә көн күреп ятучы ике абыйсы тынгы бирмәделәр: «Кая барсаң да бер кояш, гомернең калган өлешен кем янәшәсендәдер кыскартасы була, картлык көнеңдә янында җан иясе булырга тиеш»,— дип, күргән-күрешкән саен өйләнергә кыстый башладылар. Буш сүз белән йөрми иделәр. Кешесен дә тапканнар. Үтереп мактыйлар. Күрше авылда гына сигезенчедә укучы кызы белән яшәп ятучы укытучы ханым белән таныштырдылар Сәгыйрне.

Үзенә хатынлыкка тәгаенләнгән укытучы Әсманы ул, зоотехник абыйсына кунакка кайткач, мәктәп йортында бер очраткан иде. Төсе, бите хәтерендә калмаган. Бераз кызмача иделәр. Андый халәттә, аякта басып тора алган ир-ат халкына барча хатын-кыз да, төрек кардәшләр әйтмәшли, «чук гүзәл» күренә.

Әмма олыгайгач киләчәктә бергә буласы кешенә башка күз белән карыйсың икән. Ханымның гәүдәсе басынкы, утырган, яшьләрнеке төсле аяк баскан саен сикеренеп тормый. «Зифа камышлар үсми инде зәңгәр күл буйларында»,— дияр иде шагыйрь. Йөзе тулы айдай түгәрәк, юеш ком төсле чәчләренең чигәләренә мул, салкын кырау төшкән, күзләре бакыр, куллары килешле. Яңак сөякләре үз милләтен әйтеп, як-якка чыгыбрак тора. Утлы күмер чаткыларыдай ялтырап торган, бөтен битенә чәчелгән куе сипкелләргә дә күнегәсе бар.

Сәгыйрнең күкрәк тирәсе чәнчешеп-чәнчешеп алды беренче күрешүдә. «Ризалаш, язмышың бит» диюме, әллә «бер авызың пеште бит, инде ашыкма»,— дию булдымы сизгер йөрәкнең, аңлап бетермәде Сәгыйр.

Ә абыйлары, нәкъ Биктимер агай үрнәгендә, аңардан бик сорап та тормадылар.

— Житте галах булып йөрергә. Өйләнәсең. Хатын тәртипле. Туйганчы токмач ашарсың хет.

Буйдак ир «тәртипле хатын»га, Львов «кәҗәсе» янындагы шикелле, бер күрүдә гашыйк була алмады. Җитмәсә, беренче хатыны кебек үк, өч яшькә олырак икән үзеннән.

Әсма үзенә анык бәя бирә алырлык, тәвәккәл, сирәк татар хатыннарының берсе иде. Суреттән сикереп төшкән чибәр түгеллеген белеп яши. Мут ир-ат халкы үз янында күпме генә тырышып сайраса да, тик елмаеп торыр. Аш-суга маһирлыгы бар анысы. Ул акыл түтәленең, баш шәрифләренең буш түгеллеген чамалап, кыскасы, үзен хөрмәт итеп яши.

Язмыш аны бер генә сынамады. Унбиш яшендә әнисеннән калды. Тәрбияле бала буларак, ятимә кыз әтисен ташламады, рәнҗемичә карады. Алабуга педагогия институтын читтән торып тәмамлады.

Әтисенең еллыгын уздыргач кына, инде шактый олыгаеп, читтән килгән укытучыга кияүгә чыкты. Аннан аерылды. Тик Әсма гаебе белән түгел. Аны беренче хатыны алып китте. Имчәккә ияргән бозау кебек, тавыш-тынсыз гына иярде дә китте хатынына ир дигән нәмәстәкәй.

Үзенә иптәшкә, сердәшкә бер нәни кыз алып кайткан Әсма «үз аягы белән килеп кергән мал шулай ук чыгып китәргә тиештер», дип фараз кылды. Барчасына исәнлек теләп, болдырында басып калды.

Кайгыртырга туганнары, укучылары, ә юанычка кызы булгач, аңа башка нәрсә кирәкми иде. Табигать биргән гомерен шулай тымызык кына, иплән кенә уздыру фәлсәфәсе белән яшәп ятканда, аяк астыннан борчу килеп чыкмасынмы! Сәгыйрнең ике абыйсы ике яктан килеп булырга кыстый башлагач, әүвәл кискен рәвештә кире какты ул:

— Мин инде ялгызак булып, кызым белән генә яшәргә өйрәндем. Рәхмәт. Гомер җебем чит-ят җирләргә сузасым килми.

Чыннан да, ир-ат белән йоклауны ул инде оныткан иде. Кызы белән ике арага башка затны кертәсе килми. Ә менә кызы-газизе заманча уйлый торган булып чыкты. Бу мәсьәләне ул чишеп бирде.

— Әни, шәһәрдә яшисем килә. Берничә елдан укырга керәсе була. Урыс мәктәбендә чирканчык алырмын.

Әсма кызын кочаклап елады да, бераздан ризалашты.

Бергә яши башлауның беренче көннәреннән үк, ханым эчкерсезлеге, юмартлыгы, ачыктан-ачык, тел яшерми сөйләшә белүе белән шаккатырды Сәгыйрне. «Мой солдатик», «Сагирчик», җилкә сикертү, күзгә төтен җибәрү, истерика кебек сәхнә алымнарын белми иде авыл укытучысы. Ике икең — һәр җирдә дүрт.

— Йортым-җирем исән. Сиңа ышанып, бурамны сатып әрәм итмәдем. Торсын, ашарга сорамый. Җәйне шунда уздырырга да була...— Аннары: аягыңа — тышау, йөрәгеңә — богау булмам, дустым. Холкымны, фигылемне ошатмасаң, рәнҗетсәң, кайттым-киттем.

Хәерче, ямьсез бүлмәгә күз салды да: «Миңа байлык кирәкми. Дөньяда иң олы куаныч, иң затлы нәрсә — кеше күңеле. Күңелең чиста, ниятең хушлы булса — миңа шул җиткән», — дип өстәүне кирәк тапты. Бу — аның яшәеш фәлсәфәсе иде. Кызын да кешеләргә ышану, гел изгелек теләү, яхшылык эшләү рухында тәрбияләде ул.

Мондый рыясыз ачыклыкка өйрәнмәгән Сәгыйр тәмам югалып калды. Таныш булмаган хөрмәт, ихтирам хисе җылы диңгез дулкыны кебек аның бөтен барлыгын тутырды. Ул бәхетле иде.

Дусларын, якыннарын чакырып алырга булдылар. Туй урынына.

Кечтеки бүлмә җанга рәхәт, тәнгә сихәт бирүче тәмледән-тәмле аш-су исе белән тулды. Сәгыйр әнисе янында яшәгәндәге кояшлы аланлы балачагына кайткан шикелле хис итте үзен. Читлектә интеккән йөрәге рәхәтләнеп, иркенләп типте, сөенечтән дулады.

Мәҗлес ахырында, үзенә сүз җиткәч, Әсма яшәешендәге үзгәрешкә «рәсми» ачыклык кертүне кирәк тапты.

— Хөрмәт итеп килгән өчен алланың рәхмәте яусын барчагызга!.. Бу малай белән ничек торып китәрбез, әйтүе кыен. Мин торырга килдем. Юкса, кузгалмаган булыр идем... «Бүгенгә ул кирәкми, иртәгә ул эләкми» дигәндәй, ризалаштым инде. Кызым да үсеп җитте... Ә Сәгыйрнең туганнары бик ярдәмчел адәмнәр. Бик кыстадылар. Аларның сүзе, Гөлнисамның теләге минем киреләгемне, дөресе, өйрәнелгән, күнегелгән, ипләнгән тормышыма үзгәреш кертергә теләмәүне җиңделәр. Менә шул...— диде ул Сәгыйрнең буйдак яшәеш истәлеге булып маңгай белән борыннан гына торып калган йөзенә мәгънәле караш ташлап.

«Ир-атның төнге кояшы — хатын», — дип юкка гына әйтмиләр икән. Сәгыйр Әсмага тиз ияләште. Сипкелләреннән җылылык, яктылык, талгын ягымлылык иңеп торгандай тоелды аңа.

Дөрес, ялангач ирне ут яктысында күрергә гадәтләнмәгән тыйнак, оялчан Әсма түшәктә Светлана кебек могҗизалар ясый алмый. Хәтта кечкенә мендәрне баш очыннан аскарак төшерергә дә бирми. Нишлисең, татар хатыннарының күбесе ялган оялу, тарсыну, зур гаиләдә, бер бүлмәдә яшәү аркасында үзләрен ачып бетерә, ирләренә тулы ләззәтне бирә алмыйлар шул.

Тиешле гамәлдән баш тартмый Әсма үзе. Артыгы Сәгыйргә кирәкми дә иде, дөресен әйткәндә.

Юк әйбер тансык була, кара төндә йолдыз да ай тоела. Сәгыйр, вакытында кайнар ризыгын, өчпочмагын, коймагын, пәрәмәчен, чөгендерле катыгын ашап, тынычлыкка сеңде, рәхәткә тарды.

Иргә ия булу бер хәл, аны үз яныңда тота белү осталыгы да кирәклеген чамалый иде укытучы ханым.

Сәгыйрнең күңеле хушланып, тын юллары ачылып китте. Чыраена кан менде, тәненә ит кунды. Элеккеге хәяты аңа төш кебек кенә тоела башлады. Яңа гаиләнең хәленә кереп, Сәгыйрләрне иске йорттан булса да, ике бүлмәле квартирага күчерделәр. Көнитешләре тәмам җайлашып җиткәндә генә, бәллүр савыт идәнгә төшеп чәлпәрәмә килмәсенме! Хәтәр хәлләр, караңгы бүлмәдәге кара мәче төсле, сагалап кына торган икән адәм баласын.

Беренче хатыны уртак мөлкәтләрен, квартирасын бүлеп киткәч, Сагирчикны оныткан иде.

Тик ата кеше үз малайларының язмышына битараф кала алмады. Җан тартмаса, кан тарта бит. Аның олы улы тәртипле, ипле булып чыкты, өстәмә мәшәкать тудырмады. Әтисенә «Исәнме, Шәрифуллин абый» дип булса да, ара-тирә открытка юллап торды хәтта.

Кечерәк малае Ромео исә чәнечкеле-шырпылы, иркә булып үсте, укырга да теләмәде һәм ниндидер шайка белән чуалып, фатир басуда катнашып, балалар колониясенә эләкте. Ә аннары, әнисенең киңәше беләндерме, бергә торганда әтисенә бер тапкыр да исеме белән эндәшмәгән малай, Сәгыйр янына килеп җитте, хәл белергә, диган булып тукталды. Шактый яшь инде.

Атасының салкынлыгы аны борчымый. Әсма үзе дә һәм аның инде унберенчедә укучы чибәр кызы да Ромеоны якын туганнарыдай җылы кабул иттеләр. Аның ямьсез уе аек акылга да сыймый иде. Әмма, зирәк уйлап өлгергәнче, тинтәк эшен бетерер, диләр шул.

Язгы җылы көннәрнең берсендә, өйдә башка кеше юклыктан файдаланып, Ромео Гөлнисаның халат кына киеп ваннадан чыкканын чишенеп үк көтеп ала да, чит ит исеннән котырган ерткыч төсле сикереп, корбанын киң диванга бәреп ега, кулыңны тидерергә дә ярамаслык нәзакәтьле, инсафлы, каен җиләге исе килеп торган тәнне пычрата, нәҗесли...

Шуның өстенә, кнопка белән ачыла торган ике яклы пычагын кызның бугазына тери. «Берәрсенә әйтсәң, чәнчеп үтерәм»,— дип ысылдый, иләмсез күзләрен акайтып.

Кызның йөзенә, күзләренә, тал чыбыгыдай сыгылмалы гәүдәсенә бәреп чыккан афәтне әнисе сиземли, булган хәлне сөйләргә мәҗбүр итә. Әммә яшь «кияү» чыгып качкан була инде.

Әсманың йөрәге сызлый. Бәгыренә кан сава. Кысылган тешләре шыгырдый. Тик тормышның ачысын-төчесен күп татыган ана хәбәрне читкә таратып, эт кебек улау юлына басмый. Юләрләнүдән файда юк. Гамәлдән уй алданрак йөрергә тиеш. Үзе гаепле бит. Кызын көчләгән диванга ятып бер тәүлек буена җылый да, бозыклык һәм әхлаксызлык оясы — шәһәрне, тәтигә кызыккан үзен һәм карт җүләрне каһәрли-каһәрли шул ук ике чемоданын күтәреп авылына юл ала...

Карт кияү, Әсманың соңгы сәламен кулында уалап, ташландык зиратка охшаш фатирында янә берүзе кала.

...Кайгы ул кешеләрне гел аерым-аерым очрата икән шул!

Рәдиф
Гаташ



# ЧУЛПАН ЙОЛДЫЗ КАЛЫККАНДА

* * *

Акыл җуеп, кем йотылды күзләреңә?
Онытылды кисәтүле сүзләрең дә:
Бар булмышым — савап, гөнаһ җыйган башым
Сәҗдәгә егылды ул көн — тезләреңә.

Тарих мең дә тугыз йөз дә туксан дүрттә
Кол иттең син Гаташ җанын гомерлеккә.
Муенчагым — көмеш, алтын келәймәсен
Шигырь итеп язарга җан илһам көтә.

Шуны сиздем тугыз йөз дә туксан дүрттә:
Яшьлек үтте мәхәббәттә, гомер үтә —
Бәлки, соң кат ашам яңа биеклеккә:
Рәхмәт сиңа, Илаһи Нур — горур бикә!

* * *

Ник шулкадәр уйлыйм мин синең хакта?
Уйларымнан исереп, елыйм хәтта!
Җаннан таша моңнар, җырлар агыла,
Иң бәхетле Җирдә миндер — шул чакта!

Мин шулкадәр еш уйлыйм синең хакта!
Ходайдан дим син бүләктер хәятка:
Мондый бәхеткә ни өчен лаек мин? —
Гашыйкларга вәзир дә түгел хәтта...

Мин шулкадәр саф уйлыйм синең хакта! —
Шул сафлыкны дөньяда тоям хәтта,

Тик матурлык күрәм аның эчендә:
Карасы бардыр — табынам тик акка!

Мин шулкадәр уйлыймын синең хакта —
Килерсең күк син дә минем хәләткә...
Шул халәт өчен мин үләргә риза... тик
Мәңге яшәргә телим — синең хакка!

Йә, үзең соң ни әйтерсең бу хакта?!

* * *

Синең бакчаңа кунган мин — нинди Кош? —
Кума ләкин, җырым аңларга тырыш:

Ил-йортыңнан хәбәр ишетеп килдем,
Күргәнсең, дип, узган төндә шундый төш...

Былтырдан калган кып-кызыл алмалар
Алмагачта — шуны коясың, имеш...

Юраучылар йөри хәзер баш ватып,
Күрәзәләр: булмасмы бер хәтәр эш?

Сугыш юкмы? Илгә афәт килмәсме? —
Йолдызларда күренмиме үзгәреш?

Борчылудан дәһшәт тулы күзләрең:
Яшькелт дулкыннарың давыл сизә ич...

Ни яшермәс Кыз җаны тирән монда!
Тик, үткәнгә — өзеп, хуш! — дию тиеш...

Бакчаңда, бел: ул сиңа тугры күңлем —
Бәлки, йортың котын саклар изге Кош?!

* * *

Миннән соң да аязыр йә болыт торыр,
Яшь шат аваз — моңсу өнем оныттырыр, —

Һәм битараф бу Казансу ярларында
Минем яшьне түкмәс мәҗнүн таллары да...

Сөембикә аглавының кайтавазы —
Ерак тарих! Ил кызлары — милли язны

Бәйрәм итәр... Шул көннәргә карап, ерак
Киләчәккә дәшсәм әгәр, ярлык сорап,

Камил чорның бәхет җыры-чыңнарында
Табылырмы урын — минем моңнарыма?

Галәм — чиксез, барсын күреп ул аргандыр:
Вакыт-комны күп гомерләр сугаргандыр...

Гашыйк җаны, ир акылы — һәр бөртектә.
Комнар кучә... вакыт — ага... Сөю — үтә...

Әмма бүген янып, рухым күккә ашса,
Илаһи юл күрсәтүче син ләбаса!

Тугры калсаң уртак ялкын-шигырьләргә,
Мин ышанмам җирдә хәтта үлемнәргә.

...Бүген, бәлки, моңсумындыр — шигем барга?..

* * *

Яшь яр, миңа нигә ишегең бикле?
Ачылмасмы — кәтсәм дә таңга тикле,
Әллә бәхетемнең киче дә җиттеме?
Күңел көнем әллә үтеп тә китте?

Яшьлекнеңме ишеге җанга бикле?
Ялынырга, бәлки? Кайчанга тикле?
...Хисләр язы — ул син идең түгелме? —
Җәем үтеп, әллә көзләр дә җитте?

Яшәүгә дә ишек бер булыр бикле:
Сиздермичә куярлар авыр бикне.
Бәхет хисең җуйсаң, гомер дә үтәр,
Бәхет — синең сөю күк... ник тиз бетте?

Ишегең, дөнья, китсәк без, гел бикле:
Ачылмас ул мәхшәр көненә тикле.
Җанына кертми елатсын бүген яр,
Яшәү — бәхет! Үкенеч: гомер чикле.

Әйтче, син, яр! Ни фал: ишегең бикле?!

* * *

Сәламнәрем сезгә — өч кыз туганга!
Сандугач чакырып, таңнар туганда,
Кайсыгыз йокысыз моңая анда?
Кайсыгыз тәрәзә ачкан дөньяга? —
Сәламнәрем сезгә — өч кыз туганга!

Сандугач уяткан таң сызылганда
Яз сулышын тоясыздыр дөньяда.
Бакчагызда нинди яктылык анда? —
Туй күлмәге киеп, алмагачлар да
Тәрәзәгезгә киләме таңнарда?

Кайсыгыз йокысыз моңая анда?
Яшьлек күзләре язларда уяу ла.

Күзләрдән күчә жаннарга сорау да,
Җавабы табылыр, бәлки, бу айда —
Гөлгә охшап, җан ачылган язларда?

Кайсыгыз тәрәзә ачты дөньяга?
Керә матурлык — гүяки нур ага,
Миндә дә, ниһаять, илһам уяна:
Чакыру авазы ишетәм юлларда,
Миндә дә бит бар тәрәзә дөньяга!

Бу — рәхмәтем минем өч кыз туганга,
Юлым беркөнне сезгә тап булганга.
Шул бәхеттән исереп, айнымаганга
Гаташ тагын гашыйк булды дөньяга,
Ә хисләре — Сезгә, өч кыз туганга!

* * *

Гаебем синең алда — зур: чал чәчем, —
Сөеп шактый яшәдем җирдә, яшим...
«Мәхәббәт — җамал сорамый» дигәннәр,
Сорамыйдыр, шулай ук, йөрәк яшен?!

Сагышлымын ләкин: җанның бар моңы,
Табигый бик татлы ул — яшь яр моңы!
Гаебем синең алда — шул: олыгаю...
Кайсы урманга озатыйм «аю»ны?

Көләдер күк миннән Җир, күрәдер — Күк:
— Тиңме сиңа яшь йолдыз? — диядер күк...
Яшәргә ашкынган, сөяргә ашыккан
Гомер — инде «ялгыш»ын сизәдер күк...

Гаебем шул: яшь матурны күргәнмен,
Чал башны игәнмен аңа — сөйгәнмен...
Бәс, иелә, хәтта тезләнә алгач,
Каткан карт агач та түгел икәнмен!

Әллә җанны юкка кыйныйм микән мин?!

* * *

Иске савытында, тән, яңа шәрабмы? —
Сәрхүш җаным мәңгелектә корабмы?

Гомер җәе узган ирнең «азганы»,
Бәлки, бу хис? Әллә «Хакның язганы»?

Әллә табигатьтән соңгы мәрхәмәт —
Синең сөю — канда яңа хәрәкәт?!

Гади генә бер җир кызы сагышы
Йолдызларга илтәчәк нур-балкышмы?

Сайлап менә нәкъ минем рух-хисемне
Юнәлтәсең нигә шунда син мине?

Гөнаһларым күп — моны белә халык,
Биеклеккә нигә минем җан лаек?

Пәйгамбәр дә, тик үлеп, аша күккә...
Гашыйкны — ни илтә үлемсезлеккә?

Бөек Хыял һәм Ышаныч канаты
Биреп, мине яшәрттеме ярату?!

Иске савытында, тән, яшь җан шәрабым
Чайпалсын тик... Мәңгелектә корабым!

* * *

Бәлки, шагыйрьләр оҗмахы бу кала?
Ә мин — шуннан үзем бер киткән бала...

«Яшь Адәм чакларым» белгән урыннар
Сине үз итеп, сәламләп тордылар.

Уйчан идең зиратта — тау башында,
Сәгыйт Рәми каберташы каршында

Остазның рухын яд итте йөрәкләр,
Күңелдә иде мөкатдәс теләкләр...

Сораштың гел Тукай булган җирләрне,
Бабич таланты балкыган көннәрне...

Ә мәчетләр ишегеннән кергәндә,
Яулык белән чәчеңне өреткәндә,

Күккә аштык бергә — Ходай катына,—
Ә җирдә — Салават аты чакыра...

Яңгыр яуды һаман — сизмичә йөрдек,
Иң-иң ихлас тойгыларга төрендек.

И сөендем: син — мин үскән якларда,
Кайтырбыз күк Хыял — бөре чакларга...

Биек Бакча, дидең, бу гүзәл кала,
Сөен, «Хауа»м! «Оҗмах»та — эзләр кала...

* * *

*(Сиңа, Сәгыйть Рәмигә тәкълидән)*

Азат булмадым шул — булмам гомергә:
Язган миңа гүзәл коллык күрергә.

Изге санап шуны, горур мин яшим.
Күңелемне тутырган яшерен яшем! —

Кимеми гамь кайнаган савытымда,
Илаһи бу бер халәт хәятымда.

Хисләр — язмыштан узыйк дип шашса да,
Бу бәхетне алмашмам мин башкага.

Яраткан хак мине шулай — бар иткән:
Шәрекъ-гарепкә бер (!) гыйбрәт яр иткән.

Ашыкмыймын касә төбен күрергә:
Азат түгел, гашыйк булыйм гомергә!

* * *

*Тик бер сүз... аһ, авыр кагылды:*
*Йөрәк кара шәлен ябынды.*

*Ч. З.*

Кабат-кабат сорыйм йөрәк хәленне:
— Син алдыңмы аннан кара шәлеңне?!

Һаман уйлыйм: яшь бер хискә ник матәм?
Ул килешми сиңа — чынын мин әйтәм...

Ал ул шәлне — кара төстән ерак йөр...
Синдә керсез, йолдыз затлы йөрәк, бел...

Биеккә ул ашсын — тиңсез нур булып,
Сөя белмәгәннәр — калсын хур булып...

Бөек горурлыгын Кызның — балкыштан
Таныганнар көнләшсен ак язмыштан!

Кош юлына күтәр якты хисеңне:
Мин гел шуннан эзләргә әзер сине!

...Һәм, күрсәң сәҗдәгә егылган мәлемне,
Алдыма ташла шул кара шәлеңне!

* * *

Шәрабым соң сиңа агумы булды?
Утырганмы балым — ачымы булды?
Тетрәнеп мин гөлчәчәккә кагылдым —
Бәхетемнең, аһ! шулмы ахыры булды?

Сусын тапмас, ут капкан хәлгә тардым.
Ялкынланып үз гөлем — дөрләп яндым.
Тигезсезләр! — нишләдек: бер убү бу...
Яшь йолдызга бәрелеп жан, көлгә калдым!

* * *

Ни әйтим мин?
Беләм: Җирдә үз юлың...
Әзер, димен,
Сиңа җылы сүз, кулым...

Таяныч ул! —
Юл башланмый хуплаусыз.
Бәхетле бул! —
Дип кабатлыйм туктаусыз.

Биеклеккә
Ашканыңны күрсәмче! —
Бер көн күккә
Сәер кошым күчкәнче...

Әйт, кая дип
Рух канатың җилкенә?!
Моратка бит
Ирешү — хак иркендә...

Тугры һаман
Сиңа догам — Каләм, сүз...
Шулай калам —
Ихлас җанга таян, Кыз!

*1994 ел, март — декабрь.*



**Гариф Ахунов,**
**Мәгъсүм Гәрәев**

# АРЧА ҖИРЕНЕҢ АЧЫК КИТАБЫ

ДОКУМЕНТАЛЬ ПОВЕСТЬ

### Ярминкәләр

Вәгыйз Минһаҗевны без кайчан ярата башладык икән? Моны өздереп кенә әйтүе кыен. Озак еллар артта калып килгән, уңдырышсыз туфраклы Арча районын беренчеләр рәтенә алып чыгып, станца элеваторына олау-олау ашлык китергән, сугышка кадәрге чордагы сыман олауларны кызыл комачлар белән уратып, байраклар җилфердәтеп, элеватор капкасы төбенә утызлап олауны тезеп куйган көнне булдымы икән? Анда без дә катнашкан идек. Анда Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Фатих Сибагатуллин да җиңел машинасында җилләр уйнатып килеп җиткән, ялкынлы нотыгын, үзенә хас бер ихласлык вә кайнарлык белән, кызыл олаулар өстенә, дәүләткә беренче ашлыкны тапшыру тантанасына җыелган халык өстенә сибеп ташлаган иде. Барлык районга да атлыгып тормый торган Фатих Сәүбән улының үзе кайчандыр җан җылысын салып киткән Арчасына кайтуы дулкынландырды микән әллә безне? Арчадан соң байтак еллар Мамадышның данын күтәргән, Сабан туйларында мәйдан тоткан баһадир гәүдәле җитәкченең кайнар сүзләре шундый ук баһадир, шундый ук көрәшче Вәгыйз Минһаҗевка карата әйтүен Арча хакимияте башлыгы белән якынайттымы әллә безне? Арча ягы авылларын, бигрәк тә туган туфрагы булган Гөберчәкне, шул авылның чамадан тыш егәрле, тырыш кешеләрен легендага әйләндергән язучы Мөхәммәт Мәһдиевнең Вәгыйз турында язган зур мәкаләсе әллә безнең күңелләрне Арча ягына таба борып куйдымы?

Игенчеләрнең уңыш бәйрәмендә дә, терлекчеләрнең, зур бер бәйрәм итеп, уңганнар җыенына җыелган көннәрендә дә, Арчалыларның Казан каласында якташларын бергә туплап уздырган сәнгать бәйрәмнәрендә дә, сәнгать йорты яки ак таштан салган мәчетне ачып җибәрү көнендә дә булдык. Мактанып әйтү дип бертек уйлый күрмәсен хөрмәтле укучыларыбыз, «Солтанатлы Арча җире», «Татарстан игенчеләренең башкаласы» дигән сүзләр дә безнең каләмнән гәзит битләренә күчтеләр.

Әнә менә кайчан без аны чын мәгънәсендә якын күрә башладык, үз иттек — анысы өзеп кенә әйтүе кыен.

Уй-тойгыларыбызны аңлатып бирер өчен бер-ике мисал китереп, күргән-белгәннәрне уртага салып сөйләшеп карыйк әле. Әйтик жыелыш бара. Трибунага күтәрелеп, авызыннан утлар чәчеп, берәү сөйли. Залда утыручыларның моңа исе дә китми, өйрәнелгән гадәт буенча, иренеп кенә кул чапкан булалар. Икенче берәү күтәрелә трибуна янына. Авызыннан утлар чәчә ала торган оратор да түгел, «әртисләнеп» тә маташмый, әмма аның әйткән бер сүзенә кул чабалар. Ник шулай? Азактан белдек. Авызыннан утлар чәчә белүче Цицеронның бар хикмәте әнә шул матур итеп сөйләүдә, ә менә Цицерон була алмаганының матурлыгы — эш-гамәлендә икән.

Ярый, хуш, моны мисал белән беркетик. Авызыннан утлар чәчә торган ыспай егеткә, үзе эш башында утырган булдыклы житәкчегә биш ел буена әйтеп киленде: перспективасы юк дип күченеп китәргә мәжбүр ителгән бик борынгы Өчиле авылының зиратында көтү йөри, каберләрне таптыйлар, анда бит синең колхозда тир түгеп киткән яшьләрнең ата-бабалары күмелгән, изге урыннарны шулай мыскыл иттерсәк, яңа буынны нинди итеп тәрбияләрбез? Шунда бер рәшәткә тоттырып куй әле, диелде. Көчле колхозның башында торган, жиде зур авылны берләштергән әртилнең башлыгы иде, биш ел буена вәгъдә итте, әмма вәгъдәсен вак тараканга ашатты. Ә менә Вәгыйз Васил улы Минһажевка шул үтенеч бер мәртәбә генә житкерелде, бер атнадан инде Өчиле зиратына бар ягыннан әйләндереп алып, рәшәткә тотылган, вакытка бирешми торган калын торбалардан баганалар утыртылган, рәшәткәләр жете зәңгәргә буялган иде. Менә халык кемгә кул чаба — сүз сөйләүчегә түгел, сүзендә тора белүчегә!

Ихтимал, бу документаль повестьның авторларын кулга каләм алырга Минһажевның әйткән сүзендә тора белүе, буш вәгъдәләр чәчмәве мәжбүр иткәндер. Шөкер, буш вәгъдәләрне күп ишеттек инде без. Ничәмә-ничә еллар колхозгамы, совхозгамы, яки районның үзенә үкме башлык булып каяндыр килгән кешеләр авыл агайларына алтын таулары вәгъдә итеп киләләр дә, артларыннан вәгъдә таулары өеп калдырып, Казан каласына күченеп китәләр иде. Шунысы бик сәер, житәкчелектә никадәрле бушкуык булсалар да, үз якларын кайгырту жәһәтеннән бер дә генә бушкуык булмыйлар, аларның таш калада салып куйган иркен саф һавалы нарат йортлары калка иде...

Инде ярминкәләр дигәненә әйләнеп кайтыйк. Башкалабыз Казанда да, республикабызның башка калаларында да ярминкәләр үткәрелә башлаганга ун ел гына түгелдер инде. Беренче елларны халык ярминкәләргә бик әлләни ашкынып йөрмәде. Бәлки, сирәк булгангадыр. Аннары ияләнә төште. Ә менә соңгы ике елда ярминкәләргә агылган кешеләрнең исәбенә чыгарлык түгел.

Татарстандагы кырыктан артык районнан ярминкәгә азык-төлек, төзелеш материаллары, мал-туар алып килгән төбәкләрнең һичберсенә дә тел-теш тидерергә жыенмыйбыз, рәхмәт: Казан каласына да, башка калаларга да авыл эшчәннәре үз авызларыннан өзеп алып киләләр байлыкны. Әммадәхи, дип авылдагыча әйтик, бүгенгесе көнне арчалыларны уздыра алган район юк. Ничәмә-ничә ярминкәләрендә булдык арчалыларның, елдан-ел, көз, кыш, яз товар күплеге ягыннан да, ихласлык-гүзәллек ягыннан да арчалылар берәүгә дә беренчелекне бирми.

1994 елның 5 мартында Казанның Чехов базарында арчалылар ярминкәгә 300 дән артык машинага мал төяп килгәннәр иде.

— Ай жаным, хикмәт бу, хикмәт! Монда әти-әниең белән күгәрчен сөте генә юк,— диде олы яшьтәге бер апа.— Мин монда, арчалылар килгәнне ишетсәм, акчам булмаса да киләм, жаннарым рәхәтләнеп, авылда үскән ямьле чакларымны искә төшереп кайтам.

Апаның сүзләре хак икәненә ярминкәгә килеп керү белән ышанасың. Халыкның күз явын алып, шлеясына, йөгәненә, ыңгырчак каешларына елкылдап торган жиз таңкәләр, арба тәртәләренә чуптарлы сөлгеләр,

аллы-гөлле чуклар таккан ат ыспай гына атлый, бизәкле дугасындагы көмеш телле кыңгыравы, муенындагы шөлдерләре тирә-якка чылдырау, шылдырау авазлары тарата, арбага тезелеп утырган милли киемнәрдәге, бизәкле Арча читеге кигән кызлар, кырпу бүрекне кыңгыр салып, тальян гармун дәртләндереп, гаҗәеп бер горурлык белән уйнап килгән егеткә кушылып, «Арча» көен яңгыраталар. Ярминкәгә җыелган халык, ни алырга килгәнен дә онытып, җырчыларны, җай гына атлап барган шлея-чуклы, кыңгырау-шөлдерле атны сокланып, күңеле тулып озата. Ул да түгел, кибетләр арасында, мәйданның урта бер җирендә егет-кызлар, яшь-җилкенчәк гармунга ду китереп биеп яталар. Мондый биюләр халыкны шул тикле дә кузгата ки, шулай бер ярминкәдә Арчаның хакимият башлыгы Вәгыйз Минһаҗев дүрт мәртәбә төшеп биеде, аңардан дәрт алып, хөрмәтле Президентыбыз Минтимер Шәймиев тә рәхәтләнеп бер биеде. Халыкка ул шундый гади булуы белән бик ошады, ул атнада Казан халкы гел шул хакта гына сөйләде. Эш икмәктә генә түгел, хикмәттә дә икәнен аңлады Казан халкы.

Әнә бүген дә ду килеп бии арчалылар.

Рәт-рәт булып тезелгән кибетләр арасыннан барабыз. Безне йөк машиналарының әрҗәләре өстенә матур итеп фанердан ясалган кибетләр, курчак өйләре озатып кала. Ул кибетләрнең ишек өсләренә, авыл йортларындагы төсле итеп, зәңгәр, сары, яшел, кызыл, ак кашага-пәрдәләр элгәннәр, аларның өстендә кызыл ефәктән кисеп ясаган чәчәкләр, төрле плакатлар бар. «Кадерле аналар, апалар һәм сеңелләр, Сезне яз бәйрәме — 8 Март белән котлыйбыз!» «Язлар игелекле булсын, игеннәрне шаулатып үстерсен, илгә муллык килсен!» Тукай шигырьләре, Сибгат Хәким шигырьләре дә бар плакатларда. Якташ шагыйрьләрен онытмый арчалылар.

Ярминкә уртасында, урамда ук, өч машинаны бергә кушып, авыл өе ясаганнар, яннарына декоратив стена куйганнар, тәрәзәләр, тәрәзә төпләренә яран гөлләр сурәте төшергәннәр, зәвыклы сурәт, талантлы рәссам ясаганы сизелеп тора. Зур сары самавырда чәй кайный, кижеле кызыл ашъяулык япкан өстәл өстендә чынаяклар, авыл ризыклары, кәрәзле бал, татарча милли киемнәрдәге нурлы йөзле мөлаем апалар сине чәй эчәргә чакыралар. Теге өлкән яшьтәге апа әйтмешли, әкәмәт инде, әкәмәт!

Шул чагында зур самавырлы табын янына ак сакаллы, җитмеш яшьләрендәге бер карт килде. Түше уңган, шактый ук таушалган кара пинжәгенә сугыш орденнары билгесен тезеп куйган. Ике пот су сыешлы сары җиз самавырны күргәч, картның мыегы дерелдәп китте. Мондый самавыр сугыш вакытында рота самавыры иде. Арчалылар, күрәсең, гигант самавырны шул фронт елларын искә төшереп алып килгәннәр.

Карт, самавырдан күзен алмыйча, истәлекләре дөньясында йөзгән арада, авылча пөхтә итеп, ак яулыкны тамак астыннан китереп бәйләгән, аягына арчалыларның данлы читеген киеп җибәргән мөлаем апа ветеранга үтә дә якын итеп дәште:

— Әйдүк, абзый, түрдән уз. Безнең гомерләрне саклап сугышкан ветеранны тәмле чәй белән сыйлап җибәрик. Исемегез кем була?

— Исемем минем Шәрифҗан. Чәйдән олы булып булмас, ясап җибәр, алайса, кодача, бер чынаяк чәй!

Ветеран итагатьле генә булып табын янына килеп утырды, бал калагының очына гына эләктереп, гәрәбәдәй сары балны капты, чәйгә үрелде.

Ул арада сәүдә башлыгы, Җәүдәт Миннеәхмәтов пөхтә кодачага күз кысып, ветеранга бер йөз граммнар чамасы шәрап та китереп куйды. Картның йөзенә кояш чыктымыни! Чәркәне ул ипле генә итеп әйләндерде, чал мыекны сыпырып, тамак кырып алды — яшьлеге утлы-давыллы көннәре искә төште бугай, аның янына килеп, тальян гармунны сыздырып җибәргән Арча егетенә кушылып, җыр башлады...

И адәм баласы, сиңа якты йөз генә күрсәт, ягымлы итеп, олылап бер дәш кенә, җаның синең гөл таҗлары кебек ачыла, күңелең рәхмәт хисе белән тула...

Сәүдә башлыгы гармунчы егеткә әйтте:

— Энем, ветеранны шлеялы-чуклы ат белән өенә кадәрле илтеп куй, сугышта яшьлекләрен калдырган фронтовикларга бер изгелегең булыр...

Күңел кузгаткыч бу очрашудан айнып җитә алмыйча, кибетләр рәтеннән барабыз. Һәрбер кибет үзенчә яңа, кемнеңдер хыял өлгесе. Менә бу кибет-машина каршысына сөлге-мазарлар да, кашага-пәрдәләр дә элмәгәннәр, ул шыр ачык. Бу үзенә күрә авыл агаеның йорт җиһазларын саклый торган сарае-лапасы. Анда «уфалла» арбасы, имәннән кырып ясалган арба тәгәрмәче, агач кыру станогы, чалгылар, тырмалар, тагын әллә нәрсәләр бар.

Безнең күз тәгәрмәчкә төшә. Кабинада утырган шофердан сорыйбыз:

— Менә бу кырып ясалган арба тәгәрмәчен сатып алырга буламы?

Шофер, урта яшьләрдәге базык гәүдәле, таза-нык чырайлы ир-ат безне баштан-аяк күздән үткәргәч, тыйнак кына елмаеп, үзе сорау бирә:

— Нишлисез тәгәрмәч белән? Сез бит шәһәр кешеләре?

— Бәхет тәгәрмәче итеп фатирга элеп куябыз.

— Шаяртмагыз, туганнар. Мин беләм — сез авыл малайлары. Яшьлегегезне, «уфалла» арбасы тартып, урманга печәнгә, утынга йөргән чагыгызны искә төшерә бу тәгәрмәч тә, кул арбасы да.— Ул инде елмаймый, авыр итеп бер көрсенә генә.— Гафу итегез, агайлар, бу машинадагы бер нәрсә дә сатылмый. Без аны авыл кешесенең тарихи истәлеге итеп алып килдек.

Мондый мәгънәле сүзләрне ишетү җанга, каз канаты белән сыйпагандай, рәхәтлек бирә. Без авыл агаеның әле күптән түгел генә булган «лапас-сарае» янышнан китәргә ашыкмыйбыз.

— Мондый музей экспонатларын бер йөз чакрымга, бушлайга алып килеп йөрү кыйбатка төшмиме соң сезгә? Бердән, боларны бит ясап утырасы бар. Икенчедән, болай килештереп авыл лапасын ясау өчен авыл җирендә рәссамын табу да ансат түгелдер? Өченчедән, болай «бушка йөрергә» кем өйрәтте сезне?

— Сез үзегез, карап торуга, культурный кешеләргә охшагансыз. Өс-башыгыз да кыяфәтегезгә килешеп тора. Ә үзегез мәгънәсез сорау бирәсез. Исем-фамилияләрегезне сорап-нитеп тормастан, мин сезгә дөресен дөресчә итеп әйтәм: игенне бит комбайн белән генә урмыйлар, игенне колхоз кешесенең кәефе белән дә уралар. Ә безнең хакимият башлыгы Минһаҗев әйтә: «Казан халкына без Арча җиренең ачык китабын күрсәтергә тиешбез. Әгәр без тоннасы-тоннасы белән ит алып килсәк, әгәр без машинасы-машинасы белән йорт буралары, такта-токта алып килсәк, болар моны каян алганнар, ник шул тамаша тилереп Казанга китергәннәр? Туктале, чабата башы чыкты әле, дигәндәй, әүвәлге замандагы сыман, Татарстан башлыклары моны арчалыларга көчләп китертмиме, диячәкләр. Уйнасын гармуннар, сайрасын җырчы тургайларыбыз, ягъни мәсәлән, берсеннән-берсе гүзәл, таза, сау-сәламәт кызларыбыз, батыр егетләребез: ярминкә мәйданыннан шлея-чуклы атларыбыз узсын, казанлыларны сыйларга самавырларыбыз кайнап, гәрәбәдәй сары балларыбыз бизәкле коштабакларда ташып торсын, куелсын бавырсаклар, кош телләре, пар бөркегән өчпочмаклар, пәрәмячләр, машина-кибет алларына күз явыңны алырдай шторлар элинсен, бәйрәм котлавына шагыйрьләрнең иң матур җырлары язылсын — менә булырбыз арчалылар, менә булырбыз Тукай ватанының, Казан артының уңган егетләре-кызлары!

Авыл агаеның, «лапас-сараен» театр декорациясе итеп алып килгән шоферның үткен теллелегенә хәйран калып, хәтеренең әйбәтлегенә гаҗәпләнә төшеп, әмма рәхмәт әйтергә онытмыйча, алга таба кузгалабыз.



*Вәгыйз Минһаҗев (уңда), Гомәр Бәширов, Ринат Фазлыйәхмәтов, Мәгъсум Гәрәев Киров исемендәге колхозның арыш кырында.*

Шунда узган ел җәйне Вәгыйз белән өчәү генә якаларны чишеп, тормыш хәлләрен сөйләшеп утырганыбыз искә төшә. «Мин игеннәр дулкын кагып, авыр башакларын сыгылдырып утырган чагында машинада ялгызым гына кырга чыгарга яратам,— дигән иде ул.— Ни өчен дисезме? Әкрен генә музыка куям, халкыбызның иң моңлы бер көен. Музыка агыла, игеннәр дулкынлана. Менә шунда инде мин, шушы кырларга, шушы игеннәргә Арча төбәге игенчеләренең күпме маңгай тире тамганын, күпме хәләл көче кергәнен уйлыйм...»

Әлеге сүзләр белән шофер әйткәннәрне чагыштырып карасаң, болар бит тәңгәл килә, болар бит шигъри күңелле кешенең җаныннан, хезмәт халкына булган ихтирамыннан туган фикерләр. Шулар янына Вәгыйзнең гармунчы икәнен, тальянда да башка гармуннарда да өздереп, җаннарны айкап уйный белүен, йомшак бәрхет тавыш белән җырлый да белүен китереп кушсак, Арча ярминкәсенең мәгънәсе һәм зурлыгы аңлашыла башлый.

Әлеге уйлар безне гел матурлык дөньясын күзәтергә, игътибар белән күзәтергә мәҗбүр итә. Әнә бер зур йөк машинасының эчен авыл кешесенең бүгенге өй эче, «культурный» телдә әйтсәк, интерьер итеп бизәгәннәр. Кижеле сөлгеләр, көмештәй ак самавыр, аның түбәсендә кызыл чәчкәле чәйнек, мендәрләрне кабартып, өсләренә челтәрләр, әрфия япмалар япкан полировкалы агач караватахта, идәндә затлы келәм — кай төше шәһәр фатирларыннан ким. Барысы урнында, барысы тәртипле, авылча да, бераз шәһәрчә дә зәвык белән киенгән чибәр килен, бу йорт эчен карап-күзәтеп йөрүче апа-җиңгәләрнең сорауларына җавап бирә,— юк, вазифа үтәми, балкып елмая, аңардан гүяки нур агыла.

Әт елы булгангадыр, бик пөхтә итеп эт оясы да ясап алып килгәннәр Арча уңганнары, колгаларга, өй кыекларына беркетелгән сыерчык оялары да күзгә ташлана — болары инде пропаганда өчен, авыл тормышы-

ның да ямьлелеген күрсәтер өчен генә куелмаганнар. Болары акчага сатыла. Ә нигә, Казан каласында үз йортлары белән торучылар, яратып эт асраучылар азмыни? Әлеге пөхтә итеп ясаган эт оялары аларны кызыктырмас дисеңме? Ә сыерчык оялары Казан кешеләренә гел дә кирәк: шәһәр тирәсендә җиләк-җимеш һәм яшелчә бакчалары ел саен арта тора, табигать белән уртак тел табып хозурланып яшәүчеләр очар кошларның безнең якларга кайтуларын сагынып көтеп ала.

Урамда яз. Март кояшы. Төннәрен һәм иртә-кичләрен һавалар әле салкынчарак торса да, иртәләрен салкын сыкы-бәс агачларны, яшь киленнәр төсле итеп, актан киендерсә дә, кышның инде көне санаулы, «яз язлыгын итә, эретә», ярминкә яменнән күңелләре йомшарган, болгавыр заманның авырлыгыннан кырысланып каткан күңелләр нечкәрә, ә Арча сәүдәгәрләренең затлы киемнәреннән һәм затлы мөгамәләреннән бөтенләй үзгәреп киткән кешеләр этешми-төртешми, бер-берсенә юл бирә, бөтенләй белмәгән-күрмәгән кешесенә арчалыларның ярминкәсен мактый, чанага салып, капчык-капчык катнаш азык алып кайтып барган, чүмәлә чаклы палас тартып узган, яки җилкәсенә матур сырлы такталарны бер бауга төйнәп күтәргән кешеләр хакында күңеленнән шыпырт кына уйлый: ә бит яши адәм баласы. Авыр диме, кыен диме, йорт сала, мал асрый, бакчасын тәртипкә китерер өчен җилкәсенә такта бәйләме сала...

Без, «Арча җиренең ачык китабы»н язарга җиң сызганып тотынган авторлар, күңел тойгыларына гына бирелеп калырга теләмичә, ярминкәнең мәгънәсен, зурлыгын күбрәк ачарга теләп, ярминкәнең икенче башыннан биредәге хәлләрне кабаттан карап килә башлыйбыз. Ярминкәнең аргы очында, дистәләгән машинада — төзелеш материаллары. Әллә авыл малайлары булып үскәнгә, әллә башка сәбәбе бар инде, бүрәнә-такта ише нәрсәләр яныннан без тыныч кына, гамьсез-битараф булып кына уза алмыйбыз. Инде шактый ук олы агайлар булып җитешкән көнебездә дә. Бер зур машинага юнылмаган, эшкәртелмәгән чыршы бүрәнәсе төялгән. Икенче машинада — әзер бура. Өченчесендә — чи каен такталар, сайгаклыклар. Аннары сырлап шомартылган озын такталар, метр ярымлы кыска такталар, тәрәзә рамнары, ишекләр тезелеп китә. Товарларның күплегенә әле генә сокланып йөргән кешеләр бәяләрнең кыйбатлыгына тел шартлаталар, «ай-һай-һай!» — диләр. Такталар, йорт буралары, дача йорты янында торучы хуҗалары ипле генә аңлата:

— Без әле меңнәргә, миллионнарга күнекмәгән, туганнар. Сез шул бәяләрнең һәркайсын бер меңгә бүлеп карагыз, нәрсә килеп чыга? Метр ярымлы шома такта — элекке бәя белән 80 тиен, бер миллион 200 мең сум тора торган бакча йорты — бер мең дә ике йөз сум, ишекләр — 45 сум булыр.

Уйга калабыз. Чыннан да, базар мөнәсәбәтләре диган яңа төр икътисадка кергәнче бу әйберләрнең бәясе нәкъ шулай иде бит.

— Гариф абый, торып тор,— ди Мәгъсүм Гәрәев,— акчалар арзанайганчы, ягъни капчык-капчык булып йөри башлаганчы, син күпме пенсия ала идең?

— Бер йөз дә алтмыш сум.

— Хәзер күпме пенсия аласын?

— Җитмеш тугыз мең.

— Димәк, яртысы?

— Шулай булып чыга.

— Менә шул-шул! Димәк, базардагы, ягъни ярминкәдәге әйбер бәяләрен икеләтә арттырып санарга кирәк. Дөресме?

— Дөрес,— дим мин.— Бик дөрес, төтенең туры чыга.

Мәгъсүм Гәрәев шаркылдап көлә, ә мин, картлач, иягемне ышкып, уйга батып торам.

— Нинди уйга баттың, Гариф абый?

— Без минем туган-төягем Арчаны мактыйбыз, арчалылар, болай булгач, безне алдыйлар түгелме?

— Юк, Гариф абый, төтенең туры чыкмый, ха-ха-ха! Пенсияне бит сиңа Арча да, Казан да билгеләми. Мәскәүләр билгели, ягъни мәсәлән, Россия Федерациясе. Рәсәйдә хезмәт хакы соңгы ике елда өч мәртәбәгә, ә товар бәяләре тугыз мәртәбәгә күтәрелгән. Арча хакимияте 1993 елгы игенче-уңганнарга — 400 дән артык кешегә бүләк бирде. Терлекче-алдынгыларга шулай ук дүрт йөздән артык бүләк тапшырды. Алар арасында ничә трактор, ничә җиңел машина, ничә төсле телевизор, ничәмә-ничә тегү машинасы, затлы тун, кер юу машинасы, япон аппаратлары — бихисап.

Безнең сүзне күптәнге танышыбыз, экономист, фәннәр кандидаты-педагог Мортазин читтән генә тыңлап торган икән. Ул безнең белән килеп күреште дә, тәэсирләрен кызу-кызу тезә башлады:

— Күңелемдә Арча халкына булган хисләремне кем белән бүлешим икән, дип уйга батып йөри идем, рәхмәт, сез очрадыгыз. Сигез йөз хезмәт алдынгысына, югары уңыш үстергән колхозларга бер Арча районы күпме бүләк бирде, дисез. Алар арасында күпме трактор, күпме КамАЗ машинасы, күпме автомобиль, дисез. Ә менә мин, экономист, шушы арада гына «Известия» белән «Экономика» газиталәреннән укыдым. Рәсәйнең әллә ничә өлкәсендә, әйтик, Брянск, Тула кебек өлкәләрдә, районда түгел, өлкә хәтле өлкәдә — игътибар итегез! — ике ел эчендә бер генә дә комбайн ала алмаганнар. Менә нинди көнгә калган Рәсәй өлкәләре! Шөкер итегез, яшәсен мөстәкыйль Татарстан!

«Түбәнгә карап шөкер ит, югарыга карап фикер йөрт!» — дигән акыллы бабаларыбыз. Шөкер итәр нәрсәләребез дә, фикер йөртер хәлләребез дә бар. Колхозлар саткан икмәккә вакытында акча түләмичә, рәисләрнең тенкәләренә тияләр. Кредит алу мәсьәләләре дә кыенлашты. Банкларда колхозларны, районнарны «төп башына» утырталар. Комбайн сатып алырга җибәргән акча турыдан-туры комбайн заводларына барып керми, банк эшкуарлары аны башта әйләнешкә кертеп җибәрәләр дә, үзләренә кирәкле акчаны кеше кулы белән көрәп алгач, төп хуҗасына — ягъни тиешле урынына озаталар. Бүгенге тотрыксыз заманда ул арада акча бәясе инде арзанайган, комбайннар бәясе кыйбатланган була. Арчаның хакимият башлыкларына әнә шул үлчәү тәлинкәләрен дә тигез итеп тотарга кирәк ич әле. Әгәр халыкка икмәк, ит һәм сөт турыдан-туры аны җитештерүчеләрдән килеп керсә, кибетләр, сәүдә системалары аркылы егерме биш процентка арттырылмаса, халык отар, азык җитештерүчеләргә дә, кием тегүчеләргә дә рәхмәтен генә әйтер, ә ул азык-төлекне җитештерүчеләр һәм кием-салым тегүчеләр нәкъ үз вакытында уч тутырып акчасын алырлар, банк эшкуарларына ялынып йөрмәсләр иде...

Арча ярминкәсендә йөргәндә, товарлар белән тулы машина-кибетләрне күздән кичергән чакта без әнә шуларны да уйладык. Ниһаять, Чехов базарының ябык түбә астындагы үзәк мәйданына барып кердек. Бирелә халык ташкынын ерып чыгарлык түгел. Кайнап ярминкә, гөрли. Стеналар буена тезелеп киткән ләвкеләрдә жаның ни тели, шул бар: кыздырылган каз ите, каклаган каз, тутырган тавык, шарларын бөркеп торган бавыр, унлаган төрдәге торт, кабартма-коймак, прәннек, кәнфит, җиләк-җимеш — ул хәтле байлыкны, төрлелекне, борыннарны ярып кергән хуш исләрне, җанны тутырган ләззәтне сүз белән генә әйтеп бетереп тә булмый.

«Эшләгәнгә — алкыш, эшләмәгәнгә — каргыш», — дип халкыбыз юкка гына әйтмәгәндер. Моның белән ул эшсөярләргә дә, эшсөймәсләргә дә мөнәсәбәтен белдергән. Тирән мәгънәле итеп!

Ябык базарның түбә астында, биектә, иркен итеп ясалган кәрниздә Арча уңганнары музыка уйнаталар, үз төбәкләренең артистларын җырлаталар. Агыла музыка, ташый җыр! Кешеләр йөри базар мәйданын тутырып — этешми, төртешми, бер-берсенә ачы вә ямьсез сүзләр әйтми. Шундый матур моң таралганда үзеңне ямьсез тоту, культурасыз итеп тоту — оят!

Арчалылар Казанга, Чехов базарына товар сатар өчен генә килмиләр. Алар кала халкын күрергә һәм үзләрен дә күрсәтергә киләләр.

Моннан берничә ел элек уздырылган ярминкәгә әзер мәчет бинасы алып килеп, ярминкәнең капка төбенә үк салып куйганнар иде. Шул мәчет манарасыннан азан да әйтелгән иде. Моңа каш җыерып караучылар да булды, әмма Казан халкы мәчетне дә, азанны да кабул итте. Ник дигәндә, ул сәүдә дөньясына сафланган җан белән керә бит.

Корбан бәйрәме алдыннан булган бер ярминкәгә арчалылар күп итеп тере каз китергәннәр иде. Корбан чалырга.

Өлкән яшьтәге бер апа әйтте:

— Туганым, мин казыңны алам, тик бер мәчет карты аңа догасын укысын, үзебезнең мөселман кешесе суеп бирсен иде...

Халык йолаларын бик тырышып, яратып өйрәнә арчалылар. Халык аларның товарын алгач, рәнҗемәсен, рәхмәт әйтеп итен ашасын, рәхмәт укып киемен кисен.

Быел менә алар кечерәк ярминкәләр дә ясарга күнегеп киттеләр. Һәр шимбәдә районның кулланучылар җәмгыяте рәисе Җәүдәт Миннәхмәтов 20—30 машина товар җибәрә Казанга, шәһәр халкы моңа инде күнегеп килә, шимбә ярминкәсен көтеп ала, товар сайлый, кирәклесен таба, рәхмәт әйтә арчалыларга. Моннан да файдалы, моннан да күңеллерәк тагын ни бар дөньяда! Алучыга да рәхәт, сатучыларның да акчасы әйләнештә йөри. Иң мөһиме — Арча товарының акчасы Арчага кайта.

## Ярминкә кузгаткан уйлар

Ярминкәләр республикабыз халкы өчен көтелмәгән бизәкләре белән ачыла бара. Алар хәзер сату-алу чикләренә генә сыя алмыйлар. Авыл моннан унбиш еллар элек шәһәргә кыяр-кыймас кына килеп кергән иде. Бүген авылның саф рухы шәһәрне әсир итә, колачын заманча, базар мөнәсәбәте шартларында җәя.

Ярминкә — республика җитәкчеләренең халык белән аралашу, аның фикерен белү, тәкъдимнәрен җыеп, көндәлек тормышыбызда гамәли эшләргә әверелдерү чарасына әйләнеп китә бугай. Ярминкәләр авыл һәм шәһәр сәүдәгәрләренең сатып алучы белән матур мөнәсәбәт, әйбәт мөгамәлә урнаштыруына юл ача. Ярминкәләр авылның, шәһәрнең үз товарлары, аерым кешеләрнең шәхси малы белән сату итүдә көчле һәм саф кардәшлек дулкынын халык файдасына көчәйтә.

Ярминкәләрнең шушы дулкыны бөтен Казанны иртә таңнан биләп ала башлады. Башкала базарлары сәүдә ялкынын иртәнге алтыда ук дөрләтеп җибәрсә, аларның кечерәк учаклары Ырымбур трактында, Киров һәм Коләхметов урамнарында кабынды. Бу урыннарда «Салмачы» агрофирмасы, «Залесный» совхозы, Арча һәм Биектау районнарының махсус кибетләре ачылуны күздә тотабыз. Башкаланың җиде районы базарларында авыл сәүдәгәрләре башлап җибәргән ярминкәләргә йомгак ясауны Казан каласы хакимияте үз өстенә алды. Сүз дә юк, әйбәт нәрсә. Азык-төлек һәм киң куллану товарлары җитештерүче предприятиеләргә үз әйберләре белән иркенләп сату итә алу мөмкинлеге ачылды. 1993 елның май алды ярминкәсе Идел буе районы базарында иртәнге җидедә үк гөрли иде инде. Сәүдә оешмалары да, кулланучылар җәмгыятьләре дә, дәүләт предприятиеләре дә, «Салмачы» агрофирмасы да, аерым кешеләр дә сәүдә итә. Монда бар да сәүдәгәр — акчаң булса, сайла, ал! Сатып алучыларга әйбер сайлау мөмкинлеге чиксез. Кемнең товары сыйфатлы, кемнең товары өстәвенә арзанрак та, шуны ала шәһәр кешеләре. Кем матур итеп сата белә, кем ягымлы итеп каршылый, нурлы йөзен балкытып елмая, тәмле сүзен кызганмый, шуның товарын ала адәм баласы. Менә бу, ичмасам, конкуренция, ясалма түгел, чын ярыш! «Салмачы» агрофирмасының товарларыннан күзләр камаша. Җырлар

авторы,шагыйрь күңелле Илсур Хөснетдинов. Арча яңы егете, агрофирманы әйбәт җитәкли, тынгысызлыгы, өлгерлеге белән аерылып тора. Бәяләре түзәрлек «Салмачы» әзерләгән товарларның. Халык ябырылып ала. Ә менә көньяктан килгән җимеш сатучылар янында ник бер кеше булсын! Сөт-катык, каймак сатучылар да аптырашта. Товарлары үтми, кыйбатрак. Сатып кайтып китәсең килсә, бәясен киметәсең: базар ул шундый хикмәтле нәрсә!

Бер башта Татарстанның Премьер-министры Мөхәммәт Сабиров. Бу якта аның урынбасары Равил Моратов, өченче җирдә Казан хакимияте башлыгы Камил Исхаков йөри, халыкның ни уйлаганын беләселәре килә.

— Иптәш Премьер, сүзебезгә колак салыгыз әле,— дип чираттан чыга бер чая хатын.— Ни өчен шушы көнгә кадәр кибетләрдә кәбестәгә тилмертәсез? Беренче Май килеп җиткәнне көтмәсәгез дә булыр иде. Базарда бар бит әнә. Дәүләт сәүдәсен халык ихтыяҗына колак салырга өйрәтегез...

Менә шулай: халык вәкилләре күңелгә сары май булып ята торган сүзләрне генә әйтми, халык чаяланды, кыюлыгы артты, ул хәзер күңелендәге уен уйдырып сала!

Мөхәммәт Галләмович чираттагылар белән озаклап сөйләшә, аларның зарларын тыңлый, уйланырдай фикерләрне аңа әйтеп кенә торалар. Халык гел уңайны, үзенә файдалыны таләп итә.

Боларны без ник сөйлибез? Ник Арчадан читкә тайпылдык әле? Чагыштырып карау өчен. Әлеге өлгер җитәкчеләр янында да Арча һаман да Арча булып кала. Арча сәүдәгәрләре Киров районының Коләхметов урамындагы тугыз катлы йортның түбәнге катын сатып алды. Арча кулланучылар җәмгыятенең рәисе Җәүдәт Миңнәхмәтов инициативасы белән анда «Арча» исемле кибет ачылды. Без анда булдык. Сәүдә мәйданы 800 квадрат метрлы булган бина бик яхшы җиһазландырылган. Эченә керсәң — чыгасы килми. Картиналарда Тукай рухы, Арча табигатенең гүзәл манзаралары. Сатучы кызлары да Арчаныкы — шулай икәне әллә каян күренеп тора. Ягымлылар, чибәрләр, киемнәре килешле, буй-сыннары зифа. Моннан буш кул белән чыгып китә алмыйсың. Кибет мөдире Ирек Хафизов — тапкыр фикерле, үткен егет. Үзе Әлки якларында туып-үскән, дөньяларны гизеп кайткан башлы адәм.

— Ите-сөте, пешкән ризыклары Арчаныкы,— ди ул,— җиләк-җимеш — көньяктан, кием-салымны чит илләрдән дә кайтартабыз. Кибеттә төрле-төрле бүлекләр бар: шифер, такта кебек төзү материаллары да, мануфактура да, ашамлыклар да, галантерея дә... Мондый да бай һәм зәвыклы-матур кибет Казанда сирәк әлегә. Ул бөтен шартын китереп Арчаның эшчән һәм булдыклы халкына охшап балкып тора.

Кибетне ачу Май бәйрәменә туры килгән иде. Сатучыларның да, алучыларның да күңеленә бәйрәм тойгысы салып өлгергәннәр: Уфадан татар халкының сөекле җырчысы Фән Вәлиәхмәтне чакырып китергәннәр, ә ул Арча хакимияте башлыгы Вәгыйз Миңһаҗевның якын дусты икән. Ул хакта соңыннанрак сөйләрбез, ә хәзергә шунысын әйтик — җырчыбыз көмеш телле тальянда өздереп гармун уйнады, өздереп җырлады, аның бию көйләренә кибет эчендә үк рәхәтләнеп биеп тә киттеләр.

Ярминкәләр башлаган файдалы эш әнә шундый сәүдә учакларына китереп чыгарды.

Авылда сәүдә — хәзер шактый зыянлы эш. Шушындый кибетләр исәбенә зыянны капларга тырышалар. Халыкның үзе җитештергән, гаиләсеннән арткан туклану әйберләре, бакчачыларга кирәкле төзү материаллары, көнкүреш кирәк-яраклары белән сату итәргә менә дигән сәүдә предприятиесе бу. Башлары эшли район җитәкчеләренең. Казан халкы моның өчен рәхмәтле аларга.

Зур бәйрәмнәр алдыннан Казан базарларында ярминкәләр башлана. Шәһәр халкының бәйрәмен матур итү өчен авыл кулыннан килгәннең барысын да эшли.

Ә Казанның җавабы ничек булыр — анысын киләчәк күрсәтер.

## Икмәк симфониясе

Менә ун-унбиш көн инде Арча халкы йокысыннан «ИКМӘК» дип уяна. Йомшак түшәгенә ятканда да шушы сүзне кабатлый, төшендә дә икмәкне күрә дисәк тә ялгышмабыз. Хәзер райондагы барлык көч-куәт — җанлысы да, җансызы да — шушы иң кадерле байлыкны җыеп алуга һәм кышка әзерләп куюга тупланган. Шуларның кодрәте тудырган хезмәтне бүген симфоник музыка, симфоник поэма, симфоник концерт белән тыңлаштерергә дә мөмкиндер. Аерма тик шунда гына: кеше күңелендәге иң нечкә хисләрне дә уята алырдай катлаулы музыканы композиторлар иҗат итсә, икмәк симфониясен Игенче үзе яза, үзе үк башкара да.

Күрдек, шаһит булдык: «8 Март» колхозы рәисе Рәхимҗан Хөсәенов, район хакимияте башлыгы Вәгыйз Минһаҗев, «Октябрь» колхозы житәкчесе Васил Мифтахов арыш басуларында йөрделәр. Кулларында учма. Ни турында сөйләшәләр дисезме? 75—80 бөртекне күтәреп тора алырлык арыш сабагы турында. Нечкә генә булса да, ул сабакта кешелек дөньясын тук яшәтердәй көч бар. Каян килә икән аңа андый көч-дәрман? Кешедән, әлбәттә, адәм балаларыннан. Иген басуларын үз күргән, жаны-тәне белән аны яраткан крестьяннардан. Арча кешеләре узган елны көзен орлыкларны кулларында иркәләп туфракка салганнар иде. Ул бөртекләр ел буена җирнең татлы җиме белән туенып, кояш нурларының җылысын алып, яңгырның көмештәй тамчыларын эчеп, мең-мең тапкыр артып, игенчегә әйләнеп кайттылар. Хакимият башлыгы һәм әртил житәкчеләре шул хакта сөйләшеп йөриләр...

Симфония, арышлар шавы дигәннән, бер хатирә искә төште. Җыр язганда композитор белән шагыйрь кызыпмы-кызып бәхәсләшәләр иде.

— Син бит, дустым, арышның да нәрсә икәнен белмисең,— ди композитор шагыйрь дустына.

— Икмәк ул, икмәк ул — арыш,— ди шагыйрь рәнжеп.

— Композиторлар телендә арыш — ул икмәк кенә түгел, яшел аппассионата ул. Әмма аны бөек композитор Бетховен түгел, гап-гади крестьян яза, ел саен яза, беләсең килсә, ел саен чиксез күп дулкынланулар кичерә.

Композитор хаклы. Чыннан да шулай ич. Бетховен «Аппассионата»сында даһи композиторның жаныннан кайнап чыккан олы хисләре һәм тирән фикерләре тупланган. Алар музыка кораллары аша кешенең күңел түренә үтеп, жанын тетрәтәләр, тормыш өчен көрәшергә өндиләр. Крестьян аппассионатасы игенченең үтә дә авыр хезмәтенең тозлы тирен, шатлык-куанычларын, ышанычын һәм үкенүләрен, муллыгын һәм фәкыйрьлеген бергә җыеп яңгырата!

Бәлки, шуңа күрәдер, Арчаның Икмәк симфониясе, Крестьян аппассионатасы бөтен республикага ишетелерлек булып яңгырый.

## Президент сәгате

Берничә ел рәттән Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев район һәм шәһәр хакимияте башлыкларының, министрлык һәм ведомство житәкчеләренең киңәшмәсен үткәреп килә. Анда урып-җыю, халыкны кышын тукландыру өчен икмәкне мул итеп әзерләү мәсьәләләре карала... Алдынгыларның тәҗрибәсе өйрәнелә.



*Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Балтачның Уңыш бәйрәмендә. 1994 ел.*

Президентның үз сүзләре белән әйтсәк, киңәшү-сөйләшү иген кырларында чайкалган алтын башаклар дулкыны кебек, матур, ягымлы, сабыр тонда алып барыла. Партия хакимияте заманындагы сыман боерык-әмерләр, «келәмгә бастырулар» юк монда. Игенчегә, җитәкчеләргә ихтирам һәр адымда сизелеп тора.

Хәзер болай сөйләшү өчен нигез дә бар.

Кырларда инде берничә ел рәттән мул уңыш өлгерә. Табигать тә кәефебезне кырырлык афәтләр эшләми, бәла-казаларын, корылык алып килә торган көйдергеч җилләрен безнең өскә җибәрми. Озын сүзнең кыскасы, эшебез көйле-җайлы гына дәвам итә.

1992 елның киңәшмәсенә Арча хакимиятенең башлыгы Вәгыйз Минһаҗев Президентыбызга Арча кырларында үскән бодай онынннан пешерттереп, тегермән ташы хәтле күмәч алып килгән иде. Дәүләткә ашлык сату заказын беренче булып үтәгән районга — арчалыларга бу бик тә килешә иде, Президентыбызга яңа уңыш күмәчен бүләк итәргә аларның тулы хакы бар иде. Минтимер Шәрип улы Арча игенчеләрен зур уңышлары белән котлап кына калмады, Вәгыйз Васил улына Президент сәгате тапшырды — беренче номерлысын!

Президентның шундый ук сәгатьләренә Балтач районы хакимияте башлыгы Марат Әхмәтов, Чистайныкы — Абрек Хәйруллин, Югары Осланныкы — Алексей Манонин, Баулыныкы — Әбделхәй Хәйруллов, Алексеевскийныкы — Алексей Демидов, Кукмараныкы — Мөхәммәт Гатиатуллин лаек булдылар.

«Мондый сәгатьләр 20 августка кадәр план-заказларны үтәгән район башлыкларына гына биреләчәк, калганнарына исемле сәгать тә җитеп торыр», — диде Шәймиев, шаяртып.

Арчалар 1992 елда да, 1993 елда да иген үстерү һәм ашлык сатуда дәүләт заказын үтәү ягыннан беренчелекне бирәүгә дә бирмәделәр. Арча игенчеләре 1992 елны 30 мең тонна урынына дәүләткә 50 мең тонна, 1993 елны 62 мең тонна икмәк саттылар.

Арча белән янәшә Балтач бара. Алардагы уңыш бәйрәмнәре дә гаять үзенчәлекле. Бер елныкы икенчесенә һич тә охшамаган.

Халыкның гыйбрәтле бер сүзе бар: «Пешкән икмәк теләсә нинди чәчәктән дә хуш ислерәк».

Арчаның 1993 елгы уңыш бәйрәмендә (ул декабрь урталарында узды) халыкның әлеге зирәк сүзе расланды. Сәхнәдәге ак-кызыл, яшел-зәңгәр, сары-шәмәхә чәчәкләр бакчасын әйтеп тә тормыйбыз инде. Зур бүләкләр белән бергә, кулларына чәчәк бәйләмнәре тоткан кешеләр, залга төшеп, үз урыннарына сибелгәч, зал чын мәгънәсендә гөлстанны хәтерләтә башлады.

Җирнең һәр гектарыннан 45 әр центнердан артык уңыш җыеп алган колхоз-совхоз җитәкчеләре моны сизделәр булса кирәк, алар сәхнәгә колач җитмәстәй түгәрәк бодай күмәчләре күтәреп менделәр. Күмәчләрне президиум өстәленә тезеп куйгач, мәдәният сарае хуш ис белән тулды. Яңа пешкән икмәк исе борыннарны кытыклап, урак өстендәге авылның таң сызылган чакларын хәтерләтте. Урак өстендә булдыклы кодачалар, җиңгиләр ипине басу-кырларга чыкканчы таң атар-атмаста пешереп өлгертәләр бит... Мондый чакта чәчәк исләрең бер якта торсын!

Арчалыларның һәр бәйрәме, сәнгать кичәләре, ярминкәләре бер-берсенә охшамаган булыр. Уйлап чыгарырга маһир да соң арчалылар! Аларда бөек Тукаебыз рухы елдан-ел яңара, яңа төсмерләргә баеп кайта. Сөекле шагыйребез васыять итеп калдырган: «Инде эшлик саф, ачык күзләр белән, чын акыл белән». Арча төбәгендә Тукай әйткәнчә эшлиләр. Шагыйрь акылы транспарантларга беркетелеп, юл читләренә, авыл урталарына килеп урнашты. Алар халкыбызның борын-борыннан килгән гореф-гадәтләрен яңартып, иҗат чишмәләре булып торалар. Арчаларның, Балтачларның шушы гамәлләрендә әдәбият-сәнгатькә ихтирамнары, зәвык белән эшләүләре сизелә. Ярминкәдә, шофер әйтмешли, «ашлыкны комбайн белән генә урмыйлар, кәеф белән дә уралар». Тукай васыятьләрен халык хуплый. Җитмеш яшьлек Фәттерахман бабай Нуриязданов, үткәннәрне искә төшереп, бүгенге буыннарның эшен уңай бәяләп, сүзен болай итеп очлады: «Игеннәр каерылып уңсын өчен аек баш белән эшләргә кирәк. Шул чагында муллыкта яшәргә насыйп булыр». Фәттерахман бабайны телгә алуыбыз очраклы хәл түгел. Ул быел Арча җирендә язгы чәчүне ата-бабаларыбызча башлап җибәрде. Яңа Кенәр басуында муенына тубал асып, орлыкларны туфракка пешкән йомырка белән бергә чәчте. Кулы җиңел булган, андый матур йоланы заманында «Намус» романында Гомәр ага Бәширов та язып чыккан иде. Тимери карт йортында тонык кына булып сары ут яна. Язгы чәчүгә чыгарга тубаллар, пешкән йомыркалар әзерлиләр. Йомырка белән ашлыкны бергә сипсәң җиргә, бодае да, арышы да йомыркадай эре булып үсә, имеш. Өлкән әдибебез, 92 яшьлек Гомәр ага Арчаларның уңыш бәйрәменә хәер-фатихасын юллаган.

«Рәхмәт сезгә, туганнар!

Туган җирем Арча якларыннан берсеннән-берсе куанычлырак яңа хәбәрләр ишетеп торам. Сез, минем якташларым, быел иген кырларында гаҗәеп бер уңганлык, оешканлык, сокландыргыч тырышлык үрнәкләре күрсәтеп, моңарчы төшкә дә кермәгән зур уңыш алуга ирештегез. Элегрәк елларда ашлыгы белән игенчене әллә ни куандырмаган көлсу туфрактан шулкадәр уңыш алу, кайбер басуларда башактагы бөртекләрнең туксанга кадәр җитүе — моңарчы һич булмаган хәл, могҗизага тиң батырлык,

фидакарь хезмәт нәтиҗәсе ул! Бу һәммәбезгә дә зур шатлык, боларның һәммәсе өчен дә Арча якларыннан чыккан әдип һәм шагыйрьләр исеменнән рәхмәт сезгә, туганнар!

Якташларыбызның мондый авыр елларда да шундый күтәренке күңел белән эшләүләре, кыенлыкларга бирешмәүләре, көрәш байрагын югары тотулары һәммәбезне дә куандыра, сезнең бу уңышларыгыз республикабызның мөстәкыйльлек өчен көрәшенә лаеклы өлеш булып керсен, киләчәккә ышанычыбызны, өметләребезне тагын да ныгытсын! Амин!

Изге теләкләр белән якташыгыз. Татарстанның халык язучысы Гомәр Бәширов».

Аксакал әдипнең, якташ язучының котлавын зал рәхмәтле алкышларга күмеп кабул итте.

Фәттерахман бабай сәхнәдә ялгызы гына түгел иде. Аның янына «Ашытбаш» колхозында уракка керешкән көнне учмаларны көлтә итеп бәйләгән, бәбкә куйган Габделхәй бабай Хәлимов, бала чагыннан Күкчә Бирәзә кырларында эшләп картайган җитмеш яшьлек Шәхринур әби Исламова, сукачыларның республика ярышында меңләгән кешене шаккатырган ундүрт яшьлек Илдус Закиров («Динамо» колхозы) чыгып бастылар. Бабайларның өсләрендә күз явыңны алырдай камзул, билләрендә кызыл пута, башларында чигүле кәләпүш, бер бабайның кулында теге заманнарда чәчү чәчкән тубалы, икенчесе кулына урак тотып, иңенә бодай көлтәсен салган. Шәхринур әби ап-ак алъяпкычтан, алма бизәкле шәльяулыктан, үзе тагын кәкре башлы артыш таякка таянган. Залда, аларны күрү белән, бодай басуындагы төсле дулкыннар йөгерде, кешеләр җанланды, рәхәтләнеп бер кул чаптылар. Ата-баба рухын саклаган өлкән игенчеләргә дә, аларга алмашка килгән яшь буын вәкилләре Илдус кебек уңган үсмерләргә дә, Арчаның шундый матур бәйрәм оештыра белгән хакимият вәкилләренә дә рәхмәт сүзе булып яңгырады ул алкышлар! Минһаҗевның күңеленә ул алкышлар сары май булып ятты. Аның уен, аның хыялын, аның халык йолаларын яңартканын аңлады Арча игенчеләре. Рәхмәт аларга шундый да аңлы булганнары өчен! «Мондый кешеләр белән эшләве үзе үк бәхет түгелмени?» — дип, күңелләре җылынып уйлады ул. Аның ул шатлыгын Арчаның уңыш бәйрәменә кайткан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Фатих Сибагатуллин да уртаклашты — нык итеп кулын кысты. Ихтимал, бу минутларда аның күңеленнән дә җылы дулкыннар узгандыр. Арчалыларның мондый матур гамәлләрен, ил агаларын онытмыйча, аларны халык алдына чыгаруларын башка районнарга да күчерергә кирәк. Ә арчалыларның уңыш бәйрәмнәренә башка районнардагы яңалыкларны өстәргә кирәк. Әнә бит Әтнәләр Фәйзи Галиевне, — 49 ел буена колхоз йөген тарткан, инде лаеклы ялга чыккан председательне бер бәйрәмнәреннән дә калдырмыйлар, бәйрәмнең түренә китереп утырталар. Кешеләрне йөк тарткан чакта гына түгел, ялга чыккач та хөрмәтли белергә кирәк.

Фатих Сибагатуллинның исенә Балтачтагы уңыш бәйрәме килеп төште. Алар бит уңыш бәйрәмнәрен бөтенләй үзләренчә үткәрәләр. Мәдәният сараенда түгел, ачык һавада үткәрәләр алар уңыш бәйрәмен. Сабантуйлы, ярминкәле итеп! Ачык һавада халыкны кинәндереп, күңел ачтыра, рәхәтләндереп ял иттерә бит ул безнең гүзәл сабантуйлары. Кешеләрне күп итеп чакыра алу ягыннан сабантуй белән бары тик ярминкә генә ярыша ала торгандыр! Ә Балтачта шуларның икесен бергә китереп кушалар. Менә ул бәйрәм дисәң дә бәйрәм.

Тормышның тирән уйларга сала торган хикмәтле яклары бар. Тукайның әнисе Арча төбәгендә туган, балтач төбәгендә күмелгән. Арча хакимияте башлыгы Вәгыйз Минһаҗев та, Балтач хакимияте башлыгы Марат Әхмәтов та Арча районының Хәсәншәех авылында туып үскәннәр, Вәгыйз — Арчаны, Марат Балтачны җитәкли. Хәсәншәехтан икс-өч чакрым гына ары Апаз авылы бар — шунда туып-үскән Фатих Сибагатуллин башта Арчада җитәкче булды, аннары Мамадышта, инде менә

бөтен республканың иң авыр йөген тарта. Уч төбе хәтле генә тугайдан өч зур җитәкче, талантлы, кодрәтле җитәкче чыккан. Без гадәттә: «Арча 25 тән артык әдип һәм шагыйрь бирде татар әдәбиятына»,— дип мактанырга яратабыз. Баксаң-күрсәң, Арча — җитәкчеләр тәрбияләүче төбәк тә икән әле.

Әлеге өч җитәкче янына Арча районының Сеҗе егете Әхмәт Галиевне дә китереп кушарга кирәк. Казан компрессорлар заводының генераль директоры, үзе һәм инженер улы уйлап тапкан компрессорлар өчен ул Европаның иң зур бүләкләрен алды. Монысы инде Арча төбәгенең тагын бер җитәкчесе. Дүрт зур җитәкче, дүрт зирәк кешене санадык. Төпченеп эзли башласаң, алар тагын бардыр әле. Әхмәт Галиев Арчаның данын аеруча күтәрде — 1994 елны ул Испаниянең алтын йолдызына лаек булды, докторлык диссертациясе яклады һәм академик итеп сайланды.

Арчаның хәзер үз академигы бар!

1993 елның уңыш бәйрәмендә ул Арчаның бер колхозына үзләренең Казан компрессорлар акционерлык җәмгыяте җитештергән станок бүләк итте. Зур бүләк, җитди бүләк. Арчадан үсеп чыгып, бөтен дөньяга танылган Әхмәт әфәнде Галиев өчен без шатланып утырдык. Әхмәтнең юмартлыгы һәркайда мәгълүм. Бер очрашу вакытында ул үзе укып чыккан, хатыны Гөлчәчәк ханым унбиш ел буена укыткан Сеҗе мәктәбенә баян бүләк иткән иде.

Бүләк дигәннән, әйткәнебезчә, Арчаның алгы сафта атлаган игенчеләренә, дәүләт амбарларына 62 мең тонна икмәк салып куюда аеруча күп көч түккән, зирәклек күрсәткән кешеләргә 400 дән артык кыйммәтле бүләкләр тапшырылды. Икенче бер бәйрәмдә — алдынгылар бәйрәмендә терлекчеләргә, авыл хуҗалыгының төрле тармакларына могҗизалар тудырган фидакарьләргә (почта ташучыларга тикле) шулай ук 400 дән артык бүләк бирелде.

Намуслы хезмәт иткән кеше онытылмый икән. Бүләкләр бәйрәмнәрне нурлатып-балкытып җибәргән бизәк булды.

Бәйрәмнәрдә катнашкан хезмәт батырларына табыннар әзерләнгән иде. Кырларда үскән игеннәре төсле мул иде табыннары арчалыларның. Укымышлы Әхмәт Галиевнең гармун уйнавына кушылып, Түбән Каманың техник фәннәр докторы Азат Зыятдинов Арча көен җырлады. Икесе дә Арча егетләре. Димәк, бишенче җитәкче, химия предприятиесенең җитәкчесе дә Арчада туып-үскән булып чыкты.

Арчаның якын дусты, танылган җырчы, гармунчы һәм үзе иҗат иткән көйләрне җырлап, халык күңеленә үтеп кергән Фән Вәлиәхмәт Башкортстаннан бер төркем яшь җырчыларны алып килгән иде. Ул үзе Вәгыйз Минһаҗевның туган авылы Хәсәншәех турында җыр язган. Җыр Арчада беренче мәртәбә яңгырады. Болары бәйрәмнең салават күпередәй аллы-гөлле төсләре булып тоелдылар.

Урыс телендә «стимул» дигән сүз бар. Безнеңчә, аны татар теленә «өстиме ул?» дип тәрҗемә итәргә кирәктер. Хикмәте менә нәрсәдә: Арча бәйрәмнәре кешеләргә шатлык өсти, горурлык өсти, яңа бер талпынуларга этәрә. Бәйрәмдә катнашучылар, мәҗлестән соң, үз авылларына кайтырлар. Алар янына күршеләре керер. Алар хезмәт батыры табынында кунак булырлар һәм бәйрәмнең ничек узуын сорашырлар. Бүләк алып кайткан кыр батыры берсен дә калдырмыйча, түкми-чәчми сөйләп бирер. Күршесенең күңелендә: «Киләсе җәйдә миңа да махы бирмәскә кирәк әле...» — дигән уй кузгалыр. Димәк, стимул бар, стимул күңел көрлеге өсти, нәрсәгәдер рухландыра, өмет чаткысы уята...

Бу уйлануларны кыска бер афоризм белән тәмамлыйсы килә: «Арча җире бу елларда туй итә», Арча җире шатлана. Арча җире соңгы елларда Татарстанның игенчелек башкаласына, икмәк башкаласына әверелде.

Бик борынгы заманнардан Адәм баласы Җирнең кадерен белеп, аның бәхет һәм бәрәкәт чыганагы икәнен тоеп яшәгән. Ана газиз Анасы кебек кадер-хөрмәт, ихтирам-игътибар күрсәтергә тырышкан. Моның нигә шулай икәне һәркемгә дә мәгълүм: Җир бит ул безне туйдыручы, Җир — муллык чыганагы. Җир-Анабызның иң сөекле уллары һәм кызлары, әлбәттә, ИГЕНЧЕЛӘР!

Менә шушы хакыйкатьне тагын бер мәртәбә раслау, Җир-Анага булган хөрмәтне һәм игътибарны арттыра төшү өчен Президентыбыз Минтимер Шәймиев 1994 елны да киңәшмә җыйды. Бу киңәшмә март башында уздырылды. Башка киңәшмәләрдән аермалы буларак, Татарстан игенчеләренең бер өлеше Чаллыга җыелды, ә икенче көнне, ягъни 5 мартта, Арча төбәге, Әтнәләр, Балтачлар, гомумән Казан арты һәм Казан тирәсе районнары Казанга җыелдылар. Яз бәйрәме уңае белән Казанда ярминкәләр гөрләгән чак иде. Казан киңәшмәсенә килүчеләр таң башыннан ук Чехов базарындагы Арча ярминкәсенә таң калып, аның гүзәллегенә, Арчаларның әллә нәрсәләр уйлап чыгарырга сәләтле булуларына исләре китеп, тел шартлатып йөрделәр. Арчалар Казанга товарны 335 машинага төяп алып килгәннәр, кибет-машиналарны Татарстан гербы, Татарстан Республикасы флаглары белән бизәгәннәр, ярминкә урамына килеп керү белән сине бәйрәм хисе чолгап ала.

Аннары киңәшмәне оештыручы Татарстан җитәкчеләре, районнарның хакимият башлыклары, министрлык һәм ведомство вәкилләре Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының яңа бинасына юнәлделәр.

Без дә булдык анда. Татарстандагы авыл хуҗалыгының бүгенге хәле һәм киләчәктәге бурычлары турында доклад та, борчылулы чыгышларны да тыңладык. Тик болар берсе дә без ишетмәгән нәрсәләр түгел иде. Партия хакимияте вакытында да без андый докладларны, «тиеш», «бурычлы» дигән сүзләрне байтак ишеттек, шөкер... Залдагы башлыклар һәм алдынгы механизаторларның игътибарын магнит кебек үзенә тарткан Президентыбыз Шәймиев чыгышы булды. Ул төп-төгәл ярты сәгать сөйләде. Бернинди кәгазьсез, «шпаргалкасыз». Тымызык яуган җәйге яңгыр шикелле, залдагылар күңеленә үзенең уй-фикерләрен үткәзеп торды. Технология белән экономиканы бергә куша алды ул, иген игүнең хасиятләрен, терлекчелектәге уңышларыбыз һәм ирешәсе үрләребезне саннар белән, фактлар белән яттан әйтеп бирде. Димәк, ул Татарстанның экономикасы белән чынлап торып кызыксына, барысын күңеленә сеңдерә бара.

Аның телмәрен тыңлаган чакта өч урында утырган өч кеше үзенчә нәтиҗә чыгарды. Президиумның да алгы рәтендә утырган Фәйзи Галиев, 49 ел буена колхоз авылының камытын киеп, авыр йөкне ыңгырашмыйча тарткан кеше, колхоз рәисе булган акыллы зат: «Председательлектән иртәрәк киттем бугай...» — дип уйлап утырды. Арча хакимияте башлыгы Вәгыйзь Минһаҗев: «Гомерен озын итсен, ходай аңа сәламәтлек бирсен. Республикабызда мондый сабыр һәм зирәк җитәкчеләр булганда эшләр алга барачак...» — дип күңеленнән фикер йөртте. Без, документаль повестьның авторлары, аны тыңлаганда, мондый фикердә идек: «Минтимер Шәймиев авыл хуҗалыгы институтын югары дәрәҗә диплом белән тәмамлый. Аны аспирантурада калырга кыстыйлар. «Юк, — ди Минтимер, — минем әти гомер буе колхоз рәисе булды. Мин авылдан килдем, авылга китәм. Минем ният авылны күтәрү». Әнә бит нинди принципиаль кеше.

Галимлек бик югары дәрәҗә саналган чорда да аспирантурада калмый. Үз теләге белән авылга китә. Менә без аны тыңладык. Нинди саллы аның дәлилләре. Бодай сортларын да, борчакны игү технологиясен дә,

Ульян вә Самарадагы хәлләрне дә ул белеп тора. Татарстан белән аларны чагыштырып карый, барысын үз бизмәненә (кстати, фәнни бизмәненә) салып үлчи, димәк, ул житлеккән. Галим булып, практик галим булып житешкән. Мелиорация министры булу, Татарстанның Министрлар Советында эшләү, Югары Советны житәкләү, ниһаять, республикабыз халкы ышаныч белдереп, сайлап куйган беренче Президент булу — аңа акыл, зирәклек биргән, тәжрибә тупларга мөмкинлек тудырган.

Мөслимнең атаклы комбайнчысы Сабир агай Зиннуров белән сөйләшеп торган булды. Ул әйтә: «Шәймиев институттан соң Мөслим РТСына баш инженер булып килгән иде. Килү белән барлык агрегатларны сүттереп ташлады. Шуларны жыярга жиң сызганып үзе кереште. Инде менә хәзер ул Татарстан экономикасын өр-яңа баштан сүтеп жыя...» Президентыбыз турында якташларыннан мондый сүзне ишетү күңелле, әлбәттә.

## Уйланыр өчен мәгълүматлар

Арча районы 1930 елда оеша. 1990 елны аңардан Әтнә районы аерылып чыга. Район республикабызның төньягына урнашкан. Үзәге — Арча эшчеләр поселогы. Территориясе 1844 квадрат километр, халкы 47 мең ярым. Ягъни бер квадрат километрга 26 кеше чамасы туры килә. Төп милләте — татарлар (92,5 процент), урыслар (6,5 процент), марилар (0,5 процент), чувашлар (0,1 процент). Районда 29 авыл Советы, 130 авыл бар. Бер авылга уртача 276 кеше туры килә. Туулар 17 процент, үлүләр — 14,3 процент. Шул рәвешле халыкның табигый артуы 2,7 процент булып чыга. Хезмәткә яраклы кеше районда 51,6 процент тәшкил итә.

Район территориясе үрле тигезлектән гыйбарәт. Абсолют биеклекләр 170 тән 256 метрга кадәр. Балчык, таш, известь, торф, ком запаслары бар. Туфрак күбрәк чирәмле-көлсу, көрән-соры, чирәмле-карбонатлы, аксыл-соры көлсу. Урманнар мәйданның ун процентын били, еллык уртача температура 2,3 градус, явым-төшемнәр 450—460 мм.

Район территориясе аша Казан-Екатеринбург тимер юлы (Арча станцасы), Казан-Малмыж-Киров автомобиль юлы уза. Авыл хужалыгы жирләре 155,8 мең гектар били, шул исәптән сөрүлекләр 132,9 мең гектар, печәнлекләр 5,2 мең гектар, көтүлекләр 17,4 мең гектар (1990). Язгы бодай, арыш, арпа, солы, борчак, бәрәңге игелә. Терлекчелектә төп тармаклар — ит-сөт терлекләре һәм сарык асрау. Район үзәгендә милли аяк киемнәре берләшмәсе, авторемонт предприятиесе, төзү конструкцияләре комбинаты, кирпеч заводы, мех чималын эшкәртү комбинаты, сөт комбинаты, крахмал заводы, элеватор бар. Район үзәгеннән читтә агач эшкәртү комбинаты, яшелчә киптерү заводы (Яңа Кенәр авылы), урман хужалыгы урнашкан. Арчаның үзендә педагогия училищесы (хәзер ул колледж дип атала), Тукай-Кырлай авылында Габдулла Тукай музее эшли.

(Бу материаллар Татарсан китап нәшрияты 1992 елны бастырып чыгарган «Все о Татарстане» китабыннан алынды.)

Соңгы ике елда Арчада зур бер мәчет, Сәнгать мәктәбе үсеп чыкты. Әдәбият-сәнгать музее ачылырга әзерләнә.

Арчада күп урынлы зур мәдәният сарае, сәүдә кибетләре, бик яхшы китапханә, кунак йорты һәм башка күп төрле социаль-көнкүреш учреждениеләре эшли. Арчаның райүзәге белән станца арасында, Үрнәк поселогына һәм башка төбәкләргә автобуслар йөреп тора, соңгы елларда житешкән асфальт заводларының юлларны тәртипкә китерү өчен армыйталмый эшләүләре безгә мәгълүм...

Туган җир.

Туган туфрак.

Аңардан да кадерле, аңардан да газиз тагын нәрсә бар? Минһаҗ Вәсиленең балалары туган-үскән йортка, төп нигезгә җыелырга ятаталар. Арчадан Вәгыйз кайта — өлкәннәре, Казан каласыннан Ринат кайта — төпчекләре. Өлкән малай белән төпчек малай уртанчыларын — Таһир белән Зөләйханы тартып китерәләр.

Җыелалар балалар түгәрәк өстәл янына.

Түр башында әниләре — Тәскирә апа.

Өлкәнлек хокукыннан файдаланып, Вәгыйз сүз башлый:

— Әни, без уйлаштык-уйлаштык та шундый бер фикергә килдек. Хәсәншәехта безнең төп йортыбыз үз урынында торсын. Менә төпчек малай институтын тәмамлар, өйләнер, борынгыдан килгән матур гадәт буенча ул төп йортта, синең белән бергә урнашып калыр. Ә без, ике улың, төп йортка булышып торырбыз. Зөләйха сеңлебезнең үз хуҗалыгы, шуны тәртипле итеп алып барса, без шуңа канәгать булырбыз.

Минһаҗ Вәсиленең малайлары сүзне җилгә очыра торганнардан түгел. Төп нигезгә йортны җилле итеп җиткезделәр. Нарат бүрәнәдән, шифер түбәле, алты почмаклы йортның ике ягына кирпечтән «пристройка» да корып куйдылар, каршыдагы «терлек фатиры» ишегалдының буеннан-буена сузыла — анда сыер яше, тана яше, бозау яше, тавыклар өчен кетәклек, салам-печән өяр өчен бик дәү чормасы-печәнлеге бар. Иркен булсын, җанны сөендереп торсын, диделәр.

Баштарак елларны совет хакимияте җир кешесе булган крестьянны бик авыр хәлләргә китереп куйгангамы, әтиләре дә кайчан да булса бер иркен яшәргә хыялланып йөрде. Баһадир гәүдәле, озын буйлы, көчле кеше иде, мәрхүм. Бригадир булды, урман чыгарды, ат җикте, тире-яры белән эш йөртте, әмма төп һөнәре механизаторлык иде. Арчага трактор белән барып кайта торган иде. Хәсәншәех Вәсилен тирә-як авылларда дан итеп сөйли торганнар иде. Вәгыйзгә ун яшь тулыр-тулмаста ул аны урманга алып йөрде. Агач сайларга өйрәтте.

Бай урманы. Әтисе белән икәүләп, ат җигеп, урманга китәләр. Су кебек ай яктысы. Дүрт чакрымны сүзсез генә, арба тәгәрмәчләре келтерәвен тыңлап баралар. Әтисе атка чыбыркы белән сукмас, сүгенмәс. Урманга җиткәнче ул, йокымсыраган төсле, күзләрен йомып барыр. Урман эченә кереп, көндездән үк үзе сайлап куйган урынга җиткәч, атны туктатыр, йөгән тезгенен чишеп, аркалык-түшлекләрен бушатып, атны печән утларга кушар. Аннары... менә шунда инде дөньяның кызыгы башлана... Аннары — әтисе Вәгыйзне агач таныргa өйрәтә башлый. Беренчедән — эче куыш түгелме? Балта белән әкрен генә сугып карый, куыш булса, шапылдый, тыгыз булса, зыңлап тора. Кызылы чыкмыймы? Чыкса, черүгә таба юл алган ул агач! Мүкләнмәгәнме? Шуларны белешкәч, агачны кая егарга икәнен билгелиләр, урын сайлыйлар. Агачны гөрселдәтеп аударырга ярамый, «стрелюк» килеп чыгарга мөмкин. Йомшак кына итеп аударалар. Ботагын чабарга улына куша әти кеше — Вәгыйзгә, ул аның өчен бәләкәй балта хәстәрләп куйган. Ботакны әрәмәләр арасына яшерәләр. Агачның төбен калдырмыйлар. Иң әүвәл бик астан, җир яныннан ук кисәләр, кисеп аударгач, калган төп урынын балчык белән күмеп, үлән белән каплыйлар... Әтисе агач төяүнең дә хәйләсен белә: арба кырыена сөзәкләп ике күсәк куя, бүрәнәнең бер башын арба кырыена бәйләп, икенче башын күсәк белән тәгәрәтеп менгерә, менгергәнен аркан белән бәйләгәч, икенче башын иплән кенә, җай гына арбага тәгәрәтә. Эшкә җәптәш аның әтисе, сүзгә — саран. Балаларына авыр сүз әйтмәс, кул күтәрмәс. Элекке заман гадәте буенча, аңа күршедәге Шуван авылыннан димлиләр кызны. Тәскирә Минһаҗлар нәселенең җүнле ика-

нен белә, әтиләре риза. 1955 елның 17 февралендә ул Вәсилгә кияүгә чыга, 11 декабрьдә иренә тупырдап торган бер малай табып бирә — Вәгыйзне. Җылак була малай, ашыйсы килсә дә җылый, бәләкәй йомышы булса да җылый, җылый-җылый, үзенә кирәкне таләп итә-итә, томырылып үсә малай, күреп торалар: Минһаҗлар, Гобәйдуллалар нәселенә тап төшермәс бу үткен малай.

Вәгыйзнең ун яшеннән әтисенең кул арасына керә башлавы да юкка түгел. Ул күреп белгән Гобәйдулла бабасы чамадан тыш гаярь кеше була, биш мәртәбә йорт сала, биш мәртәбә яндыралар йортын — хөсетлелек бәласе! Татарның иң әшәке сыйфаты: юк булсаң бирәлми, бар булсаң, күрәлми!

Ярый, хуш, бүрәнә салган йөк белән авылга кайтып житә яза болар. Ә авыл янында гына тау бар, шул тауга күтәреләсе. «Шәкүр» исемле ат Вәгыйзнең әтисе Вәсилне ярата, чөнки ул аңа ипи ашата, ипи капчыгы белән янында солы йөртә. «Шәкүр» — бик үз холыклы ат. Башка кеше белән ул авылдан ары чыкмый, авыл башына житү белән борыла, чыгымчылый. Чыбыркы дигәнне аның жене сөйми, иркенлек, үз дөньясы кадерле аңа, «демократия» дигәнне ул кешедән дә күбрәк аңлый, берәрсе явызлык белән аның сыртына чыбыркы төшерсә, ул инде дулый, пошкырына һәм арбаларны ватып, каралты-кураларга бәрелә-бәрелә, сине һәлакәткә алып бара.

Тау мену кыен. Беренче хут белән «Шәкүр» тауның яртысыннан артыгын уза, ике зур таш күтәреп менгән Вәгыйз, арба кире чигенмәс өчен, ташларны арткы көпчәкләр астына кыстыра, ат хәл җыеп, тагын беркавым атлый, тагын ташларны көпчәк астына кыстыра Вәгыйз — әтисе улының җәптәшлегенә, бер әйткәнне һич кенә дә онытмыйча, үзе белеп эшләвенә сөенә, сөенә...

«Шәкүр»не, картайгач, заготскотка җибәрделәр. Бау белән бәйләп җибәрделәр. Бауларны өзеп, дулый-дулый, машина кузовларын ватып качкан иде ярсу ат. Аннары аны чылбырлап озаттылар, чылбырны өзә алмаган баһадир ат. Вәгыйз аны җәлләп җылады, нинди сабыр табигатьле булса да, әтисе дә түзә алмады, улына күрсәтмәс өчен, бүреген маңгаена, күз өстенә төшереп җылады.

Халыкта «Нәселдән килә, затына тарта», — дигән гыйбрәтле сүз бар. Фән телендә аны «гена» дип йөртәләр. Халык әйткәне бик матур: «затына тарта». Затлы нәсел, затсыз нәсел дигәне дә шуннан килә, күрәсең.

Вәгыйзнең ата-бабалары — затлы нәсел. Минһаҗ бабасы оныгын үзе белән урманнарга алып чыга, су буйларын, сәхраларны гиздерә, чәчәкләрне аңлатып йөри, үзенең гражданнар сугышында, фашистларга каршы сугышта катнашканнарын сөйли, аның тубыктан бер аягы юк. Вәгыйз исемле малай, бабасыннан: «Кая китте бу аягың?» — дип сорый бервакыт, «Мимеч ашады ул аякны, балакаем...» — ди Минһаҗ бабасы.

Минһаҗ бабасы акчаны учында кысып кына тота, балта осталарына да акчаны улы Вәсил түгел, үзе бирә торган иде. Бер мәлне шулай Минһаҗ бабасы, учына кыскан килеш, бишәрлекләрне лапас салучы балта осталарына бирә. Һәр бишлекне кысып кына чыгара. Вәгыйзгә ул чагында биш яшьләр булгандыр, качып кына карап торды да, сикереп төшеп, бабасының кулындагы акчага ябышты. Бабасының акчаны ычкындырасы килми. Бабай тарта — бер яктан, малай тарта — икенче яктан. Тартыша торгач, акча урталай өзелде дә малай ертылган акчаны тотып йөгерде. Бабай куа малайны, малай кача бабайдан...

Гобәйдулла бабасы үтә дә тырыш, үтә дә үз сүзле була Вәгыйзнең. Бишенче йортын яндырганнары урынына салып куйгач, авыл советы ул йортны тартып алып, Гобәйдулланы гаиләсе белән мунчада калдыра. Гобәйдулла урманнан төп чыгарырга керешә. Вәгыйзне дә төп ярырга ул өйрәтә. Әйләнмәле агачны яру өчен көч тә кирәк, хәйлә дә. Әнә шунда Вәгыйз тормыштагы авырлыкларны җинеп чыгарга төп ярудан өйрәнә.

Гобәйдуллага хәсәншәехләрнең исе китә торган иде. Аның ни рәвешле чәчү чәчкәнен авыл кешеләре гыйбрәт итеп сөйли торганнар иде. Гобәйдулла муенына ике пот арыш керешле тубал таккан, кул белән чәчү чәчә, ә артында ябага тай (ул аны йөгәненнән путасына бәйләп куйган). Гобәйдулла тубал белән чәчү чәчә, ә ябага тай аның артыннан үзенә дип махсус ясалган тырма белән җирне тырмалап килә. Менә бит нинди хикмәтләр! «Казгансаң маллар табыла, йөрәккә кан савыла»,— дип юкка гына җырламый, күрәсең, адәм балалары. Игенче ашыйсы икмәген, ипекәен кайнар тир түгеп үстергән.

Гобәйдулла бабасыннан, Минһаҗ бабасыннан, әтисе Вәсилдән күчкән җаптәшлек һәм булдыклылык Вәгыйзьне гел югарыга, гел биеккә үрләтә. Күршедәге Кенә мәктәбендә урта белем алган чагында ул җәйләрен олаулар төяүче булып эшли. Ашлык төйи, сенаж төйи, печән төйи. Унике-унөч яшьтән шулай. Гәүдә олы. Әтисе белән урман кисәргә бара, җиденче сыйныфта укыганда инде ерак урманнан, ун чакрымнан кәнәнә икешәр йөк утын алып кайта.

Эшләп үсү, хөрәсән ялкавы булмау — малайның беләк мускулларын ныгыта, ул үзендә зыңгылдап торган көч, дәрман барлыгын сизә. Үзләреннән ярты чакрым ары тегермән чатына чаклы ике потлы герне көн саен күтәреп бара, күтәреп кайта. Монысы тугызынчы сыйныфта укыганда була. Үзендә ул булачак көрәшчене, батырны тәрбияли.

Гадәттә, көчле кешеләр әллә ни моңлы булмый. Алар, гадәттә, тимердәй мускуллары белән горурланырга яратալар. Гаҗәеп хәл, Вәгыйздәге табигый көч-куәт аның җан нәфислеген, күңел нечкәлеген күмеп китә алмый. Тегермәнче Түркәдән — Анатолий Хлопушиннан ул гармун уйнарга өйрәнә.

Хәсәншәех авылының урамнары, Шушма елгасын урта бер җирдә калдырып, ике як яр буйлап сузылганнар. Ярның бер ягында гармунчы малай Марат Әхмәтов яши, кичләрен ул тальян гармунын сайратып Шушмага аргы яктан килә, ә бу яктан гармунын сайратып, аңа таба Вәгыйз Минһаҗев кузгала. Китә ике яшүсмернең гармун ярышы. Язларын Шушма елгасы тулып ташый, яшь-җилкенчәкнең йөрәкләрен ярсытып, дәрья суы болыннарга җәелеп китә. Су өстендә гармун тавышы икеләтә көчәя торган була бит ул. Яр буена җыела кызлар, җыела егетләр! Әй гомернең алтын мизгелләре! Әй гомернең сихри-тылсымлы чаклары! «Яшь гомерне уза, диләр, узганын күрсәң иде...» — дип җырлап йөргән чакларыбыз! Бердә генә, бердә генә узмас кебек иде ул заманнар, зәңгәр томаннар, алсу хыяллар артына кереп югалганнар инде алар, һәм безгә хәзер аларны төшләребездә генә күреп, сагышка батып йөрергә генә калган.

Ул чагында кайнар йөрәкле ике гармунчы малай, Хәсәншәех малайлары, Татарстан игенчеләренең иң гүзәл районнарында — Вәгыйз Минһаҗев — Арчада, Марат Әхмәтов — Балтачта хакимият башлыклары булырлар дип кем уйлаган?

Ул заманнарга ерак әле. Аларның әле урта мәктәпне тәмамлыйсылары, институтларда укыйсылары бар.

Әмма тормыш үз дигәнен итә, матурлыкны да, авырлыкны да боларга күрсәтә, боларны утларга-суларга салып сыный, чарлый, чыныктыра.

Минһаҗ бабай Вәгыйзьне үзе белән биләмгә алып чыгарга ярата. Ул сүзчән. Тарих сөйли Минһаҗ бабай. Менә бу Хәсәншәех авылына Хәсән дигән кеше нигез салган. Хәсән — аның исеме, «шәех» дигәне — дәрәҗәсе. «Хәсән хәзрәт» дигән кебек. Хәсән дә, тагын башкалары да Казан ягыннан, чукындырудан качып киләләр бирегә. Чукындырырга теләүчеләр Хәсәнне куып җитеп, башын кисеп төшерәләр. Вәгыйз ул урынга, аның кабере булган җиргә таш һәйкәл ясата, ул урыннан салкын сулы чишмә агып ята, кешеләр аны «Изгеләр чишмәсе» дип йөртәләр. Рәшәткә белән әйләндереп алып, агач утырталар.

Шушы чишмә, изге урын, Вәгыйзнең әтисе Васил каберенә килеп тоташа. Ул да бик гыйбрәтле хәл, анысын соңыннанрак сөйләрбез.

Вәгыйз, унынчыны тәмамлагач, Казанга барып, Ветеринария институтына укырга керде. Уку аңа җиңел булмады. Хикмәт — укырга әзерлекләме, түгелме турында бармый, Васил абзыйның балалары укырга һәммәсе дә сәләтлеләр, шулай булмаса, югары уку йортларына, институтларга кереп укый алмаслар иде, әмма авыл кешеләре әле алтмышынчы елларда шактый ук фәкыйрь яшиләр иде, институтларда укый торган балаларын карап-тәрбияләп торырлык рәтләре юк иде. Вәгыйзгә шуңа күрә дә үз көнен үзе күрергә, үз тамагын үзе туйдырырга туры килде. Заводта ул тимер кисүче (резчик) булып ялланды. Килгән саен бер сменалык эш бирәләр иде. Шуның белән тамагын туйдырды, шуның белән өс-башын карады.

Эшләгән эшендә берәр төрле авырлык чыкса, көмеш телле тальянын алып, шул заманнарны искә төшереп утырырга ярата Вәгыйз...

...Җемелдәвек асылташлар тезгән, күрүге аллы-гөлле төсләрдән балкып-балкып китә торган көмеш телле гармун аның күкрәк өстенә ята. Аннары бөтен иңенә сузыла. Вәгыйзнең күкрәге иңлеге итеп сузар өчен бер метрлы күрүк кирәктер, ихтимал. Сузыла гармун күреге. Шаулы кыңгырауларын кага, җаннарны айкап ала торган көмеш тавышы белән биек түшәмле, нарат сагызы аңкытып торган авыл йортын сихри авазлар белән тутыра. Минһаҗ Василенең Вәгыйзе яшьлеген, ярсулы җанын, Шушма елгасының дәрья сулары булып җәелгән чакларын исенә төшерә. Байлар урманы, кыңгыраулы атлар, болын чәчкәләре, салкын сулы чишмәләре, күпне күргән агайлары белән, ап-пак яулык, ак алъяпкыч япкан, ак йон оекбашлар өстеннән киеп куйган сары гәрәбәдәй тугызлыунберле чабаталары белән, кепканы кырын салган хром итекле егетләре белән Хәсәншәех авылы Вәгыйзнең җанына кереп утыра, моң-сагышлары булып, күңел дулкыннары булып, яшьлеге-җүләрлеге булып агыла, ярсый, дулкынлана, язгы ташулар булып, күккә — биеккә талпынган сабан тургайлары, җәйге таңның чыклы таллары, кояш чыгар алдыннан офыкны биләгән таң шәфәкъләры булып җәелә.

Хәсәншәех егете Вәгыйз гармун уйный.

Хәсәншәех егете Вәгыйз яшьлеген исенә төшерә...

...Васил Вәгыйзенең күкрәгендә моңлы-дәртле авазлар сипкән кыңгыраулы көмеш гармунның үз тарихы бар. Арча сабантуена Башкортстанның данлы җырчысы Фән Вәлиәхмәтов килде. Аның яхшы җырчы икәнен белә иде Вәгыйз Минһаҗев, әмма бик оста гармунчы да икәнен белми иде әле.

Фән Вәлиәхмәтов буйга ул хәтле үк калку булмаса да, күкрәк киңлеге һәм гәүдәсенең баһадирлыгы ягыннан Вәгыйз Минһаҗев белән бер чама. Штанга күтәрергә яисә татарча көрәшүче булып, сабантуй мәйданнарында, цирк коләмнәрендә генә йөрергә яратылган диярсең!

Йа хода, ул әле әнә нинди бәрхет тавыш белән җырлый. Ул гынамы! Ул әле өздереп-өздереп гармун уйный икән. Гармуны да гармуны — әллә кемнәрнең күз явын алырлык! Үз гомеремдә аз күрмәде Вәгыйз гармуннарны, әмма мондый матур тавышлы, мондый да көмеш тавышлы гармун күргәне юк иде.

Очраштылар, кул кысыштылар. Вәгыйз Фәнгә, сабантуен бизәгәне өчен, чиксез рәхмәтле булуын әйтте һәм... үгезне мөгезеннән тотып сөйләшергә булды.

— Фән туган, әнә минем «Волга» машинамны алып кит, җаның тагын ни тели, һәммәсен дә ал, калдыр миңа гармуныңны!

Фән Вәлиәхмәтов бик тә итәгатьле бала икән, форсат чыгудан файдаланып, машиналы булып калырга да, тагын нindидер затлы нәрсәләр алып баеп китәргә дә уйламады.

— Гармунның монысын мин үземә дип ясаттым, әле мин аның белән Казан концертларында да чыгыш ясарга тиешмен, алмыйм мин синең

«Волга»ны, юкса ул, синең юмартлыктан файдаланып талау булыр иде. Мин сиңа, Вәгыйз туганым, шушындый ук оста-мастердан ясатып бирәм кыңгыраулы көмеш гармунны.

Килештеләр, кул кысыштылар.

Әмма ул арада көтелмәгән бер хәл килеп чыкты: Фән Вәлиәхмәтовның атаклы гармунын Казан сәхнәсеннән, дөресрәге — стадионнан урлап киттеләр.

Вәгыйз Казан милициясен кузгатты. Гармун табылырга тиеш, ул бер генә! Бердәнбер гармун ул — аны яшереп асрап булмый.

Милиция эшкә кереште. Казанның барлык урыны күзәтү астына алынды һәм... гармунны табып та китерделәр. Бер институтның ике студенты, гармунны урлап, ике ярты аракыга сатканнар. Ә алучысы шиккә төшкән, гармунның махсус ясалганлыгын аңлап, милициягә хәбәр иткән. Урлаучыларны, әлбәттә, биш-алты елга ирекләреннән мәхрүм итәргә була иде, аларны Вәгыйз белән Фән Вәлиәхмәт каршысына бастырдылар, әмма йомшак күңелле ике гуманист гармун каракларын оялту белән генә чикләнделәр...

Фән Вәлиәхмәтов, Казан концертларыннан соң, көмеш телле, кыңгыраулы гармунын Вәгыйзгә бүләк итте. Вәгыйз аңа шундый ук гармунны удмурт остасы В. Мухаяровтан эшләтеп алып бирде.

Атаклы гармун белән бергә Фән Вәлиәхмәтов Хәсәншәехка кайтты. Яңарак кына дуслашкан ике зыялы Вәгыйзнең әтисе Вәсил абзый каберенә зиратка бардылар.

Кабер ягасында тын гына басып тордылар.

Аннары Вәгыйз әтисенең кабере туфрагын сыйпап:

— Авыр туфрагың җиңел булсын, рәхмәт сиңа, әткәй, барысы өчен дә! — диде. Фән Вәлиәхмәтов бик дулкынланып:

— Вәгыйз туганым, бу бит җыр сүзләре. Мин моңа җыр язам... — диде.

Икенче очрашуда җыр әзер иде инде. Удмурт остасыннан ясаткан гармун да әзер иде.

Көмеш телле гармунны моң гына, талгын гына сайратып, Фән Вәлиәхмәтов Арча сабантуенда һәм Хәсәншәех сабантуенда шул җырны җырлады. Ул җыр хәзер — бөтен Татарстанның яраткан җыры булып әверелде:

Төшләремдә күрәм әтиемнең,
Җырлый-җырлый, атын җиккәнен.
Әнием жылы караш ташлап,
Зур капкадан чыгып киткәнен.

Кайта идең кырдан кичкә калып,
Сөйли идеңниләр күргәнең.
Шундый тәмле иде кипкән икмәк,
Куян күчтәнәче, дигәнең.

Әйтә идең миңа, гомереңне
Бушка үткәрмә син, улым, дип.
Изгелекләр эшләп үтсәң әгәр,
Балкып торыр гомер юлың, дип.

Әйткән сүзең, изге теләкләрең
Үтәлерләр һәрбер эшемдә.
Авыр туфраккаең җиңел булсын,
Рәхмәт, әткәй, барысы өчен дә.

Гармуннар сайраша, агач яфраклары лепердәшеп сөйләшә, яңа табышкан ике дус, гармун телләре аша, газиз әтиләргә багышланган җыр аша, изге теләкләрен кешеләргә әйтеп бирәләр...

Фәрихәттәйгә быел, 1994 елда, 69 яшь тула. Йөзе аның нурлы, тавышы ягымлы, әллә балаларын сагынып яшәгәнгә, аның йомшак һәм ягымлы тавышына моң да сеңеп калган. Аз гына көйләбрәк, бер дә генә ашыкмыйча, кояш нуры тулган зур иркен бүлмәдә, авыл хатыннары төсле итеп тамак астыннан китереп бәйләгән яулыгына әледән-әле кагылгалап, сөйләп утыра ул.

— Фатихым минем илленче елның 12 апрелендә туды. Туган көнен бәйрәмгә туры китереп яздыргандырмы әтисе Сәүбән, башка сәбәбе бардырмы, мин ул кадәресен үк белмим, белергә теләп төпченмим дә, шунысы хак: аның туган көне булып Беренче Май исәпләнелә.

Безнең Апаз әллә ни зур авыл түгел инде ул, шуңа күрә безнең авылда урта мәктәп тә булмады. Фатихым минем урта мәктәпне, ягъни унынчы сыйныфны, Шушма урта мәктәбендә укып тәмам итте. Мәктәп директорлары Габделнуров Гафур иде, соңгы елларда гына безгә үзе кереп чыкты. Бик күп балалар укытып чыгардым мин, Фәриха апа, ди, әммәдәген шулар арасында Фатих Сибагатуллин аеруча булдыклы, аеруча тырыш укучыбыз ие, ди. Без аның белән горурланабыз, бөтен Республиканың игенчеләренә, терлекчеләренә баш булып тора бит, ди. Дөресен генә әйткәндә, ди, Фатихтан башка да зур түрәләр бар безнең мәктәпне бетереп чыккан, әммәдәхи Фатих бер генә. Ник дип әйткәндә, минем башка укучыларыбыздан ярдәм күргәнем булмады, ә менә Фатих Сәүбанович үзе укып чыккан мәктәпне онытмаган, мин үз гомеремдә беренче мәртәбә үзебезнең шәкертебездән файда күрәм, ди. Нинди файда икәнен әйтмәде, минем төпченә торган гадәтем юк. Һәрхәлдә, үз кесәсен кайгыртмагандыр Габделнуров Гафур, халык мәнфәгатен кайгырткандыр, улым Фатих аңа ярдәм иткән икән, бик рәхмәт аңа. Әтисе Сәүбән дә бик ярдәмчел кеше ие, күрше-коланнан бер нәрсәсен дә кызганмады. Тик менә иртәрәк дөнья куйды шул. Егерме җиденче елгы ие, миннән ике яшькә яшьрәк ие ул. Сиксән сигезенче елның октябрь аенда, октябрьнең өченче числосында безне калдырып китеп барды. Гомер буе механизатор булды, Арчага трактор белән барып кайта торган ие. Яшьрәк чакта машинага бәрелгән булган, шул чыкты азактан. Алтмыш бер яшендә китеп барды якты дөньядан. Иллә дә акыллы, иллә дә гаилә җанлы кеше ие. Фатихымның да булдыклылыгы әтисе Сәүбәннән дип беләм. Фатихымны әйтәм, ун яшеннән минем белән печән чабарга йөрде. Унҗиде ел буе чаптым мин печән. Урманда ун чүмәлә печән чапсак, берсен лесникка бирәдериек, тугызы үзебезгә каладырые.

Урманнан кайтышлый, печән йөге өстендә Фатихым белән сөйләшәбез.

— И балам, ни күрәсен белгән юк инде,— ди торганыем.

— И әни, исән генә бул, ышанычыңны аклармын,— ди иде Фатихым.

Тәки әйткән сүзендә торды. Әнә ишегалдыннан кергәндә күргәнсездер: кала суккан төсле итеп йортлар салып бирде. Нарат бүрәнәдән. Биш бала тапсам да, ир балам бит минем берәү генә. Кызым Флюрә — Ленинградта, хәзер Петербур диләр бугай инде. Илле бишенче елны туган кызым Казанда яши. Кечесе Әлфия Балтачта. Культура бүлегендә экономист. Үзебезнең авыл егете, үтә дә чыккан моңлы бала, безнең Хәсәншәех егете Марат Әхмәтов кул астында эшли дип беләм инде мин аны. Мин үзем дә Хәсәншәехныкы бит. Арча хакимияте башлыгы Вәгыйз Минһаҗев та Хәсәншәехныкы. Бергә үстеләр инде Вәгыйз белән Марат — гармунда ярышып, ә авылларыбыз Апаз белән Хәсәншәех берберсенә кыз биреп, бергәләшеп туйлар үткәрделәр. Минем менә Апазга килгәнемә 48 ел була хәзер, Вәгыйзнең әнисе Тәскирәнең дә безнең Апаздан Хәсәншәехка китеп кияүгә чыкканына шул чамадыр инде, артык булмаса...

Карале, мин Казан тикле Казаннан килгән кунакларны сүз белән сыйлап утырам, авыл көчтәнәчләре белән сыйлыйм әле, әнә самавырым да кайнап чыкты, сез килгәчтен инде электрда кайнатмадым чәйне, табыныбыз ямьле булсын дип; самавырымны куйдым...

Фәрихәттәй яшьләрчә бер җиңеллек белән урыныннан күтәрелеп, самавырын алып килде, табынга төрле-төрле нигъмәтләр тезә башлады. Без уңайсызланып, табын янына утырудан баш тартмакчы булганыек, кая ул! Фәрихәттәй безгә авыз ачарга да ирек бирмәде.

Калганын инде без табын янында сөйләштек. Дөресрәге — ул сөйләде, без аны бүлдерми тыңладык.

— Нык куллы минем Фатихым. Ул ягы да әтисеннән. Нык куллы, шырый-бырый йөргәннәргә юл куя торган түгел. Бер әйтер, берәгәйле әйтер, әммәдәхи үч алмас, каныкмас. Өстәвенә юмарт, ярдәмчел. Анысы да әтисе Сәүбәннән. Ул да бик юмарт ие. Теге авыр елларны бер пот оны булса, ачыккан күршеләр сорап керсә, ярты потын биреп чыгарыр иде, мәрхүм, авыр туфрагы җиңел булсын, ярабби... Берни дә кызганып яшәмәде, берәүдән дә. Яраттылар үзен, якын күрделәр, шуңадыр, бәлкем, тракторчыларның бригадиры итеп күтәрделәр.

Минем Фатихым Арчада эшләде, Мамадышта, гел мактап, зурлап тордылар үзен, аңа карап азынмады-узынмады, дөньяда аны багып үстергән әнисе барлыгын да онытмады. Өйгә, туган авылы Апазга ул, әлбәттә, сирәк кайта. Әммәдәген чит илдән-мазардан кайтса, берәр әйбер кертеп чыкмый калмый. «И улым, бар нәрсәм дә бар бит, нигә болар?» — дим. «Булсын, әни, сау-сәламәт бул, яме»,— дип гел дә мине юатырга тырыша.

...Фатихымның балалары да акыллы булып үсәләр. Улы Фәрит, әтисе кебек, көрәшче. Арча сабантуенда да, Мәскәү сабантуенда да икенче батыр булып калган. Шунысын бигрәк тә яратам, комсыз түгел, мал җыярга ашкынмый, хәттаки көрәшеп алган әйберләрен дә баздә калдырырга тырыша. Әле күптән түгел көрәшеп кер юу машинасы алганые, миңа китереп бирде.

...Мин үземне, кунакларым, бәхетле кеше дип саныйм. Фатихым беркайчан да кире сүз әйтмәде. Әтисенең дә ачуланганын белмим — мине дә, балаларны да. Бакчага чыгалармы, баш күтәрми, сыпырып эшлиләр. Күршеләр дөнья бетереп дәгъвалаша, бер-берсенең чәчләрен йолкырга әзер, минекеләр тавыш-тынсыз.

Бишенче баламны әйтмәгәнмен икән, Фатихның сеңлесен, анысы Маһиәнвәр исемле, хәзерге Апаз мәктәбендә, директор.

Әни кешенең бар белгәне — балалар өчен ут йоту бит аның, туганкайларым. Фатихымны Арчадан Мамадышка алып җибәрәсе иттеләр берзаман. Җылыйм да җылыйм — Фатихым үзе яшь, үзенә гел эш өеп кенә торалар кебек тоела миңа. «И балакаем, никләр риза булдың? Мамадыш — үзе зур, үзе хәерче бит ул»,— дим. «Әни, кайгырма, баш исән булсын да авыру-сырхау тимәсен, дөрес, мин ерак китәм, шулай да вакыт-вакыт кайтып күренермен»,— дип юата мине, балакаем.

Фәрихәттәй улы Фатихны, Татарстан Республикасының хәзерге Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Фатих Сәүбән улы Сибагатуллинны менә шулай тасвирлап бирде безгә.

Фатих әфәндененң үз-үзен тотышы да, уңышлардан башы әйләнмәве дә, атларга гашыйк булуы һәм чабыш аты сатып алуы да, татарча бик матур сөйли белүе дә әнисенең сөйләвеннән безгә аңлашылды. Безнең алда Татарстанның бер җитәкчесе Сибагатуллин гына түгел, аны тәрбияләп үстергән татар хатынының — ягымлы-мөлаемлык һәм сабырлык алиһәсе булган әниләребезнең дә образы күз алдына килеп басты.

Без Фәрихәттәйгә бер генә сорау бирдек:

— Әйтегез әле, Фәриха апа, кайнана һәм кайнаталарыгыз кемнәр иде? Алар белән мөнәсәбәтегез ничек булды?

— Кайнанам Сәрбиҗамал исемле. Уникe бала тапкан. Шуларның унысы ир бала, икесе — кыз. Уникe баланың ни бары икәве исән кала. Олысы Сәүбән, минем ирем буласы кеше. Мин буш стена арасына килдем. Ирем Сәүбәннең әтисен раскулачивать иткәннәр.

— Чәчегез белән җир себереп, борыныгыз белән боз тишеп, Сәүбән белән икегез тырыштыгыз. Рәхмәт сезгә. Бу бәхетсезлеккә дучар ителгән нигезне ташламадыгыз. Инде менә барысы да җайланды. Алга таба балаларыгызның игелеген күрегез, — диделәр күршеләр. Аларның әйткәне фәрештәләрнең амин дигән сәгатенә туры килгәндер, балаларыбыз игелекле булып чыктылар...

## Генералның кече командирлары һәм солдатлары

### Батырлар сөйли

Генерал дип без Арчаның хакимият башлыгын, аның кече командирлары дип колхоз рәисләрен, солдатлары дип гади колхозчыларны, механизаторларны, терлекчеләрне атыйбыз. Солдатсыз, армиясез генерал — генерал түгел. Кече командирлардан башка да ул җиңү яулый алмый.

Сүзебез иң әүвәл шулар турында. «Батырлар сөйли» бүлегендә сүз Арча районының бүгенге көндә иң зур уңышларга ирешкән «Ашытбаш» колхозы турында барыр.

1992 елны без ул колхозның байтак кешесе белән сөйләшергә өлгердек.

**Илсур Вәлиев — «Ашытбаш» колхозының рәисе:**

— Халык быел бигрәк тә булсынга дип эшләде, амбарларның икмәк белән тулуын теләде. Әмма туксан икенче елның язында һәм җәендә, ягъни язгы чәчү вакытында һәм урак өстендә, табигатьнең безгә карата мәрхәмәтле булуын да истән чыгармыйбыз. «Җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява» (Тукай). Бөртеклеләрнең һәм кузаклыларның чыгышы һәр гектардан 51 центнер булды. Элеккерәк елларда төшкә дә кермәгән уңыш.

Дәүләт амбарларына 1700 тонна гәрәбәдәй саф орлык салынды. Аның өчен акча алдык уч тутырып, халык белән исәп-хисапны өзәргә тотылыр.

**Мөхәммәт Мортазин — «Северный» совхозы бригадиры:**

— Сөбханалла, йа ходаем, нинди муллык! Авыл картлары ул муллыкка тел шартлатып йөриләр. Түгәрәкләп алганда, гектарыннан 48 центнердан да артыграк чыкты. Бер кырда арыштан хәтта 70 центнер суктырып алдык. Җыеп алуы, киптерүе, җилгәрүе, амбарларга салып куюы яки элеваторга илтеп дәүләткә тапшыруы ансат булгандыр дисезме? Булмый торсын! Халык эшчән, булдыклы, алны-ялны белми эшли. Яшьләр дә аңлы, өлкәннәр кебек намуслы. Армиядән кайткан егетләр җир җимертеп эшли, көнне төнгә ялгап! Ирек Әскәров белән Вильдан Ибнеевны күрсәтер идем мин сезгә. Икмәкнең кадерен белә хәзер халык!

**Садыйк Кәримов — «Акчишмә» совхозы экономисты:**

— Көн үтсенгә дип йөрмәгән, булсынга хезмәт иткән кеше бүген икмәкле дә, акчалы да, миңа калса. Мисалга еракка китәргә яратмыйм мин. Бездә Зөфәр дигән егет бар, фамилиясе — Мөхәммәтдинов, үзе комбайнчы, үзе үтә чыккан елгыр, ягъни сизгер димәкче булам. Быел без аны «Дон»га утыртып карадык. Яңа машинаның көч-куәтен, башка комбайннардан өстен якларын бик тиз сизеп алды ул. Аңа сизгерлек, мөгаен, нәсел-нәсәбеннән киләдер. Әтисе Вәгыйз абый да озак еллар комбайнда эшләп, пенсиягә чыкты. Картаймыш көнендә дә өендә түшәм-

гә төкереп ятмый, тимерчелектә эшләүче яшьләргә булыша. Зөфәрнең энеләре — Гомәр белән Илһамга да машина «җене» кагылган, алары да — менә дигән механизаторлар. Алар гаиләсе быелгы уңышны үстерүгә, җыеп алуга күп көч салды.

Эшләгән кешегә җан да җәл түгел: көнне төнгә ялгап эшли икән адәм баласы, халык байлыгы артсын өчен җанын-тәнен кызганмый икән, уч тутырып акчасын алсын, аның йортына машина-машина ашлык кайтсын, алтын куллары башкарганның рәхәтен күрсен.

## Рәхимҗанның күңел төбендә ята шәфкать бөртеге

Бу кеше безнең күңелдә байтак вакытлар серле бер табышмак булып йөрде. Буе-сыны белән башкалардан һич кенә дә аерылып тормый, елмаеп-көлеп йөргән чагын сирәк күрәсең. Озаклап, холкын-фигылен белергә теләп, текәлеп карап торганнар да булды. Чырае аның һаман бер төсле — болытлы көн сыман сүрән иде. Колхозы аның районда гына түгел, республикада да әледән-әле мактап телгә алына. «8 Март» — икмәкле, итле-сөтле, бәрәңгеле колхоз. Кешеләре әйбәт эшли, әйбәт яши. Ә менә Рәхимҗанның чырае һаман караңгы, һаман болытлы. Әгәр без бер вакыйганың шаһиты булмасак, аны һаман да сөмсерләре коелган кеше дип йөрер идек әле...

Арча халкы туган ягының эш күрсәткән сөекле улларын һәм кызларын тәбрикләргә җыелган иде. Бу хәл 1993 елның апрель азакларында булды. Залдагыларның йөзләре кояш кебек балкый. Авыллардан килгән хезмәт батырларының горурланып, ай-кояштай балкып утырырга хакы да бар иде шул: арчалыларның бәйрәменә Президент үзе килгән бит. Арчаның уңган рәисләре арасында Рәхимҗан Хөсәеновның да исеме телгә алынды. Аннары ул сәхнәгә үзе чыгып басты. Салмак тавыш белән, артыгын күпертмичә генә, үзе җитәкләгән колхозның уңышларын телгә алды. Түбән Аты, Урта Аты, Кылачы авылларында газ кертүнең бик мәшәкатьле, авыр булуын да яшермәде. Аннары ул карашын Президентка юнәлтте:

— Хөрмәтле Минтимер Шәрипович,— диде.— Безнең колхозның кешеләре шәһәр халкына уртакул биш колхоз җитештергән хәтле сөт биреп киләләр. Гектарыннан 45 центнердан артык иген уңышы җыеп алдык. Газ кертүне үз акчабызга эшлибез. Менә шундый кешеләрнең балалары күрше авылларга йөреп интегәләр, мәктәбебез юк. Күршегә йөри торгач, үз колхозлары белән элемтәләре югала башлый. Халык алдында оят. Яшермим, мәктәп, бигрәк тә урта мәктәп салу колхоз көченнән генә килә торган эш түгел.

Колхоз рәисенең мактанырга чыкмавын, авылларга кирәкне кайгыртып, өстенә бастырып әйтүен зал хуплады. Хөкүмәт нәрсә карый, Президент нәрсә карый — менә ниләр борчый җитәкчене. Зал гөр килеп кул чапты, тик бу алкышлар соңгысы түгелме икән?

«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән исемне Президент Указы белән Рәхимҗанга әлерәк кенә тапшырганнар иде. Аның шул хакта әйтеп, кулын кысарга дип кенә торганда, әнә нинди проблема китереп куйды колхоз рәисе. Бик урынлы куйды, Президент хәтле Президент якламаса, аны кем яклар?

Яклады аны Минтимер Шәймиев. Нәкъ әнә шул көнне Рәхимҗанның чыраендагы караңгы болытлар таралып киткәндәй булды. Баксаң-күрсәң, ул кешенең күңел түрендә шәфкать бөртеге ята икән ләбаса!

Ике җитәкче кул кысыштылар.

Түбән Атыда мәктәп булачак.

Сүзне бер башлагач, әйтеп бетерик инде: Рәхимҗанның шәфкатьле, миһербанлы җаны үзе эшләгән авылларда халык матур яшәсен, уңайлыкны, тәртиплелекне күрсен дип тырыша икән.

Халык моны онытмас, меңе белән кайтарыр. Рәхимҗан моны белеп тора. Яңа елны каршылау, Нәүрүз бәйрәме, 8 Март, Корбан бәйрәме, гаетләр, андагы сый-хөрмәтләр, сабантуйларындагы күңел ачулар! Барысы халык өчен, игенчеләр күңеле түгәрәкләнсен өчен эшләнә. Рәхимҗан — бәйрәмнәрнең җаны. Ул әгәр кулында тальянны сайрата башласа, һәммә кеше җырга кушыла, биредә сәнгатькә тәмам гашыйк булганнар инде. Рәис һәр бәйрәмдә профессиональ артистларны Казан каласына барып үзе алып кайта.

Болары — бер нәрсә. Инде бер көйләнгәч, традициягә әйләнеп, халык үзе оештыра торган чаралар. Ә менә сәламәтлекне саклау, кешеләрнең саулыгына зыян китермәү — анысы инде җитәкчедән өзлексез борчылып, уйлап-кайгыртып торуны таләп итә. Адәм баласы таза-сау булмаса, аның эштә кайгысы юк. Шуны күздә тотып, Казаннан танылган белгечләрне чакыртып, профилакторийне авылда оештыралар. Бала-чаганы, әби-бабайларны, берсен дә калдырмый, врачларга күрсәтәләр. Акчасын табипларга колхоз түли, авылның республика шифаханәсенә илтеп, операция ясаттырган өч колхозчы өчен дә колхоз үз акчасын бирә.

Зур бер коллективны җитәкли алу, төптән уйланган гадел карарларга килү, киләчәкне алдан күрү, əти-әнисе гаиләдә тәрбияләгән мәрхәмәтлелек, миһербанлылык, шәфкатьлелек сыйфатларына бәйледер, күрәсең. Шул сыйфатлар булмаганда халык мәнфәгатен кайгырту мөмкин түгелдер. Рәхимҗанның әтисе Сабит абзый сугыш утларын айкаган, ат җигеп, тракторлар йөртеп гомер кичергән кешеләрнең бригадиры була. Иген игә. Ул игенчелек шаһлыгында чын сабит булган, көчле җилләргә каршы тора алмыйча канатлары каерылган торна булмаган. Әтисенең тимертомырлар арасында кайнашуы, әнисенең хатын-кыз башы белән трактор йөртүе Рәхимҗанның машиналар «табибы» һөнәрен сайлауда йогынты ясамый калмагандыр. Әнә шул ике игенче, ике хезмәт кешесе тугыз балага акыллы, чын тәрбия бирә алганнар. Ата-ана тәрбиясе бер Рәхимҗанга гына йокмаган. Балтач районының Рәхимов исемендәге колхозында куәтле «К-700» тракторын йөртүче Шәрифҗанга да, Арчаның Сафин исемендәге совхозын җитәкләүче энесе Нурисламга да зур юлга, баганалы олы юлга чыгарга ата-ана тәрбиясе ярдәм иткән.

— Укысагыз, машиналар телен белсәгез, беркайчан да хур булмассыз, — дип үстерә Сабит абзый балаларын. Картлык көнендә улларының вәгъдәләрендә торуларын күреп, язмышыннан канәгать булып яши ул. Эшләрендә, хезмәт урыннарында нык вә какшамас булулары — сабитлыкның матур гәүдәләнеше! Сабит малайлары бит! Рәхимлелек, мәрхәмәтлелек, кешенең хәленә керә белү — болары Рәхимә ападан. Уллларының берсенә Рәхимҗан дим исем кушканнар икән, димәк, аның күңеленә балачактан ук рәхим-шәфкать орлыгы салганнар. Ә рәхимлелек ул — кешеләргә дәрт, көч, илһам биреп тору, ул кешеләрне аяу, аларның ялгышларын күпертмәү, аларны кызгана белү дигән сүз. Дөресен дөресчә итеп әйтик, ул әле, кешеләр бәхетле яшәсен өчен, аларны оештыра белү дә дигән сүз. Андагы бу сыйфатлар моннан ике ел элек «8 Март»тан аерылып, башка чыккан «Сәрдә» колхозының тернәкләнеп китүенә дә, бүген аның үзенең халык белән уртак тел табып, матур итеп яши белүендә дә күренә.

Әйе, әйе, Сабит улы Рәхимҗан — һәр эшендә сабит! Әйткән сүзеннән кире кайтмас, барган юлыннан тайпылмас, вәгъдәсен вак тараканга ашатмас, егетнең дә егете булып калыр. Аңа үз балаларын да шулай итеп үстерергә насыйп булсын, ярабби...

## Ата сүзе

Мифтаховларның нәсел-нәсәбе турында безгә бөтенләй диярлек билгеле түгел. Шулай да Кәримә апа белән Ибраһим абый тәрбияләп үстергән тугыз баланың берсен беләбез. Ул Васил

Мифтахов: утыз биш яшендә, белеме — экономист, 1957 елны туа, Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлый. 1984 елдан «Октябрь» колхозы рәисе. Ихтимал, Василның җитәкчелеккә сәләте әтисе ягыннан киләдер. Ибраһим абый заманында колхоз башында торган, механизаторлар бригадасын җитәкләгән. Исәп-хисапка хирыслыгы әнисе ягыннан килә бугай. Кәримә апа — гомерен санау-исәпләү эшенә багышлаган кеше.

...Василның диплом алып кайткан көне. Әтисе янына килеп утыра. Улының институт тәмамлавына сөенгән ата ипләп кенә сүз башлый.

— Ху-уш, улым, институт бетердең,— ди.— Тамагың тук булыр инде. Әмма дә ләкин үзеңнең генә тук булуың җитми бит әле. Дөньяда ач кешеләр дә аз түгел. Аларны да онытмасаң иде...

Васил әтисенең башка үгет-нәсихәтен хәтерләми. Бер генә әйткән җитмеш яшьлек Ибраһим абзый, берәгәйле итеп әйткән. Шуннан бирле ата сүзе улының кыйбласы булып калган.

«Октябрь» колхозы кырларында гектарыннан 56 центнер уңыш җыялар. Урыны-урыны белән 70 центнер да чыга. Булдыксыз колхозларның бер гектардан алган бәрәңгесе чаклы бит, җәмәгать!

Васил елмая.

— Голландиядә, минемчә, бөтен ил буенча гектарыннан 70 центнер җыеп алалар.

Аның сүзләре безгә аңлаешлы: эшли белеп эшләгәндә, үз вакытында тиешле ашламасын керткәндә, Арча җирләре дә тулаем 70 әр центнер уңыш бирергә сәләтле.

Васил эшләнгән ел турында гына гәп кормый, алга карап мәгънәлерәк фикер йөртергә, фәлсәфәгә кереп китәргә ярата. Без тау хәтле ашлык көшеле янында туктап калдык. Колхоз башлыгы бер безгә, бер көшелгә карап алып сүз башлады:

— Монда ничә миллион бөртек яки ничә уч бодай бар дип уйлыйсыз?

— Әйтүе кыен.

— Анысын исәпләп чыгаручы табылыр, мөгаен. Һинстанда шахмат уйлап тапкан акыл иясе хакында риваять бар ич. Безнең эрага кадәр XII гасырда булган, дип сөйлиләр. Акыл иясе шакмаклы такта күтәреп раджа, безнеңчә әйтсәк, кенәз янына килгән, ди. Моңа кадәр берәү дә белмәгән уен уйнап карарга тәкъдим иткән. Кенәз җиңелгән җиңелүен, әмма әлеге уен аның күңеленә бик тә хуш килгән. «Сора, ни теләсәң шуны бирәм»,— дигән ул кунагына. «Алтын да, асыл ташлар да кирәкми, әфәндем. Миңа ашлык бөртекләре бирсәң, шул җитә»,— дигән ди теге акыллы кеше.— Менә шушы шахмат тактасы санынча, беренчегә — берне, икенчесенә — ике тапкыр күбрәк, алга таба һәр шакмакка элекке санны квадратка күтәреп. Соңгы алтмыш дүрт шакмакка кадәр шулай». Гасырлар узу белән моны гыйлемле математиклар уйлап чыгарганнар. Теге борынгы заманда акыл иясенә бирергә кенәзнең биләмәләрендә үскән ашлык бөртекләре генә түгел, бәлки, бөтен дөньяныкы да җитми икән. Без моңа гаҗәпләнмибез. Икенче бер нәрсә борчый безне. Менә шушы көшелдәге бодай бөртекләрен үстерү өчен игенченең җиргә күпме тире тамды икән?! Хәзерге заман техникасының да куәтен кушып, боларга адәм баласының күпме көче керде икән?! Боларны исәпләргә омтылып караучы ник берәү табылсын. Шушы вазифаны үтәүче булса, игенченең хезмәте дә, икмәкнең хакы да дөрес бәяләнер иде. Бу — бик тә кирәк нәрсә. Бигрәк тә бүгенге көндә...

Болай итеп Васил Мифтахов фикер йөртә. Нинди уй-борчылу, нинди фикер тирәнлеге ята бу сүзләрдә! Моны 35 яшьлек рәис уйлый. Игенчелектә эшләүчеләрнең хезмәте дөрес бәяләнмәү, шушы көнгә кадәр яшәп килгән гаделсезлек аның җанын борчый. Борчылып кына йөрми Васил, авыл халкына кулыннан килгәнчә ярдәм дә итәргә тырыша. Ничек итеп дисезме? Игенченең үзе үстергән икмәген үзенә бирү юлы белән. Дәүләткә сата торган кыйммәт бәядән түгел, әлбәттә. Үзләре иген үстерүчеләрне генә икмәкле итү ягында түгел Мифтахов. Авылда эшләп,

пенсиягә чыкканнарны да, укытучыларны да, медицина хезмәткәрләрен дә, авылның башка төр зыялыларын да. Чөнки ашлык авылда яшәүче һәркемгә кирәк.

Халыкның үз абзарларындагы шәхси мал-туарны асрар өчен колхоз 120 гектар печән үстергән. Монысы инде бөтенләй дә бушка бирелә. Саламны да кешеләр күпме кирәк, шулай алалар. Көченнән килгән гаиләне ике сыер, тана, бозау, сарыклар, кош-корт асрарга җитәрлек терлек азыгы белән тәэмин итә ала колхоз. Бу өлкәдә бернинди проблема юк. Болай булгач, «Октябрь» колхозына кергән Зур Бирәзә, Урта Бирәзә, Наласа авылларында гомер итүчеләргә тормыш бераздан җинеләя төшә. Бу — безнең күптәнге хыялыбыз. СССР дигән бөек державада тоталитар система хөкем сөргән заманнарда «Барысы да халык өчен!» — дип күпме генә кычкырмасыннар, нинди генә яңгыравыклы плакатлар элеп куймасыннар, берсе дә халык өчен булмады, халыкны кычкыртып талау гына барды. Элекке Арча районына караган «Искра» колхозы рәисе, фронтовик, хезмәт ветераны Фәйзи Галиев ул заманнарны «Икмәк» язмышы» китабында бөтен фаҗигасе белән ачып бирә алды. Тик, ни кызганыч, ул китап тиешенчә пропагандаланмады, халыкка барып ирешмәде, Арча кибетләрендә озак ятты. Моны Арчаның хәзергесе түгел, ә аннан элгәреге хакимияте, китап кадерен белмәүчеләр эшләде, рәхмәт яугырлары!

«Октябрь» колхозы игенчеләре 1992 елны 7300 тонна ашлык үстереп алганнар икән, дөнья күләмендәге иң гадел үлчәм белән алганда, 7300 кеше ачтан интекми дигән сүз. Васил Мифтахов кебек намуслы һәм булдыклы җитәкченең теләге — моны тагын да арттыру. Әтисенең үгетнәсихәтен тормышка ашыруда ул шуны үзенең игелекле мөһим эше дип саный.

## Рәхмәт сиңа, Игенче!

Арча хакимиятенең эше, ул хакимиятнең башлыгы Вәгыйз Минһаҗев хакында, аның уй-теләкләрен гамәлгә ашырган кече командирлары — колхоз рәисләре һәм совхоз директорлары, турылыклы солдатлары булган механизаторлар хакында сөйләдек без сезгә.

Инде бу бүлеккә йомгак ясап, шуны әйтәбез:

Безнең тәрәзә төбендә кечерәк кенә бер көлтә хәтле букет бар. Аллыгөлле чәчәкләре белән балкып утырмый ул. Алтын-сары төсләре белән көз явын алып балкый. Арча, Балтач, Әтнә, Биектау, Буа, Питрәч, Теләче, Азнакай, Сарман, Минзәлә, Зәй, Балык Бистәсе, Кама Тамагы басуларында үскән шушы алтын башаклы җыелма көлтә-букетта без Татарстаныбызны, халкыбызның көчен-куәтен, акылын һәм талантын, дәрт-дәрманын, өмет-ышанычларын күрәбез.

Каян килгән аңа шундый илаһи кодрәт, бетмәс-төкәнмәс көч-куәт?

Җавабы катлаулы түгел. Адәм баласы: киң күңелле, олы җанлы зат, бөртекләрне учларында иркәли-иркәли, аларга җан җылысын да кушып, йомшак туфракка салган. Шул бөртекләр кояш нурларының җылысын алып, яңгыр тамчыларының саф дымы белән тукланып җыйган ул баһадир көчне! Хәзер шул бөртекләр зур Икмәк булып Кешенең үзенә кайта.

Бөртекләре төрле башакта төрлечә. Кырыклысы бар, иллелесе, алтмышлысы. Игенче берне чәчә, кырык-алтмышны кайтарып ала. Бер центнердан — кырык-алтмыш центнер! Мондый колхоз-совхозлар хәзер бездә аз түгел. Арчада — «Ашытбаш», Балтачта — Рәхимов исемендәге, Буада — «Татарстан», Азнакайда — «Авангард», Минзәләдә — Ленин исемендәге, Зәйдә — «Зәй», Теләчедә — «Баландыш». Биектауда — «Алга», Сарманда — «Петровский»...

Саный китсәң, әлеге районнарның һәркайсында алгы сафта атлаучы колхоз һәм совхозларны барлау өчен бер кул бармагы гына җитми. Алар Арчада — унике. Балтачта — сигез, Буада — алты...

Ундырышлы кара туфракта гына түгел, комлы, көлсу, ташлы яисә ачы туфракта да мул уңыш үстерергә сәләтле икәнен раслады Галиҗәнап Игенче!

Бар галәмнең җан чишмәсе — Кояш! Ул һәрбер җан иясен — терлек-туарын, җәнлекләрен, кош-кортны, беренче нәүбәттә, әлбәттә, кешене хезмәткә чакыра.

Адәм баласының тереклек чишмәсе — Икмәк! Әнә шуның хакына Игенче, төн йокыларын онытып, тозлы ачы тирдә коена-коена, алны-ялны белмичә эшли. Авыл өчен генә түгел, шәһәр өчен дә. Үзе өчен генә түгел, барыбыз өчен дә. Авыл кешесе шуны яхшы белә: иген төбе — киңәнеч, авылда бер бәрәкәт булса, шәһәрдә — ун бәрәкәт була. Шушы изге эше өчен, аның бернинди үлчәү белән дә үлчәп бетереп булмый торган хезмәте өчен, без Игенче алдында баш иярга тиешбез!

Шөкерана кылыйк, җәмәгать, Татарстан быел, ягъни 93 елда да икмәкле! Келәт-амбарларыбыз алтын орлыклар белән, ындырларыбыз алтын көшелләр белән тулган. Без икенче ел инде мөстәкыйль Татарстаныбызда икмәкне шулай мул үстерәбез, вакытында җыеп алабыз. Декларация кабул ителүгә өч ел тулса да, мөстәкыйль икмәгебезне икенче ел гына җыябыз. Юк, без ялгышмыйбыз. Чөнки иген үстерү тәгәл бер ел дәвам итә. Августта чәчәбез, икенче елның августында җыеп бетерә язабыз. 1991 елда җыйган икмәгебез Декларация кабул ителгәнче чәчелгән иде. 1992—93 елгылары бу мөһим вә тарихи документ көченә кергәч эшләнде. Без, Татарстан кешеләре, мөстәкыйль яшәргә, үз байлыгыбызга үзебез хуҗа булырга өйрәнә башладык кына әле. Бу өлкәдә әле утны-суны кичәсе, үз байлыгыз үзебезгә булсын өчен көне-төне көрәшәсе бар. Мөстәкыйльлек хезмәткә бүтәнчәрәк карарга өйрәтә.

Ә безнең халык, Ходай ярдәменә таянып, үзе дә дәрт-дәрман белән эшләргә күнеккән. Мисаллар кирәкме? Балтач осталары Рифкать Габделхаков һәм Рифкать Гыйззәтуллин «Дон» комбайннары белән 13 әр мең центнер ашлык суктырырга өлгерделәр инде. Һәркайсының икмәген ындыр табакларына ташу өчен сигезәр тонна йөк ташый ала торган 163 «КамАЗ» машинасы кирәк. Шуның кадәр йөк ташырга машинасын җилдән җитез йөртүче Балтач шоферы Фидаил Дәүләтгәрәев сәләтле икән.

Икмәкнең комбайнчылар һәм йөк ташучылар көче белән генә табынларга килмәвен дә онытмыйк. Болар янына җир сөрүче данлы сукачыларыбызны китереп кушыйк. Балык Бистәсеннән — Үзбәк Мусин, Арчадан — Ләбиб Галәвиев, Азнакайдан — Айрат Ихсанов, Әтнәдән — Ренат Василов... Моның белән генә бетми алар республикада. Болар — эшләгән эшләреннән тәм таба белүчеләр, болар эшләре балкып калуны алга сөрүчеләр. Болардан тыш Игенчене яңа сауган сөт белән сыйлый белүче савым осталарыбыз Наилә Адаева (Биектау), Синара Гыйләҗева (Әтнә)... кебек алтын куллы апа-сеңелләрне да онытмыйк. Татарстанның барлык халкы сокланырлык кешеләр болар, республика чемпионнары!

Авыл хуҗалыгындагы уңышларыбызны осталыкка гына кайтарып калдыру дөреслеккә туры килеп бетмәс. Президентыбыз, Югары Советыбыз, Хөкүмәтебез авыл хуҗалыгы өлкәсендә дөрес юлны сайладылар. Республика бюджетыннан минераль ашламалар сатып алу өчен дотация бирелә. Шуның өстенә игенче хезмәтен кешечә бәяләү сизелә башлады. 1992 елны күп районнар халыкка икмәкнең бер килосын 30 тиеннән сатып бирделәр. 1993 елда Азнакайның «Авангард» акционерлык җәмгыяте икмәкнең килосын — бер, Арча, Биектау, Теләче, Алексеевск, Сарман районнарында биш сумнан сатабыз дип торалар. Икмәккә бәя мәсьәләсендә районнар Арча җитәкчелегенең карашыннан чыгып эш итәләр. Дөрес юнәлеш бу. Намус белән, тырышып эшләгән кеше икмәкле булырга тиеш. Моны халык йөзе белән кайтарачак. Татарстанда арыш басулары алтын төсле, бодай дулкыннары ялкын төсле иде. Шул кырларда булган чакта ике халыкның данлы шагыйре Шәехзадә Бабичның шигыре искә төшә:

Игенкәйләр, сезгә бер үтенеч:
Мөмкин булса рөхсәт бирегез...
Тәмле исегезгә исергәндә,
Мәдхияләр җырлап йөрербез.
Рәхмәт сиңа, Игенче, бәхет игүче!

## Күршеләр

### БАЛТАЧ

Арчаның иңгә-иң куеп, терәлеп торган күршеләре — Биектау, Әтнә, Теләче, Балтач.

1994 елның 17 маенда, шомыртлар ап-ак чәчәктә утырган, чияләр чәчәк таҗларын ачып җибәргән мәлдә Казан каласыннан унбиш язучы, автобуска төялеп, Балтачка барырга чыктылар.

Сугышка кадәрле дә, сугыштан соң да әле Арчадан Балтачка бару юлы бик начар иде, машиналар адым саен чокырларга төшеп, даңгыр-доңгыр бара иде. Ул газаплы заманнар узды, Казан-Арча, Арча-Балтач юлы хәзер алма тәгәрәтерлек. Безнең автобус әнә шул тигез асфальттан алга элдертә. Кырларга карап барабыз. Биектау басулары да, Арча басулары да, яшел хәтфә япкандай, ямь-яшел булып җәелеп яталар. Күптән түгел генә Мәскәү гәзитләренең берсендә мөстәкыйльлек өчен көрәшкән милләтләрне өнәмәүче бераү Татарстан Республикасының флагындагы яшел төсне «ядовито-зеленый» дип язган иде. Безнең әдипләр, уҗымнарның күзне иркәли торган яшеллегенә сокланып, теге мәгънәсез урыстан көлеп: «Ядовито-зеленые озимые»,— дип шаярталар.

Күңелләр көр безнең: Арча-Балтач кырларына мул булып язгы шифалы яңгырлар явып узды. Ходай кушса, игеннәр быел да мул булып, хезмәт кешеләрен шатландырсыннар иде...

Без — Арча якларының патриотлары Мөхәммәт Мәһдиев, Гариф Ахунов, Татарстанның төрле районнарында туып-үскән каләмдәшләребезгә Арча районының Түбән Мәтәскә, Югары Мәтәскә, Мөндеш, Төрнәле авылларының төзеклегенә, нарат-чыршы бүрәнәләрдән алты почмаклы, урыс капкалы итеп салган дәү, таза йортларга игътибар итүләрен сорап, ул авылларның хәтта авыр сугыш елларында да ачтан интекмәвен, үзләре үстергән икмәкне хөкүмәт талап бетерә язган елларда да һөнәрчелек белән, тырышлыклары белән үзләрен-үзләре туйдыра алуларын сөйләп барабыз.

Төрнәлегә җитәрәк уң кул тарафта япа-ялгыз агачлар төркеме күренә. «Ул зират нигә ялгыз, авылы юкмыни?» — дип кызыксына каләмдәшләр.

— Ул Кечкенә Өчиле зираты, авылы 1961 елны юкка чыкты. Гариф Ахуновның туган авылы иде бу,— ди Мөхәммәт.

— Аның янында нинди диңгез?

— Казан елгасын буып ясатты аны Арчаның хакимият башлыгы Минһаҗев, кырларны сугарыр өчен Өчиле янында диңгез булдырды. Ул гынамы? Өчиле беткәннән соң утыз елдан артык ташландык хәлдә яткан зиратка бер атна эчендә койма койдырып, аның рәшәткәләрен зәңгәргә буятып алды. Ринат Мөхәммәдиев, мин, Гарифҗан үзе анда булдык, җәй көне иде, «диңгезендә» су коендык, гаиләләре белән шунда ял итәргә килгән Арча кешеләрен күрдек, балык тотып, су коенып, рәхәтләнеп яталар. Миңһаҗев кайчан нәрсә эшләргә икәнен яхшы белә. Аны өйрәтеп торасы юк. Без аны ата-бабалар рухына игътибарлы булганы өчен дә ихтирам итәбез.

Автобус Төрнәле урамыннан чыгып, «Үрнәк» совхозына якынлаша. Бу тирәләргә җиткәч, язучыларның чыраена гаҗәпләнү билгеләре чыга. Тау башында — карт наратлар. Аны узгач, ташпулатлары белән «Үрнәк» совхозы күзгә ташлана.

— Заманында мин укыткан Арча педучилищесы шушында булган. Сугыш елларында Арчадан күченгән. Мөхәммәт абый белән Гариф абый

укыган училищеның бинасы анда әле дә саклана, тик ул хәзер педучилище түгел, механизаторлар мәктәбе, аны да заманча үзгәрткәннәр инде,— колледж булган. Ул хәзер тракторчылар, комбайнчылар гына хәзерләп калмый, тегүчеләр белән пешекчеләр дә әзерли, икътисадның да нигезләрен биредә белем алучыларга төшендерә,— ди Ренат Харис, алтын тешен ялтыратып елмая.

Чыршылар бик күп булып үскән урман яныннан узабыз. Бу — Арча урман хуҗалыгы. Заманында бу урманнарның һәммәсенә алпавыт Габдрахман Ишморатов хуҗа булган. Патшаның унөч киңәшчесеннән берсен тәшкил иткән Ишморатов биредә җәйләрен үз резиденциясендә ял иткән, биредә ул такта яру заводы, ат заводы тоткан, юмарт күңелле алпавыт булган, җәйләрен бирегә кайткан чакларында Арча авылларына закәт өләшкән. Әнә нинди кешеләре булган татарның. Әтнә тарафларында да татар байлары күп булган, ул яклардан зур галимнәр, генераллар чыккан.

Кабат әйтәбез: бу тирәләрдә урманнарны чыршы били, бу, күрәсең, Урал тауларның итәкләренә якынлаша. Чыршылар очлы башлары белән күккә-биеккә омтылалар, алар янында яфраклы агачлар бәләкәй булып, чүгебрәк калалар. Сәяхәткә чыккан әдипләрнең күзләрендә гаҗәпләнү билгеләре әнә шуңардан икән.

Арча белән Балтач җирләре чигендә безне Балтачның хакимият башлыклары каршылый. Алар арасында безнең яраткан шагыйребез, «Керим әле урманнарга» дигән атаклы җырның авторы Гарифҗан Мөхәммәтшин да бар. Балтачта ул хакимият башлыгының урынбасары булып эшли. Хакимият башлыгы Марат Әхмәтов Казанга киңәшмәгә киткән, иртәгә әдипләр белән үзе очрашырга, көне буе безнең белән булырга вәгъдә биргән.

Яңгыр сибәли башлый. Бик гүзәл милли киемнәр кигән кызлар безне урман кырыена ясап куелган беседкага чакыралар. Анда өч самавыр кайнап тора. Кызлар безне хуш исле кайнар чәй белән сыйлый. Табында бал, кәнфит, үзләре пешергән печенье, кош теле, өчпочмак, сумса, тагын әллә нәрсәләр... Тамак тук әле безнең, әмма шулхәтле матур киенгән, шулхәтле матур итеп үз ана телләрендә, татарча сөйләшкән кызларның йорт ризыкларыннан авыз итмичә китеп булмый. Кунакчыллык безнең халыкның борынгыдан ук килгән матур сыйфаты инде ул. Болгавыр һәм авыр заманда кунакларын сыйларга тәмле ризыклар пешерә алган, балаларының йөзләреннән кояш нуры балкып торган халык үлмәс. Кайда татар бар, анда ризык бар, анда юмартлык бар, анда якты йөз һәм тәмле сүз бар. Арчада да бу шулай, Арчаның күршеләрендә дә!

Балтачка таба кузгалабыз.

Яңгыр, автобус тәрәзәләрен шадралатып, инде ныгытып ук ява. Безнең күңелләр боекмый. Без җаныбызда әле гүзәл татар кызларының елмаюын саклыйбыз.

Вакытсыз арабыздан киткән талантлы шагыйрь Зиннур Насыйбуллинның «Дөньялар яктыра елмаю нурында» дип җырлана торган җыры бар. Иллә дә дөрес тотып алган соң кешеләрнең күңел халәтен!

Сөзәк тауга йөгереп менеп барган төсле булып, Балтачның ак түбәле ташпулатлары, нарат йортлары күз алдында пәйда була, ул арада инде безнең автобус райүзәкнең асфальтлы урамнарыннан чаба һәм күп булып мәктәп балалары-үсмерләр җыелып торган бина каршысына килеп туктый. Гел дә милли киемнәр кигән гүзәл кызлар, урман буендагы төсле, безнең ипи-тоз белән урамда каршылыйлар, яңгырга чыланудан да курыкмыйлар, бәгырькәйләр! Нинди ихласлык, нинди ныклык безнең халыкта!

Тамак ялгап алгач, Балтач мәчетен карарга барабыз. Ул 1994 елны Тукай бүләгенә куелган иде. Ак кирпечтән, тәрәз йөзлекләре кызыл кирпечтән ясалган биек мәһабәт мәчетне күргә, күңелдә горурлык хисе уяна. Аңа Тукай бүләге бирелмәде, Нижгарда моннан да матуррак мәчет

бар, диделәр. Мәһдиев әйтмешли, причем монда Нижгар! Күз явыңны алырдай мәчет бу. Һәммә нәрсәгә тәнкыйть күзлегеннән карый торган Аяз Гыйләҗев тә: «Мин сезгә әйтә килдем, мәчет бер-ике елда әштерөштер генә салынмаска, ун-егерме ел буена иҗат ителергә тиеш, дидем. Менә бу, ичмасам, мәчет!» — диде.

Дин сараеның эченә кергәч, без тагын бер мәртәбә Аяз сүзләрен кабатладык: «Менә бу, ичмасам, мәчет!»

Болын чаклы идәнне тутырып, бизәкле палас җәелгән. Түшәмнәр биек, орнамент чәчәкләр ябыштырылып, ак, сары, кызыл төсләргә буялган. Тәрәзә йөзлекләре (эчке яктан) алтын путал белән бизәлгән орнаментлы, тәрәзә араларында акка зәңгәр белән язылган догалар — гарәп хәрефендә. Келәмле мөнбәр. Икенче катка менә торган баскычта келәмнәр. Икенче катта бер якта мәдрәсә, бер якта — хатын-кызлар бүлмәсе, алар дога кылырга, намаз укырга шунда җыелалар икән.

Зурлыгы-иркенлеге, биеклеге, җылыткычлары матур бизәкле каплавычлар белән тышланган булуы, мәдрәсәсендә бер йөздән артык баланың дин белеме алуы, ә мәчет башлыгының — урта яшьләрдәге чибәр, ягымлы ир-атның, колхозда эшләгән җиреннән мәчеткә күчүе безне таң калдырды.

— Сез, колхозда эшләгән гап-гади кеше, өстәвенә чагыштырмача яшьрәк тә кеше, ничек дин юлына кереп китә алдыгыз? Гарәп телендәге догаларны өйрәнү, гарәп алфавиты үзе дә гади кеше өчен авыр бит? — диде Ринат Мөхәммәдиев.

— Минем дин юлына кереп китүем Җәлил хәзрәт аркасында...— дип җавап бирде мәхәллә башлыгы.

— Бу мәчетне кем проекты нигезендә салдыгыз? Архитекторы кем? — дип кызыксынды Равил Фәйзуллин.

— Моның проектын Шамил Гәрәев эшләде. Әмма ул архитектура буенча махсус белем алган кеше түгел. Ил буйлап йөреп өйрәнеп чыкты ул затлы мәчетләр салуны...

Шулай итеп, безнең алга өч кешенең исеме калкып чыкты — берсе районның хакимият башлыгы Марат Әхмәтов, шундый зур, мәһабәт мәчетне салуга акчасын, материалларын табарга булышучы һәм шундый зур мәчет салуны хуплаучы. Икенчесе — мәчетнең архитектурасын чамалап, бик житди проектын әзерләүче Шамил Гәрәев. Өченчесе — кешеләрне үз артыннан ияртеп, аларның рухи мөмкинлекләре ачылуга этәргеч ясаучы Җәлил хәзрәт...

Безнең алда зур шәхесләр, серле шәхесләр. Аларны күрү, аларның дөньяларын белү безнең өчен укылмаган китап төсле, серле булып калды. Безгә аларны табып бирергә, алар белән очраштырырга Гарифҗан Мөхәммәтшин вәгъдә бирде.

Яңалык һәм кыюлык һәркемне сокландыра, якты өметләр уята. Өметләребезнең акланачагын көтеп, без район территориясеннән гел эчкәрәк керә бардык. Элекке район үзәге булган, әмма хәзер Балтачка караган Чепьяга юл алдык. Безне монда тагын да зуррак гаҗәпләнү көтә иде.

Без Чепьяда «Халыклар дуслыгы» музеена эләктек. Соңгы елларда, Кавказда һәм Европада канлы сугышлар барган, Балтыйк буе дәүләтләре элекке бөек держава — СССРга карата гел явыз сүзләр генә әйтеп торган бер заманда «халыклар дуслыгы» дигән сүзне ишетү сәеррәк иде, әлбәттә. Әмма гади бер авылдагы уникаль музейны күреп, аның белән танышканнан соң сәерсенү бетте, әлеге музей белән горурлану, аны оештыруның инициаторы Гарифҗан агай Галиевкә күңелдә рәхмәт хисе торып калды. Музейда татар, мари, удмурт тормышын, патша заманындагы аларның киемнәрен, бәйрәмнәрен, бер-берсенә мөнәсәбәтләрен күңел кузгатырдай җанлы итеп, майлы буяу белән язган күпме картина бар. Боларны Казан рәссамнары килеп ясамаган, боларны удмурт кешесе, авыр язмышлы үзешчән рәссам Дмитрий Иванович Соловьев язган. Шушы якның патриоты, Балтач районы кешесе.

Гарифҗан агай залдан-залга күчеп, безгә музейдагы экспонатларны аңлатып йөри.

Беренче зал — бу якларның үткәне. Чепья тарихы.

Икенче зал — Беренче урыс революциясендәге Балтач.

Өченче зал — Балтач якларының Бөек Ватан сугышы белән бәйле язмышы.

Дүртенче зал — бүгенге тормыш.

Татар халкының кием-салымы, бизәнү әйберләре чиксез-чамасыз җыелган бу музейда. Чулпылар гына бер йөздән артык, беләзекләр, алкалар, хәситәләр, күкрәкчәләр, калфаклар, кәттәшиләр... Көнкүрештәге кораллар: кырлы бәләк, кере, каба, киле, тукмак, ат дирбиялары, киндер сугу станнары. Менә бит авыл халкын изге эшкә күтәрә алган Гарифҗан агай Галиев берүзе нинди музей булдырган. Бу музей — Татарстан дәүләт музееның филиалы, Гарифҗан Галиев аның директоры. Биредә Кытай, Төркия, Америка, Германия делегацияләре булган, аларның дәррәү төшкән рәсемнәре һәм музейның Почет кенәгәсенә язган соклану сүзләре бар.

Гарифҗан агай безгә мамонтның шушы территориядән табылган гигант сөякләрен күрсәтте. 137 килограммга җиткән бивеньле, 12 килограммлы тешләре янында без озак басып тордык.

Бик зур богаулар, шөлдерләр, ат дагалары, кыңгыраулар — мәктәп балалары һәм аларның әти-әниләре китергән экспонатлар. Ел саен күпләп юкка чыга торган шушы экспонатларны Гарифҗан агай, укытучы кеше, Бөек Ватан сугышы ветераны үз вакытында җыеп калырга өлгергән.

Музей — тузан җыеп утырган борынгылык түгел, ул халыкның киләчәккә карап яшәве. Булып узган фаҗигаләрдән гыйбрәт алуы. Ә фаҗигаләр баштан ашкан. Себер тракты аша килгән каторжаннарны бирредә дә туктата торган булганнар. Урысның классик язучылары Салтыков-Щедрин, Короленко, Радищев шушы юлдан Чепья аша узганнар, берничә ел шушында яшәгәннәр дә. Ул хакта музей хәбәр итә. Бөек Ватан сугышында Чепья зонасының 16 процентттан артык халкы һәлак булган. Чутай авылының бер гаиләсеннән генә дә әтиләре, дүрт баласы сугыш кырларында ятып калган. Иске Чепьяның сугышка киткән 170 кешесеннән 87 се әйләнеп кайтмаган. Сталин культы чорында нахакка төрмәгә ябылып үтерелгән кешеләр авыл саен диярлек. Алар арасында Рияз Алкин, Гали Галиев, Елена Павлова кебек дәүләт җитәкчеләре, райбашкарма рәисләре, райком секретарьлары бар. Алкин, мәсәлән, Янгул волость башкарма комитетында рәис, Арча райкомында беренче секретарь булып эшләгән, Казанның Бауман районы коммунистларын җитәкләгән, ә 1938 елны кулга алынып, төрмәдә эзсез югалган. Удмурт язучысы Г. Медведев 33 яшендә кулга алынып, төрмәдә һәлак булган. Фаҗигаләр күп, фаҗигаләрдән гыйбрәт алырга кирәк. Әмма нинди генә авырлыкларга карамастан тормыш дәвам итә, алдынгы кешеләрен алгы планга чыгарып куя. Гап-гади авыл кешеләре — Смаил авылыннан Габдулла Габдрахманов, Янгул авылыннан Ринат Габдрахманов скульпторлар булып киткәннәр. Аларның башкарган сәнгать әсәрләре дә музейда саклана. Балтач районында тал чыбыгыннан кәрҗиннәр, өстәл-урындыклар үрүче осталар яши, без аларның данын дөньяга чыгара белмибез. Кызганыч та, үкенечле дә! Әнә бит Рәсүл Гамзатов Дагстанның көмеш савытлар ясаучы Кубачи осталарын бөтен дөньяга танытты.

Балтачтан чыккан Ватан сугышы батырлары — алтау. Музейга аларның портретлары куелган, тормыш юллары, батырлыклары турындагы мәгълүматлар тупланган. Бүгенге көннең фидакарьләре укытучылар, җәмәгать эшлеклеләре, Югары Советларның депутатлары, съезд делегатлары күп бирредә, теләсә кайсы районнан күбрәк...

Менә шушы урында бер хикмәтле мәсьәләгә тукталып, әңгәмә корыр өчен сорау куйыйк: ут күршеләр булган Арча белән Балтачлар бер-

берсеннән көнләшмиләрме? Шул җирлектә аларның низаглары килеп чыкмыймы? Юк, чыкмый. Алар дуслыкның кадерен белеп, бер-берсеннән тәҗрибә алып яшиләр. Бу раслау һавада асылынып калмасын, буш сүз булмасын өчен мисал китерәбез.

1994 елның февраль башында Президентыбыз Минтимер Шәймиев хезмәт алдынгыларын котларга Балтачка килде. Татарстан Республикасы президенты Балтач хезмәтчәннәре белән очрашуны күптән түгел ачылган мәчет белән танышудан башлады. Ул мәчетнең архитектурасына югары бәя бирде, мәчет каршында ачылган мәдрәсәдә 180 баланың укуы белән кызыксынды, мәчет мулласы Шәрифҗан хәзрәткә Казанның мех берләшмәсендә эшләнгән намазлык бүләк иткәннән соң, мөтәвәллият әгъзалары белән әңгәмә корды, бу әңгәмәдә катнашкан Арча хакимияте башлыгы Вәгыйз Минһаҗевтан сорады: «Минем Арча мәчетендә булганым юк. Сезнең мәчет тә шундый мәһабәтме?» — диде. «Юк, безнең мәчет алай ук түгел, без Балтачлардан калышабыз бу мәсьәләдә», — дип җавап бирде Минһаҗев. Шунда Балтач хакимияте башлыгы Марат Әхмәтов үз сүзен әйтүне кирәк тапты: «Минтимер Шәрипович, безнең мәчет, бәлки, Арчаныкыннан яхшырактыр, әмма аларда Сәнгать мәктәбе бар. Андый мәктәпнең әле Татарстан районнарының берсендә дә булганы юк. Менә ул мәһабәт, без андый мәктәпне, андый гүзәллекне үзебездә булдыра алмабыздыр шул...»

Вәгыйзнең дә, Маратның да Хәсәншәех малайлары булуын, бер болында аунап үсүләрен, берсе югары очтан, берсе түбән очтан гармун уйнап кичке уеннарга чыгуларын алдагы бүлекләрдә әйткән идек. Менә хәзер бер үк авыл малайлары Арчаны һәм Балтачны җитәклиләр, ике район да алдынгы, хакимият башлыкларында хөсетлелек юк, аларда бер-берсеннән яхшы мәгънәдә көнләшү, бер-берсе белән ярышып эшләү генә бар. Андый матур көнләшү бу төбәкләрне алга гына илтәчәк.

* * *

Татарстан әдипләре Шода авылында татар әдәбияты классигы Мирхәйдәр Фәйзи музеен караганнан соң, өч төркемгә бүленеп, авылларга киттеләр. Ринат Мөхәммәдиев бригадасы (А. Гыйләҗев, Ш. Галиев, Р. Харис) Борбаш авылына киттеләр. Мөхәммәт Мәһдиев җитәкчелегендәге бригада (Г. Зәйнашева, М. Галиев, Р. Гаташ, Р. Зәйдулла) Карадуганга юл алды. Гариф Ахунов бригадасы (И. Юзиев, Р. Фәйзуллин, Р. Мингалим, Балтачта яшәгән Г. Мөхәммәтшин, «Ватаным Татарстан» гәзите хәбәрчесе А. Юнысова) Куныр авылына килеп туктады.

Юл сөйләшү өчен бирелә, юлда юлдашлар табыла. Без Мирхәйдәр Фәйзинең Ырымбур тикле Ырымбурдан ничек һәм ни өчен Балтач якларына килеп чыгуына, «Галиябану» кебек гүзәл драманы шушында табуына аптырап, бу «тартып китерү генә» түгелме икән? — дип уйлый идек. Харис Фәйзуллин гаиләсендә унбер бала булган. Композитор Җәүдәт Фәйзи, профессор Мидхәт Фәйзуллин, тәрҗемәче Сәгыйть Фәйзуллин безгә билгеле иде. Шушы гаиләнең бишенче баласы Әхмәтгәрәй Шода авылында мулла булган икән. Мирхәйдәр 1901, 1906, 1916, 1923 елларда шушы мулла йортында булган. Ул йорт әле дә саклана. Җиде бүлмәле, ике катлы гаҗәеп матур йорт. Хәтта хәзерге заман өчен дә! Мирхәйдәр Фәйзи килгән саен шушы йортта айлар буе яшәп, Шода авылы яшьләренең кичке уеннарын, җыр-такмакларын ишеткән, аларның кием-салымнарын күргән, эш-гамәлләрен күзәткән. 1916 елны килүендә ул «Галиябану» музыкаль драмасының оеткысын күңеленә сеңдергән һәм, Ырымбурга кайтып, тиз арада әсәрен тәмамлаган.

Ихтимал, Балтач якларының гүзәл табигате, сокланырлык урманнары, болын тугайлары аны канатландыргандыр. Без, Арча әдәбиятка 25 язучы бирде, дип горурланабыз. Балтач та бит әнә Мирхәйдәр Фәйзине татарның иң көчле сәхнә әсәрен язарга рухландырган, талантлы җырлар авторы Гарифҗан Мөхәммәтшинны үстергән, Медведевны тәрбияләгән,

жырчы Җәвaһирә Сәлахова шушы җирдә туып-үскән. Барыннан да бигрәк, бу як дәүләт эшлеклеләре белән данлы, бу хакта алдарак тәфсилләп язган идек, инде.

Куныр авылына килгән бригаданы тагын бер хикмәтле хәл таң калдырды. Кунырда да, Балтачтагы төсле үк, мәчет бар, зурлыгы, мәһабәтлеге дә шундый ук икән.

Колхоз рәисе Хәмит Гәрәевтән сорадык:

— Балтачтан күчереп салдыгызмыни бу мәчетне? — дидек.

— Юк, — диде ул. — Мәчетне башта Кунырда салдык. Аны минем абыем Шамил Гәрәев проектлаштырды. Илдәге барлык проектларны өйрәнеп чыкканнан соң. Ул үзе архитектор түгел, әмма бик тә зиһенле кеше. Башта аның проектын үз авылыбызда сынадык, халык та, җитәкчеләр дә хуплагач, ул аны Балтачта салдырды.

Менә монда инде без тагын да татар халкының иң бөек заты Тукай белән очрашабыз: «Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, әдип ул, шагыйрь ул!» Әйе, зур булмаса халык, шагыйрь булмаса халык, мондый талантлы улларын тудыра аламыни?

Өч бригада өч авылда мәдәният сарайлары тулы халык белән очрашканнан соң, иртәгесен сәгать унда без Субаш авылына җыелдык. Әдипләрнең күңеле көр, чырайлары балкып тора, әдәби кичәләр зур булып, мәгънәле булып узган иде. Шул хакта бик тә теләп, күңел тойгыларына тулы ирек биреп, шаулаша-шаулаша фикер алышкан, шатлыкларны, күргән-сокланган нәрсәләрне уртага салып сөйләшкәннән соң, Субаш мәдәният сараена йомгаклау кичәсенә җыелдык. Очрашуны Балтач хакимияте башлыгы Марат Әхмәтов ачты. 350 кеше сыешлы залда шыгрым тулы булып, үсмерләр, апалар, җиңгиләр утырган. Алдан әйтелде — ике шигырь укырга! Кереш-мазар сөйләп, сай фикерләр чәчмәскә!

Әйбәт булып чыкты унбиш кешелек десант: кирәген әйтә, кирәк түгелен әйтми. Шигыренең кәттәсен укый — авылга багышланганын, кайнар мәхәббәт хисләрен, табигатькә гашыйклыгын. Бәйрәмдә өч халык язучысы, бер халык шагыйре, сигез Тукай бүләге лауреаты, ике Җәлил бүләге лауреаты, бер Халыкара Андерсен дипломаты катнаша. Мәһди әйтмешли, солидный халык.

Хакимият башлыгы канәгать: аның шомырт кара кашлары тетрәнгәләп куя, шомырт кара күзләре нур балкыта. Язучылар берлеге җитәкчесе елмайгалап утыра, ул да канәгать, аның елмайганын күреп, ниндидер ягымлы сүз әйтергә дип, хакимият башлыгы язучылар җитәкчесенә таба борыла.

Йомгаклау очрашуыннан әдипләр туп-туры Сасна пучинкәсенә юнәлә. Алдан әйтеп куйганча, үсмерләр дә автобуслары белән шунда киләләр.

Сасна пучинкәсенең зиратына 26 яшьлек Мәмдүдә абыстай күмелгән. Ул — бөек Тукаебызның әнисе. Үз әниең, нинди генә булмасын, ул башка әниләрдән газизрәк. Татарстан әдипләре Мәмдүдә абыстай җирләнгән изге туфракка түбәнчелек белән баш иделәр. Бирелә без, ниһаять, бик күпләрнең остазы булган Җәлил хәзрәтне очраттык. Ул, зират капкасы төбенә басып, төрле мәктәпләрнең югары сыйныф балаларына вәгазь сөйләде. Ул яшь, сакалсыз, йөзеннән нур сирпелә, сүзләре яшь йөрәкләргә сары май булып ята.

— Зират — мәңгелек йорт, диләр. Алай түгел. Зират — мәңгелек йортыбызның капкасы. Шул капкадан узгач, гүр иясе булгач кына без мәңгелек йортыбызга китәбез. Укучы балалар! Сез безнең киләчәгебез. «Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел!» — дигән олы сүзне онытмагыз. Ата-бабаларның каберенә юлны суытмагыз. Сез башыгызга буш кепка кигәнсез. Аның козерегы ярты метр, калган ягы гел дә куыш. Сез аңа акча әрәм иткәнсез. Сез Американың химиядән ясалган сагызын чәйнисез, аңа шулай ук акча әрәм итәсез. Сез газитләргә язылыгыз, җөмһүриятебезнең һәм дөньяның хәлләрен белеп торыгыз. Газиткә язылган акчагыз сәдакадан булсын. Башка урыннарда ул чагында сәдака биреп йөрмәсәгез дә була. Хәзер... кадерле укучылар, бөек Тукаебызның

әнисе күмелгән кабер янына керербез, Коръән укырбыз. Кыз балаларның башында яулыгы булганнар керсен зиратка, булмаганнар койма буена тезелеп тыңласын Коръән догаларын.

Малайлар, кызлар зиратка тәртип белән генә керделәр. Җәлил хәзрәтнең Коръән догаларын мысыр мәкаме белән җанга ятышлы итеп укуын тәэсирләнеп тыңладылар. Әдипләр Мәмдүнә каберенә чәчәк-гөлләр куйдылар. Зират янында инде бурасы күтәрелгән, манарасы нарат такталардан бик мул итеп ясалган булачак мәчетне карадылар.

...Каракүл янында тагын бер күңел кузгаткыч хикмәтле хәл булды. Бәйрәмнән соң без анда ял итәргә дип барган идек. Беренчедән, күл үзе бик матур, бик борынгы тарихлы икән. Икенчедән, аны яшел урман әйләндереп алган. Яңгырдан соң балкып чыккан кояш күл өстенә алтын багана сузган, өздереп кошлар сайрый, табигатьтән барлык сихәтне алып калырга теләгән Равил Фәйзуллин, инде чишенеп, лапылдап күлгә чумды да. (Ул инде 26 апрельдән үк су коена башлаган иде.) Болар барысы унбиш кешелек әдипләр десантын кузгатып, җилкендереп җибәрде. Урмдагы өстәл янына җыелып, без Каракүл турында шигырь язу өчен конкурс ачарга булдык. Шагыйрьләр моңа бик теләп риза булдылар.

Бу язма авторларыннан берсе, Гариф Ахунов, күңеленнән генә, берәүгә дә әйтмичә, конкурста катнашырга риза булды. Әлбәттә, ул әйткәнне, аның күңеленә килгәнне башка бер шагыйрь дә әйтә алмаячак. «Ерак океаннар, диңгезләр дулкынланса, Каракүл дә дулкынланмый калмаячак. Балтач җире, Арча җире дөнья белән тоташкан. Каракүл әле тыныч, аның кояш нурыннан алтын багана булып сузылган көмеш суларында татар шагыйре Фәйзуллин йөзеп йөри. Димәк, дөнья тыныч, сандугачлар дөньяның тынычлыгына мәдхия укып, язгы җырларын сузалар. Сабан тургае күкләрдә талпына-талпына, кояшка таба менеп бара, Балтач игенчеләренә җыр бүләк итә. И кадерле туган туфрак, и газиз Казан арты, бөек Тукаенны балаларың гомер буе онытмасын, ошбу илаһи минутларда җир йөзенә яңа бер Тукай тусын!»


*Балтач районы хакимияте башлыгы Марат Әхмәтов.*

Марат Әхмәтов кулына баян китереп тоттыралар. Ул борынгы халык көен сузып җибәрә һәм үзе бәрхет тавыш белән җыр башлый. Ул шундый да моңлы, шундый да җанга ятышлы итеп уйный, бу минутларда ул үзенең хакимият башлыгы икәнен дә, житди-сабыр булырга кирәклеген дә оныта. Аның бәрхет тавышлы җыры әдипләрнең җаннарын айкап ала, Аяз Гыйләҗев, яшьлегендә кичергән төрмә газапларын, нахакка интегүләрен исенә төшереп җылый, Илдар Юзәй аны җебегәнлектә гаепләп утыра торгач, үзе дә җылап җибәрә, ә Гөлшат Зәйнәшова күңелен туйганчы бушатыр өчен урманнарга ук кереп китә...

Өзә үзәкне Маратның җыры, җаннарны айкап ала һәм шунда аның бер гамәле искә төшә: Балтач хакимиятенең башлыгы татар гармунын Америкага алып чыкты. Телевидение аның гармун уйнавын, юк-бар җирдә генә түгел, Американың иң зур барларында татар моңын яңгыратуын бөтен дөньяга күрсәтте...

Тукайның «Шүрәле»се Канада урманнарын айкап йөргән төсле, татар моңы Америка киңлекләрен айкап яңгырды.

Күкрәк тутырып, горурланып әйтә алабыз: мөстәкыйль Татарстанда үзбаш эшли белүче, халык сәнгатен тирәнтен ихтирам итүче яңа буын җитәкчеләр үсеп чыкты.

## Уйлану өчен мәгълүматлар

Балтач районында 30 мең кеше яши. 78 авыл һәм поселокта татарлар, удмуртлар, урыслар, марилар гомере сөрә. Авыл хуҗалыгы районы булган Балтач ел саен алдынгылар рәтендә булып килә. Игенчеләр фидакарьләрчә эшли. Әмма терлек-туар үрчетү бигрәк тә алга киткән. Районда уртача савым 4400 килограмм тәшкил итә, кайбер колхозлар инде 5000 килограммга җиткерделәр савымны. Иген уңышының райондагы уртача нәтиҗәсе — 45 центнер. Харис Галимуллин җитәкләгән «Социалистик Татарстан» исемле колхозда һәм тагын берничә колхозда бу сан күп өлеш югарырак. Галимуллин колхозы бөтен республикада дан тота.

## Җырны Арча башлый, Әтнә, Биектау кушыла

Болай дип әйтергә тулы нигез бар. Мисаллары да җитәрлек. Без Әтнә һәм Биектауда 1993 елны да, 94 елны да булдык. Аларның бәйрәмнәрен, уңыш бәйрәме белән бергә үткәргән ярминкәләрен карадык, сәнгать бәйрәмнәрен күреп сөендек.

Әтнә һәм Биектауда, игенчеләрнең һәм терлекчеләрнең ел буена башкарган эшләренә йомгак ясау бәйрәмнәрендә (ә ул бәйрәмнәр март башында үткәрелде), арчалыларның күркәм эшләре турында ягымлы, ихтирамлы сүзләр күп сөйләнде. Арча халкы дәрәҗәсендә эшләргә омтылуны да хуплау кирәк, бик кирәктер. Мондый хәл, телгә алынган өч районның мәнфәгатьләреннән тыш, мөстәкыйль Татарстаныбызны да чынлап торып аякка бастыруны күздә тота бит. Шундый уртак теләк, уртак эш, уртак казанышка да китерә. Әтнәгә һәм Биектауга Казанның Идел буе һәм Ленин районы делегацияләре килеп, шәһәрнең авыл белән иңгә-иң торып эшләү теләге белдерүе дә тормыш авырлыкларын бергәләп җиңү максатын куя.

Әтнәгә дә, Биектауга да Арча районы хакимияте башлыгы Вәгыйз Минһаҗев җитәкләгән делегация килгән иде. Әтнә һәм Биектау районнарының хакимият башлыклары Габделәхәт Хәкимов белән Рөстәм Миннеханов, Арча белән бер дәрәҗәгә чыгу Республиканың хәлен җиңеләйтүгә зур өлеш булыр, дигән җитди теләк белдерделәр. Алар моны бик җаваплы килеп әйттеләр, чөнки бу алар җитәкләгән төбәкләрдәге халыкның уй-фикерләрен чагылдыру иде.

Бәйрәмнәргә килгәндә, аның нигезендә хезмәт кешесен хөрмәтләү ята. Һәр делегациянең үзенә генә хас сөйләү осталыгы һәм милли бизәге бар. Әтнәдә, мәсәлән, Мари-Эл республикасының Марки төбәгеннән килгән делегация котлавы, һәвәскәр артистларының гүзәл җырлары һәм баяннар авазы ут күршеләре белән тату һәм дус яшәүнең үрнәге булса, Теләче һәм Питрәч вәкилләренең Биектау хезмәтчәннәрен ихластан ихтирам итү, аларга тагын да зуррак уңышлар теләү булып яңгырады.

Бәйрәмнәрнең былтыргы йомгакларга кагылган өлешендә Әтнәләр үз эшләренә җентекле анализ ясадылар. Аларның сөйләүләреннән Арчадан башка чыккан райондагы уңышларына күпмедер дәрәҗәдә сөенү дә аңлашыла иде. Канәгатьләнү дип әйтмибез, канәгатьләнү ул үсүдән туктау дигән сүз. Кайчандыр беренчеләрдән булып үзенең халык театрын булдырган, Фәйзи Галиев, Наил Сабиров, Әдһәм Сәмигуллиннар кебек ветеран колхоз рәисләре булган районның канәгатьләнергә, арыганталчыккан буыннарны ял иттереп ятарга хакы юк иде кебек.

Шуңа күрәдер, күңелдә шигырь сүзләре дә туып өлгерде:

Башка чыккан кешенең
Башы тулы уй булыр.
Төн нигезне санга суксаң,
Көзен ямьле туй булыр.

Әйе, башка чыккан кешенең башы тулы уй. Моннан әле берничә ел элек кенә Арчадан аерылып чыккан районның хәл итәсе проблемалары күп. Юллар аз. Учреждение биналары җитешми. Төзелешләр аз булды шул, азрак булды. Башка чыккач, әтнәлеләр җиңне сызганыбрак, дәртләнебрәк тотындылар эшкә.

Ләкин, хикмәт дөрес сәясәт алып бару, икътисадны ныгытуда гына түгел. Күңелдә бөреләнеп йөргән бер анык фикерне аеруча басым ясап әйтәсе килә: әдәбиятка һәм сәнгатькә игътибар итмәгән, аны үги бала урынына күргән төбәк беркайчан да мантымый. Безгә чит илләрдә байтак йөрергә туры килде. Татарстанның визит карточкасы булып Тукай һәм Җәлил санала. Сез күпме икмәк үстерәсез, сез күпме нефть чыгарасыз, сез күпме сөт аласыз бер сыердан, дип сорамыйлар, чөнки цивилизацияле илләрдә экономика, хәзерге термин белән әйтсәк, икътисад үзеннән-үзе хәл ителергә тиеш. Аны хәл итмичә һич кенә дә ярамый, чөнки барлык бүтән өлкәләрнең үсеше икътисадка бәйле. Күптән түгел генә әле район җирләрендә көндәлек матбугатны күпләп алдыралар иде, «Казан утлары»н күп укучылар авыл пенсионерлары һәм укытучылар иде. Бер йөз мең данәдән арткан «Казан утлары» бүгенге көндә күпкә кимеде, гәзитләрнең дә тиражы азайды, татар телендә чыга торган гәзитләрдән бары тик «Ватаным Татарстан» гына быел шактый тираж җыя алды, «Татарстан яшьләре»нең дә тиражы зур, әмма ул сенсация белән, кайбер очракларда хәтта әдипләргә яла ягу белән җыя тиражны, яшьләрне мәхәббәт маҗаралары белән дә җилкендерә. Матбугатның хәле кыен, ә менә китап чыгару катастрофа хәлендә. Мәдәниятыбызга, матбугатка игътибар иткән районнарны без зур хөрмәт белән искә алабыз. Арча да, Әтнә дә, Балтач та ул яктан калышмыйлар. Арча, Балтач, Әтнә һәвәскәрләр сәнгатенә зур игътибар бирә. Вәгыйзнең, Габделәхәтнең, Маратның да үзләре гармунчы, үзләре менә дигән җырчы булулары моңа сәбәпчедер. Уйлый белү, оештыра белү ягыннан гына түгел, сәнгатьне аңлый белү ягыннан да талантлы кешеләр килә район хакимиятләренә. Балык Бистәсеннән Хатип Газизовны да сәнгатькә мөкиббән җитәкче дип санарга кирәктер. Хикмәти Хода, андый җитәкчеләрнең күңеле йомшаграк, хезмәт кешеләренә мөнәсәбәте ягымлырак, ихтирамлырак була. Татарстан андый җитәкчеләрне күптән көтә иде инде...



*Әтнә районы хакимияте башлыгы Габделәхәт Хәкимов.*

Сәнгатькә мөнәсәбәт ягыннан берничә төбәктә булган гыйбрәтле хәлләрне укучыларга җиткерергә кирәктер дип уйлыйбыз.

Татарстан телевидениесе Габдулла Тукай турында, аның бөтен гомеренә багышлап, 20 серияле нәфис фильм әзерли. Бу эш инде өч ел буена

бара. Фильм төшерү Тукай-Кырлайда, Балтач районының Шода авылында, Әтнәнең Күшәр авылында булды. Нинди атаклы Арча, нинди атаклы Тукай-Кырлай — бу авылда Татар дәүләт академия театрының артистларын бик сүлпән һәм гамьсез каршыладылар. Шуннан сәнгать әһелләренең күңеле сүрелде. Ә бит Тукай-Кырлайга бөтен республика булышты: нинди мәһабәт музей салынды анда, нинди куәтле буа төзелде! Мәдәният сарайларын, мәктәп биналарын әйтеп тә тормыйбыз инде. Арчадан Тукай-Кырлайга тикле асфальт юл сузылды, юлның ян-ягына егерме чакрым озынлыктагы буй урман утыртылды. Шул замандагы Министрлар Советы җитәкчелеге, Рәиснең беренче урынбасары Мансур Хәсәнов никадәрле көч түкте шушы чараларны үткәрү өчен. Язучылар берлеге идарәсе шулай ук кайгыртты. Тукай-Кырлайлылар моның өчен рәхмәтле булырга, фильм төшерүчеләрне биш куллап каршыларга тиешләр бит. Ә бит Кырлай Тукайның туган җире түгел, Тукайның туган авылы — Кушлавыч. Безнеңчә, бу факттан Арча хакимияте нәтиҗә чыгара белергә тиеш. Анда бит хакимият башлыгының вакыты җитеп бетмәсә, урынбасарлар Зиннәтулла, Шәфигулла әфәнделәр бар, сәнгатьне тирәнтен аңлаучы әлеге җитәкчеләр һәм тагын Ринат Фазлыйәхмәтов бар. Болар — барысы да аңлы һәм акыллы кешеләр. Тукай-Кырлай колхозы идарәсенә аларның килешмәгән эш эшләүләрен аңлатып бирерләр дип нык ышанабыз.

Ә менә «Тукай» фильмын иҗат итүчеләрне Балтач хакимияте кояш кебек балкып каршы алды, Мирхәйдәр Фәйзи яшәгән йортны алар иркенә тапшырды, фильм төшерү өчен кирәкле барлык шартларны тудырды. Моның өчен Балтач хакимияте башлыгы Марат Әхмәтовның бер сүзе җитте. Димәк, алар Тукайның әнисе Бибимәмдүдәнең үз районнарында, аның да Сасна пучинкәсенә булуына гаять зур ихтирам белән карыйлар. Аның каберен мәктәп балалары һәм яшьләр килеп, гел карап-багып торалар.

Тукай турындагы фильмны төшерүгә Әтнә район Күшәр авылы бик җитди карады. Кырык чакрымдагы Каенсар авылыннан алар бердәнбер тарантасны табып алып кайттылар, укытучылар бәләкәй Апушны каршылаганда кирәкле унбишләп малайны әзерләделәр, атлар бирделәр, бик күп хатын-кызлар: апалар, җиңгиләр, әбиләр, яшь киленнәр кинога төшергә риза булып, борынгыча киенделәр. Моның да сәбәбе бер генә: Әтнә районының хакимият башлыгы Габделәхәт Хәкимов, профсоюз җитәкчесе Наил Сабиров («Чулпан» колхозының элекке җитәкчесе), колхоз рәисләре, гомумән, бөтен авыл халкы әлеге эшкә якты күз белән карадылар. Күшәр авылы өч көн эчендә ду килде: ул малайлар, ул бабайлар, ул апа-җиңгиләр урамнарны тутырып тордылар. Кичке ат саклау картиналарына кирәкле атлар болыннарны тутырып йөрде, малайлар елга буена, карт тирәк янына кочагы-кочагы белән утын ташыдылар. Мондый мөнәсәбәт булганда, эшләмәс җиреңнән канатланып эшләрсең. «Искра» колхозын кырык тугыз ел буена җитәкләгәннән соң лаеклы ялга чыккан Фәйзи Галиев тә килгән, аның да җаны түзмәгән иде. Без аның акыллы кеше икәнен беләбез, ул сабыр гына тавыш белән безгә акыллы киңәшләрен бирде. «Мин Әхтәм Зариповка нык ышанам. «Идел кызы» романы буенча эшләнгән алты серияле «Габбас хәзрәт» фильм-спектаклен бик талантлы башкарып чыккан иде ул»,— диде.

«Арча җиренең ачык китабы»н язабыз икән инде «Тукай» фильмын төшергән чакта гына аңлашылмау килеп чыкты дип, без Арчага күләгә төшерә алмыйбыз. Арча хакимияте фильмны Ашытбашта төшергән чагында сәнгатьчеләргә һәр яктан булышырга тырышты.

Биектаулыларның 1993 елгы уңыш бәйрәмендә халыкның күпчелеге күршеләреннән ничектер арткарак калып баруына борчыла шикелле тоелды безгә. Ләкин бу читтән ярдәм көтүгә өметләнү түгел, үз көченә ышануга, эчке мөмкинлекләрен эшкә җигүгә нигезләнгән иде.



*Биектау районы хакимияте башлыгы Рөстәм Миннеханов.*

Тагын бер елдан, 1994 елның март башында узган бәйрәмдә биектаулыларның йөзе ак икәне билгеле булды. Бер ел эчендә алар бик тә өметле адым ясадылар. Биектау хезмәтчәннәре Татарстан хөкүмәтенең икмәккә биргән заказын республикада өченче булып үтәп чыкты — дәүләт амбарына 23 мең тонна ашлык салды. Сыерлардан сөт алу 1992 елгыга караганда 395 әр литрга, ит житештерү 32 процентка артты. Моңа «Урак һәм чүкеч», «Маяк», «Алга», «Ленин» исемендәге колхозлар зур өлеш кертте.

Менә шулай эшләр: җырны Арчалар башлый, Әтнә белән Биектау ул җырны дәвам итә. Әтнәдән халык күңелен район һәвәскәрләре күтәрсә, Биектауда сәхнәгә «Лик» модалар театры һәм республиканың профессиональ артистлары чыкты. Модаларны сәхнәгә алып чыгучы кызлар да, җырчы артистларыбыз да гүзәлләр иде.

Җырны Арча башлый дигәннән, Вәгыйз Минһаҗев Әтнәгә дә, Биектауга да баян алып килгән иде. Бүләген беренчесендә «Әтнә» көен уйнап, җырлап тапшырды. Ә менә Биектау ягында — мәшһүр композиторыбыз Салих Сәйдәшевнең туган ягында — районның Арчалар, Сарманнар, Минзәләләр кебек үз көе юк икән әле. Баянны җырсыз гына тапшырырга туры килде аңа...

## Теләчеләр сәхәр ашата

Казан ярминкәләрендә хәзер берсеннән-берсе кызыклы нәрсәләр күрергә була. Алдагы бүлекләрдә Арча ярминкәләренең гаҗәеп булуын, товарны 130-ар машинага төяп алып килүләрен сөйләгән идек инде. Шул ук Арча ярминкәләрне зур бәйрәмнәр алдыннан гына түгел, аена дүртәр мәртәбә, ягъни атнаның һәр шимбәсендә үткәрә башлады. Кукмаралар, Сабалар, Биектаулар, Балтачлар да бик тырыша, товарларын затлы итеп алып килергә, арзанрак бәягә сатып, Казан халкын шатландырырга җай таба.

Ә менә Теләчеләр... Теләчеләр, нинди дә булса бер хикмәтле нәрсә уйлап чыгару ягыннан, гел Арчалардан өйрәнеп торалар.

1993 елның 8-Март алды ярминкәсенә алар зур хәзерлек белән килгәннәр иде — шундук халык теленә кереп, Казан урамнарында һәм аның ерак бистәләрендә теләчеләр хакында сүз куерды:

— Теләчеләр сәхәр ашата!

Ярминкәнең яме мал белән. Татарстанда үткәрелә торган сәүдә бәйрәмнәрендә мәсьәләнең ул ягы күптән хәл ителгән инде. Ә менә ярминкәләрне халыкның көндәлек тормышына, гореф-гадәтләренә җайлаштырып үткәрү һәркемнең дә кулыннан килми. Борынгы гадәтләр халыкның үзенә кайта — менә нәрсә сөенечле!

Теләче ярминкәсенә таң атканчы ук чакырганнар иде. Моның сәбәбенә ярминкәгә килеп кергәч кенә төшенү мөмкин булды. Теләче сәүдәгәрләре базарда мөселманнарга сәхәр ашатуны оештырганнар. Бу изге эшне «Родина» колхозы рәисе, Татарстанның Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре Мансур Хөсәенов үз өстенә алган. Ураза тотучыларга сәхәр ашатырга яңа суйган сыер ите, карабодай боткасы, төче

коймак, вареньеләр белән җимешле чәй тәкъдим иттеләр. Колхоз алып килгән күчмә кухняның казаны астына иртән сәгать дүртләр тирәсендә ук ягып җибәрделәр. Бу вакытта март башында әле караңгы була. Дөрес, авылда, ихтимал, таң әтәчләре, беренче әтәчләр аваз саладыр, әмма кала кешеләре йоклый әле. Теләче ярминкәсенә караңгыда ук килеп, сәхәр ашаучылар күп түгел иде, әмма бар иде. Әйбәт бит, җәмәгать! Борынгы затлы гадәтләр кайта бит, ул гадәтләр кешеләрнең исләренә дөньяда әхлак барлыгын, ышану-инану барлыгын төшерә.



*Теләче районы хакимияте башлыгы Рөстәм Кәлимуллин.*

Теләче районы хакимияте башлыгы Рөстәм Кәлимуллинның һәм куланучылар җәмгыяте идарәсе рәисе Әсхәт Гайнуллинның һәр ярминкәгә яңалык алып килергә тырышулары моның белән генә чикләнми. Әлеге яңа район, Сабадан аерылып чыгуына әле нибары ике ел гына булган район, колхоз-совхоз җитәкчеләрен базар шартларына күнектерүне максат итеп куя. Рәис-директорлар үз хуҗалыкларында җитештерелгән азык-төлекне алып килеп урнаштыргач, авылларына кайтып киттеләр. Яз якынлаша, авылда эш муеннан. Ай-һай, күп авылда эш! Түбәләрдән тамган тамчылар да, көн уртасында өй кыекларыннан асылынган сөңге бозлар да, авыл яңгыратып каңгылдаган ана казлар да, машиналар паркыннан ишетелгән гөрелте дә язны, язгы кыр эшләрен искә төшерә. Бу эшләрнең барысында да син башлап йөрергә тиеш, язгы авазлар һәм «язның шыпырт сулышы» синең йөрәк аша уза, җитәкче иптәш!

Ленин исемендәге колхоз рәисе Закирҗан Бикмөхәммәтов мондый сүзләр әйтте:

— Алты машинага төяп, печән, фураж, дуңгыз балалары алып килдек. Колхоз малларына да, авыл кешеләренең шәхси абзарындагы терлек-туарга да җитәрлек азыгыбыз бар. Фуражыбыз да август аена кадәр җитәр. Әйбәт ашаткач, сыерлар сөтне күп бирә. Көнлек савым бездә хәзер 21 литрга җитте.

Теләченең колхоз һәм совхозларында терлекләр биргән ит-майның муллыгын ярминкәнең сәүдә рәтләрендә дә күрергә була иде.

Теләче ягы безнең көнелләргә Татарстанның халык язучысы Фатих ага Хөсние, ике зур сугышны узган классик язучыбыз Мәхмүд ага Максуд, Тукай бүләге лауреаты Мәхмүт Хәсәновы белән кадерле. Хуҗалыгын тырыш хезмәте, намуслылыгы белән аякка бастырып килгән Теләче ягы әдәбият һәм сәнгатькә дә яңа талантларын үстереп бирер дип өметләнәбез.

## Питрәч тәҗрибә уртаклаша

Питрәчнең данын сугыштан соңгы елларда безнең мәшһүр рәссамыбыз Харис Якупов күтәрде. Шәле чибәрләре аның киң колачлы полотноларында чын мәгънәсендә авылда үсеп чыныккан, алсу битле, бернинди эштән дә курыкмый торган таза беләкле яшь киленнәр, апалар һәм җиңгиләр образы булып килеп керделәр. Авыл, гомер-гомергә эш эшләп өйрәнгәнгә, чыра ботлы кызларны яратмады, битен-башын сыйпап кына егетләргә ярарга тырышкан «сылулар» да аның күңеленә хуш килми иде.

Бераздан Питрәч авыллары — бигрәк тә Шәле, атаклы колхоз рәисләре, бәрәңге үстерүнең осталары булып җитешкән агрономнары белән дан алды.

Камил Шакиров исемле акыллы рәис, Шәле кешеләреннән өйрәнеп, үз районының даныи бөтен Татарстанга танытты. Бу язмаларның бер авторы, әйтик, Мәгъсүм Гәрәев, республика радиосында эшләгән чагында, туган-үскән авылы Шәлегә кайта. Күрше авылда рәис булып эшләгән Камилебез ни сәбәпледер Шәлегә килеп чыккан. «Нинди йомыш сине безнең авылга китереп чыгарды?» — дип кызыксына радио корреспонденты. «Казаннан кайтып килеш,— ди рәис.— Юл уңаенда базарларга да сугылган идем. Шәле бәрәңгесе! Шәле бәрәңгесе! — дип халык чират торып ала. Сәбәбе нидә икән — менә шуны беләсем килде,— ди ул ачыктан-ачык.— Сәрдектә дә шундый шәп бәрәңге үстерергә хыялланам. Орлыгын сезнең авылдан юнәтергә исәп...»

Дөресен әйткәндә, сүзендә тора торган кеше булып чыкты Шакиров, ул үзе җитәкләгән колхозда Шәле бәрәңгесен үрчетеп кенә калмады, Казанда оештырылган бәрәңге үстерү трестының җитәкчесе дә булып торды.

Бүгенге көндә дә Казан базарларында Шәле бәрәңгесенең даны югалмаган. Аның тарихы гыйбрәтле. Ул тарих Питрәчтә яшәгән селекционер-агроном Хәким Бикҗановка бәйле. Хәким дигән акыллы галим Питрәчнең тәҗрибә кырында яңа сорт бәрәңге чыгара алды. 1966 елның 4 июле көнендә СССР Авыл хуҗалыгы күргәзмәсе биргән таныклыкта мондый сүзләр бар: «Татарстан АССРның сорт сынау участокларында бәрәңгенең уңышы гектарыннан 247—336 центнер тәшкил итте, ягъни, «Лорх» сортыннан 58 центнерга артык. Товарлыклы бәрәңгенең чыгышы 94 процентка кадәр. Крахмалы — 17,2—18,8 процент. «Питрәч» сорты авыруларга бирешми, тәмле, чәчүлеге озак һәм әйбәт саклана».

Шәле кешеләре сугыштан соңгы елларда, озак вакытлар, бәрәңгене Хәким абый кырыннан алып утырттылар. Шалкан төсле сап-сары, куш йодрыктай эре бәрәңге Шәле халкының үзен генә түгел, Казанны да ризыклы итте. Кукмара исә Шәледән ташыган орлык белән бәрәңгеле булды.



*Питрәч районы хакимияте башлыгы Флүн Хәбибуллин.*

Шуннан соң Шәленең бәрәңге эпопеясе Флүн Хәбибуллин белән бәйле. Татарстанда иң мул бәрәңге үстергән совхоз директоры ул. Хәбибуллин Питрәчтә Голландия технологиясен беренче булып кулланды һәм аның никадәр зур нәтиҗәләргә алып килүен республикага танытты.

— Инде шулай икән, Флүн Шәмселгарифович, Питрәчнең бәрәңге данын кайтару өчен нәрсәләр эшләргә кирәк?

— Питрәчнең бәрәңге тарихын белгәнегез өчен рәхмәт. Юкса журналистлар белән әдипләр һәрнәрсәне беренче хәрефеннән башлап сөйләтергә күнеккәннәр. Казанга ташылган бәрәңгенең яртысы узган елны безнеке иде. Мондый сикереш — Голландия технологиясен куллану нәтиҗәсе. Шәледә бәрәңге 424 гектарда иде. Күп бит, бик күп. Янгырлар китте. Техника өлгерми. Шәле халкы — олысы-кечесе — сәнәк белән казып, көн саен 18 әр гектар бәрәңге алып барды. Аларга һәр көнне акча түләдек. Мондый эшсөярләргә акча җәл түгел!

— Киләчәкне ничек күз алдына китерәсез?

— Мөмкинлекләрне барлап чыктык. Бәрәңге мәйданын киметмәскә диелде. Тик хикмәт менә нәрсәдә: бәрәңге алу вакыты шактый четерекле — көннәр кыскара, яңгырлар теңкәгә тия башлый. Казан өчен кирәкле бәрәңгене колхоз-совхозларның үзләрендә сакларга булдык. Моның өчен кышын сакларга заманча җиһазландырылган саклау урыннары кирәк. 4—5 колхоз андый саклагычларны инде төзеп тә бетерде, берничәсе җиһазларын алып кайтты. Өлгергән саклагычларны «Татарстан кыры-93» бәйрәмендә катнашучылар Күн авылында үз күзләре белән күрделәр. Әлеге корылмалар тулысынча өлгергәч, Казанның сәүдә оешмалары Питрәч бәрәңгесен бер уңыштан икенчесенә тикле ташып тора алырлар дип өметләнәбез.

Татарстан, мөстәкыйль җөмһүриятебез, чит илләр технологиясен кертә. Моның белән килешергә кирәк. Әнә Зәйдә, тагын башка районнарда Франция технологиясе белән шикәр чөгендере игәләр. Ул технология безнең республика хатын-кызларын авыр кул хезмәтеннән коткара. Голландиячә бәрәңге үстерү техникасын без җитәрлек кадәр юнәтеп, колхоз-совхозларга бушлай бирдек. Бәрәңге үстерүне дә, шикәр чөгендере үстерү кебек, тулысынча механикалаштырырбыз шикелле.

## Сабантуйлар

Без бәләкәй чакларда сабантуе җиткәнне авыл кешеләре ашкынып көтеп алалар иде. Ул чагында инде авыл болыннарында печәннәр чабылган, басуда игеннәр күзләрне иркәләп, хәтфәдәй җемелдәп, дулкынлана башлаган була. Арчага тезелешеп атлар китә, бер авылдан гына да тугыз-ун ат бара. Сиртмәле җинел арбаларга яшь-җилкенчәк төялә, хром итекне гармун күрүгә кебек итеп сыдырган, күлмәк якаларын чишеп җибәргән, башка сигез өлгеле, төймәле кепка киеп алган егетләр, тальяннарын сайратып, җырлап баралар.

Биек тау башына кунаклаган Арча белән поездлар шаулап уза торган станца арасында, бормаланып-бормаланып, Казан елгасы ага. Сугышка кадәрле мул сулы иде ул елга, анда балыкның бәртәсе дә, чабагы да, хәтта чуртаны да бар иде. Агым шәбрәк урыннарга салынган сөкәләрдән булдыклы балыкчылар көн саен берәр чиләк балык ташый торганнар иде. Мул сулы иде Казан елгасы, ник дигәндә, ул елганың буеннан-буена тегермәннәр эшли, ә ул тегермән янында авыл кешеләре ел саен буа буа торганнар иде.

Ай-һай, ямьле иде сугышка кадәр Казан суы буйлары!

— Арча янында, тау астында ук, елганың ике ягында бик иркен һәм ямь-яшел болын җәелеп ята иде. Әнә шул болында, ямьле елга тугаенда, язгы сабан туена меңнәрчә-меңнәрчә кеше җыела. Күзләр камашырдай чуар киемле халык, кырмыска оясы кебек кайный, мәш килә торган иде.

Елга буенда җигүле атлар тора. Тарантаслар, сиртмәле җинел арбалар, шлея-чуклы аргамаклар. Аларның өстендә җиз тәнкә, муеннарында шөлдер, дугаларында җиз кыңгыраулар зыңгылдаша.

Сабантуе тулы гармун, сабантуе тулы яшьләр! Күпме кыз, сылу авыл иркәләре шул сабантуйларында парын тапты, күпме егет, төрле тарафлардан килгән егет-җиләннәр үзләренә кыз сайлады!

Әнә нинди иде сугышка кадәрле сабан туйлары! Анда малайлар йөгерешә, бүрәнә өстендә егетләр капчык белән сугыша, чүлмәк вату, бау тартышу, түкми-чәчми су ташу, колга башына бәйләп куйган әтәчне алып төшү, каяндыр Алан авылы ягыннан килеп чыккан өермәне — атлар чабышын карау, каты беләкле егетләрнең, мәйдан тотар ирләрнең чирәм өстендә көрәшкәннәрен карау...

Сугыштан соңгы елларда сабантуйларының яме китә башлады. Каяндыр исерекләр килеп чыкты, аннары... халык уеннарын ниндидер спорт

ярышлары, «әртистләрнең» җанга ятышсыз җырлары алыштырды, бозылды халыкның мең еллык гореф-гадәте, бозылды бәйрәм яме...

Ниһаять, менә соңгы ике-өч ел эчендә сабантуе янә дә үз эзенә килеп төште. Халык уеннары кайтты, шытыр-пытыр сүз, ялган сүз, уйдырма сүз, халык телендә йөргәнчә әйтсәк, «кызыл сүз» чүп-чар өеменә ташланды.

1993 елны Арча сабантуенда Татарстан Республикасының Президенты Минтимер Шәймиев катнашты. Аның Татарстан районнарыннан ни өчен Арчаны сайлаганлыгын һәммә кеше белә иде — Арча соңгы елларда игенчеләрнең БАШКАЛАСЫ булып танылды. Игеннәрне вакытында урып-җыюда булсын, игенчелек культурасын күтәрүдә булсын, ашлык тапшыруда дәүләт заказын беренче булып үтәүдә булсын — Арча беренчелекне бирәүгә дә бирмәде.

Әмма... ни хикмәттер — башка вакытта бигүк сөендермәгән болытлар бүген килеп җиткәннәр дә иртәдән башлап яңгыр яварга кереште. Сабантуйларының матурлыгын тулысынча күрсәтергә теләгән Арча халкы да, Арчаның хакимият башлыклары да яңгырның кирәк түгел чакта, үч иткәндәй, коярга тотынуына инде үртәнә үк башлаганнар иде, Минтимер Шәрип улы гап-гади бер сүз әйтте:

— Туганнар, яңгырга үпкәләмик. Ява бирсен. Икмәк ява бит...

Шул минуттан башлап үкенүләр бетте, барлык уеннар уйналды, ат чабышы да булды, көрәшчеләр дә, янып-көеп утыручыларны дулкынландырып, тулы көчләренә көрәштеләр. Үз вакытында әйтелгән бер ягымлы сүз бөтен проблемаларны хәл итте дә куйды.

1993 елның 13 июнендә үткәрелгән Арча сабантуе кешеләрнең күңеленә үзенең матурлыгы, бик әйбәт оештырылган булуы белән генә түгел, хөрмәтле президентыбызның юату сүзе белән дә кереп калды.

1994 елны Арча сабантуе 12 июньдә булды. Сабантуйларын уздыруда «җитмеш җиде пот тоз ашаган» Ринат Фазлыйәхмәтов безне кояштай балкып каршы алды, хакимият башлыгының урынбасарлары Шәфигулла белән Зиннәтулла әфәнделәр дә сабантуен карарга Казан каласыннан кайтканыбызга шатлануларын ихлас белдерделәр. Аннары безне Арча кулланучылар җәмгыятенең рәисе Җәүдәт Миннәхмәтовка җылы кулдан тапшырдылар.

Без иң әүвәл кибетләрне карарга булдык.

«Сезгә сәүдә йорты «Арча» хезмәт күрсәтә!» — дип капка башына бик матур хәрефле плакат эленгән җиде йорт янына киләбез. Болар — курчак өйләре. Аллы-гөлле төсләргә буялган, тәрәзәле-ишекле йортлар.

— Безнең Казанда «Арча» исемле зур гына кибетебез бар. Анда без көн саен Арча товарларын сатабыз. Кибет мөдире — элекке әфисәр. Әлки мишәре...— дип әйтеп тә бетерми Җәүдәт, ут борчасы кебек җитез, ыспай гәүдәле, башына чигүле кара түбәтәй чәпәгән ир уртасы кеше безнең каршыда пәйда була һәм елмаеп-көлеп безнең белән күрешә.

— Гариф абый, исәнмесез! Туган якларга кунакка кайттыгызмы? — дип ул безне кочаклап ук ала.

— Сез танышмыни? — ди Җәүдәт, гаҗәпләнеп.

— Таныш булмыйча соң! Үзең бит безне Казандагы «Арча» кибетенә юлладың. Үзең больниста ята идең ич,— дим мин.

— Әйе, әйе, шулай бит әле. Йә, Казандагы «Арча» кибете ошадымы сезгә?

— Кибет менә дигән! Кибетче кызлары аннан да әйбәтрәк: ягымлылар, чибәрләр, зәвык белән киенгәннәр. Сандугачлар кебек, бер-берсен уздырып сайрыйлар.

— Товарны мактауларын әйтәсезме?

— Нәкъ шуны әйтәбез. Шундый да оста мактыйлар товарларын, алмас жиреннән алырсың.

— Ә директоры? — ди Җәүдәт.

— Директоры бик үткен. Сөйләшә дә белә, оештыручы икәне әллә каян күренеп тора.

— Рәхмәт,— ди Җәүдәт,— бу безнең адреска да мактау булып чыга бит әле. Директорны мин сайладым Казандагы «Арча» кибетенә. Менә алар безнең сабантуена нинди кәттә йортлар ясап куйдылар, сез әйтмешли, боларның товарын алмас җиреңнән алырсың!

Җаның ни тели, абыйга да, сабыйга да товар бар «Арча» сәүдә йортында: азык-төлек дисеңме, кием-салым дисеңме!

Шул хәтле дә гүзәл курчак йортлары итеп җиде кибет ясаганнары өчен хуҗаларга рәхмәт әйтеп, алга таба кузгалабыз.

Ике урында түбәсен чыршы ылысы белән япкан, урманда йөрү тойгыларын уята торган ашханәләрне горурланып күрсәтә безгә Җәүдәт. Йа хода! Осталар да соң арчалылар уйлап чыгарырга! Сабантуена авыллардан килгән халык ач йөрмәсен дип, гигант ашханәләрен дә корып куйганнар. Ашханәнең ишеген ачып, башны тыгып карыйбыз, күзгә берьюлы ун өстәл ташлана, борынга тәмле аш исләре килеп бәрелә. Димәк, ашханәләр уенчык түгел, ашханәләр кешеләрне кайгыртып корылган.

Алда — ниндидер карусель. Түбәсе үтә күренмәле сары, кызыл, яшел, зәңгәр төстәге ефәк белән ябылган. Бик дәү — гигант карусель, эчендә прилавкалар, эчендә товар, җаның ни тели — шул бар.

Инде Арчаларның могҗизасы шуның белән беттеме дисәң, «Әкият» кафесы алдына килеп туктыйбыз. Каен киртәләр белән уратып алган кафе ишегалдында яшь-яшь әниләр улларына, кызларына тәмле ризыклар алганнар да бергәләп шуны балалары белән ашап утыралар. Бу авыр һәм болгавыр заманда шуннан да матуррак күренеш була аламы?

— Инде хәзер мин сезгә, кадерле кунаклар, сабантуй кибетләренең иң зурысын күрсәтәм,— ди Җәүдәт Миннәхмәтов һәм безне ул арырак алып китә.

Бер йөз метр озынлыктагы арага 25 кибет салынган. Арча, Үрнәк, Курса, Чулпан, Тукай-Кырлай... кулланучылар җәмгыятьләренең кибетләре икән. Берьюлы егерме биш кибет! Һәммәсе дә буяулы-бизәкле, пәрдәле-кашагалы, һәммәсенең дә түбәсендә Татарстан флаглары яки герблары — зәвыклы һәм законлы.

Шактый ук читтә машиналар. Анда да сату итәләр. Алары һәвәскәрләр икән, алары — кызыктыра торган түгел.

— Һәвәскәрләрне читкәрәк кудык,— ди Җәүдәт,— безнең матур кибетләребезне ямьсезләп тормасыннар. Сату итәргә аларга да рөхсәт. Тик алар дәүләт кибетләренә караганда кыйбатракка сатарга тырышалар. Әмма алар теләгән белән генә түгел шул. Күрәсезме, алар тирәсендә кеше юк диярлек, безнең кибетләрдәге малны чират торып алалар...

Сабантуй башланырга сигнал була. Без мәйдан ягына ашыгабыз. Безне шигырь белән үтә дә матур итеп язылган плакат озатып кала:

Сабан туе — хезмәт туе,
Шатлык һәм бәхет туе.
Уйнап, биеп, җырлап, көлеп,
Бәйрәм итик көн буе.

Сабантуй мәйданыннан бәйрәмчә бизәлгән атлар вәкарь белән генә узалар. Ул атларның олауларында язгы чәчүдә дан алган хезмәт батырлары. Сабантуй флагын күтәрәләр. Район хакимияте башлыгы Миннәҗев бәйрәмгә җыелган халыкны сабан бәйрәме белән котлый.

Калганы барысы да район сабантуеның программасында куелганча бара: 1994 елгы сабан батырларын котлау, фольклор коллективлары чыгышы, Арча педагогия колледжының спорт уеннары, Арча районы халык талантлары концерты...

Халык парашютчыларны көтә, халык мәйдан уртасына көрәшчеләр чыкканны көтә...

Һавада күренгән парашютлар, аларның җилдә җилфердәп килүләре, сабантуе мәйданына төшеп утырулары алкышларга күмелә. Аннары татар милли көрәше башлана...

Сабантуеның күп төрле уеннарын әйтми калдырырга мөмкин, әмма ат чабышын әйтми калдырып булмый. Без бәләкәй чакларда атлар Алан авылы ягыннан өермәләнеп күтәрелә торганнар иде. Халыкның шатлык авазлары, атларның җайдакларын ярсытып торулары, иң арттан килгән атның муенын сөлгеләр белән бизәү гадәткә кергән иде.

Хәзер Арчада, сабантуй мәйданыннан ерак та түгел, ипподром мәйданы булдырдылар. Атларның тоягына кыен булмасын өчен, мәйдан юлларына кирәкле балчыкны, комны, вак ташны Башкортостаннан алып кайттылар.

Ат чабышын карарга дигәч, халык дәррәү шул мәйданга юнәлде. Биредәге аеруча матур бер детальне әйтми калдырсак, ат чабышы чабыш булмас төсле тоела безгә.

Вәгыйз Минһаҗевның күптәнге дусты Фән Вәлиәхмәт көмеш телле гармунында Арча көен уйнап бара ат чабышы мәйданына. Башка гармуннарга әйләнеп карауучы да юк, әмма Вәлиәхмәт гармунын барлык кеше күздән үткәрә һәм сокланып тел чартлата: уйнап та карый соң Уфа татары тальянда! Җаннар эри, күңелләр кузгала, дөньяда яшәвеңә, Фән Вәлиәхмәтнең шул тамаша матур итеп, виртуозларча гармун сайратуына шаһит булганың белән горурланып, ат чабышын карарга барасың...

## Урак-Чүкеч дуслыгы

Бу бүлектә сүз башкалабыз районының сабантуе турында барачак. Укучы дустыбызның күңеленә сорау килүе мөмкин: «Нигә әле Арча турындагы китапка Казанны китереп кушалар? Казанның Арчага ни мөнәсәбәте бар?»

Җавап бирәбез: Казанның авыл районнарына турыдан-туры мөнәсәбәте бар. Казанның барлык районнары язгы, җәйге, көзге эш өстендә авыл халкына бик теләп ярдәм итәләр. Арча районына Казанның Совет районы шефлык итә. Совет районының хакимият башлыгы Альберт Әскәр улы Камалиев хакында махсус сөйләү кирәк булыр. Уртачадан калкурак базык гәүдәле, йомшак фигыльле бу башлык авылларда урак өсте башланыр алдыннан зур әзерлек эшләренә керешә. Арча районының барлык колхоз рәисләрен, совхоз директорларын Казанга хатыннары белән бергә чакырып, бик зур бер ашханә залында аларны кешечә кунак итә. Урак өсте алдыннан колхоз-совхоз җитәкчеләренең нинди ихтыяҗлары бар, кемгә күпме машина, күпме шофер, күпме эшче көчләр кирәк — барысын да уртага салып сөйләшәләр. Шундый ягымлы, шундый олысымак түрәнең сүзен аяк астына салып булмый бит инде. Шоферлар авылга бу юлы инде чын мәгънәсендә теләп баралар. Шунысы бик әйбәт: авылга күпме ярдәм кирәген Камалиев түшәмнән алмый, колхоз-совхоз җитәкчеләренең үзләреннән ала. Ә бу исә авыл игенчеләренә ифрат та ошый, ник дисәң, аларны санга сугып, олылап, хөрмәтләп сөйләшәләр бит.

Арча районы хезмәтчәннәре соңгы елларда игеннәрне җыеп алу, дәүләткә ашлык сату ягыннан алдынгылар сафында бара икән, димәк, монда Казанның Совет районы эшчеләренең дә өлеше бар. Урак-Чүкеч дуслыгы менә шулай була ул. Кайчандыр бөек СССР державасы яшәгән заманнарда туган ул төшенчә бүген, яңа шартларда, яңа төсмерләргә байый. Арча ярминкәләренә, уңыш бәйрәмнәренә Совет районы җитәкчеләре кайта, Казанның кибетләре, ашханәләре, чәйханәләре кайта, татар ашының иң тәмлеләрен, телеңне йотардайларын пешереп алып кайта казанлылар!

Иген уңышы җыеп алынгач, бәрәңгеләр казылып беткәч, Альберт әфәнде Камалиев Арча унганнарын тагын үзенә җыя, дусларча-туганнарча әңгәмә корып җибәрә... Арчалар да бурычлы булып калмый, бәрәңгенең иң яхшыларын олау-олау итеп көзен Казанның Совет районы кибетләренә озаталар.

Бу дуслыкның нинди чагылыш тапканын белү өчен Казанның Совет районы сабантуена юнәләбез.

Каен урманына алып керә торган юл буена кибетләр, киосклар, кафелар, әкият йортлары тезелеп киткән. Хакимият аппаратыннан Зәйнетдинов безне алып бара. Ул янып торган кара татар. Исеме һәм әтисенең исеме ни өчендер Валерий Геннадьевич. Нигә алай икәнен сорыйбыз: «Әти минем урыс, өч мәртәбә китте бездән, өч мәртәбә кире кайтты. Мин фамилияне әнинекен алдым, исемем әти куйганча калды инде»,— дип саф татарча әйтә Валерий. Ул яшь әле, чибәр, каратут йөзе ягымлы, тулы ай кебек балкып тора. Сабантуе мәйданына җиткәнче без утызлап кибет очраттык. Татлы сулар да, шәраблар да, туңдырма да, мануфактура, балалар киемнәре дә, урын-җир әйберләре дә бар аларда. Кибетчеләре милли киемнәрдән. Ягымлы итеп каршылыйлар, татлы су, «Күгәрчен сөте» кәнфите, печенье, шоколадлар тәкъдим итәләр.

— Боларның күбесе — Арчадан килгән кибетләр,— ди Валерий.

Казаннан, Дербышкидан, тау өстендәге яна поселоклардан халык ташкыны агыла. Әтиләре сабыйларын муенына атландырган, әниләре бәләкәй кызларын җитәкләгән, баганалы олы юллардан, агыла халык, тальян гармуннар сайраша, махсус билгеләнгән автобуслар сабантуйга килүчеләрне ташый.

Арчадагыча иркенлек, муллык, матурлык.

Тәртип сагында торучы милиционерлар ак кительләрдән урман аланындагы ромашкалар кебек күренәләр. Алар күп, ифрат күп. Өстәвенә тагын, гадәттә булмаганча, ягымлылар, кычкырмыйлар, каныкмыйлар, ягымлы итеп дәшәләр.

Халык ташкыны язгы гөрләвекләрдәй агыла.

Кибетләр тулы шәраб, әмма исерекләр юк. Монысы да Арчадагыча! Юкса бер мәлне сабантуй, сабантуй булудан туктап, махмырчылар оясына әйләнә башлаган иде.

Сабантуйның олы юлыннан бер төркем халык ничектер тупланыбрак, ашкынулырак килә. Баксаң-күрсәң, хөрмәтле Президентыбыз Шәймиев пәйда булган икән. Ул кибетләр янына туктый, кибетчеләрдән сораша, аңа җавап бирәләр, ризык тәкъдим итәләр, фотоаппаратлар Президентны чалт та чолт сурәткә төшерә.

Бераздан сабантуе президиумына хөрмәтле кунаклар, ил агалары, сугыш һәм хезмәт ветераннары кереп утыра. Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев тә, үзен озатып йөрүчеләр белән бергә, Сабантуй президиумына килә.

Ничәмә-ничә мәртәбә күзәткән бар: кешеләрне ихласлык бизи. Минтимер Шәрип улы кайда гына булмасын, һәммә нәрсәне чын күңелдән карый.

Сабантуе башлануы аның йөзендәге күләгәләрне, сөмсерләрне куып җибәрде. Президиум кешеләренә биреп чыккан чигүле бәрхет түбәтәйне дә ул матур гына итеп киеп куйды. Кап-кара костюм, ап-ак күлмәк, кара бәрхет түбәтәй аның нурлы йөзен тагын да ача төште.

Флаг күтәрделәр.

Татарстан гимны уйналды.

Аягүрә басып, берничә минут тып-тын тордык.


Казанның Совет районы хакимиятен котларга башкортлар, марилар, мордвалар, чувашлар, удмуртлар төркем-төркем булып килгәннәр иде. Мәйдан уртасында дәртле биюләр өермәләнә башлады. Минтимер Шәрипович аларны эчке бер рәхәтлек белән, рухланып карады, йөзе алсуланган, күзләре елтырый иде. Сабантуеның аксакалын котлау кебек юмористик биюне ул исә елмаеп, рәхәтләнеп көлеп карады.

Парашютларда төшүчеләр дә, бәйрәмчә бизәлгән атлар да, байрак күтәреп, яшьләрчә җиңел атлаган ветераннар сафы да — барысы да дулкынландыра иде бугай аны. Ул әледән-әле Совет районы хакимияте башлыгы Камалиевкә дәшә, уй-тойгыларын аның белән уртаклаша иде.

Арча районы хакимияте башлыгы Вәгыйз Минһаҗев президиумда күренүгә, ул, ай-кояштай балкып, Вәгыйзне үз янына чакырып алды һәм күңелендәге уй-тойгыларын аңа, нәкъ менә аңа, үзенә хас сабырлык белән сөйләргә керешге.

Җөмһүриятебезнең иң беренче башлыгы, хөрмәтле Президенты өчен, ихтимал, барлык районнарның хакимият башлыклары да бердәй тигез кадерледер. Әйе, хакимият башлыкларының барысына карата да ул күңелендә ихтирам саклыйдыр. Әмма бу минутларда Президентыбыз Вәгыйз Минһаҗевка аеруча якты күз белән карый, аны дустанә тәбрикли кебек тоелды безгә. Әнә шуны тою безнең өчен рәхәт иде.

Ил байлыгын арттырган ирне ил онытмый шул, онытмый!





## ИЛҺАМ ШАКИРОВКА 60 ЯШЬ

# ТУРГАЙ КАРТАЯМЫ?

Заманында бер өлкән язучыбыз үзенең хикәясен шулайрак исемләгән иде. Күп еллар үткән булса да, бу хикмәтле сорау гел истән чыкмый, аңа җавап табу да уйга керми, кош буларак, галиҗәнаб тургайның картаямы-юкмы икәнен дә ачыклыйсы килми. Чөнки сүз мәгънәсе тирәндәрәк: акыл чиге җитмәслек җиһанда адәми затның бердәнбер икәнен һәм аның матди җирлектән өстен, исәп-хисапларга бирешми торган бәгырь-күңел дәрьясы, моң-аһәң чишмәсе барлыгын һәм аның вакыт агышына бирешми торган илаһи халәт икәненә ишарәдер бу — җавап таләп ителмәгән сорау...

Ә кеше дигәнең олыгая шул, гомернең фасыллары аңа үз чалымнарын өсти тора. Миллионнар күңелен юаткан һәм елаткан Илһам Шакиров та менә олыгаю ызанынннан үткәненә борылып карый. Хәтерендә — еллар-алкышлар шавы, сәхнә каршында — заллар-күзләр диңгезе, пәрдәләр артында — кояшлы-яңгырлы-җилле-буранлы юллар йомгагы.

Ул дөньяга тәүге аваз салган көн — 1935 елның 15 феврале. Ямьле Сарман төбәгендә Яңа Бүләк авылында гомер кичергән Гыйльметдин белән Нуриәсма татар йортына нинди асыл малай бүләк итүләрен үзләре дә белмәгәннәрдер. Кулларыннан эш килгән, кинәнеп яшәргә җыенган гаиләнең алтынчы сабые тусын да, кая инде аларны аерып карау... һәрберсе үзенчә кадерле. Ә менә исемне, ил-күздә булмаганракны, авазлар яңгырашыннан ук ягымлы аһәңгә тиңне кушалар — Илһаметдин... Илһам!..

Илһам дигән моңлы бала, Ходай биргән сәләте өстенә, балачак елларына ишелеп төшкән әрнү-кайгылар да аның күңел тарлавыгындагы нәзберек моң чишмәсенә юллар сапкандыр.

Сугыш алдыннан, илне күз-яшькә күмгән кара елларда, аның әтисен, авылның бердәнбер тимерчесе Гыйльметдинне төнлә килеп кулга алалар. Күндәм авыл агае шул китүдән гаип була. Уйнап-көлеп кенә үсәсе малай — Илһамның сабый күңеле иртә киселә. Бу фаҗигане ул йөрәгенә йомып, бик күп гомер йөртә, беркайчан да кешегә чыгармый, зарланмый.

1941 елда сугышка алынган иң өлкән абыйсы — Имам да хәбәрсез югала. Эчтән әрнеп сулкылдаган сабый моңга бирелеп кенә юаныч таба. Мәктәптә укыган чакта ук, клуб сәхнәсеннән авылдашларына да моң өләшә. Хәтәр сугыш кырына сөйгән егетләрен озаткан кызлар, ир-улларын җуйган килен-аналар кечкенә Илһамны елап-елап тыңлыйлар.

Әнкәсе аны горурланып та, алдагы язмышы өчен борчылып та тыңлый. «Бигрәкләр дә моңлы итеп җырлыйсың, балам, бәхеткәйләрең генә була күрсен инде...» — дип башыннан сыйпый, хәсрәтле күз яшен күрсәтмәс өчен улын күкрәгенә кыса.

Бәхет... Атказанган, шөһрәтле сәнгать кешесе өчен ул — тулы заллар, кайнар алкышлар, дан тәхете, халыкның чиксез рәхмәте. Әмма тормыш-чынбарлык кырыс та, аяусыз да — бар да үтә, монда инде вакытның үз кануннары хакимлек итә.

Илһам Шакиров тормышта да, сәнгатьтә дә хакими түрәләргә ярарга тырышмады, үз иманына беркайчан да хыянәт итмәде. Казан дәүләт консерваториясен

тәмамлаганнан соң ул, рус классик арияләрен, романс-җырларын башкарып, дан-дәрәҗәләргә тизрәк тә, җиңелрәк тә ирешә алган булыр иде. Әмма ул, үз халкына тугры шәхес буларак, гаҗәеп бай табигатьле татар җырын башка милләтләргә дә җиткерү, таныту максатын үз алдына куя. Элеккеге бербөтен илнең Көнбатыш чигеннән алып Көнчыгыш чигенә кадәрге киңлекләргә таралып гомер сөргән татар галәменә, бөтен төрки халыкларга милли җырыбыз җәүһәрләрен югары кимәлдә җиткереп, дистә еллар буена фидакарьләрчә хезмәт итте ул.



Татарның хәтерен җыр белән генә түгел, ә үзенең кыю-хөр фикерләре белән дә уятырга, тарихи горурлыгын кайтарырга теләп, ул меңнәрчә тамашачыларның йөрәгенә төбәп хакыйкать уклары юллый иде. Шуңа күрә аны үткер күзле махсус оешмалар һәрчак сагаеп күзәттеләр, кирәк чакта, астыртын-яшерен рәвештә, аның җан тынычлыгын алырга тырыштылар. Әмма Илһам кебек даһины алар җинел генә юк итә алмыйлар иде шул.

Тукайдан соң, Гаяз Исхакый кебек көрәшче ирләр читкә тибәрелгән елларда, әкренләп сүнәргә дучар ителгән халыкны бүгенге рухи күтәрелеш чорына кадәр өметиман белән яшәтүче, дәверләр күперен тоташтыручы гали затларның берсе — Илһам Шакиров иде.

Ул олы сәхнәгә менгән чорда мәңгелеккә күчкән Сәйдәшнең якты моңнары яши, классик композиторларыбыз Нәҗип Җиһанов, Александр Ключарев, Рөстәм Яхин, Мансур Мозаффаров, Җәүдәт Фәйзи, Заһит Хәбибуллин, Сара Садыйковалар җиң сызганып эшләгән дәвер иде. Шушындый мәртәбәле корифейлар белән бер заманда яшәп иҗат итү Илһам Шакировның кабатланмас бәхете булгандыр, мөгаен.

Поэзиягә чал Урал аръягыннан Хәсән Туфанның кайтуы... Нәкый Исәнбәт, Сибгат Хәким, Әхмәт Фәйзи, Мостай Кәримнәрнең сугыштан соңгы яңа сулышлы шигърияте... Алтмышынчы елларда бер дулкын яшь шагыйрьләр: Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Рәдиф Гаташ, Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалимнәрнең күкрәп килеп керүе...

Театр сәхнәсендә — Хәлил Әбҗәлилов, Фуат Халитов, Габдулла Шамуков, Хәким Сәлимҗанов, Хөсәен Уразиков, Гөлсем Камская, Фатыйма Ильская, Шәүкәт Биктимеровларның каһарманлыгы... Аларның мәсләген дәвам итеп, Ринат Тажетдинов, Равил Шәрәфиев, Әзһәр Шакиров, Наилә Гәрәева, Нәҗибә Ихсанова, Айдар Хафизов, Наил Дунаев, Хәлим Җәләловларның килүе...



**Драматургиядә Тинчурин «шинеленнән чыккан» Хәй Вахит, Шәриф Хөсәенов, Туфан Миннуллин, Аяз Гыйләҗевләрнең яна әсәрләр белән татар театры офыгын киңәйтүләре...**

**Җыр сәнгатендә — Фәридә Кудашева, Рәшит Ваһапов, Гөлсем Сөләйманова, Фәхри Насретдинов, Зифа Басыйроваларның кабатланмас моңнары...**

**Татар галәменең мәккәсе — Казан учагының кодрәтле ялкыны берләштергән бу мәртәбәле исемнәр, аерым кыя булган мәшһүр Бакый ага Урманчены да кертеп, үзе бер эпоханы күз алдына китерә. Шушы эпоханы, гасырга бер генә туа торган сәмави тавышы, моң-аһәңе белән юатып, наз-рух чишмәсе белән сугарып торучы моңдаш, замандаш Илһам Шакиров булды.**

**РСФСРның, Татарстан һәм Каракалпакстанның халык артисты, Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, зарлы вәданлы милләтебезнең бөек улы Илһам Шакировка шушы елның 15 февралендә алтмыш яшь тула.**

**Аның исәнлегенә дога кыл, төрки-татар дөньясы...**

**Быелгы ел — Илһам елы, илһамлы ел булсын.**

**Илханын көткән халыкның моң ханы — Илһамы бар!**

**Марсель ГАЛИЕВ.**

•

## Ходай биргән

Җанга кирәк «азыклар» арасында иң тансыгы, иң татлысы җырдыр, мөгаен... Һәм җырчы сәнгать әһелләре арасында иң популяр кеше дә ул... Язучыны бирәү белә, бирәү белми, ә җырчыны белмәгән кеше юк. Шул ук вакытта язучыга ялган шөһрәт, ялган дәрәҗә тудырып була, әмма җырчыга түгел, җырчыны ясалма рәвештә «бөек» итеп булмый. Чөнки Ходай бирмеш җырчылык таланты шулкадәр ачык, табигый, бердәнбер генә ки, аны, ягъни ул талантны, юри зур итеп тә, кечкенә итеп тә күрсәтеп булмый — ничек яратылса, шулай яши ул...

Миңа үз гомеремдә ирләрдән һәм хатын-кызлардан күп җырчыларны тыңларга туры килде. Алар барсы да танылган җырчылар иде, ләкин һәркайсы үзенә башка, бер-берсенә һич охшамаган талантлар иде. Мәгәр шушы күп төрлеләр арасыннан әкренләп кем дә булса берәү аерыла башлый. Тыңлаучы да күбрәк шуңа колак сала, шуның җырлавын күтә башлый... Ул инде аны бик хаклы рәвештә бүтәннәрдән аера, чөнки нәкъ менә аның тавышында, моңында, җырында үзенә иң кирәкне, иң тансыкны, иң якын-кадерлене ишетә... Һәм бу «берәүнең» тыңлаучыны тәмам әсир иткән тылсымлы җыр-моң кодрәте аңа чын мәгънәсендә үлемсез дан-дәрәҗәне китерә дә инде.

...Кайчандыр әнә шундый табигый рәвештә үзеннән-үзе килгән данга Гөлсем Сөләйманова ия иде. Бик гади, бик тыйнак, әмма татар халкының тирән мәхәббәтен яулаган чын милли җырчыбыз иде ул... Бүгенге көндә исә бу үлемсез шәрәфле данның иясе, әлбәттә, Илһам Шакиров! Ходай аңа шул данга лаеклы кодрәтне биргән, халык исә аны таныган һәм сайлаган... Монда инде Илһам файдасына нидер өстәп маташуның кирәге дә калмаган — аңа саулык теләүдән башкасын!

**Әмирхан ЕНИКИ,**
язучы.

•

## Мин аңа гашыйк идем

*( Автобиографик әсәрдән өзек )*

**1960** елларның башында Г. Тукай исемендәге Филармония җитәкчеләре Илһам белән минем өчен яшьләр бригадасы төзеде һәм без Илһам белән берничә ел бергә эшләдек.

Аның белән эшләгәндә, минем җаным тыныч иде. Илһам консерватория тәмамлаган, тавышы яхшы, көчле, матур. Тамашачылар аны бик тиз арада яратып өлгерделәр. Ул бик тиз популярлашты. Концертларда аңа аркаланырга, ышыкланырга була иде. Халкыбызның иң матур көйләрен: борынгыларын да, хәзерге заман көйләрен дә, композиторларыбызның яңа матур җырларын да

бердәй зур осталык белән башкара. «Иске карурман»ны, «Менәргә иде Урал тауларына» җырларын сузып җибрсә, тамашачылар тын да алмый. Илһамның миңа йогынтысы зур иде. Аңардан күп нәрсәгә өйрәндем. Җырларның бик тирәндә яткан моңын ачарга, музыканың иң нечкә хасиятләрен табарга өйрәтте ул. Мин аны үземнең остазым, өйрәтүчем дип саныйм. Илһам белән без бик дус, тату яшәдек, һәр нәрсәне киңәшләшеп, уртаклашып, гастрольләрдә туганнарча йөрдек. Ике бертуган кебек йөри торгач, күңелләребез шулкадәр якынайды, мин аңа гашыйк булдым. Гел аны гына уйлыйм. Сәхнәдә бергә, юлларда бергә, азга гына күрешми торсак та, миңа ямансу була башлый. Гел аңа гына карап торасым, гел аның гына җырлавын тыңлап торасым килә. Әллә үзе, әллә сихерле тавышы гашыйк итте. Хәер, ул елларда Илһамга гашыйк булмаган хатын-кыз калдымы икән безнең татар дөньясында?.. Яшь кызлардан алып, олы яшьтәге түтәйләргә кадәр барсы да Илһамга гашыйк булгандыр. Шундый сүзләр дә йөри иде: Илһам бер түтәйдә фатирда тора иде, түтәйнең Илһам яшендәге улы бар икән, консерваториядә Илһам белән бергә укып йөри икән. Шул түтәй дә үлеп Илһамга гашыйк, имеш. Улыннан ныграк тәрбияли, сыйлый, ризыкларының иң тәмлесен Илһамга ашата икән... Мин генә ничек Илһамга гашыйк булмыйча калыйм ди?! Илһам үзе дә миңа гашыйк шикелле тоела иде. Бәлки, миңа гына шулай тоелгандыр... Әллә минем үлеп гашыйк булуымны сизеп, җавап рәвешендә генә үзен миңа гашыйк шикелле тотканмы?.. Кыскасы, арабыз бик серле иде. Илһам белән Әлфия бер-берсен яраталар икән, өйләнешәчәкләр икән, дигән сүзләр дә халыкка таралды. Бервакыт Илһам: «Әлфия, әйдә өйләнешәбез!» — дип тә әйтеп куйды. Әллә тирәнтен уйлап әйтте, әллә уйлап-нитеп тормыйча, шаяртып кына әйтте. Мин ул сүзне уенга борган булдым. Ни дисәң дә, ул миннән яшьрәк, мин инде ирдән аерылган балалы хатын идем. Ярый әле өйләнешмәгәнбез... Ике тәкә башы бер казанга сыямыни? Икебез дә бер-беребезгә юл куймас холыклы, сәхнәдә дә ярышып җырлаган шикелле идек. Аннары ул гыйшык уты нигәдер минем күңелемдә озакка бармады, сүнде, сүрелде. Илһамның үзенең дә күңелендә миңа карата мәхәббәт уты дөрләп китмәде. Без дуслар гына булып калдык. Дуслар буларак бик күңелле көннәребез булды. Илһам киң күңелле, кешегә ярдәмчел, әлбәттә, иҗатта ярдәмчел (тормыш итү, көнкүрештә ул үзе ярдәмгә мохтаҗ). Шул ук вакытта ул шаян да, минем кебек үк уен-көлке ярата. Шаярабыз, төрле шуклыклар, көлкеләр китереп чыгарабыз. Их, еллар, еллар...

**Әлфия АФЗАЛОВА,**
Татарстанның халык артисты.

●

### «Агу» чыгарган җирдә

Урта Азия шәһәрләрендә гастрольдә вакытта (1967 ел) Илһам Шакир группасын Кыргыз филармониясе автобусында йөртәләр. Бик күп шәһәрләрдә булганнан соң, чират Хәйдәркан шәһәренә килеп җитә. Автобус шоферы тарткалаша башлый:

— Мин Хәйдәрканга бармыйм. Ул әллә кайда, тау өстендә, минем тормозлар начар. Аннан соң, сезнең концертка анда кеше дә килмәячәк. Анда күп булса биш-алты татар бардыр.

Илһам шофердан сорый:

— Ул шәһәрдә халык нәрсә эшли соң? — ди.

— Таудан терекөмеш чыгаралар,— ди җегет.

Шуннан Илһам, кызып китеп, шоферны аты-юлы белән сүгә башлый.

— Агу чыгара торган җирдә татардан башка кем эшләсен! Тиз бул, алдакчы, кабыз машинаңны, киттек! — ди.

Автобус таулар арасына юл ала. Концерт башланырга ике сәгать алдан менеп җитәләр болар тау башына. Хәйдәркан шәһәренә. Кечкенә генә бер шәһәрчек, бер мәктәп, клуб һәм терекөмеш, сөрмә заводы. Бердәнбер клуб янына, сабан туена җыелган кебек, татар халкы килгән. Болары — билетсыз калганнары. Алар гармуннар, сый-хөрмәт белән артистларны каршы алалар.

— Илһам ага, зинһар, артык билет саттыр. Ату да күрә алмый калабыз, җырыңны ишетә алмый калабыз! — дип, халык җылый-җылый ялына.

— Нишлим соң, агайнеләр! — ди Илһам.— Клубыгыз дүрт йөз генә урынлы бит.

— Басып торырбыз, Илһам туган, чыдарбыз, идәнгә утырырбыз! — дигәч, Илһам, сыйдыра алган кадәр, халыкны кертергә куша.

Куанычтан халык Илһамны, шоферны, башка артистларны кочаклап, сөеп рәхмәт әйтәләр, чирәмгә җәелгән дәстарханга — табынга дәшәләр.

— Илһам ага, — ди бер салмышрак татар. — Без синең җырларыңнан башка яши алмыйбыз. Утыз елга бер генә татар концертының да монда килгәне юк иде. Кайлардан килеп чыктыгыз сез монда?

Илһам Шакир:

— Соң, шулай бик сагынгач, җырымны да бик яраткач, нигә минем концертка исерек килеш килдең, туган? — дип ачулана башлагач, салмыш агай, күз яшьләре белән җылап, болай ди:

— И Илһам дус, Илһам дус, бәйрәм бит бүген, олы бәйрәм. Сине күрү бәйрәм түгелмени? Бәйрәмдә кем генә бераз тотмый калсын.

Икенчесе аңа кушыла:

— Тауларга качкан бу тәмугка ничекләр килеп чыктың син, Илһам кардәш? Бу бит төрмә-зиндан җире. Монда, бу җәһәннәмгә урыс, кыргыз артистлары да килергә курка. Агулы урын бит бу. Монда сиңа озак калырга ярамый...

Бу шәһәрдә иң күбесе татарлар икән. Җитәкче урыннарда Идел буеннан куылган немецлар. Шәһәрдә яшәүчеләрнең уртача гомере кырыктан узмый, ди. Һава тулы, ризык-су тулы терекөмеш-агу пары икән. Элек монда тоткыннарны эшләткәннәр, хәзер татарлар эшли.

— Алайса нигә бу агулы җирдә ятасыз? Кайтыгыз үзебезнең Татарстаныбызга! — ди Илһам.

— Һи, Илһам туган, — ди бер ир. — Монда акча күбрәк түлиләр шул.

Концерт башланыр алдыннан Илһам артистларга әйтеп куя:

— Күпме хикәя-шигырегез бар — сөйләгез, күпме көй беләсез — уйнагыз, нинчә биюегез бар — биегез! Рәхәтләнеп калсын бу халык!

Концерт башлана. Имчәк балалары белән яшь аналар, ярым исерек ирләр — зал дыкма-дык тыгызланып тула. Шуңа да карамастан, зал шулкадәр тыныч, тәртипле, һәр сүзне, һәр җырны игътибар белән йотып утыра. Илһамның моңа күңеле була һәм ул, гадәттә ике сәгать ярым җырласа да, бу юлы биш сәгать өзлексез җырлый. Халык кызык җирдә иркенләп көлә, моңлы хикәя, сагышлы җыр ишетсә, тыела алмыйча җылый. Аннан соң уч төбеннән ут чыкканчы кул чаба... Концерт таңгача дәвам итә. Ниһаять тәмамлана. Бөтен халык артистларны шәһәр читендәге күпергә чаклы озата бара. Буш автобус әкрен генә алдан бара. Артистлар, Илһам халык белән бергә атлый. Читтәнрәк караган кешеләр бу күренеш ниндидер бер олы кешенең күмү, матәм процессы дип уйларга мөмкиндер. Ләкин автобус буш... Халык җырлый, гармун-баян уйный, халык җылый.

— Тагын килегез, җаннарым! Онытмагыз безне! Без бит монда ятимнәр! Онытмагыз! — дип кычкыралар.

Илһам Шакир исә аларга:

— Туган якка кайтыгыз, гомерегезне монда әрәм итмәгез! — ди.

Артистлар автобуска керә. Автобус китеп бара. Барысының да күңеле тулган. Шулчак Илһам шоферга тыныч кына әйтеп куя:

— Их син, дус кеше! Нибары алты татар, дисең...

Еллар уза. КамАЗ төзелә башлагач, Илһам Чаллыга килә. Концерт беткәч, бер төркем тамашачы сәхнә артына, Илһам янына керә.

— Без Хәйдәрәкан шәһәрендә очрашкан идек. Сез килеп киткәч, халык җирседе, озак торып булмады. Җырың тартып кайтарды, рәхмәт сиңа, Илһамыбыз! — ди алар.

**БАТУЛЛА,**
язучы.

●

## Сибгат Хәким

### Мин юл сорыйм...

Халкым минем гомер буе читтә...
Читтә... һаман бәхет тартамы?
Чита... Чатта милиционер тора,

Ул да безнең Казан татары.
— Татарча җыр-пластинкалар юкмы?
Әлфияләр, Илһам Шакиров?..

Таң алдыннан Чита урамында
Сөйләшәбез икәү шау килеп...
Мин юл сорыйм,
Ул миннән җыр сорый...
Пластинкалар әллә мең минем,
Янда алар, җанда алар, җанның
Күзәнәге саен моң минем...

●

## Җырчылар җырчысы

Миңа, концертларны алып баручы буларак, Илһам белән егерме еллап сәхнәдә бергә эшләргә, иҗат итәргә туры килде. Ул беренче булып «Әниемә хат» дигән җыры белән зур сәхнәгә күтәрелде. Ул килгәч, безнең филармониядә татар җыры, татар моңы үзенең колачын җәйде. Илһам халыкка гына түгел, җырчыларга да җырчы булды. Аның моң мәктәбеннән күпләр сабак ала башладылар. Илһам җырчы гына түгел, артист буларак та, сәхнәдә кайчакларда юморист та булып китә, тапкыр сүзгә дә оста иде. Бервакыт шулай Мәскәүнең Колонналы залында концерт бирәбез. Җыр тынган арада бер мишәр агае сикереп торды да: «Иптәш Илһамов, ничава гына ерлыйсың икән, ну, гел татар да татар, ә син менә урысча җырла!» — ди бу.

— Абзый кеше,— ди Илһам.— Без бит бүген татар җырын тыңларга җыелдык, анысын белеп килгәнсездер шәт...

— Минем хатын марҗа, аның өчен җырла!

— Хатының марҗа икән, өйгә кайткач үзеңне урысча җырлатыр да, биетер дә.

Илһамның бу сүзеннән халык шау итеп көләргә тотынды.

Танылган баянчы Рамил Курамша күп еллар буена гастрольләргә йөрде. Илһам бик пөхтәлекне ярата торган кеше. Концертка соңга калган артистларны җене сөйми иде. Бервакыт, Әлмәт ягындамы икән, бер авылдан икенче авылга машина белән илтергә тиешләр, клуб янына иртән җыелдык, Курамша юк та юк, көтәбез. Илһам: «Әйдә, киттек!» — дип шоферны кузгатты. Курамша клубка каршы гына фатирга төшкән иде. Кузгалып маташканда күрәбез: баянын күтәреп чыгып килә бу. Әйдә утыртыйк, дибез. Илһам: «Баянын күтәрсен дә җәяү барсын, туктатма!» — диде. Шулай итеп, кузгалып киттек. Ә теге авылда концерт көндезге уникедә башлана, халык шыгрым тулы. Илһам бер әргәнче таптырып, шуңа кушылып, ә күп кенә җырларны болай, ялгызы җырлады.

Илһам Курамшага бер сүз әйтмәде. Ни хикмәт, оста баянчы Рамилебез шуннан соң гаҗәеп төгәл кешегә әйләнде дә куйды.

Илһам бөтен халәте белән зыялы шәхес. Аның әйткән фикерләре әле дә колагымда яңгырап тора: «Кайберәүләр монысы иске, монысы яңа җыр дип сөйлиләр. Чын җыр беркайчан да искерми, кайберәүләрнең җырга булган карашы гына искерә. Җыр — бөек сәнгать төре, аны халыктан алырга кирәк тә, халыкка үз йөрәгең аша кайтарып бирергә кирәк»...

**Фәйзи ЙОСЫПОВ,**
Татарстанның атказанган артисты.

●

## Нури Арслан

### Мәдхия

Илһам бирә икән кем Илһамга?
Шундый моңлы аның тавышы!
Халык белән тулган заллар тарта,
Киң кырларга җәелә тавышы.

Алып китә Идел буйларына,
Хәтерләтә ерак узганны.
Бөек язмыш җырчы уйларында:
Бәгырьләрне баскан тузанны

Юар өчен ләйсән булып ява,
Яшен булып балкый күкләрдә.
Илһам күле аңа зәңгәр һава,
Ул яшәргә өнди, күкрәргә!

Илһам җырлый, җырлар әсир кыла,
Рухландыра яшьне, картны да:
Нәфис татар моңы яңрап тора,—
Игелеккә күңел тартыла.

Җырчы Илһам кайдан илһам ала?—
Идел-йорттан, туган халкыннан.
Зур алкышлар һәр дәм юлдаш аңа—
Кайда барса, калмый артыннан!

●

## Илһам — моң ул!..

Гасырлар буена күп җәфалар күргән, милләт буларак эзәрлекләнгән, җир йөзенең һәр төбәгенә сибелеп яшәгән, үзенең бай тарихын, гореф-гадәтләрен, динен, телен, моңын югалту чигенә китереп җиткезелгән халкыбызның иң авыр елларында, 1950 елларда, сәнгатебез мәйданына килгән Илһам Шакиров — безгә табигать, Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән, җыры белән рухыбызны коткаручы илаһи зат ул. Илһам мәшһүр җырчыларыбыз Г. Сөләйманова, Р. Ваһапов, С. Садыйкова, З. Басыйровалардан эстафета итеп алган моңны тирәнәйтте, аңа яңа төсмерләр, бары тик үзенә генә хас төсмерләр бирде. Илһам моңы, нота итеп кәгазьгә яза башласаң, фиксациягә бирелмидер, ул моңнар гадәти миллизмнар, бормалар гына түгел, Илһам тавышы — тоташ моң ул!..

1950 елларда телебез, моңыбыз кысрыклануның соңгы чигенә килеп җиткән иде. Җырларыбыз мәйданында Леман, Ширман, Гиршман, Шапиро кебек «эшлекләләр», аларга ияргән, үзебезнең милләттән булган «җыр-музыка әһелләре», бу өлкәдә патшалык иткән җитәкчеләр: «Безгә моң кирәкми!.. Что такое моң?..» дип зур-зур киңәшмәләрдә, съездларда ачыктан-ачык безнең кадерле моңыбызга каршы көрәш алып барганда, җыр мәйданына яшь Илһам килеп, киң күкрәге белән бу афәткә каршы чыкты. Һәм җыр тирәсендә әвәрә килгән әлеге «эшлекле»ләрне, хәсрәт җырчыларны айнытып җибәрде. Илһам җыры моңыбызны савыктыра башлады һәм саклап калды. Илһамның көчле, мәһабәт тавышы, Тукаебыз әйткәнчә «чын безнеңчә милли, матур» итеп җырларга, моңлы итеп җырларга чакыручы набат булды.

Сарман якларындагы Илһам туып-үскән Яңа Бүләк авылы белән минем туган авылым Иске Теләнче арасы өч-дүрт чакрым гына. Без — якташлар. 1954 елда танышып, дуслашып киттек һәм минем җыр өлкәсенә килүем, иҗатымның күбрәк җырга багышланган булуы иң элек Илһам белән дуслыгыбызга бәйле. Ул елларда әле мин яңа гына яза башлаган яшь язучы идем. Үземнең иҗат юнәлешем кайсы жанрда булачагын әле анык белми идем. Җыр жанрына мине Илһам алып керде. Беренче шигырьләремнең берсе булган «Менәргә иде Урал таулларына» дигән бер генә строфалы дүрт юллыкны блокнотыма язып куйганмын да онытканмын. Шул дүрт юлны укып чыкты да Илһам: «Бу бит җыр сүзләре, син моңар өстәп тагын 2 строфа шигырь яз!» — диде. Һәм композитор Мансур Мозаффаровтан көй яздырырга вәгъдә итте. Берничә көн үтүгә, җыр әзер булды. Бу җыр зур дәрәҗәгә ирешә, озын гомерле, матур җыр булды. Мин Илһамга бик рәхмәтлемен, бурычлымын.

Соңгы елларда яшь композиторларыбыз, яшь җырчыларыбыз моңыбызга тагын игътибарсызлык күрсәтә башладылар. Күп кенә җырларыбыз музыка ягыннан да, шигъри яктан да сай, артык гади, заманча дигән модага ияреп язу аркасында, төссез, моңсыз. Җырларыбыз Илһам моңнарыннан тайпылмасын иде.

**Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА,**
язучы.

Моннан ун ел элек бөек җырчыбыз Илһам Шакировның 50 еллык юбилеен билгеләп үткән идек. Бәйрәм кичендә әдипләребезнең Илһам Шакировка багышлап язган шигырьләре, мәкаләләре, теләк-фикерләре тупланган кульязма китапны сәхнә уртасына чыгып, юбилярга тапшырдык. Халык гөрләтеп кул чапты, Илһамыбыз, моның үзе өчен иң зур бүләк икәнен искәртеп, рәхмәт әйтте...

Дөнья мәшәкатьләренә чумып, мин бу вакыйганы инде оныткан да идем. Моннан берничә ел элек Түбән Кама шәһәренә командировкага баргач, кунакханәдә шушы бердәнбер данәдәге кызыл тышлы кульязма китапны артист Рәшит Сабиров кулында күрдем. Бер кичкә генә биреп торуын сорагач, Рәшит әфәнде уңайсызланып кына болай диде: «Бик кыйммәтле, кадерле китап бит бу. Артист турында шигъри, әдәби энциклопедия! Монда шагыйрьләребезнең, язучыларыбызның Илһам абый турында язган алтын сүзләре тупланган... беркемгә дә бирмәскә кушты».

Бу җыентыкны Илһам Шакиров юбилеена дип махсус үзем туплап һәм төпләп, сәхнәдә кулына үзем тапшырганны әйткәч кенә, ул аны миңа бер төнгә биреп торырга булды.

Еллар үтеп, инде бөтенләй диярлек онытылган бу кульязма-китапны яңадан укып чыккач, төне буе йоклый алмадым. Татар халкы үзенең илаһи затларын хөрмәт итү, аларга кадер-хөрмәт күрсәтү гадәтләрен бөтенләй үк онытып бетермәгән икән әле! Әнә бит, милләтебезнең былбылы — бер Илһам Шакиров турында гына күпме җырлар, такмаклар чыгарган, шигырьләр, хикәяләр язган... Һәм минем әлеге бердәнбер данәдә генә булган шушы кадерле китапны һәммә милләттәшләремә дә җиткерәсем, укытасым килде. Әйдә, татарның таркаулык, вак көнчелек, манкортлык кебек яман гадәтләрен генә түгел, ә менә шушындый олы җанлылык, кече күңеллелек, милләт каһарманнарына кадер-хөрмәт күрсәтү кебек затлы сыйфатларын да ил-кавем ишетеп, күреп торсын әле!..

Бу кульязма китап дөньяга килгәннән соң инде байтак вакыт узды. Быел без үзебезнең яраткан җырчыбыз юбилеен янә дә билгеләп үтәрбез. Бәйрәм кичәсенә әлеге китапны тагын да тулыландыра төшеп, һәммәбезгә дә җитәрлек итеп нәшрияттa бастырып тарату теләге туды миндә.

Шушы ниятне тормышка ашыру җәһәтеннән мин Илһам Шакировка багышланган шигырьләр, чәчмә әсәрләр, истәлекләр, яисә фикер-теләкләрнең һәммәсен җибәрүләрен үтенеп республика радиосы һәм газеталары аша халыкка мөрәҗәгать иттем.

Илһам китабын дөньяга чыгаруда матди ярдәм күрсәтүчеләргә дә бик рәхмәтлебез. Шушы көннәрдә сезнең кулыгызга халкыбыз үзе асыл улы Илһамга багышлап нәшер иткән китап килеп керер. Чыннан да, юкка гына: «Кешегә кадер-хөрмәт күрсәтә белгәннәр генә үзләре дә кадер-хөрмәткә лаек»,— димәгән бит борынгылар.

**Разил ВӘЛИЕВ,**
язучы.

●

## Нәби Дәүли

### Җырчыга шагыйрь сүзе

Туган җирең — Сарман ягы,
Дөньяның тын почмагында.
Бөтен Ватан сагышлары
Синең татар җырларыңда.

Нинди авыл, шәһәрләрне
Узмадың син юлларыңда.
Татарстан чәчәкләрен
Йөртәсең җырларыңда.

Тыңлый сине Урал, Себер,
Казах тыңлый кырларында.

Таулар үтеп, сулар кичеп,
Дуслык бара җырларында.

Кемнәрнеңдер аһ-зарлары
Синең тавыш чыңлавында.
Бәхет белән куандырып
Шатлык туа җырларыңда.

Туган илгә чын мәхәббәт
Яши синең уйларыңда.
Илһам дигән исеменә
Лаеклы син җырларыңда.

Гади сүзне син җыр иттең
Йөрәгеңнең кылларында.
Шагыйрь йөри синең белән,
Дустың булып җырларыңда.

●

## Утлы күмер кала

Табигатьнең шундый бөек кодрәте барлыгын мин шул елларда таныдым. Юк, учакта ут тәмам сүнеп бетми икән, нинди каты давылларда да кайдадыр утлы күмер кала, аны большевистик гарасат сүндереп, мәкерле ленинчы тәгълимат күмеп бетерә алмый икән. Юк! Учак уты бирешми. Ул саклана белә, көчен җуймый һәм нәкъ кирәкле мизгелләрдә генә дөрләп кабына ала...

Күз алдына китерегез, моннан утыз еллар элек нефтьчеләр мәркәзе булырга әзерләнгән Әлмәт шәһәрен. Апрель азаклары. Күктә тулган ай. Өй түбәләренә тияр-тимәс кенә, җир өстенә сагышлы көмеш авазлар түгеп, киек казлар оча!.. Ул чактагы Әлмәт язы урамнарын белсәгез сез!.. Кая борылма, тездән лай, урамнарда машиналар артыннан сызылып сыек пычрак кала. Дәүләт оешмалары алдында һәр җирдә тимер кыргычлар, су тутырылган тимер ялгашлар тора. Тездән лайны ерып-ерып киләсең дә резин итекләреңне юасың... Мәктәп болдырларында йөзәрләгән аяк киемнәрен күреп имәнеп китәсең...

Мәдәният сараенда Илһам Шакиров концерты. Җырчының даны шулай бөек, ерак-еракларга таралган, шушы сазлы урамнарны үтеп, кесә фонарьлары белән юл яктыртып, бер-берсенә дәрт-көч биреп, концертка йөзәрләгән әлмәтлеләр җыелган. Тормыш бер чакта да җиңел түгел, нефтьче хезмәте дә авыр, мәшәкатьле... Кемнәр бу авыр торбаларны кулдан-кулга күчереп йөрткән, бетон блоклар, баганалар күчергән, канау казыган әлмәтлеләр Илһам Шакировның моң диңгезенә кереп чумганнар. Сәхнәдә «Кара урман» агыла... «Әниемә хат» яңгырый... «Көзге ачы җилләрдә» уйнап ала. «Уел» башлануга, күпләрнең күзләренә кайнар яшь килеп бөялә. Һәрбер җыр йөрәкләрне милләт белән, учакта җемелдәшеп яткан күмер чаткылары белән тоташтыра. Залда басып торучылар да күп, ишек-тәрәзәләргә адәмнәр килеп бөялгән, җырчыны сәхнәгә кат-кат чакыралар. Берәүнең дә бу кичтән аерыласы, бәхет диңгезеннән чыгасы килми, зал берләшә, әлмәтлеләр бер сулыш белән сулыйлар — аларның шушы кадәр Бердәм, Тату, Бөек булганнары юк иде...

Менә концерт тәмам... Халык ишелеп бәхет диңгезеннән караңгы, дымлы, суык, лайлы урамнарга тарала. Ләкин алар хәзер бөтенләй үзгә халык, дөнья караңгылыгыннан биегәйгән, күңелләр яп-якты, сүзләр түгәрәк, алар үзгәргәннәр. Көннәр буе ят телдә сөйләгән радио-телевизорларга күнеккән, эштә әдәп саклап, арадагы сыңар урыс хакына вата-җимерә урысча сөйләшеп йөрергә мәҗбүр ителгән кешеләр хәзер үзгә — алар ТАТАРЛАР. Ах, татар булуларын нигә алар шулай сирәк тоялар? Әйе, алар бу кичтә бөтенләй бүтән кешеләр, алар баеп кайтып баралар, көчәеп. Әле өйләргә таралышкач та алар дөнья мәшәкатьләрен онытып торалар, өйләрендә, түрләрне яктыртып, өстәл тирәли утырышалар да рәхәтләнеп татарча куе чәй эчәләр. Бер-берсенә ягымлы, кадерле сүзләр әйтәләр. Нигә алай? Ни булды? Бәлки, бик күпләр ни булганын төгәл генә сөйләп тә бирә алмаслар, әмма алар үзгәрешне сизәләр, аларның шушы бәхетле мизгелне озаккарак сузасы килә. Иртә таңнан нинди авыр эшләр көткәнен белгән хәлдә, алар йокларга ятырга ашыкмыйлар.

Кем уятты аларның җаннарын? Кем баетты изелгән, боек татарны? Кем ул бөек тылсымчы? Ул — Илһам Шакиров. Табигатьнең серле баласы, тыңдаучысез олуг тылсымчы. Илһам хакында соңгы елларда күп язылды, аның хакында китаплар басылды. Әмма бөек җырчыбызның кылган гамәлләренең олылыгын без бүген — телебез татарча ачылырга торганда, караңгы офыклар артында якты офыгыбыз да җемелдәгәндә аермачык әйтергә тиешбез. Әгәр без бүген, егерменче гасыр ишегеп ябарга җыенганда, татар җаны әзме-күпме исән калган дип расларга телибез икән, без гасыр дәвамында татарны милләт итеп саклап калырга омтылган бөекләр турында тел яшермичә сөйлик инде. Булган алар, тарихта милләт эзен сакларга тырышучы олуг затлар, булган. Минемчә, аларның иң олысы һәм иң бөеге — Илһам Шакиров.

**Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ,**
язучы.

●

## Туган тел сакчысы

Халкыбызның мәшһүр улы, милләтебезнең йөзек кашы вә визит карточкасы, барлык мөселман дөньясының, төрки җиһанның җыр сәнгате өлкәсендәге рухи ае вә кояшы Илһам Шакиров алдында һәрбер татар кешесе, бөтен төрки-мөселман дөньясы бурычлы. Мәңге бурычлы. Без «татар» сүзен әйтергә, татар түбәтәен кулыбызга алырга куркып, татарлыгыбызны танырга өркеп йөргән заманнарда да Илһам Шакиров, татар түбәтәйле башын горур тотып, сәхнәләр түреннән, киң мәйданнарда «Туган тел»не җырлап йөрде.

Татарны зурлау һәм күкләргә күтәрү өчен күпне кичерде. Үзе өчен күпне югалтты Илһам Шакиров, һәм без бу мәңгелек бурычыбызны, әҗеребезне түләргә тиешбез. Тиз арада аның барлык җырлары язылган грампластинкалар, кассеталар, видеофильмнар сатуга чыксын иде. Илһам Шакиров турында фотоальбом һәм китап дөнья күрсен! Кибетләрдә аның сурәте булган календарьлар, значоклар, вымпеллар сатылсын...

Бүген Илһам Шакиров шактый искергән фатирда яши. Читтән килгән милләттәшләрен кабул итәргә дә кыенсына. Тиз арада аның фатирына ремонт үткәрү фараздыр хөкүмәт исәбенә. Аның фатирын алтын белән йөгертсәң дә язык булмас. Аңа аерым йорт, бер дигән дача бирергә кирәк. Кирәк. Мин, Башкортостан татары, шуны таләп итәм.

Илһам Шакиров ялгыз яши. Һәм бүген дә Татар дәүләт филармониясендә җан асрар өчен эшләп йөри. Татар халкына, түрәләргә оят бит. Болай да аның гомере гел юлда, салкын клубларда үтте. Татар халкы! Бер Илһам Шакировынны, Әлфия Авзалованы зурлый алмыйсыңмыни? Илһам Шакиров күптән дәүләт тәэминатында яшәргә тиеш ләбаса.

Илһам Шакировның машинасы һәм шоферы булырга тиеш (Татарстан хөкүмәтенең Илһам абыйга җиңел машина алып бирергә хәле җитмәсә, үч итеп, Башкортостан татарлары, тиенләп булса да акча җыеп, үзебез алып бирербез).

Мин бары тик шуны гына беләм: ул оҗмахта яшәргә тиеш. Газапларны күп күрде инде ул. Җитәр. Илһам Шакиров — барлык татар дөнья-кавеменең сөекле җырчысы, рухи Президенты!

Илһам Шакировны барлык мөселман дөньясы зурлый. Аның юбилей кичәләре Уфада да, башка ил-төбәкләрдә дә үтәр. Башкортостан Президенты Мортаза Рәхимов Илһам Шакировка «Башкортостанның халык артисты» дигән мактаулы исем бирергә бурычлы. Илһам абый Уфаның почетлы гражданины да булырга тиеш әле. Инде мәшһүр җырчы «Рәсәй Федерациясенең халык артисты» исемен йөртә икән, бу хакта Рәсәй Президенты да уйланырга тиеш.

**Замир НИЗАМЕТДИНОВ,**
журналист, татар халкы Милли Мәҗлесе депутаты. Башкортостан.

●

## «Илһам Шакиров кайсы рота солдаты?»

Мин хезмәт итә торган частьта дистәгә якын татар егете булып, очрашкан вакытларыбызда авыз тутырып ана телебездә сөйләшә, кәеф килгәндә, җырлап та җибәрә торган идек. Күбрәк аулакта җырлыйбыз, чөнки

урыс, украин егетләре: «Сезнең көйләр гел бер төрле генә икән»,— дип ачуны китерәләр. Шулай инде, сукыр тавыкка бар да ярма. Телеине аңламагач соң, жырыңны ничек төшенсеннәр. Әле сирәк-мирәк Казан жырлый башлаганда да: «Нәрсәсе бар инде бу каля-валяның!» — дип, радиоалгычны борып куярга матапіучылар табыла. Бигрәк тә Гнеденков фамилияле шадра ефрейтор бәтрәкләнә. Ну, үзе дә беркөнне алды кирәген. Әлфия Афзалова белән Илһам Шакиров концерты вакытында радиоалгычны сүндерергә дип барганда Рәис Әхмәдиев дигән якташ тегенең изүеннән борып алып, пешекче Васяның озын саплы чүмече кадәр йодрыгын иснәтте үзенә. Шуннан бирле хассынучы күренми әле. Шулай да без, үзебез жырлау өчен, аулаграк урынны сайлыйбыз. Буш ара булдымы, жыелышып, керәшен Мишаның ат сараена ычкынабыз. Миша безне кояштай балкып каршылый, яңа чабылган хуш исле печән жәеп, утырырга урын әзерли. Әгерже районының Тугызбуй авылы егете Рифкать Садыйков чандыр иңбашына хромка каешын киеп ала: «Кәнсирт» башлана. Тик менә тамашачы берәү генә. Ул да булса «Васька» кушаматлы жирән алаша. Ул үзе кымтыр-кымтыр иттереп яшел сусыл печән ашый, үзе колакларын шомрайтып безнең жырлаганны тыңлый. Ара-тирә, алкышлаган сыман тоякларын шап-шоп иттереп, арата такталарына бәргәләп ала, борын тишекләрен киереп, «пуфр!» итеп пошкыргалап куя. Монысы үзенчә: «Афәрин!» дип әйтүедер инде, күрәсең.

Бервакыт шулай туган якларны сагынып, жырлашып утырганда яныбызда гына: «Привет, хлопцы!» — дигән тавышка сискәнеп куйдык. Күтәрелеп карасак, сарай ишеге төбендә хром итекләрен ялтыратып, подполковник Руденко басып тора. Жәһәт кенә сикерешеп торып, честь биреп, аны сәламләдек.

— Утырыгыз, утыр,— диде Руденко тамак төбеннән гөлдерәп чыккан украин шивәсе белән.— Әйдә, жырлагыз әле тагын, мин дә тыңлармын, әгәр каршы килмәсәгез...

Һе, каршы килеп кара! Командирның үтенече дә боерык дәрәжәсендә икәнен беләбез лә. Шуңа күрә, телибезме-юкмы, «кәнсиртебез»не дәвам итәргә туры килә.

Кара да гынай урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк үтәргә...

Руденко, чыдамы житеп, безне азаккача тыңлап торды да:

— Ни турында соң бу жыр? — дип сорады.

Без, бер-беребезне тулыландыра-тулыландыра жыр сүзләренең эчтәлеген сөйләп бирдек.

— Кхм! Бик төшенке жыр икән. Заманалар авыр дисезме? Кхм. Кем шулай язган аны?

— Кем язганын кем белгән,— диде Миша, подполковникның тел төбен аңлап.— Халык жыры бит ул. Борынгы жыр. Аның исеме дә «Иске кара урман» дип атала, әнәтерә.

— Алай икән...

Сүзгә Рәис кушылды:

— Һи, иптәш подполковник, сез аны Илһам Шакиров жырлавында тыңласагыз, аһ итәр идегез!

Руденко итеге кебек ялтырап торган козыреклы фуражкасын салып, пеләшен кашып алды:

— Ильгам Шакиров? Кайсы рота солдаты соң ул Ильгам Шакиров?

Шаян холыклы Шәйхул «пырх» итеп көлеп жибәрә язган иде, вакытында учы белән ерык авызын каплап өлгерде. Без дә елмаюларыбызны күрсәтмәскә тырыштык...

Кистереп әйтергә яраткан Рифкать монда да югалып калмады:

— Илһам ул безнең татарлар хезмәт итә торган һәр ротаның да солдаты, иптәш подполковник! — диде.

**Шамил МАННАП,**
шагыйрь.

●

## Мәхмүт Хөсәен

### Моң дәрьясы

Моң дәрьясына чумасың,
Илһам чыгып жырласа.

Былбыллар тыңлый көнләшеп,
Җирне сихри моң баса.

Моңнар сабантуенда ул —
Мәйдан тоткан каһарман.
Яшь җырчылар канат яра
Илһам алып аңардан.

Илһам Шакиров җырласа,
Күңел күге аллана.
Хәтер түрендә яктырып
Тукай, Сәйдәш җанлана.

●

## Хәтердә

Һич оныта алмыйм, 1948 елның бик матур бер көне иде. Урманнан атлы арбага утын төяп кайтып киләм. Юлым — Яңа Бүләк авылы аша узасы. Шул чак ишетәм: берәү арттан «Сарман» көен ифрат моңлы итеп җырлап килә. Карасам, бәләкәй арбага коры-сары төяп, шуны тартып кайтучы бер малай икән. Ул килеп җиткәч, дәштем: «Туктале, энекәш, синең исемең ничек? Уфаллаңны так та менеп утыр арбага»,— дим. «Мин Илһам исемле укучы. Әниемә ярдәм итәм. Ягарга утын алып кайтам,— диде.— Рәхмәт инде, абый, ни теләсәң, шуны җырлыйм»,— дип бик кәефләндерде. Яңа Бүләккә җиткәнче ул минем күңелне күтәреп җырлап кайтты. Хушлашканда мин аңа: «Син, Илһам, бик зур җырчы булырсың. Тырыш. Тырышкан ташка кадак кагар»,— дидем. Бәхеткә, минем бу юравым юш килде.

**Заһит ӘХМӘДИЕВ,**
Ватан сугышы ветераны (Азнакай).

●

## Нәкъ үз вакытында...

Татарның сөеклеләренә әверелгән Гөлсем Сөләйманова һәм Рәшит Ваһаповлардан соң җыр сәнгатендә тынлык булып алган иде. Бу — олы вакыйга туар алдыннан азга гына көттерү газабы булгандыр, мөгаен. Кинәт кенә җыр сәнгатенә мәйдан тотарга Илһам Шакиров килеп керде. Нәкъ менә татар җырына гына хас башкару манерасы, моңа кадәр кабатланмаган моң бизәкләре белән ул күңелләребезне тиз арада биләп алды. Дөнья халыклары арасында аерым урын тоткан борынгы җырларыбызның сулышын киңәйтте, аларга яңа тормыш бирде. Ул тышкы кыяфәте-рәвеше белән дә халыкны үзенә карата алды.

Хәтерлим әле, Илһам Шакировның зенитта чагы. Мөслимдә мин аның концертын карадым, җылап та, уйланып та, моңланып та тыңладым. Бөек талант иясенең тантанасы, триумфы иде бу! Ул чактагы халәтне беркайчан да кабатлап булмый. Гадәти концерт, гадәти җырчы гына түгел иде ул, һәр җыры — милли драма, һәр җырында — халыкның гасырлар сыйган тарихы... Искиткеч сәләт өстенә аңа Ходай эшчәнлек, зур тырышлык та биргән икән. СССРның татар яшәгән төбәкләрендә Илһам аһәңе барып җитмәгән нокта да калмагандыр. Ә күпме җырларга ул канат бирде, сирәк кенә булса да, үзе дә менә дигән көйләр язды.

Дөньяда соңга калган яисә вакытыннан алда туган талантлар була, Илһам исә нәкъ үз вакытында, татар халкының моңга сусаган мәлендә мәйданга килде.

**Марсель СӘЛИМҖАНОВ,**
Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия
театрының баш режиссеры.

●

## Без өчәү идек

Илле дүртенче ел микән, кара көзнең шомлы, яңгырлы бу көнендә музыка училищесында бер егет килеп керде. Телогрейкадан, кирза итектән, чәче машинка белән төбенәчә алынган.

— Нишләп соңга калып килдең, кайсы районнан? — дип сорыйбыз.

— Мин Сарман ягыннан. Армиягә китәргә әзерләнеп килгән идем. Өс-башым да шундый гына. Ильяс абый Әүхәдиев (училище директоры) армиядән калырга ярдәм итте. Монда җырларга өйрәнергә исәп. Дөресен әйткәндә... өйрәнәсе дә юк инде... бәләкәйдән үк җырлыйм...

Ул чакта мин өченче курста идем. Тиз генә гармун китертеп бер аудиториягә кердек. Мирсәет Яруллин да шунда иде. Яна танышыбыз бөтен училищены яңгыратып җырлап җибәрде. Җыелды бар студент.

Аның торыр җире дә юк иде, без аны шул училищеның подвалында яшәүче ятимә апаның бер бүлмәле фатирына урнаштырдык. Ел буе аның аягыннан шул кирза итек төшмәде. Менә шундый иде яшь Илһам Шакиров. Мирсәет Яруллин, мин, ул — өчәү бергә Кекин ашханәсенә йөрибез, беребезнең акча бетсә, икенчебездә кырып-себереп табыла...

Шәп, көчле, табигый тавышы булуга карамастан, Илһам үз өстендә көне-төне эшләде, һәрчак кулында китап, һәрчак пианино янында иде.

Илһам консерваториягә алданрак керде, аннары — без. Ул елларда инде стипендиягә генә карап ятмыйбыз, кесәгә акча тамгалый, кызларга да күз аткалыйбыз. Мин үзем хатыным — ул чактагы горур-чибәр Йолдыз белән, Илһам Нажия исемле җырчы кызга муеннан гашыйк. Кыланып китеп, рестораннарга да кергәлибез, күбрәк концертларга йөрибез, ул чорда Менжинский клубына, опера-балет театрына Исай Ширман дирижерлык иткән берләштерелгән симфоник оркестр концертларына барабыз. Анда Бах, Шуман, Глинка, Бетховен, Чайковский, Салих Сәйдәшев, Нәҗип Җиһанов әсәрләрен тыңлыйбыз. Олег Лундстрем житәкчелегендәге эстрада оркестры Черек күлнең аргы башындагы иске цирк бинасында концертлар бирә иде.

Ярлы булсак та яшь идек, мәхәббәтле идек. Илһам гына... Нажиясенең хыянәтен, ялганын бик авыр кичерде, гомерлек күңел ярасы алды...

Ул чактагы Илһам — тыйнак, хәлгә керә торган, игътибарлы егет иде. Хәзерге Илһам Шакиров та шундый.

**Фасил ӘХМӘТОВ,**
композитор

●

## Аның үзенчәлеге...

Язмыш татарга Муса Җәлил, Абдулла Алиш кебек батыр йөрәкле пәһлеваннарны бүләк иткән икән, нигә ул халыкның күңел түрендәге тирән моңын җыр белән әйтеп бирүче үзенә хас, үзенчәлекле талантлар белән дә куандырмасын икән! Илһам Шакиров — әнә шундый сирәк пәйда була торган ифрат үзенчәлекле зур талантларның берсе. Хикмәт аның сулышы иркен, тавышының тембры бик тә ягымлы булуында гына түгел. Дөрес, алары да бик кирәк һәм кадерле. Ләкин, минемчә, Илһам талантының асыл сыйфаты аның моңга ифрат та бай булуында. Әйтерсең, татарның барлык моң-зарын Илһам үз йөрәгенә җыйган. Аның тагын бер үзенчәлеге, минемчә, шундадыр ки, ул нәкъ татар ирләренә хас тавыш хуҗасы. Әгәр Гөлсем Сөләйманова татар хатын-кызлары тавышының үрнәге булса, Илһам — татар ирләре тавышының өлгесе. Ягъни, башка бер халык ирләре тавышына да охшамаган, нәкъ татар ирләренә генә хас үзенчәлекле тавыш белән җырлый ул.

Әгәр мин хата уйламасам, Илһам талантының көче, аның затлы яклары, барыннан да бигрәк, борынгы халык җырларын башкарганда сокландыра. Мәсәлән, «Иске карурман»ны җырлаганда Илһамга кушылып урман үзе дә җырлый кебек. Күңелдә шундый тәэсир кала.

Озын гомерле булсын, халыкны тагын шулай озак еллар дәвамында бәхетле итсен иде бу сөекле җырчыбыз, бөек талант иясе. Амин.

**Гомәр БӘШИРОВ,**
язучы.



**Әбрар Кәримуллин,**
Татарстан фәннәр академиясе академигы

# МИЛЛИ КИТАБЫБЫЗ ТАРИХЫ ТУРЫНДА

Мең еллык тарихы булган болгар-татар әдәбиятын, ерак гасырлардан килә торган милли телебезне мәктәпләрдә, югары уку йортларында аерым предмет буларак укытуларга, бу өлкәләрдә фәнни тикшеренүләр ясауга, фән кандидатлары, докторлары әзерләүгә без инде гадәти хәл, шулай булырга тиеш дип кенә карыйбыз. Чөнки телебез, әдәбиятыбыз — милләтебезнең рухи мирасы, милли аңыбыз, тарихи хәтеребезнең аерылгысыз өлеше. Милләтне милләт итеп тотучы, саклаучы башка көч, башка мираслар да бар. Мин бу яктан теге яки бу халыкның яшәеш тарихын, аның сәнгате, мәгърифәте, иҗтимагый фикер тарихын, төгәл һәм табигать фәннәре өлкәсендәге уңышларын да күздә тотам. Шул исәптән, халыкның ачыш һәм табышларын, өмет һәм хыялларын, теләк һәм югалтуларын теркәп барган, аның тарихи хәтере булган, халыкның азатлык һәм бәхет өчен көрәштә зур таянычы, ярдәмчесе, ышанычлы коралы булган милли китап, китапчылык тарихын да көн тәртибенә куярга вакыт дип саныйм.

Теге яки бу халыкта китап барлыкка килү — милләтнең культура дәрәҗәсен билгели торган иң көчле дәлилләрнең берсе, аның рухи дөньясында тоткан роле әдәбиятныкыннан һич тә ким, түбән түгел.

Китап барлыкка килүнең нигезе халыкның әлифбасы, кульязма китабы, мәктәп-мәдрәсәсе, уку-укытуга, белемгә булган олы ихтыяҗына барып тоташа. Әгәр халыкта мондый ихтыяҗлар юк икән, аңа китапны көчләп тә тагып булмый. Теге яки бу халыкта китап язу, китап басу барлыкка килгән икән, бу факторлар ул милләтнең һәм мәдәни, һәм матди яктан тиешле дәрәҗәдә өлгергәнлеге күрсәткече. Менә шуңа күрә дә теге яки бу халыкта китап барлыкка килү һәм аның үсеш тарихын өйрәнү — бу ул халыкның мәдәнияте, мәгърифәте, иҗтимагый фикер үсешенең тарихына барып тоташа, шуның чагылышы булып та тора.

Китап — ул халык тарихының көзгесе дә, хәтере дә. Әгәр халыкны китаптан мәхрүм итсәң, ул халык хәтерсез халыкка әйләнәчәк. Хәтере саегайган, хәтерен югалткан халыкның киләчәге дә юк, андый халык милләт буларак маңкортка гына әйләнә.

Цивилизация, халыклар, милләтләр тормышында китапның тоткан урынына галимнәр, әдипләр, философлар гомер буе югары бәя биреп килгәннәр. Үзен үзе хөрмәт иткән милләт, дәүләт язма һәм басма сүзен күз алмасы кебек саклаган, өйрәнгән, үстергән. Иң авыр шартларда да язма, басма сүз турында кайгыртып килгән, китап аңа ышанычлы ярдәмче, киңәшче, юлдаш булып калган.

Китаплы милләт — тарихлы милләт. Шул ук вакытта китап тарихыннан башка милләтнең яшәеш тарихын, аның әдәбияты, иҗтимагый, фәнни фикере

үсешен, аның кешелек дөньясы казанышларыннан хәбәрдарлеген, ан-белем дәрәҗәсен ачык билгеләү, тарихта тоткан урынын ачыклау да мөмкин түгел. Без моны татар халкы тарихын яктырту өлкәсендә дә ачык күрәбез.

70 нче елларга кадәр СССРда татар китабын, аның революциягә хәтле чорын өйрәнү тыелган өлкә булып килде. Менә шуңа күрә совет идеологлары татарларда 1917 елга хәтле китап басу булмаган дип такылдап тордылар, ә икенчеләре исә, революциягә хәтле татарлар Коръән, һәфтияк, догалыктан башка нәрсә басуны белмәгән, алар дөнья мәдәниятеннән артта калган, надан халык булган, дип күпләрнең башын бутап, алдап килделәр. Менә шундый шартларда мин үзлегемнән иске язулы татар китабы тарихын өйрәнүгә керешеп киттем. Бу теманы өйрәнү Институтның фәнни тикшерү планына кертелмәде. Курыктылар. Иске язулы татар китабын өйрәнү бернинди түләүсез, ял вакыты хисабына, яшерен рәвештә диярлек алып барылды. Дистәләгән еллар буе алып барган эзләнүләр, архивларда, китапханәләрдә актарынулар нәтиҗәсендә татар китабы үткәненең 1917 елга хәтле чоры төп баганалары торгызылды. Без хәзер татарларның бүтән төрки халыклардан элгәре хәрефләр җыеп китап басу эшенә керешүен ачтык. Әгәр 1917 елга хәтле Русиядәге бөтен төрки халыклар бергә 500—600 исемдә милли китап басырга ирешкән булса, без, татарлар, шул вакытка 15000 ләп исемдә милли китап чыгарганбыз. Китап басу (тиражы) буенча Русиядәге халыклар арасында урыслардан гына калышканбыз. Татар китабы үзенең эчтәлеге буенча универсаль, бөтен фәннәрне колачлый. Революциягә хәтле татар китабы репертуарында төп урынны мәктәпләр өчен төрле фәннәргә караган дәреслекләр, халык өчен фәнни-популяр әсәрләр алып торган. XX гасыр башында ел саен диярлек 200—250 матур әдәбият әсәрләре чыгып килгән. Татар теленә 1917 елга хәтле 200 ләп урыс язучысы әсәрләре тәрҗемә ителгән. Көнчыгышның бөек әдипләре, философлары Газәли, Әл-Кинди, Мәгарри, Фараби, Гомәр Хәйям, Дәһләви, Низами, Фирдәүси, Тафтазани, Рүдәкиләр татар укучыларына яхшы таныш булган. Европаның бөек классиклары Ж. Ж. Руссо, Һ. Һейне, Ф. Шиллер, Байрон, Г. Сенкевич, Г. Андерсоң, Ж. Верн, Бичер Стоу — дистәләгән язучыларның әсәрләре туган телебездә басылып чыккан. Фәнни популяр, матур әдәбият әсәрләре белән бергәттән аерым халыкларның тарихы, экономикасы, географиясе, философиясе, сәнгате буенча китаплар дөнья күргән. Татар укучысы физика, химия, биология, геометрия, астрономия, техника буенча чыккан басмалар аркылы үз телендә кешелек цивилизациясе казанышлары белән дә танышкан. Дәрес, Коръән, һәфтияк, дин тарихы буенча да китаплар аз басылмаган. Кыскасы, 1917 елга хәтле чыккан татар китабы үзенең эчтәлеге, универсальлеге белән дөньядагы алдынгы халыклар басма сүзеннән калышмаган.

Теге яки бу халыкның мәдәни өлгергәнлеге аның үз басма һәм язма сүзенә мөнәсәбәте белән дә билгеләнә. Мәдәни яктан алдынгы халыклар үзләренең һәр басма сүзен фәнни белешмәлекләргә терки, һәр басманы документ буларак та мәҗбүри данә итеп архивта саклау ягын да кайгырта. Менә шуңа күрә бу халыкларда китапны документ буларак саклау эше дә оештырылган, моның белән ул илләрнең махсус китапханәләре (Милли китапханәләр) шөгыльләнә, шул ук эшне китап палаталары да кабатлый.

Икенче яктан мондый халыкларда басма сүз үзе фәнни тикшерену предметы булып та тора. Ул гына түгел, бу халыкларда милли китап тарихы югары уку йортларында махсус фән булып та укытыла, урта мәктәпләрдә китап һәм китапханәләрдән файдалану буенча элементар белемнәр бирелә.

Кызганыч ки, татар милли китабының тарихы бүгенгә хәтле мәктәпләрдә түгел, хәтта вузларда да укытылмый. Милли китап тарихын өйрәнү, китап белгечләре әзерләү буенча бездә берни дә эшләнми, дисәң дә ялган булмас. Әрмән, әзәрбайҗан, латыш, эстон, үзбәк, казакъ (инде мин иске китаплы башка халыкларны искә алмыйм), грузиннарның язма һәм басма сүз тарихын өйрәнү буенча махсус фәнни-тикшерену институтлары бар. Бу халыкларның югары уку йортларында милли китап тарихы махсус фән булып укытыла. Сәнгать һәм мәдәният институтларында, университетларында милли китап тарихы буенча аерым кафедралар эшли. Китап белгечлеге буенча аспирантуралар ачылган, диссертацияләр яклауга керешкәннәр. Икенче төрле әйткәндә, китапчылык, милли китап тарихы ул халыкларда әдәбият, тарих кебек фәннәр булып гамәлгә кертелгәннәр: уку йортларында да, фәндә дә.

Югарыда искә алынган халыклар белән чагыштырганда, татар китабының бай тарихын өйрәнү, укыту, бу өлкәдә кадрлар хәзерләүнең башланмавы белән бүгенге көндә килешеп яшәү татар халкының киләчәге, аның милли тарихи аңын күтәрү, культурасын торгызу өчен эшләми. Бигрәк тә бүген татар халкы милли

азатлык, Татарстан мөстәкыйльлек өчен көрәш алып барган заманда мәдәниятебезнең аерылгысыз өлеше, аның горурлыгы, тарихи аңын тәрбияләүдә гаять әһәмиятле чара булган милли китабыбыз тарихын аякка бастыру аерата әһәмиятле икәнен аңларга тиештербез инде.

Бу өлкәдә башкарасы эшләр тау-тау. Иң беренче чиратта без милли китабыбызның эчтәлеген, аның таралу географиясен барларга, халкыбызның тарихында тоткан урынын билгеләргә тиештер. Югарыда әйтеп үткәнчә, милли китабыбызның революциягә хәтле чоры гына азмы-күпме аякка бастырыла башлаган иде. 1917 елдан соңгы татар китабы тарихын өйрәнү мәсьәләсенә без бирегә тукталып тормыйбыз. 1917 елга хәтле милли китабыбызның тулы тарихын тудыруга гына тукталабыз. (Басма, шрифтлар жыю юлы белән китап басуга хәтле яшәп килгән кульъязма китабыбыз тарихын өйрәнүнең торышы турында да монда сүз булмаячак. Бу үзе махсус өлкә, бу турыда татар археографлары үз сүзләрен бәлки әйтер).

Дөрес, басма сүз кульъязма китапның яңа шартлардагы дәвамы. Сакланып калган кульъязма мирасыбыз, кульъязма китаплар һәм аның традицияләре тиешле дәрәҗәдә ачыкланган, өйрәнелгән булуы, һичшиксез, басма китабыбызның барлыкка килүе, аның эчтәлегенең эволюциясен тирәнрәк ачыкларга, басма китап чыгаруның үзенчәлекләрен тирәнрәк ачарга ярдәм итәр иде, әлбәттә.

Инде әйтеп үтелгәнчә, иске язулы басма татар китабының әле бары үзәк юлы, тарихи кәүсәсе, аның географик ботаклары гына торгызылган. Бу әле милли китап тарихыбызның яфраксыз кәүсәсе генә. Милли китабыбызның яфраклары шаулап торган агач кебек тарихын булдыру өчен әле күп көч куярга кирәк. Бирегә менә шушы юнәлештә нинди тармакларны ачыклау, өйрәнү, торгызу, ниләр эшләргә кирәклеге турында кинрәк тукталып китү урынлыдыр.

Билгеле ки, китап басу эше белән типографияләр, литографияләр — басмаханәләр шөгыльләнә. Миңа билгеле материаллар буенча татар китабын басу белән Русиядә 1917 елга хәтле иллеләп басмаханә шөгыльләнгән. Аларның ун-унбише турында гына азмы-күпме мәгълүмат ачыкланды, калганнарының әле без нигездә исемнәрен, кайда эшләгәннәрен генә беләбез. Бу басмаханәләр кайда, кайчан, кем тарафыннан оештырылган, кайсы елларда эшләгән, нинди әсәрләр һәм күпме китап басылган, аның нәширләре кемнәр һәм нинди нәшриятлар булган, аларның татар китабы тарихында тоткан роле, мәгърифәтебезгә, мәдәниятебезгә керткән өлеше — менә боларны ачыкламыйча, өйрәнмичә без милли китабыбызның тулы тарихын тудыра алмыйбыз.

Күп кенә басмаханәләрнең хуҗалары үзләре үк нәширләр дә булган. Нәширлек белән шөгыльләнүче аерым нәшриятлар, аерым нәширләр дә булган. Аларның кайберләре аерым исем астында ширкәт төзеп эш йөрткән («Гасыр», «Милләт», «Файда», «Өмед», «Каләм», «Нур», «Мәгариф», «Акча», «Мәктәп» һәм башкалар), ә кайберләре аерым шәхесләр исемендәге ширкәтләр-нәшриятләр оештырган (Берадәрән Шәрәфләр, Кәримовлар, Хөсәеновлар һәм башкалар). Шулар өстенә күп кенә мәгърифәтчеләр, әдипләр, мөгаллимнәр, сәүдәгәрләр, дин әһелләре, галимнәр, табиплар, да китап бастыру эше белән шөгыльләнгән. Андый зыялылар арасында дистәләгән, йөзгә якын китап чыгарган затлар бар.

Урыс китабы тарихында азмы-күпме эз калдырган нәширләр һәм нәшриятләр турында монографияләр языла, диссертацияләр яклана. Ә без әле революциягә хәтле эшләгән нәшриятларның, күренекле нәширләрнең исемнәрен дә белеп бетермибез. Үзләренең фидаи хезмәтләре белән милли басма сүзне аякка бастырган, аны алдынгы халыклар китабы дәрәҗәсенә күтәргән, мәдәниятебез, мәгърифәтебез үсешенә зур өлеш керткән осталарның эшчәнлеге хәзерге көнгә хәтле китабыбыз тарихында ак тап булып кала бирә. Татар матбагалары, нәшир һәм нәшриятләр үткәнен өйрәнми, язмый торып, милли басма сүзебезнең тулы тарихын, мәдәниятебез өлкәсендә тоткан ролен күрми үтәбез, икенче төрле әйткәндә, культурабызның дәрәҗәсен танымауга, татар басма сүзенә карата аның дошманнары биргән бәягә юл куябыз.

Югарыда күрсәтелгән ике юнәлеш — татар милли китабы тарихын торгызуның төп нигезләре булып тора. Ләкин китап тарихы, китапчылык белеме күрсәтелгән бу ике юнәлеш белән генә чикләнми. Китап дигән могжиза ул рухи һәм матди казанышларның синтезы. Ул фән, сәясәт, әдәбият, сәнгать, ижтимагый фикер, икътисад — кешелек яшәешенең бөтен ягына тыгыз бәйләнгән. Шул ук вакытта аларның тарихы уңышлары һәм ялгышларының көзгесе дә, үсешне тизләтүче катализатор да.

Күз алдына китереп карагыз: әгәр кешеләр китап басуны уйлап тапмаган булса, без бүген нинди хәлдә булыр идек? Фән, мәгърифәт, эшләп чыгару,

икътисад хәзерге уңышларга ирешә алмаган булыр иде. Әйтик, кешеләр менә бүген китапсыз калса, цивилизация тәгәрмәче хәрәкәте гаять әкренәер иде.

Китап, басма сүз тарихы мәдәният ягыннан алдынгы халыкларда бөтен даирә, фәннәр белән тыгыз бәйләнешендә өйрәнелә. Әдәбият тарихы нигездә милли әдәбиятның төп юнәлешләрен ачыклау, рухи хәзинәбездә зур эз калдырган әдипләрнең иҗатын барлау белән чикләнә дияргә була. Әдәбият белгечләре теге яки бу авторның аерым әсәрләренә, аның иҗатына объектив бәя бирү өчен китап тарихына да таянырга мәҗбүр. Теге яки бу әдипнең танылуын, халыкка ни хәтле тирән үтеп керүен аның әсәрләренең ничә тапкыр, күпме тираж белән басылуыннан, башка телләргә тәрҗемә ителүеннән башка анализлау коры сүзгә кайтып калыр иде.

XIX йөз һәм XX йөз башында дөнья күргән татар язучыларының әсәрләре барысы да диярлек цензура тегермәне аркылы узган, «төзәтелгән», патша мәнфәгатьләре сагында торучы цензор белән «соавторлыкта» дөнья күргән.

Революциягә хәтле татар әдәбияты турындагы барлык хезмәтләр, аерым әдипләрнең иҗаты турында мәкалә һәм китаплар әнә шул цензура тегермәне аша үткән, аның «редакциясендә» чыккан басмалар текстына гына нигезләнгән. Цензура тегермәне аркылы үткән басмалар нигезендә генә революциягә хәтле татар әдәбиятының торышына, дәрәҗәсенә, эстетик фикернең торышына объектив бәя биреп булуы мөмкин түгел. Революциягә кадәрге татар әдәбиятын, аерым әдипләрнең иҗатын өйрәнүдә милли китап бирә торган фактларны эшкә җикмәү әнә шуна китерә дә. Бездә бит ичмасам бу мәсьәләгә караган бер генә хезмәт тә юк. Әйтик, «Патша цензурасы һәм татар матур әдәбияты» дигән тема да читтә кала бирә. Урыс әдәбияты тарихы буенча хезмәтләрдә хәтта аерым әдипләрнең аерым әсәрләре цензура тарихы буенча да монографияләр бар, урыс әдәбияты үсешендә патша цензурасы сәясәтенең нәрсәләргә китерүе дә махсус өйрәнелә.

Милли әдәбият дәреслекләргә кергән авторлар, аларның анда искә алынган әсәрләре белән генә чикләнми. Әгәр без, әйтик, XX йөз башы татар әдәбиятын хрестоматияләргә кергән 15—20 ләп исем белән генә сурәтлибез икән, аның тулы хәзинәсен күрсәтүдән ерак торачакбыз. Бу дәвердә аерым китап һәм вакытлы матбугат битләрендә шигырьләре, хикәяләре, драма, повесть, романнары басылган каләм тибрәтүчеләр саны 500 ләп санала. Белгечләребез әдәбиятның бу мохитен өйрәнми, күп очракта белми дә диярлек, ә китапчылык, китап белгечләре, библиография боларны барлый, туплый, терки һәм шуның аркасында милли әдәбиятның үсеше, таралуы, диапазоны, әдәбият дөньясының тулы картинасын тудырырга мөмкинлек бирә. Кыскасы, милли китап тарихыннан тыш милли әдәбиятның тулы күренешен ачып бирә алмый.

Милли китабыбыз тарихын торгызмый, аның репертуарын билгеләми, эчтәлеген ачыкламый торып, без халкыбызның мәгарифен, фәнни һәм иҗтимагый үсешен, милләтебезнең аң-белем дәрәҗәсен дөрес, объектив ачып биреп бетерә алмыйбыз. Совет чоры коммунистик идеологларының татарлар 1917 елга хәтле тоташ надан булган, яисә татарларда китап басу бөтенләй булмаган, булса да дини әсәрләр басудан узмаган, дигән «теорияләр» белән мәдәниятебез тарихын бозу, саташтыру әнә шуннан килә дә инде. Халкыбызның кешелек казанышларыннан хәбәрдәр булуы дәрәҗәсе, аның рухи дөньясы байлыгын реаль ачыклау өчен без милли китабыбыз тарихын төрле фәннәр буенча китаплар басуның торышы һәм аларның халык арасында таралу җәһәтеннән дә өйрәнергә тиешбез. Димәк, без татарларда физика, математика, химия, биология, геология, география, медицина, ветеринария, авыл хуҗалыгы, техник фәннәр буенча да китап басуыбызны барлау хаҗәт.

Дөрес, бездә татар һәм Татарстан тарихы буенча азмы-күпме китаплар язылды, диссертацияләр хәзерләнде. Аларның фәннилеген, объективлыгын карау монда безнең бурычка керми. Ләкин бу аз санлы хезмәтләр халкыбызның төрле чорларда тарихи аңы, аның үзгәреше, тарихыбызның ни дәрәҗәдә һәм нинди юнәлешләрдә өйрәнелүенә тулы җавап бирмиләр. Әгәр «Татарларда тарихи китаплар басу» темасына диссертацияләр язылса, икенче төрле әйткәндә, татар китабының бу өлкәдәге уңышлары махсус тикшерелсә, бу бездә халыкның тарихи аңы, аның дәрәҗәсе, милли тарихыбызның кайсы яклары һәм ни дәрәҗәдә өйрәнелүенә, киләчәктә нинди юнәлешләргә игътибарны арттыру кирәклегенә җавап бирер иде. Ә бит 1917 елга хәтле татар, төрки-татар, мөселман, Европа һәм гомумән дөнья халыклары тарихы буенча йөзләгән китаплар нәшер ителгән, дистәләгән тарихчы галимнәребез булган, башка телләрдән күп кенә тарихи әсәрләр тәрҗемә кылынган. Халкыбызның тормышы, мәгърифәте белән танышкан урыс һәм чит ил галимнәре юкка гына татарлар тарихларын гына түгел,

күрше һәм ерак илләр үткәнен дә шактый яхшы белә дип искә алып үтмәгән. Менә шуңа күрә татар китабы репертуарында тарихи әсәрләрне барлау, аларның басылу тарихын, тиражын, таралу даирәсен өйрәнү дә китапчылык фәненең актуаль мәсьәләләренә карый, тарихыбызны һәм аң үсешебезне өйрәнүдә фәнгә яңалыклар, ачышлар алып киләчәгенә шигем юк.

Мин шушы ук фикерне педагогия теориясе, тарихы һәм методикасы,халык педагогиясе буенча дөнья күргән татар китапларын өйрәнүгә карата да әйтер идем. Революциягә хәтле татар китабы репертуарында мәктәп-мәдрәсәләр өчен дәреслекләр, уку кулланмалары басу төп урынны алып торуын инде алда искәрттек. Бездә, әйтик, арифметика һәм геометрия буенча беренче китаплар кайчан чыккан, аларның эчтәлеге һәм кулланышы ничек үсә барган, авторлары кемнәр, нинди педагоглар, галимнәр булган — кыскасы, халкыбызда математик белем дәрәҗәсен, мәктәпләрдә бу фәнне укыту ни дәрәҗәдә булуын бу төр китаплар басу тарихыннан башка ачу мөмкин түгел. Шушы ук фикерне башка төгәл һәм гамәли фәннәр буенча (физика, химия, геология, география һ. б.) басылган дәреслекләргә һәм фәнни-популяр әдәбиятка карата да әйтергә кирәк.

Бездә тел һәм әдәбият буенча китап басу нинди тизлектә, нинди юнәлештә, нинди принципларда, нинди күләмдә алып барылган? Аларны кемнәр язган, кемнәр нәшер иткән, аларның кайсылары киңрәк танылган? Бу хезмәтләр нинди фәнни-методик нигезләрдә төзелгән? Нигә әле шушы сорауларга да җавап эзләмәскә?!

Бу өлкәдә бездә инде беренче адым да ясалды. Педагогия фәннәре кандидаты Ф. Ибраһимовның «Белем әлифбадан башлана» дигән хезмәте әнә шуның гүзәл үрнәге. Ә бит безнең дәреслекләр репертуары әлифбалардан гына тормый. Бу өлкәләргә караган татар китапларының тематикасы дистәләгән фәннәргә, предметларга карый бит.

Татар китабы репертуарында халыкның гореф-гадәте, дөньяга карашы, тормыш тәҗрибәсе, гаилә, тәрбия өлкәсенә мөнәсәбәтле әсәрләр дә аз түгел. Бу төр басмаларның тарихын китапчылык күзлегеннән тыш халыкның эстетик фикер тарихы, тәрбия, дәүләт һәм хокук, тагын башка җәһәтләрдән дә чыгып өйрәнү кирәк. Революциягә хәтле татар халкы бары тик дини кануннар буенча гына яшәгән дип язарга яраталар. Югыйсә, дөньяви хокук буенча да киталар аз булмаган. Татарларда юридик белем, дәүләт һәм хокук, дини канун һәм дөньяви законнар яшәешен дә бу өлкәдә чыккан китаплар тарихыннан башка дөрес бәяләү мөмкин түгел.

Татар китабына аерата хас булган бер фактор бар. Бу аның «күптеллеге». Урта гасырларның башында дөньяда иң югары мәдәниятле халыклардан булган гарәп культурасы аша безгә гарәп графикасы гына түгел, гарәп әдәбияты, фәне, фәлсәфәсе, ислам дине үтеп керде. Шул исәптән, бу бөек халыкның теле дә бездә җирлек тапты. Татар басма китабы барлыкка килү белән халыкта гасырлар буе кульязма булып таралган мөселман халыкларының язучы, философ, дин белгечләре, тарихчылары һәм башка галимнәре әсәрләре бездә нигездә гарәп телендә басылып килгән — гарәп теле аркылы халкыбыз шул мәдәниятнең җимешләрен үзләштергән. Гарәп теле барлык мөселман халыкларының фән теленә әйләнгән, гарәп булмаган мөселман халыклары тудырган, гарәп телендә язылган хезмәтләр дә болгар-татар укучысы арасында таралган. Шуңа күрә гарәп телендә язылган барлык әсәрләр дә гарәп культурасы һәйкәлләре дип санала алмый. Шул ук вакытта татар китабы репертуарында фарсы, төрек, чыгтай, казакъ, әзәрбайҗан һәм башка телләрдә чыккан, шул халыклар әдәбияты, мәдәнияте әсәрләре дә аз түгел. Татарлар тарафыннан ул әсәрләр кайсы телдә басылуына карамастан, барысы да татар милли китаплары булып тора. Чөнки аларны татар мәгърифәтчеләре, нәширләре бастырып чыгарган, алар татар укучысына адресланган һәм татар мәдәниятенә, мәгарифенә хезмәт иткәннәр. Татар китабы репертуарында бу телләрдә китаплар басу нинди күләмнәрдә барган, алар милләтебезгә нәрсә алып килгән — бу мәсьәләләр турында бернинди тикшеренүләр алып барылганы юк.

Менә шуңа күрә «Гарәп телле татар басмалары», «Фарсы телле татар китаплары», «Төрек телле татар китаплары» һәм башка телле татар басмалары тарихы буенча монографик планда тикшеренүләргә керешергә кирәк. Татар халкы мәдәнияте тарихында гарәп, фарсы, төрек, казакъ һәм башка халыкларның әсәрләрен нәшер итү барышы, аның репертуары, эчтәлеге, халык арасында таралу дәрәҗәсе, тоткан урынын ачыкламыйча татар мәдәнияте, иҗтимагый, эстетик фикер тарихын объектив сурәтләү авыр булачак. Шул ук вакытта нәширләребезнең исламның кануни әсәрләрен басу тарихы да аерым тикшеренүләрне сорый.

Болар белән беррәттән мин татар телендә дөнья күргән урыс әдәбияты, урыс галимнәре, педагоглары төзегән дәреслекләр, фәнни-популяр хезмәтләр басылу тарихы да махсус өйрәнелергә тиеш дип саныйм. Ул гына түгел, татар басма китабы репертуарында гарәп, фарсы, инглиз, немец, итальян, кытай, француз, төрек һәм башка халыклар әдәбияты, фәне әсәрләрен тәржемә итеп басу һәм аларның безнең халык арасында таралуын үсешебезгә керткән өлешен өйрәнү дә татар китап тарихының актуаль бурычларыннан дип саныйм.

Революциягә хәтле татар китабы тарихын өйрәнү бурычлары өстә карап үтелгән темалар, проблемалар белән генә чикләнми. Татар басма сүзенең үсү юлларын, аның репертуары үзенчәлеген, күләмен китап цензурасы тарихыннан тыш күз алдына китерү авыр. Татар китабы өстеннән «тәүге» һәм «җәза» цензурасы гына түгел, сәяси һәм христиан миссионерлары цензурасы да булган. Рәсми патша цензурасы киртәләрен үтеп дөнья күргән татар китабын жандармерия органнары һәм христиан миссионерлары да күзәтеп торган, инде дөнья күргән күп кенә китаплар өстеннән әләк язып, аларга арестлар салуга ирешкәннәр. Татар китабы өстеннән булган бу төрле цензура һәм эзәрлекләүләрне белми, өйрәнми торып, аларның татар китабының гомуми үсеше һәм китапның эчтәлегенә китергән зыяннарны ачыкламыйча  татар басма сүзе тарихын өйрәнү, аңа бәя бирү бер яклы гына булыр иде. Татар китабы цензурасы ул шул ук вакытта царизмның татар милләтенә каршы алып барган милли, социаль, рухи изү буенча торган сәясәтенең көзгесе дә.

Татар басма китабы үзеннән үзе барлыкка килмәгән. Аны оештыру өчен безнең бабаларыбызга төрле киртәләр, төрле тыюларны үтәргә туры килгән. Русиядә урыслар һәм христиан динендәге бүтән халыклар өчен типографияләр ачарга рөхсәт ителгән булса, татарлар, мөселман халыклар өчен бу эшне оештыру тыелган була. Хәреф җыеп китап бастырырга рөхсәт сорап татар мәгърифәтчеләре, зыялылары бер гасырга якын патшага «прушениеләр» язганнар, пайтәхет юлын таптаганнар. Татар халкының мәгърифәте өчен янып йөргән бу фидаи бөек затлар кемнәр булган соң? Инде китап басарга рөхсәт алуга ирешкәннән соң гасырдан артык дәвердә, революциягә хәтле авыр елларда күп хезмәт һәм зур чыгымнар сорый торган бу изге эш татар басма китабына нигез салу, царизм шартларында басмаханәләр ачу, китаплар чыгару, тарату милләтне китап аша белем, мәгърифәт, дөнья мәдәнияте белән таныштыруга кемнәр юллар ачкан?

Басма, язма сүзгә хөрмәтле булган халыклар үзләренең милли китап өлкәсендә эшләгән барлык күренекле китапчыларын барлый, аларның тормышын, эшчәнлеген, милли культураны үстерүдә тоткан урыннарын өйрәнеп, монографияләр язалар, андый халыкларда «китап эшлеклеләре» сериясендә хезмәтләр чыгып тора. Ни өчен соң без үзебезнең бу китапчыларыбызның эшчәнлеген өйрәнмибез? Татар басма китабының пионерлары булган Габделгазиз Бурашов, Хәмзә Мамышев, Гали Рәхмәтуллин, Корбангали Исхаков, Йосыф Апанаевларның эшчәнлеген генә түгел, исемнәрен дә белмибез.

Беренче урыс китабын басуны оештырган Иван Федоров турында дистәләгән монографияләр, меңләгән хезмәтләр язылган, һәйкәлләр куелган. Беренче белорус китапчысы Скорина исеме дә бөтен дөньяга билгеле. Казакъ, эстон, латыш, литва китабына нигез салучы, башлап җибәргән китапчылар турында бу халыклар инде әллә кайчан монографияләр чыгардылар.

Мөселман халыклар арасында беренче булып китап басуга керешкән, революциягә хәтле сан ягыннан төрки халыклар арасында иң күп китап чыгаруга ирешкән бай тарихлы китабыбызны кем гамәлгә куйган, үстергән кешеләр арасында исемнәре тарихка алтын хәрефләр белән язылырга тиешле затлар — сында исемнәре тарихка алтын хәрефләр белән язылырга тиешле затлар — йөзләгән зыялыларыбыз бар. Бу — бертуган Кәримовлар, бертуган Әхмәдуллиннар, бу — Фатих Кәрими, Мәхмүт Мәрҗани, Риза Фәхретдинов, Галимҗан Баруди, Мөхәммәт Идрисов, Әхмәт-Гәрәй Хәсәни, Рәхимҗан Сәгыйтовлар...

Татар китабы үсешенә зур өлеш керткән китапчылар арасында башка милләт кешеләре дә булган, бу — И. Харитонов, Ермолаева, Л. Шевиц, Н. Катанов, Коковиннар һәм башкалар. Аларның исемнәре татар китабы тарихында тиешле бәя һәм тиешле урыннарын табарга тиештер бит.

Китап басуның төрле ысуллары бар. Бездә хәреф җыеп китап басу да, ташбасма һәм агач басма ысулы белән китап басу ысуллары да киң кулланылган. Аларның татар китабы үсешендә тоткан урынын өйрәнү, милли полиграфиябез тарихын торгызу да китап белеме, тарихына барып тоташа. Китап басу ысуллары, аны камилләштерү, китап басуның экономиясенә барып тоташа. Китапның үзкыйммәтен, тиражын, полиграфиясен, сату шартларын өйрәнү дә әһәмиятле.

Китапның халыкка барып житүе, киң таралуы китапның бәясе белән дә бәйләнгән бит. Аның тиражы, басма саннарының күплеге бәя белән генә түгел, халыкның укый-яза белү дәрәҗәсе белән дә бәйләнгән. Әгәр XX йөз башында татарлар ел саен 400, 500 йөз исемдә өчәр миллионга якын тираж белән китап басып килгәннәр икән, ул китаплар бер вакытта да келәтләрдә тузан жыеп ятмаган икән, моның сәбәпләре китапның сату бәясе, халыкның китапка ихтыяҗының зурлыгына барып тоташа. Әгәр революциягә хәтле татарларда укый-яза белүнең ни дәрәҗәдә торуын билгеләргә кирәксә, аны ул халык чыгарган китапларның саны һәм тиражы буенча да үлчәп булыр иде. Җан башына чыгару буенча татар китабы Русиядә урыс китабыннан калышмаган дияргә мөмкин.

Китап тарихы үз чиратында китапны бизәү сәнгате, шрифтлар эволюциясе һәм аның төрләре, полиграфия базасы, китап басу кадрлары әзерләү мәсьәләләрен дә эченә ала. Татарларда китап сәнгате, китапчы рәссамнар, татар китабының төрләре, типологиясе, серияләре тарихы да китап тарихына карый. Димәк, бу яктан китап тарихын өйрәнүдә сәнгать белгечләре, хәтта техника, редакцион эшләрне өйрәнүче белгечләр дә читтә кала алмый.

Бездән ике йөз елга якын соңга калып китап басу эшенә керешкән үзбәк, казакъ, әзәрбайжан, молдаван һәм башка халыклар милли китаплары тарихы буенча йөзләгән монографияләр басып чыгардылар, басма сүзләре тарихын күп яктан өйрәнеп киләләр.

Татар милли китабы тарихын өйрәнү буенча югарыда искә алынган, әле кул да тимәгән темалардан башка бурычлар да бар. Алар арасында иң актуальләрнең берсе — иске язулы татар китабының тулы репертуарын барлау, тасвирлау, аның аннотацияләнгән фәнни, җыелма күрсәткечен, документаль каталогын төзү һәм аны басып чыгарып укучыларга җиткерү.

Латин, аның артыннан урыс графикасына күчләп күчерү нәтиҗәсендә татар-гарәп графикасында ике йөз елдан артык басылган татар китаплары реакцион басмалар дип игълан ителде, аларны китапханәләрдән, шул исәптән, элек Ленин исемен йөрткән Татарстан Республика китапханәсеннән дә җыеп алып юк иттеләр. Патша заманыннан башлап мәҗбүри рәвештә мәңгегә сакланырга дип җибәрелгән Санкт-Петербург публик китапханәсендә, элек Румянцев музее, хәзер Русия Милли китапханәсендәге татар китаплары тулы түгел булып чыкты. Мәҗбүри рәвештә бирегә җибәрелә торган татар китапларын гомумән каталоглаштырмаганнар, келәттә тартмалар өеп куйган кебек өеп куйганнар. Соңыннан бу китапларны тасвирлау оештырылгач, шушы процесста аларның күбесен «актуаль түгел, кирәк түгел» дип юкка чыгарганнар. Татар басмалары XVIII гасырның урталарыннан Русия фәннәр академиясе китапханәсенә мәҗбүри рәвештә җибәрелә башлый. XX гасырның 60 елларына татар китапларының иң баерак тупланган җыелмасы менә шушы китапханәдә саклана иде. 60 елларда бу китапханәдәге барлык татар китапларын таратып бетерделәр: бер өлешен юкка чыгардылар, бер өлешен төрле төрки республикаларга өләштеләр, бер өлешен чит илләргә җибәрү өчен китап алмашу фондына тапшырдылар. Хәзерге вакытта иске язулы татар китаплары азмы-күпме дәрәҗәдә әнә шул ике китапханәдә, Казан университеты китапханәсендә һәм Башкортстан милли китапханәсендә саклана. Бу китапханәләрдә революциягә хәтле чыккан татар китабының 55—60 проценты саклана дияргә була. Хәзерге көн укучысы шуңа күрә революциягә хәтле чыккан барлык басмаларны бу китапханәләрдә таба алмый. Шуның өстенә бер-ике данәдә генә сакланган теге яки бу китапны эзләп табу өчен әнә шул шәһәрләргә барырга, махсус рөхсәт алып, зур чыгымнар ясап эзләргә туры килә.

Революциягә хәтле чыккан татар китапларының фаҗигале язмышы, аның сакланып калган өлешенең киң катлау укучыларга хәреф киртәсе артында булуын да искә алып, аларның тулы, фәнни, аннотацияләнгән, хәзерге язу графикасына күчереп тасвирланган каталогын төзү татар мәдәнияте, фәне, мәгърифәте, тарихы өчен ни хәтле әһәмиятле икәнен аңлау өчен Сократ башы кирәк түгел. Татар китабының мондый җыелма каталогын төзү өчен инде беренче зур эш эшләнгән. Бу юлларның авторы Казан, Мәскәү, Петербург архивларында саклануччы патша цензорларының архивларын тикшереп, теге яки бу китапны дөньяга чыгаруга рөхсәт биргән язуларны, төрле-төрле исемлекләр, документларны өйрәнеп, революциягә хәтле патша цензора рөхсәтләре белән дөнья күргән барлык китапларны барлап чыкты, картотекаларга салды. Шул уңай белән китапның үзендә күрсәтелмәгән тиражларын да ачыклады. Күрсәтелгән китапханәләрдә сакланмаган тагын нинди татар китаплары булуын менә шушы картотекалар буенча ачыклый алачакбыз һәм аларны киләчәктә чит илләрдәге китапханәләрдән дә барлаячак-

быз. Безнең мәгълүматлар буенча татар китаплары Финляндиянең Һельсинки, Төркиянең Истанбул, Австриянең Вена университетлары китапханәләрендә дә саклануы билгеле.

Иске язулы татар басма китабының җыелма, тулы фәнни каталогын төзү эшенә керешүне мин моннан ике дистә ел элек күтәреп чыккан идем. Ләкин Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында да, башка җирләрдә дә «бу бик кирәк эш» дип әйтүдән тыш бернинди чара күрергә теләмәделәр. Инде СССР дигән канлы концлагерь таркалып, Татарстан азмы-күпме коллыктан чыгу юлында беренче адымнарны ясый башлагач, безнең Ленин китапханәбез Татарстанның Милли китапханәсенә әйләнде. Ул югары категориягә күчте. Статусы шулай күтәрелү бездә басма сүзебезгә булган игътибарны да арттырды, югалып бара торган басмаларыбызны барлауга, милли китап фондын тулыландыруга, аны өйрәнүгә мөмкинлекләрне киңәйтә башлады. Дистә еллар буенча ТӘТИ, Казан университеты, Казан китапханә институты, Татарстан Мәдәният министрлыгы үгисетеп килгән бу эшне гамәлгә кую мәсьәләсен Татарстан Милли китапханәсе директоры Р. Вәлиев аякка бастыру эшенә керешге. Бирелә иске татар китапларын барлау, җыю, саклау, пропагандалау эшенең бөтен әһәмиятен аңлап, бу эшкә гомум милләт күзлегеннән карап, иске язулы татар китапларының җыелма фәнни каталогын төзү эшенә керешү буенча беренче адымнар ясалды. Хәзер Милли китапханә каршында ике-өч фәнни хезмәткәр шушы эшкә тотынды. Дөрес, алар бу эш белән даими шөгыльләнә алмыйлар. Бу хезмәтне үтәү өчен махсус төркем төзелергә тиеш. Шуның белән бергә ул Татарстан фәннәр академиясе, Казан университеты китапханәсе фәнни хезмәткәрләре катнашында, Мәскәү, Санкт-Петербург, Уфа китапханәләренең актив ярдәмендә генә башкарыла алыначак.

Татар китапларының революциягә хәтле басмаларының җыелма аннотацияләнгән документаль каталогын төзү дә Татар милли китабы тарихын ачыклауның бер өлеше. Инде күреп үткәнчә, милли китап тарихын өйрәнү буенча махсус фәнни-тикшеренү институты ачар вакыт та җитте. Ә бездә бу фән буенча шөгыльләнүче бернинди оешма, бернинди бүлек тә юк.

Татар китабы тарихын өйрәнүнең шундый хәлдә булуының тискәре нәтиҗәләрен мин бары бер өлкәдә — «Татар энциклопедиясе»н төзүдә генә күрсәтеп үтмәкче булам. Бу энциклопедиядә татар китабы тарихы, китапчылык, Татарстанда төрле телләрдә китап басу барышына караган мәкаләләр дә бирелергә тиеш. Китапчылык, китап тарихы буенча шушы энциклопедиягә кертү өчен мин йөз илледән артык белешмә язуны тәкъдим итсәм дә, аның 30—40 проценты гамәлгә ашырылмаячак.

Чөнки ул сүзләмәләрнең күпчелеге өйрәнелмәгән, алар турында энциклопедиягә мәкалә язу өчен ул темаларны махсус өйрәнергә кирәк. Татар китабының революциягә хәтле чоры турында азмы-күпме нәрсә эшләнгән булса, аның совет дәвере турында бернәрсә эшләнмәгән дияргә мөмкин. Димәк, бу чор китабыбыз тарихы да энциклопедиядә чагылмаячак.

Китап тарихы бит ул китапханәләр тарихы, шәхси китапханәләр, библиография эше, китап сату, пропагандалау эшләре белән дә бәйләнгән. Болар да бездә өйрәнелмәгән. Димәк, татар шәхси китапханәләре, китапханә эшләре, милли библиографияләребез тарихына караган материал да энциклопедиядә чагылыш тапмаячак.

Моннан егерме еллар элек Казанда, Русиядә китап басуның иң танылган шәһәрендә китапханә институты ачылган иде, хәзер ул Казан мәдәният һәм сәнгать институты исемен йөртә. Аның бер факультеты китапханәчелек, китапчылык, библиография буенча кадрлар чыгара. Татар китабының үзәге булган Казанда эшләүче бу институтта бары тик урыс китабы тарихы, урыс китапханәләре тарихы, урыс библиографиясе буенча гына сабак алалар, икенче төрле әйткәндә, урыс китапханәләрендә эшләү өчен генә кадрлар хәзерлиләр. Монда татар китабы тарихы, Татарстанда китап басу эше, Татарстан китапханәләре, татар китапханәләре, татарча библиография төрләрен, тарихларын, татарча белешмә әдәбият, татар китапларын тасвирлау үзенчәлекләрен өйрәнмиләр. Татар китаплары белән эш итү өчен бит әле ул китапханәче, библиографларның татар телен дә, татар әдәбиятын һәм тарихын да, татар сәнгате һәм иҗтимагый фикер тарихын да өйрәнүләре кирәк. Бу институтта укучы студентларның хәтта паспортында «татар» дип язылганнары да туган телен белми, яисә начар белә. Кыскасы, бу институтта татар китапханәчеләре һәм библиографлары әзерләнми. Институтының фәнни-тикшеренү планы буенча татар китабы, татар китапханәләре, татар библиографиясенә караган бернинди эш алып барылмый.

Кыскасы, бу институтның күрсәтелгән факультетының милли китапханә, милли китап, милли библиография өчен бернинди кирәге юк. Миңа калса, бу институтның күрсәтелгән факультетын ябып, аны Уфадагы кебек сәнгать институты итеп кенә калдырырга кирәк. Ә китапханә эшләре, китапчылык буенча кадрларны хәзерләүне Казан университетына яисә Татар Милли университетына тапшырырга, анда шундый факультет яисә бүлек ачарга кирәк. Бу университетларда алар татар телен, әдәбиятын, тарихын, иҗтимагый фикеренең үткәнен дә өйрәнеп, чын мәгънәсендә милли, татар китаплары белән нәтиҗәле эшли ала торган, милләтебезнең мәдәниятен күтәрүгә ярдәм итә алырдай белгечләр булып чыгарлар. (Казан мәдәният һәм сәнгать институтында үткән елны 15—20 студент өчен татар китабы тарихы буенча кыска гына махсус курс укытылу, аны да читтән чакырылган кешегә тапшыру белән генә татар китабы буенча кадрлар әзерләп булмый).

Бу институтта татар телен укыту, татар телендә лекцияләр алып бару турында авыз кортып сүз алып баруның мәгънәсе юк. Андагы кадрлар (китапханәчелек факультетында) 80 процент башка халык кешеләре, алар гына түгел, алар арасында татар саналганнары да туган телендә лекция укый алмыйлар. (Дөрес, монда татар телен камил белә торган 3—4 кеше бар, ләкин алар да татар китабы, китапханәчелек эше, библиографиясе буенча белгеч түгел). Монда татар китабы, татар китапханәләре буенча кадрлар хәзерләүгә төкереп карауның бер чагылышы итеп бу институтның китапханәсенә татар телендә бер генә газета, бер генә журнал да алдырылмавы бик яхшы сөйли. Инде институт китапханәсенә татар китаплары алу турында сөйләп тә торасы юк.

Әгәр без халкыбыз тарихының басма сүзгә бәйләнгән өлкәсен торгызырга, аны фән итеп өйрәнергә, бу өлкәдә кадрлар әзерләргә чынлап торып уйлыйбыз, аның зарурлыгын аңлыйбыз, аның милли, тарихи аңыбызны торгызудагы роленә әһәмият бирәбез икән, безгә хәзер үк: 1) Кульъязма һәм басма китап тарихы буенча фәнни-тикшеренү институты оештырырга; 2) Университет каршында китапханәчелек факультеты ачу эшенә керешергә тиешбез.

Татар китабы, китапханәчелек, библиография буенча югары квалификацияле милли кадрлар, фәнни хезмәткәрләр әзерләү буенча чаралар күрә башларга да вакыт күптән җиткән. Ә моның өчен Казанда бу фәннәр буенча аспирантура ачу, диссертация яклау советы да оештырылырга тиеш. Мәскәү, Санкт-Петербургта бу өлкәдә эшләп килүче советларда милли китаплар, бигрәк тә төрки милли китаплар буенча фәнни җитәкче булырдай кадрларны мин белмим. Русиядә төрки милли китап тарихы буенча диссертация яклау советы юк. Милли китап, инде әйтеп үткәнемчә, туган тел, милли әдәбият, халыкның мәгарифе, мәдәнияте, тарихы, милли аңы белән тыгыз бәйләнгән. Татарны монгол дип санаган, аның исемен дә белмәгән (инде теле, әдәбияты, тарихы турында әйтеп тә тормыйм) кеше татар милли китабы буенча советта аңа нинди бәя бирәчәге, ничек караячагы билгеле. Минем үземә Мәскәүдә татар китабы тарихы буенча докторлык диссертациясе яклаганда шуның нәрсәгә китерүен бик ачык күрергә туры килде. Менә шуңа күрә татар китабы буенча диссертацияләр язарга ашыгып торучылар күренми. Китап белеме буенча кандидатлык диссертациясе язарга уйлаганнар диссертация темасы итеп урыс китабына караган теманы сайлыйлар. Татар китабы буенча фәнни хезмәткәрләр әзерләү өчен кешеләр табуы гаять авыр булуның башка яклары, икенче төрле киртәләре дә бар. Казан мәдәният һәм сәнгать институтында китапханәчелек факультетын тәмамлаган кешеләргә татар милли китабына бәйләнешле диссертация язарга керешкәнче, аспирантурага керү өчен иң кимендә татар әдәбиятын, халык тарихын, гарәп язуын үзләштерергә кирәк. Ә татар филологиясе буенча югары белемле кешегә татар китабы буенча аспирантурага керү өчен өстәмә рәвештә китап белеме һәм татар китабы тарихын өйрәнергә кирәк.

Әгәр Казанда (университетта) китапханәчелек факультеты яки бүлеге оештырылса, анда милли китап буенча кадрлар җитештерелсә, бу мәсьәлә шактый җиңел хәл ителер иде. Һәм мондый шартларда ТӘТИ яки Казан университетының гуманитар фәннәр буенча диссертацияләр яклау советларының берсе каршында китап белеме буенча диссертацияләр яклауны да ачарга җиңел булыр иде. Әгәр шундый эш оештырылса, безгә милли китап тарихына багышланган диссертацияләр яклау буенча Урал-Идел төбәгеннән килүчеләр дә булыр иде.

Тора-бара бу советны, кульъязма һәм басма китап фәнни тикшеренү институты ачылгач, шунда күчерү дә акланыр иде.

Өстә искә алынган темалар, проблемалардан күренгәнчә, татар китабы дөньясы, аның үткән юлы әле күтәрелмәгән чирәм хәлендә диярлек. Бу күтәрел-

мәгән чирәмдә әле беренче буразна гына салынган. Коммунистлар диктатурасы заманында татар китабының ябылган тема булуына шаккатасы юк. Ул сталинизм милли сәясәте, әдәбиятыбызны, телебезне, мәгърифәтебезне буу, рухи геноцид сәясәтенең җимеше. Милли китабыбыз тарихын, аның совет чорындагы язмышында өйрәнми, ачыкламый, торгызмый торып, урыс патшалары һәм коммунизм тарафдарларының татар милләтенә, аның мәдәниятенә каршы алып барган сәясәте нинди зур югалтулар алып килүен, татар халкының манкортлашу фаҗигасен объектив рәвештә ачып бетерә алмаячакбыз.

Халыкның мәдәниятен, милли һәм тарихи аңын үстерүдә, саклауда басма сүзнең тоткан урыны гаять зурдыр. Әгәр безнең басма китабыбыз булмаган булса, татар халкының язмышы тагын да караңгырак булыр иде.

Мин басма сүзебезне татар милләтен рухи үлемнән саклап калуда гаять зур көч, бөек корал булган дип саныйм. Китап милли телебезнең иң бөек, иң нәтиҗәле сакчысы булган һәм шулай булып кала да. Китабы булмаган халыкның милли теле саклануы, үсеше, баюына ышанырга мөмкин түгелдер дип саныйм. Милли китап ул халыкның тарихи аңын саклаучы көч тә, аның тарихының көзгесе, елъязмасы да. Милләтне милләт иткән, аны саклап килә торган нигездә ике көч бар. Аның берсе милли тел, икенчесе — аның тарихи аңы, тарихи хәтере. Моңа халыкның гореф-гадәтләрен, рухи хәзинәләрен дә кушарга була торгандыр. Ә менә шушы көчләрне саклаучы, яшәешен көчәйтүче нәрсә — КИТАП. Милли китапның милләт язмышында шундый титаник көч, алыштыргысыз корал, юлбашчы булуы үзе генә дә аңа игътибар, хөрмәтнең ни дәрәҗәдә югары булырга тиешлеген күрсәтә. Ә без үз язмышыбызда, яшәешебездә, трагик тегермәннәр аркылы үтеп тә милләт булып югалмыйча саклану терәгебезгә — китабыбызга ни хәтле битараф караштабыз һәм әле дә шулай булып калабыз. Үз китабына тиешле хөрмәте булмаган халыкны мин мәдәниятле халык, үсеп җиткән милләт дип саный алмыйм. Күренекле зыялылар, галимнәр, философлар юкка гына тегеләр яки бу халыкның тарихи, мәдәни дәрәҗәсен аның басма сүзенә булган мөнәсәбәте белән билгеләмиләр.

Милләтебезнең мәдәнияте, сәнгате, иҗтимагый һәм фәнни фикере юлында татар китабы милли әдәбияты, милли телдән ким роль уйнамаган. Тел, әдәбиятны, аларның тарихын өйрәнү мәктәп программаларына кертелгән, югары уку йортларында да укытыла, югары белемле филология кадрлары әзерләнә. Туган тел әдәбиятыбыз, театр, музыкабыз өлкәсендә кадрлар әзерләнә, йөзләгән диссертацияләр язылган, монографияләр басылган, зур-зур белешмәлекләр чыгарылган һәм алар әле дә басылып тора. Ә милли китап тарихы, китапханәчелек эше, библиографиябез тарихы буенча хезмәтләр кайда? Галимнәребез кайда? Бу юлларның авторы гына тулы бер институт башкарып чыгара ала торган эшне эшләр әле дип тынычланып яшәү — тормыштан аерылганлык, нәрсәнең нәрсә икәнен аңламау булыр иде. Әгәр ул шундый җиңел нәрсә икән, тел һәм әдәбият, музыка һәм рәссамлык та шундый ук нәрсә, ул тармакларда да бер галим, бер белгеч җитә дияргә туры килер иде. Телебез, әдәбиятыбыз, тарихыбыз буенча йөзләгән диссертация, берничә йөз монография язылуына, бу өлкәдә йөзләгән галим эшләвенә карамастан, телебез, әдәбиятыбыз, халкыбызның тарихы буенча әле ак таплар диңгез кебек киң, эшләнәсе, җавап көтә торган мәсьәләләр буа буарлык. Инде күреп үткәнчә, басма сүз дөньясында бу мәсьәләләр аннан да күбрәк.

Бөтен Европа илләрендә, СССРның колонияләре булган Литва, Латвия, Эстония мәктәпләрендә күптән инде китапчылык, милли китап тарихы, китапханәләрдән, каталоглардан, библиографияләрдән файдалану, алар белән эшли белү махсус дәрес буларак өйрәтелә. Кызганыч ки, безнең күп кенә галимнәребез дә библиографик яктан надан, шуңа күрә басма сүз океанында адашып йөриләр, инде башкалар ачкан Американы ачу белән вакытларын әрәм итәләр, шуның аркасында бездә фән һәм техника үсеше дә әкрен бара, күпме акча бушка түгелә.

Без бу язмабызда хәзерге заман китап җитештерү, басу техникасы, китапханә һәм библиографик эшләрне компьютерлаштыру, басма сүзне ничек укучыга җиткерүне җиңеләйтү кебек мәсьәләләргә кагылмыйбыз, аларның да китапчылык эшенә тоташуы турында сүз алып бармыйбыз. Безнең хәзерге максатыбыз милли китабыбызның язмышы, аның тарихын торгызу, бу өлкәдә гамәли һәм фәнни кадрлар әзерләү, милли китабыбызга карашны кискен үзгәртү кирәклеген күрсәтү, аңлатырга тырышу.

Бүгенге көндә милләтебезнең тигезлек һәм мөстәкыйльлек өчен алып барган авыр көрәше елларында милли китабыбызга игътибар гаять зур һәм җитди булырга тиеш. Китап язмышы — ул тел язмышы да, милләт язмышы да, менә шуны даими күз алдында тотып эш итәргә кирәк.



**Ибраһим Нуруллин,**
филология фәннәре докторы, профессор

# БУЛГАН УЛ ТӘНКЫЙДИ РЕАЛИЗМ!

Профессор Ф. Хатиповның «Тәнкыйть реализмы булганмы?» исемле мәкаләсен укып («Казан утлары», 7 сан, 1994 ел) дәшми калсам, мин, «Татар әдәбиятында тәнкыйди реализмның тууы һәм үсеше» дигән темага докторлык диссертациясе язып яклаган һәм реализм буенча белгеч саналган кеше буларак, үземә хөрмәтем беткән кебек, әдәбият белеме өлкәсенә килүче яшь галимнәр дә мине хөрмәттән мәхрүм итәрләр иде.

Бу язмасында профессор Хатипов аңа исем итеп куелган сорауга «Юк, булмаган ул тәнкыйди реализм. Ә бәлки «житлеккән реализм» дип атау дөресрәк күрелгән иҗат юнәлеше һәм иҗат методы гына булган» дигән мәгънәдә җавап бирә. «Җитлеккән реализм» дип атауга килгәндә, бу атаманы мин нәкъ шулай дип, «житлеккән реализм» дип үземнең «XX йөз башы татар әдәбияты» исемле китабымда инде кулланган идем. Тик ни өчендер Ф. Хатипов моны искә алмый. Бусы сүз уңаенда. Ә мәкаләгә килгәндә, аның тәнкыйди реализмны юкка чыгару өчен китерелгән төп дәлиле түбәндәгегә кайтып кала.

XIX гасырдагы Европа һәм рус әдәбиятларының, XX йөз башы татар әдәбиятының классик реалистлары тормыштагы ямьсез якларны сурәтләү белән генә чикләнмәгәннәр. Аларның әсәрләрендә матур кеше образлары да, яшәешнең матур яклары да житәрлек. Ләкин бит, совет чоры теоретикларының фикеренчә, хикмәт тәнкыйтьләүнең ничә процент булуында түгел, бәлки тәнкыйди реализмның җәмгыятьнең үзен, нигезләрен тәнкыйтьләүче реализм булуында. Ә бу фикер Ф. Хатиповка — пәри! Аның карашынча, классик реалистлар (иң зурлары да) җәмгыятьне революцион үзгәртеп кору тарафдарлары булмаганнар. Профессор Н. А. Гуляевка кушылып, аның сүзләрен контексттан аерып алып, ул, мәсәлән, болай яза: «Бальзак, Диккенс, Теккерей, Флобер тормышны революцион үзгәртү методларын кабул итмәделәр».

С. М. Петров, Днепров, Караганов кебек теоретикларның уртак фикеренчә, тәнкыйди реализмның төп асыл сыйфаты булган социаль детерминизмны да Ф. Хатипов зир-зәбәр китерә. Юк ул анда, дип кенә жибәрә.

Ярар, башлыйк әнә шул социаль детерминизм мәсьәләсеннән.

Белинский һәм Добролюбовтан башлап «Реализм» исемле калын китап авторы С. М. Петровка чаклы күп тәнкыйтьче һәм галимнәрнең бердәм фикеренчә, реализм дип йөртелә торган иҗат тибына, икенче төрле әйтсәк, иҗат ысулына, хас төп сыйфат — кешене иҗтимагый тирәлек белән сәбәпле бәйләнештә, ягъни иҗтимагый тирәлек җимеше, шул тирәлек тарафыннан формалаштырылган итеп сурәтләү. Теориягә бик бирелмичә, гади акыл белән генә уйлап караганда да бу

фикернең дөреслегенә ышанырбыз. Чөнки тормышның, җәмгыятьнең үзендә үк шулай бит ул. Географик шартлар, климат, хуҗалык итү рәвешләренең кешенең эш-гамәлен билгеле бер юнәлешкә җибәрмәве, гореф-гадәтләрен билгеле бер рәвешкә китермәүләре мөмкин түгел.

Салкын Себердә яшәүче якутлар белән Агыйдел һәм Дим буйларындагы башкорт-татарларның фикерләве һәм хис-тойгылары, гореф-гадәтләре нәкъ бер төсле була алмаган кебек, гомере буе иген игеп, табигать кочагында яшәгән крестьян белән завод-фабрика эшчесе дә нәкъ бер төсле фикерли, һәр нәрсәдән нәкъ бер төсле хисләнә алмыйлар. Реализм дигән иҗат тибының эченә керә һәм аны тәшкил итә торган иҗат методларының барысында да кешене иҗтимагый тирәлек белән сәбәпле бәйләнештә сурәтләү принцибы үткәрелә һәм ул һәркайсысында үзенчәлекле рәвештә тормышка ашырыла. XVIII йөздә көнбатыш Европа һәм рус әдәбиятларында, XIX гасырда татар әдәбиятында формалашкан мәгърифәтчелек реализмында, мәсәлән, ул чорларда кеше — тәрбия җимеше, дигән фәлсәфи караш аннарны биләгәнгә күрә, тирәлек дигән нәрсә башлыча гаилә һәм мәктәп белән чикләнгән.

Шуңа күрә әдипләр кешене гаилә һәм мәктәпкә бәйле итеп, шуның җимеше итеп сурәтләгәннәр. Ә инде Бөек француз революциясеннән соң, мәгърифәтчеләр вәгъдә иткән җир җәннәте урнашмагач, һәм тирәлекне фикер идарә итә дигән постулатлар авып төшкәч, тирәлекнең үзен өйрәнергә керешәләр. Хәзер, киресенчә, фикерне тирәлек барлыкка китерә дигән нәтиҗәгә киләләр.

Ә политэкономия һәм социологиянең уңышлары бу «тирәлек» дигән төшенчәнең хәлиткеч төп элементы социаль-экономик мөнәсәбәтләр булганны ачып бирә. Әлеге караш әдипләр аңына да үтеп керә һәм аларны социаль детерминизм принцибын, ягъни кешенең үз-үзен тотышын, хис-тойгы һәм уй-фикерләрен башлыча аның социаль-сыйнфый хәле билгели дигән принципны кабул итүгә китерә. Әнә шул принципны иҗатта куллану һәм тормышка ашыру үз чиратында әдәби типлар, типик характерлар тудыруга һәм аларны үзара тормышчан мөнәсәбәтләргә куярга мөмкинлек бирә. Һәрбер тип яисә типик характер берәр социаль катлауның яшәеш үзенчәлеген һәм мәнфәгатьләрен чагылдырганга күрә, аларның җыелмасы яшәп килүче җәмгыятьнең күп кенә характерлы якларын һәм, ахыр чиктә, тулаем җәмгыятьнең төп асылын дөрес итеп ачып бирә. Әгәр бу җәмгыять үзенең үсеш, күтәрелеш баскычларын узып, төшүгә, җимерелүгә таба йөз тоткан җәмгыять булса, аның асылын бөтен чынлыгы белән ачып бирү үзе генә дә бу җәмгыятьне тәнкыйтьләү булып чыга бит. Франциянең акча капчыгына табына торган җәмгыятен фаш иткән Бальзак, Россиянең феодаль-крепостнойлык җәмгыятенең әшәкелеген ачып биргән Гоголь, Толстой, Тургенев, татар феодаль-буржуаз җәмгыятенең эчке хәлен дөрес чагылдырган Гаяз Исхакый һәм Фатих Әмирхан реализмнары әнә шундый реализм иде. Аларның Исхакыйдан һәм Әмирханнан калганнары берсе дә революцион-демократ та, большевик та түгел иделәр. Тәнкыйди реалист булу өчен, димәк, дәһшәтле революционер булуның кирәге юк. Талантың булса, тормышны яхшы белсәң һәм социаль-детерминизм принцибы кушканча эш итсәң, шул җитә. Бүтәнчә була да алмый. Чөнки тәнкыйди реализм әдәбиятындагы һәрбер тип бер вәкиле үзе булган берәр социаль катлауның яшәү рәвеше кушканча гамәл кыла, уй-фикер йөртә, хис-тойгы кичерә.

Күренә ки, шул социаль катлауның җәмгыятьтәге урыны, теләк-омтылышлары, мәнфәгатьләре геройны хәрәкәт иттерә торган пружина булып тора. Дөрес, кешенең тумыштан килә торган темпераменты һәм башка психологик сыйфатлары да аның хәрәкәтен, үз-үзен тотышын билгеләүдә катнашалар, һәм бу хәл классик реалистлар иҗатында да чагылыш тапкан. Тәнкыйди реализм турында язган совет галимнәре дә моны инкяр итмиләр. С. М. Петров, мәсәлән, телгә алынган китабында бу мәсьәләгә шактый кин тукталган һәм бу күренешкә исем дә биргән: психологик детерминизм.

«Җитлеккән реализмда социаль детерминизм һич тә хәлиткеч нигезләү буларак кулланылмады» дип, социаль детерминизмны юкка чыгаргач, Ф. Хатипов аңа алмашка бүтән бер «пружина» тәкъдим итәргә тиеш бит. Һәм ул аны тәкъдим дә итә. «Әдипләр,— дип яза ул,— барыннан да бигрәк, характерның эчке куәтенә, күңел хәрәкәтенә, тормыш логикасына өмет багладылар». «Күңел хәрәкәте» ни буладыр, «тормыш логикасы» дигәндә нәрсә күздә тотыладыр, моны ходай үзе генә белә. Әмма сүзнең әлеге психологик детерминизм турында барганлыгын чамаларга мөмкин. Ф. Хатиповның аны, психологик детерминизмны, социаль детерминизмга нисбәтән беренчел итеп куйганын да чамалау кыен түгел.

Беренчеллек, икенчеллек мәсьәләсендә Ф. Хатипов хаклы булса, Фатих Әмирханның Хәяты, мәсәлән, Салих Фатихов диган яшь байдан үзенә тәкъдим ясаган хат һәм фоторәсем килгәч, «күрмәгән-белмәгән кешегә ничек ризалык бирим» дигән күнел талпынышына буйсынып, тәкъдимне кире кагарга тиеш иде. Әмма ул күп уйланулар, газапланулардан соң, уңай җавап бирү фикеренә килә. Чөнки ул туып-үскән даирәдә борын-борыннан эшләнеп килгән куәтле кагыйдә әлеге талпынышны сүндерә, юкка чыгара. Бу кагыйдә буенча кыз кияүне үзе сайларга түгел, бәлки ата-анасы кулай тапканга сүзсез риза булып барырга тиеш. Әнә бит социаль детерминизм ничек өстен чыкты.

Яки менә «Галиябану» драмасының бер герое Бәдри. Ни өчен ул яраткан кызын кан жылатып Исмәгыйльгә бирмәкче була? Чөнки ул, капиталның авылга үтеп кереп, крестьяннарны икегә аерган бер заманда, ярлылар арасына авып төшүдән коты очып, байлар, кулаклар янынннан урын алырга хыялллана. Исмәгыйльнең бабасы булып алса, һәм ул вәгъдә иткән мең сум да кулына керсә, шул хыялы тормышка аша ич! Аның һәр тиен өчен калтырап торуы да шул социаль хәленнән килә. Яисә менә рус әдәбиятыннан Обломов тибы. Кылырга уйлаган гамәлләре бары тик хыялында гына башкарыла торган үтә ялкау бу зат — тулысынча крепостное право җимеше. Димәк, Обломовлар үрчемәсен өчен крепостное правоны бетерергә кирәк. Бәдри һәм Исмәгыйльләр булмасын һәм Галиябанулар бәхетсезлек упкынына очмасыннар өчен капитализмның авылны икегә яруын туктатырга, ягъни авылны тамырыннан үзгәртеп корырга кирәк. Хәят кебек татар кызлары бәхетсезлек корбаны булмасыннар өчен татар феодаль-буржуаз җәмгыятен дә тамырыннан үзгәртергә кирәк. И. А. Гончаров романы да, «Хәят» повесте да, «Галиябану» драмасы да укучыны әнә нинди нәтиҗәләргә этәрәләр. Социаль детерминизм һәм җәмгыятьнең үзен тәнкыйтьләү дигән асыл сыйфатлар тәнкыйди реализмда гына түгел, бәлки Ф. Хатиповның сөйгәне — житлеккән реализмга да хас булган икән бит: ул да җәмгыятьнең үзен тәнкыйтьләгән икән.

Кыскасы, булган ул тәнкыйди реализм, һәм рус әдәбиятында (бәлки татар әдәбиятында дадыр) аның хәзер дә баш калкыту ихтималы юк түгел.

Илленче елларда ук мин фәкыйрегез тәнкыйди реализмның асылы, аерым алганда, аның мөһим бер сыйфаты — җәмгыятьнең үзен тәнкыйть итә торган реализм булуы турында югарыда әйтелгән фикерләргә килгән идем. Хәтеремдә, Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең 1957 елгы бер утырышында кандидатлыктан берлек әгъзалыгына күчерелгәндә, сорауларга җавап бирү рәвешендә, хәзер совет әдәбиятында тәнкыйди реализм юнәлешенә җирлек барлыкка килде, дигән фикер әйтеп ташладым. Аны болайрак нигезләгән идем. Сталин урнаштырган тәртипләр хәзер илебезнең алга таба үсешен тоткарлый торган бер система рәвешен алды. Ә бу системаны әдәби-сәнгати чаралар ярдәмендә тәнкыйть итү (ә аны тәнкыйть итү кирәк) тәнкыйди реализм була да инде, рус әдәбиятында моның инде яралгылары күренә башлады, дигән идем. Залыгин белән Сенин иҗатларын, Яшинның «Рычаги» һәм Гранинның «Собственное мнение» хикәяләрен моңа мисал итеп китергән идем.

Бу чыгышым шома гына үтмәде, билгеле. Шул утырышта катнашкан Хәсән Хәйри минем белдерүемне житди сәяси хата дип бәяләде. Инде килеп, хәзер «демократ» җитәкчеләрнең тырышлыгы нәтиҗәсендә Рәсәйдә кешеләрне бәхетсезлеккә дучар итә торган иҗтимагый-сәяси строй урнашса, рус әдәбиятында тәнкыйди реализмны уятып алып эшкә кушарга ихтыяҗ туарга бик мөмкин.

Мәкаләсенең тәнкыйди реализмга караган өлешендә Ф. Хатиповның кеше образларын тудырудагы универсальлек принцибын тәнкыйди реализмнан алып «җитлеккән»енә бирергә тырышуның, Пушкинны, Тукайны тәнкыйди реалистлар җөмләсенә кертүенең хата булганлыгына да тукталып тормыйм.

Социалистик реализм белән бәйле рәвештә татар совет әдәбиятына кагылышлы урыннарны да игътибарымнан читтә калдырам. Чөнки анда тар милләтче һәм антикоммунистлардан мактау ишетергә теләгәндәй, социалистик реализмны бүкәй итеп күрсәтергә көчәнүдән бүтән нәрсә юк. Фикерләре дә гаять аңлаешсыз һәм буталчык.

Хәер, совет әдәбияты һәм социалистик реализм мәсьәләләре буенча Ф. Хатипов белән бәхәсләшү, чытырманлыкны ерып бару кебек кыен булса да, аның әлеге «дошманнары» белән ничек итеп сугышуын, сугыш алып бару алымнарын күрсәтеп китү зарар итмәс дип беләм.

Иң элек, укучылар мине дөрес аңласыннар өчен, мондый бер искәртмә. Социалистик реализмны да, совет чоры татар әдәбиятының теләсә кайсы әдибенең, теләсә кайсы әсәрен дә, аларны яклаучыларның хезмәтләрен дә тәнкыйть итү тыелган эш түгел. Рәхим ит, тәнкыйтьлә, ләкин тәнкыйтең гадел булсын һәм

цивилизацияле мөнәсәбәтләр кагыйдәләрен бозмасын. Ф. Хатиповның тәнкыйте исә вакыт-вакыт ул кагыйдәләргә туры килеп житми. Кайчакта ул фокус күрсәтүче кебек карталарны йә яшерә, йә алыштыра. Менә социалистик реализмны бер сугуда юк итмәкче булып, ул СССР язучыларының беренче бөтенсоюз съездында кабул ителгән уставны күздә тотып «устав,— дип язып китә,— язучылардан тормышны революцион үсештә яктыртуны таләп итте, ягъни аны хәрәкәттә чагылдырырга киңәш итте». Игътибар итегез, хөрмәтле укучым, профессор абыебыз күзгә күрсәтмәскә тырышып кына «революцион үсеш» дигән төшенчәне «хәрәкәттә» дигән төшенчә белән алмаштырып куйды. Хәзер социалистик реализмның төп сыйфаты — тормышны революцион үсештә чагылдыру таләбенә һөҗүм итәчәк. Менә! «Рәсем, сынлы сәнгатьтән аермалы буларак, бер әдәби ысул да яшәешне тик тору хәлендә күрсәтмәде». Социалистик реализмга кадәрге әдәби юнәлешләр вәкилләре дә тормышны динамикада, хәрәкәттә чагылдырганнар. Димәк, тормышны революцион үсешендә күрсәтүне социалистик реализмның асыл сыйфаты итеп карап булмый. Төп сыйфаты юкка чыккач, социалистик реализм үзе дә юкка чыга түгелме? Әнә ничек ансат, бер сугуда юк итте дә куйды!

Әмма бу юлы Ф. Хатиповның карта алыштыруы шома чыкмады һәм фокусчыга дан китермәде.

Беренчедән, хәтта сынлы сәнгать тә чынбарлыкны туктап, катып калган итеп чагылдырмый. Брюлловның, мәсәлән, «Помпеяның соңгы көне» исемле әсәре каршына басыгыз да, игътибар белән җентекләп, озаклап карагыз. Бу фажиганең ничек башланганын да, ничек котырып үскәнен дә, хәзерге хәлен дә, бәхетсез кешеләрнең иртәгәге көнен дә күз алдыгызга китерерсез. Яисә менә Репинның «Не ждали» дигән картинасы. Сөргеннәнме, каторгаданмы кайтып кергән революционерның өс-башы, йөз-кыяфәтеннән, гаилә әгъзаларының аңа карап каткан йөз-чырайларыннан без бу затның ничек революцион хәрәкәткә кереп китүен һәм суык якларда кичергән газапларын, аны хәзер ни көткәнен барысын да чамалыйбыз.

Кыскасы, сынлы сәнгать яшәешнең бер мизгелен генә чагылдырса да, аны моннан элекке нинди мизгелләр тудырганын һәм киләчәктә нindиләренә юл ачканын анык аңларга мөмкинлек бирә.

Икенчедән, чынбарлыкны революцион үсешендә чагылдыру дигәндә бөтенләй бүтән нәрсә күздә тотыла. Тормышны революцион үсештә күрсәтү ул — тормышның үзендәге социалистик эчтәлекле яңалыкларны яралгы хәлендә үк тотып алып, тулы канлы тормышчан образларда гәүдәләндереп бирүне күздә тота. Ә бусы инде безнең галимгә тагын — пәри! Ул аңардан тизрәк котылырга ашыга. Бу очракта ул хәтта бүтәннәр фикерен бозып күрсәтүдән һәм яла ягудан да тартынмаган. Тормышны революцион үсешендә чагылдыру турында сүз алып баручылар, янәсе, әлеге яңалыкларны «яралгы хәлендә итеп түгел, киң таралган типик күренеш итеп гәүдәләндерүне таләп иткәннәр».

Социалистик реализм турында шактый күп язган теоретикларның берсе булган мин фәкыйрегезнең «Әдәбият теориясе» исемле китабының 125 битен ачабыз да укыйбыз: «Чынбарлыкны революцион үсеш-үзгәрештә чагылдыру — тормышка диалектика законнары белән үзгәрә торган процесс итеп караган хәлдә, киләчәкнең бүген яралгы рәвешендә генә булган билгеләрен күреп алып, тулы канлы образларда чагылдыру дигән сүз». Кайда монда ул яралгыларны киң таралган күренеш итеп тасвирларга чакыру?

Шушы уңай белән һәм, Фәрит коллегамның социалистик реализм белән тәнкыйди реализм арасында бәйләнеш күрергә теләмәвен, социалистик реализмны реализм үсешендә яңа, югары этап итеп карауга дошман булганын искә алып, тагын бер фикерем белән уртаклашмакчы булам.

Элеккеге бөек реалистлардан аеруча үткен күзле, сизгер күңелле, киң һәм тирән карашлылары, җәмгыятькә үсеш-үзгәреш процессындагы бербөтен итеп карап, анда туып тора торган яңа тенденцияләрне тотып алып, тормышчан типларда гәүдәләндерә белгәннәр. Бу яктан аеруча И. С. Тургенев аерылып тора. Аның Базаровы, Рудины, Елена Стаховасы, мәсәлән, җәмгыятьнең үзендә шытып чыккан яңа яралгыларның сәнгатьчә гәүдәләнеше булып торалар. Яисә менә Л. Н. Толстойның Наташа Ростовасын алыгыз. Булачак декабрист хатыннарының яралгысы ич бу! Яки менә Ф. Әмирханның Хәяте, Рокыясы. Киләчәктә мәдәният, мәгариф һәм сәясәт өлкәләрендә мул җимеш бирәчәк гүзәл хатыннарыбызның беренче образлары бит болар!

Моның белән мин Тургенев һәм бүтән классиклар да социалистик реализм методын кулланганнар дип әйтергә теләмим. Социалистик реализм очрагында

бит сүз социализм яралгыларын җанлы образларда гәүдәләндерү турында сүз бара. Әйтик, Павел Власов һәм аның анасы Пелагея Ниловна кебек.

Әгәр без социалистик реализмның тормышны тарихи-конкрет чагылдыру дигән бер сыйфатының турыдан-туры тәнкыйди реализмнан күчкәнен һәм киләчәкнең яралгыларын тотып алып, тормышны перспективага күз ташлап чагылдыру дигән принцибының да буш урында гына барлыкка килмәгәнлеген искә алсак, социалистик реализм — реализм үсешендәге яңа этап дип раслау да зур көферлек булмас.

Гафуыгызны үтенеп, карта алыштыруга тагын бер мисал китерми кала алмыйм.

Социалистик реализмга һөҗүм башлар алдыннан «артхәзерлек» үткәрү рәвешендә ул автор Октябрь социалистик революциясен һәм аның идеалларын юкка чыгарырга азаплана. Большевиклар, ди ул, халыкны революциягә җәлеп итәр өчен бик кешелекле лозунглар күтәреп чыктылар: тынычлык, җир, азатлык, тигезлек. Әмма болар алдау гына булып чыкты, тынычлык урынына, дип дәвам итә Ф. Хатипов, гражданнар сугышы кабынып китте. «Авыл кешеләре җирдән мәхрүм калдылар».

Карагыз әле, Фәрит туган, «солых» сүзе урынына «тынычлык» сүзен кулланып, карта алыштырдыгыз бит. Чөнки ул вакытта бит сүз беркайда, бернинди мылтык атылмау һәм туп шартлатмау мәгънәсендәге тынычлык түгел, бәлки Германия белән сугышны туктату һәм солых урнаштыру турында барган. Ә инде җир мәсьәләсендә сез хакыйкатьне бигрәк тә рәнҗетәсез. Җиргә тилмергән крестьяннар нәкъ менә Октябрь нәтиҗәсендә җир алдылар, җиргә гарык булдылар. Ә инде күмәкләштерү соңрак булды һәм күп еллардан соң колхозчылар, райкомнар тырышлыгы белән, үз җирләреннән хуҗа булудан читләштерелгәннәр икән, бусы инде бүтән мәсьәлә.

Профессор Хатипов мәкаләсе уңае белән ясалган искәртмәләрне бер йомгакка чорнасак, түбәндәге нәтиҗәгә килербез.

Әгәр без, совет галимнәре эше дип, әдәбият белеменең элеккеге казанышларын себереп түгеп, яңадан велосипед уйлап чыгарырга керешсәк, һәм өстәвенә, карта алыштыру методы белән эш итсәк, бер урында таптанудан уза алмабыз. Әдәбият фәнебез бер карыш та алга китмәс.

# АЛТЫН БӨРТЕКЛӘР ЮГАЛМЫЙ



Җитмешенче елларда миңа Себер якларында, татар туганнарыбыз янында булгаларга туры килде. Бер баруымда Төмән өлкәсенең Чикча авылында яшәүче мөгаллимә Һаҗәр апа Алишкина миңа шактый таушалган, еллар тузаны саргайткан аерым китап битләрен тотып килде.

— Менә тыңлап карагыз әле, нинди матур шигырьләр, тик авторы гына билгеле түгел, бәлки сез беләсездер...— диде.

Гарәп хәрефләре белән басылган әсәрләрне тыңлаганнан соң, аларның авторы Тукайлар, Дәрдемәндләр замандашы икәнен чамаларга мөмкин иде. Әмма тәгаен генә әйтү кыен. Шигырьләре таныш та, таныш түгел дә кебек. Болай шәкли яктан Шәехзадә Бабичны да хәтерләткән шикелле, урыны-урыны белән Мәҗит Гафури чалымнары да бар сыман.

Мен манараң өстенә, хәсрәтле җырчы, әйт азан!
Моң белән яңрат, уят тизрәк татарлар дөньясын!

«Габдулла Тукаевка багышлыйм» дип куелган «Азан» шигыре әнә шулай башлана... Яки менә Дәрдемәндкә багышланган «Мәхәббәтем» шигыре:

Тормыш сингез —
Җилле дингез,
 Күз карам!
Ялгыз калдым,
Төн — күзалдым,
 Саргаям,
 Миннән ник качтың?
 Күккә ник аштың?
 Ник сөйдең дә ник
 Тәмугка аттың?

Җитмешенче еллар өчен колакка ятрак, әмма күңелгә бик якын бу шигырьләрне мин күчереп язып алып кайттым. Билгеле, аларны безнең матбугатта бастырып чыгаруның мөмкин эш түгеллеген аңлый идем. Болай, үзем өчен генә алып кайттым. Аннары мондый затлы шигырьләрне кем язганлыгын беләсе килү дә көчле иде. Әмма бу эш алай җиңелдән булып чыкмады. Татар шигъриятен өйрәнеп азау ярган кайбер галимнәргә күрсәткәләп карасам да, нәтиҗә булмады. Алар да: «Шәехзадә Бабичныкы, яки Сәгыйть Рәмиев әсәрләре түгел микән?» — дип әйтүдән ары уза алмадылар. Мин әлеге «алтын бөртекләрен» архивыма салып куйдым... Әмма алар турында онытмадым, мөмкинлек чыккан саен кемгә дә булса укып, авторын ачыкларга тырыштым.

Беркенне шулай үзебезнең «Казан утлары» редакциясенең поэзия бүлеге мөдире, шагыйрь Рәдиф Гаташка күрсәттем мин бу шигырьләрне.

— Кызыклы шигырьләр,— диде ул.— Сүнчәләй йә Ченәкәй түгелме? Тукта әле, Әмирхан ага белмиме икән бу шагыйрьне? Аңардан сорыйк әле.

Шалтыраттык.

— Башкаларын әйталмыйм, әнә тегесе — Дәрдемәндкә багышланганы — Сәгыйть Сүнчәләй шигыре,— диде Әмирхан ага Еники.

Булды, аңлашылды! Чыннан да «Мәхәббәтем» шигыре Сәгыйть Сүнчәләйнең 1961 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Сайланма әсәрләре»ндә дә бар икән. Тик «Дәрдемәндкә багышлыйм» дигән сүзе генә юк. Күрәсең, цензура кайчысы кисеп калдыргандыр. Шулай булгач, бу сайланмага татарлар дөньясын уяныргa, үз хәленә карап уйланырга чакырган шигырьләрнең кертелмәвен аңлавы кыен түгел. (Гәрчә алар Октябрь инкыйлабына кадәр үк язылган булсалар да.) Әлеге шигырьләр 1992 елда нәшер ителгән «Татар поэзиясе антологиясе»ндә дә юк.

Хәлбуки, Дәрдемәнднең тууына 120 ел тулу уңаеннан гәзиткә (мин ул вакытта «Социалистик Татарстан» редакциясенең әдәбият-сәнгать бүлегендә эшли идем) Сибгат ага Хәким мәкаләсен әзерләп бирүем өчен «югарыдагы иптәшләрдән» үземә дә кисәтү эләккәне хәтердә әле... Чөнки ул мәкаләдә Сибгат Хәким бүгенге яшь шагыйрьләрне язу осталыгына нәкъ менә Дәрдемәндләр буыны әдипләреннән өйрәнергә чакырган иде.

Әйе, хәбәрдарлыкның сулышы кысылган ул елларда:

Бар, булыр, бетмәс татарлар: бар теле — тәмле теле.
Бар җаны, бар яшьләре, үлмәс татар, үлмәс,— диегез,—

кебек ялкынны ничек инде кабынырга торган күңелләргә чыгарып бөркесеннәр!

Инде шөкер, авызларны бәйләп куйган кызыл чүпрәкләр алып ташланды. Шигъри хәзинәбездәге әлегәчә тыелып киленгән алтын бөртекләр дә берәмберәм көн яктысына чыгарылып, карашыбызны нурлый, күңелләребезне баета башлады. Якын киләчәктә, ихтимал, Сәгыйть Сүнчәләйнең дә сайланма әсәрләре тулырак, күркәмрәк булып дөнья күрер. Ихтимал, ул китапны төзүчеләр Себер якларыннан табылган менә бу әсәрләргә дә игътибар итәр. Хәлбуки, алар әле бүген генә язылган шикелле, гаять заманча яңгырыйлар. Шагыйрьнең никадәр алдан күрүчәнлегенә сокланмый мөмкин түгел...

**Шамил МАННАП.**

# Сәгыйть Сүнчәләй

## Азан

*(Габдулла Тукаевка багышлыйм)*

Мен манарaң өстенә, хәсрәтле җырчы, әйт азан!
Моң белән яңрат, уят тизрәк татарлар дөньясын!

Үтте төн, бетте, кояш чыгышында инде атты таң.
Җитте йоклау! Һәммәсе торсын да тизрәк уйлансын!

Бар авылларга, калаларга азаның яңрасын,
Бер катып беткән татар күңеле зарыннан йомшасын!

Әйт азан! Таң атты, кошлар да уянып сайрасын!
Кычкырып моңлан: һава, җир, күк-аһыңны тыңласын!

Изге рухлар, изге җаннар бер сөенсен таушыңа!
Кычкырып, торгыз баен, ярлы гавамен, мулласын!

Изге тәкбир яңрасын, барсын Ходайның каршына!
Һәм матур таң атканын һәркем ишетсен, аңласын!

Моң белән әйткән азанны ишеттер халкыңа,
Әйт! Азаның яктылык җиткәнне сөйләп чыңласын!

Төнге золмәт утлары сүнсен, аларның урнына
Милли рухлар нурга чумдырсын татарның дөньясын!

Әйт азаныңны, шагыйрь! Таңга калсын бар галәм!
Таулар-урманнар, сулар, кырлар азаннан яңрасын!

Бер гаҗәпләнсен кояш, таң, җен, фәрештә, җир, адәм!
Бар да торсын, мактасын тәңрен, яраткан Алласын.

**21 гыйнвар.**

## Җырларым — күз нурларым

Әй, минем күңлем ярасыннан чыгучы җырларым!
Әй, җәһәннәм-тормышымны оҗмах иткән хурларым!
Таңдагы моңлы азан илне уяткан төсле үк,
Яңрагыз сез дә! Туган җирдә, минем күз нурларым.

Бар татарның күңеленә дуслык кояшы кертегез,
Ул да якты дөньяда барлыкны сез белгертегез.
Бар, булыр, бетмәс татарлар; бар теле — тәмле теле.
Бар җаны, бар яшьләре, үлмәс татар, үлмәс,— диегез.

Күп өметсезне юатып, кайгылыга кул сузып,
Күп үлекне тергезеп, сансыз чиренлеккә түзеп,
Күп катып беткән күңелләрне төбеннән йомшатып,
Яктылык җырлап, халыкка таң туасын белгезеп,

Моң белән сез җырлагыз! Тик үз татар халкым өчен
Җырлагыз сез, яңрасын тормышны баскан вәхши төн!
Җырлагыз, атсын таңы, чыксын кояш, бетсен газап!
Җырлагыз, күз нурларым! Бик бит кыен, бик бит читен!..

## Ялгызлык

Ялгызым тормыш күрергә талпынам,
Ялгызым иркен йөрергә талпынам.
Бу хәзерге тормышым ямьсез, кара,
Бит хәзер мин һәр газапка буйсынам.

Ямь табалмыйм тын гомердә, саргаям,
Әкрен-әкрен яшь, кызу дәрттән таям.
Тоткын охшашлы зарыктым, кайгырам,
Тик өмет бар, шул өметкә янтаям.

Шик тә тотмыйм: мин кайчан да бер заман
Кулны селтәп, айрылырмын дөньядан.
Яшь таңым шул чакта тик атса-атар,
Әйтелер шунда минем таңга азан.

## Чәчәкләрне өзмәгез

Бетте кыш, яз да үтә, җәйге җылы җилләр исә,
Кыр, болын, урман яшәрде, бакчада гөлләр үсә.

Бар үлән, гөлләр, чәчәкләр һәм уҗым бар дөньяга
Ямь бирәләр; ялтырап күктән кояш нурлар чәчә.

Шул җылы, ямьле табигать шатланып торганда сез,
И туганнар, бер дә зинһар, бер чәчәк тә өзмәгез!

Тотмагыз, пычратмагыз, өйгә алып та кайтмагыз!
Тимә, үссен! Булмасын корбан! Бүтән ямь эзләгез...

Таңресен мактаучы көчсезгә тупас кул сузмагыз,
Өзмәгез, сындырмагыз — дөнья канунын бозмагыз!

Ул елап та ялваралмый; бәгъренә кан коймагыз,
Әй туганнар! Тыңлагыз, зинһар сүземне, тыңлагыз!

**24 март.**

## Мәхәббәтем

*(Дәрдемәндкә багышлыйм)*

Йолдыз нуры,
Оҗмах хуры —
Син, бибкәй!
Таҗым, даным,
Гомрем, җаным —
Син, бибкәй!
Мине ник үптең?
Үптең дә үттең;
Ник күп сөймәдең?
Үптең дә киттең.
Кайдан килдең,
Кайдан индең,
Бибкәем?
Ник сөйдердең,
Ник көйдердең,
Бибкәем?
Мине ник үптең?

Үптең дә киттең;
Ник кул селтәдең,
Ник ашыгып очтың?
Тормыш синсез —
Җилле диңгез,
Күз карам!
Ялгыз калдым,
Төн — күзалдым.
Саргаям.
Миннән ник качтың?
Күккә ник аштың?
Ник сөйдең дә ник
Тәмугка аттың?
Киттең миннән,
Күктән иңгән
Бибкәй нур!
Киттең, сеңлем —
Үлде күңлем,
Булдым хур.
Инде мин сүндем,
Хәсрәттән үлдем;
Сөешү тәхтеннән
Төштем, сөрелдем.

*2 гыйнвар.*

## Өзек

*(«Варяг» көе)*

Бетәр, күп тормас — караңгы тормышлар,
Күчәр күңелдән бар каралар!
Төшәр күкрәктән авыр гүр ташлары,
Китәр йөзләрдән тап, каралар...

# Каюм Насыйриның тууына 170 ел



Халкыбыз милли бәйсезлеген югалткач, аның рухи тормышы бик озак дәвергә караңгылык упкынына бата, илбасарларның шәфкатьсез җәбере халык авыз иҗатына, дини-мистик белем бирүче мәктәп-мәдрәсәләребез, әхлакый тәрбия бирүче мәчетләребезгә дә иркен сулыш алырга ирек бирми. Менә шушы өметсезлек, гаҗизлек һәм мәхрүмлек заманында туган кавеменең яңарышы, аң-белем өлкәсендә дөньявилыкка борылып алга китеше өчен тиңсез эшләр эшли алган, төнебезгә ай, көнебезгә кояш чыгарып, исемен милли тарихыбызда мәңгеләштергән, күп кенә кардәш халыкларның дә рәхмәт хисен казанган мәгърифәтчебез Каюм Насыйриның тууына быел 170 ел тула.

Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров 1825 елның иске стиль белән 14 февралендә Казан губернасының Зөя өязе (хәзерге Татарстан) Югары Шырдан авылында туа. Башлангыч белемне атасыннан алгач, ул 1841 елда Казанга килә һәм шундагы мәдрәсәләрнең берсендә 1885 елга кадәр дини белем ала, гарәп-фарсы телләрен үзләштерә, үзлегеннән урысчаны өйрәнә. 1855—1870 елларда инде ул Духовное училище дигән урыс мәктәбендә татар теле укыта.

1879 елдан соң К. Насыйри барлык вакытын язучылык эшенә багышлый. Күп санлы дәреслекләр, сүзлекләр төзи, фәнни-популяр хезмәтләр иҗат итә, аларны үз хисабына бастырып чыгарып, халык арасында тарата. Халык авыз иҗаты үрнәкләрен җыеп нәшер итүе, киң катламнарга кирәкле, аның көнкүрешен җиңеләйтергә булышучы, зиһенен баетырга хезмәт кылучы әсәрләрне бүтән телләрдән тәрҗемәләп, туган кавеменә тапшыручы бу фидаи җанның — татар дөньясында әлегәчә мисалы булмаган фидакяр эшлекленең мондый тырышлыклары кайбер кадимчел руханиларның, искечә йомылып гомер итүче бәндәләрнең житди каршылыгына очрый, әмма алдынгырак карашлы җәмәгатьчелек, хәтта шовинизмнан азат урыс халкы вәкилләре дә К. Насыйриның мәгърифәтчелек эшенә теләктәшлеген белдерә — аны 1885 елда Казан университеты янындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенә хакыйкый әгъза итеп сайлыйлар.

Туган халкын яңа дәвердә төрле фәннәрнең нигезләре белән беренче мәртәбә таныштыручы зат Каюм Насыйри була. Ул туган теленең гыйльми грамматикасын барлыкка китерүдә беренче адымнарны атлый, математика, география, ботаника, физика һәм гыйлемнең бүтән тармаклары буенча бик күп китаплар яза һәм бастырып чыгара, 24 ел буе еллык календарьлар чыгарып, анда дөньяның, табигатьнең күп серләрен аңлатып, гаммәне беренче нәүбәттә хаҗәт белемнәр белән коралландыра, берничә гасыр дәвамында артка гына тәгәрәргә мәҗбүр ителгән татарның яңадан һушын җыюына, бүтән алдынгы халыклар сафына басар өчен киң көрәш җәелдерә башлавына сәбәпче була. Мәгариф, гыйлем эстәү чарасы буларак кулланыштан чыгарылган татар теленә нәкъ менә Каюм бабабыз аның табигый хокукларын кайтара, аны халыкчан нәфис стиль белән баета, фәнни стиленә матур үрнәкләр бирә, иҗтимагый, сәнгатьчә фикерләвенә дәртдәрман өстәрлек мәшһүр әсәрләрне — дөнья әдәбияты үрнәкләрен китап киштәләребезнең даими кунагы итә.

Каюм Насыйри 1902 елның 2 сентябрендә 77 яшендә Казанда вафат була. Күренекле педагог, үзенчәлекле галим, кыю фикер иясе, фидакяр язучы һәм журналист, мул җимешле нәшир — замандашлары күңелендә ул әнә шундый олуг шәхес булып уелып кала.

## ТАТАРСТАН ЮГАРЫ СОВЕТЫНЫҢ СЕССИЯСЕНДӘ

16—18 гыйнвар көннәрендә Казанда Татарстан Республикасы Югары Советының XXIII сессиясе эшләде. Аның барышында Татарстан хөкүмәте составына үзгәрешләр кертелде. ТР Премьер-министры Мөхәммәт Сабировның үз теләге белән эштән азат итүне сорап язган гаризасы канәгатьләндерелде. Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев республикабыз тарихының бик тә катлаулы һәм җаваплы чорында Мөхәммәт Галләм улының эшчәнлегенә югары бәя бирде һәм, ул киләчәктә дә үзенең бай тәҗрибәсен җөмһүриятебез мәнфәгатьләрендә файдаланыр, дигән теләк белдерде. Шунда ук М. Сабировка ТР Югары Советының Рәхмәт хаты да игълан ителде.

Депутатлар бердәм рәвештә, Татарстан Президентының тәкъдимен хуплап, элек ТР Югары Советы Рәисе булып эшләгән Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшинны ТР Премьер-министры итеп расладылар.

Сессия «1995 елның 1 кварталына Татарстан Республикасының бюджетыннан дәүләт чыгымнары турында» Закон проектын карап тикшерде. Халыкны җәмгыяви яклауны көчәйтү максатларында һәм «Минималь хезмәт хакы турында»гы Закон нигезендә, 1995 елның 1 февраленнән хезмәт өчен түләүнең минималь күләме 110 мең сум дип билгеләнде. ТР Югары Советы Чечня вакыйгалары уңае белән карар кабул итте.

## ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫ — ШВЕЙЦАРИЯДӘ

25—28 гыйнвар көннәрендә Татарстан Президенты М. Шәймиев Швейцариядә булып, Давос шәһәрендә ачылган Бөтендөнья икътисади форумында катнашты һәм Россиядә региональ проблемалар турында чыгыш ясады. Форумда катнашучылар аны зур кызыксыну белән тыңладылар. М. Шәймиев БМОның Генераль секретаре Б. Гали һәм дөньяның төрле илләреннән килгән дәүләт һәм хөкүмәт башлыклары, күренекле җәмәгать эшлеклеләре белән очрашып сөйләште.

Очрашулар дәвамында Женева кантоны белән Татарстан Республикасы арасында хезмәттәшлекне киңәйтү турында килешүгә ирешелде.

## ЧЕЧНЯ ХАЛКЫНА — ТАТАРСТАН ЯРДӘМЕ

Татарстан халкы Чечнядәге хәлләргә битараф кала алмый. ТР Югары Советы Президиумы әгъзасы, язучы Разил Вәлиев җитәкчелегендәге рәсми делегация 11—14 гыйнвар көннәрендә Чечен Республикасында (Ичкериядә) һәм Ингушетиядә булып кайтты. Курку белмәс чечен халкына Татарстан вәкилләре «АН-24» самолетында дарулар, медикаментлар, балалар өчен туклану әйберләре һәм 4 тонна ашамлык (барлыгы 60 млн. сумлык) алып бардылар.

25 гыйнварда исә Чаллыдан Чечняга 17 автомашинадан торган махсус колонна кузгалды. Гуманитар сәяхәткә Чаллы шәһәр хакимияте башлыгы урынбасары Галимҗан Зарипов җитәкчелек итте. Чечня халкына матди булышлык күрсәтүчеләр арасында бертуган эшмәкәр Нәфис һәм Рәфис Кашаповлар да бар иде. (Ичкериягә Нәфис Кашапов үзе белән 500 млн. сумлык кием-салым, азык-төлек, дарулар һ. б. кирәк-яраклар алып барды).

26 гыйнварда Чечняга Казаннан «Як-40» самолетында гуманитар йөк белән «Карамай» фирмасы директоры Алимас Вәлиев җитәкчелегендәге делегация очты... Әнә шулай, Чечняның батыр халкына татарстанлыларның матди һәм рухи ярдәме даими дәвам итә.

## УНИВЕРСИТЕТКА — 190 ЕЛ

Казан дәүләт университеты үзенең 190 еллык юбилеен тантаналы төстә билгеләп узды. Дөньякүләм танылган әлеге югары уку йортында хәзер 918 галим эшли: шуның 148е — фән докторы, 529ы — фән кандидатлары. Университетның 14 факультетында 8557 студент 34 белгечлек буенча белем ала. 602 тема буенча фәнни-гамәли эшләр алып барыла.

Университетның 4,6 миллион китап фонды булган бай китапханәсе бар. 19 илнең 34 университеты белән ике арада шартнамә төзелгән.

## ГАЗЕТА БӘЙРӘМЕ

«Татарстан яшьләре»... Бу исемне белмәүче татар кешесе сирәктер. Күләме кечкенә булса да, ул чын мәгънәсендә зур газетага әйләнә алды. «Кызыл яшьләр», «Яшь сталинчы», инде килеп «Татарстан яшьләре». Исеме төрле чорда төрле булса да, газета яшьләр һәм милләт ихтыяҗлары өчен көрәшчеләр сафында кала бирә.

Январь ахырында газета үзенең 75 еллык юбилеен билгеләп үтте. Бүгенге көндә татар телендә иң күп тираж белән чыга торган (140 меңгә якын) бу мөхтәрәм басманың дуслары бик күп икәнен юбилей бәйрәме бик ачык раслады. Кай тарафлардан һәм

кемнәрдән генә булмады котлаулар! Чит илләрдән, күрше республикалардан, татарлар күпләп яшәгән торган бик күп төбәкләрдән. Газета коллективы (баш мөхәррире — Исмәгыйль Шәрәфиев) Президент М. Шәймиев кул куйган Татарстан Республикасының «Мактау грамотасы» белән бүләкләнде.

## ПЕН-КЛУБКА КЕРӘБЕЗМЕ?

Әдәбиятны күзәтеп барган кешеләр ПЕН-клубның нәрсә икәнен белә булыр. Бүгенге көндә ул — язучыларның иң абруйлы халыкара берләшмәсе. 1921 елда күренекле инглиз язучысы Джон Голсуорси нигез салган Халыкара ПЕН-клуб, талантлы әдипләрне берләштергән иҗат берләшмәсе булып, ул азатлык, демократия, гуманизм идеалларын, кеше хокукларын бөтен дөньяда таратуга ярдәм итә торган зур көч бүген. Һәртөрле тоталитар режимнар андый берләшмәләрне беркайчан да яратмаган. Заманында Халыкара ПЕН-клуб безнең илдәге диссидент язучыларны яклады.

ПЕН җыелмасын сүтеп караганда, инглизчә шагыйрь, публицист, язучы сүзләренең баш хәрефләре килеп чыга. Халыкара ПЕН-клубның башкарма комитеты Лондонда урнашкан. Аның башында сайлап куелган генераль секретарь тора. Ике елга бер мәртәбә ПЕН-клубның президенты сайлана. Хәзерге вакытта әлеге оешмага 100гә якын милли ПЕН-үзәк керә. Моннан ике еллар элек урыс ПЕН-үзәге төзелде. Ул Рәсәйнең аеруча талантлы язучыларын (алар арасында Б. Ахмадуллина, А. Битов, А. Вознесенский, Б. Окуджава, Ф. Искәндәр һәм башкалар бар) берләштерә. Дөресен әйтергә кирәк, ПЕН-үзәк әгъзаларын ишәйтү ягында түгел. Билгеле булганча, урыс ПЕН-үзәгенә 50 гә якын актив язучы керә. Ә керергә теләүчеләрнең саны 300 дән артык. Халыкара ПЕН-клуб рус телендә язучы әдипләр өчен махсус Букер премияләре булдырды (ел саен 10 мең фунт-стерлинг күләмендә). Күптән түгел казах һәм әзәрбәйҗан язучылары да үзләрендә ПЕН-үзәк булдырдылар. Ниһаять, татар язучылары да бу хакта уйлана башладылар. 7 гыйнварда Татарстан милли китапханәсендә бер төркем татар зыялылары татар ПЕН-үзәген булдыру турындагы мәсьәләне уртага салып сөйләшү өчен җыелдылар. Алар исәбенчә, бу үзәк Халыкара ПЕН-клубка мөстәкыйль берләшмә сыйфатында керәчәк. Бу оешманың эшчәнлеге турында Мәскәүдә яшәүче әдип М. Юныс белгәннәрен сөйләде. Булачак татар ПЕН-үзәгенең устав проектын Ә. Мушинский укыды. Аннары фикер алышулар булды. Күренекле әдипләр Г. Бәширов, Ә. Еники, М. Госманов, Р. Вәлиев һәм башкалар татар ПЕН-үзәге идеясен яклап чыктылар. Оештыру комитетына Зөлфәт Хәким, Ә. Мушинский, Р. Мостафин, Ф. Зөлкарнәй, Римзил Вәлиев, Т. Бариев керде.

## ҖИҢҮНЕҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА БАГЫШЛАП

19 гыйнварда Татарстан Язучыларының Г. Тукай исемендәге клубында сугыш һәм хезмәт ветераннарыннан торган «Дуслык» халык ансамбле (җитәкчесе — Хәнифә Абдуллина) зур концерт күрсәтте. Җиңүнең 50 еллыгына багышланган әлеге кичә тамашачыларда бик җылы тәэсир калдырды.

## БАБИЧ КИЧӘСЕ

Мәркәзебезнең Г. Тукай музеенда шагыйрь Шәехзадә Бабичның тууына 100 ел тулуга багышланган кичә булып узды. Аны Татарстан китап нәшриятының бүлек мөдире, язучы Галимҗан Гыйльманов белән Татарстан халык артисты Хәлим Җәләлов алып барды.

## ШӘЙХИ МАННУР КӨННӘРЕ

24—25 гыйнвар көннәрендә Мамадыш районында олуг әдибебез Шәйхи Маннурның тууына 90 ел тулуга багышланган тантаналар булып үтте. Бирегә Казаннан, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев җитәкчелегендә, әдәбият-сәнгать эшлеклеләреннән ике дистәгә якын кешене берләштергән делегация килде. Аларны Мамадыш туфрагында район хакимиятенең яңа башлыгы Р. Әхмәтов һәм башка рәсми кешеләр каршылады.

Кунаклар беренче көнне Тулбайда — әдипнең туган авылында — ана багышланган музей-китапханәне ачуда катнаштылар; зиратка барып, Ш. Маннур һәм аның әнисе каберләренә тере чәчәк бәйләмнәре салдылар; кичен исә Олыяз авылы мәдәният йортында халык белән очраштылар. Икенче көнне тантана район үзәгендә — кайбер промышленность предприятиеләрендә һәм үзәк мәдәният сараенда дәвам итте. Әдәбият сөючеләр алдында Татарстанның халык язучыларыннан Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, танылган шагыйрьләрдән Ш. Галиев, Г. Зәйнашева, С. Гәрәева, яшьрәк буын вәкилләреннән Р. Низамиев, Р. Газизов, Хәйдәр, М. Сафин, әдәбият галимнәреннән Ф. Галимуллин, Н. Нәккаш һ. б. чыгыш ясады. Елдагыча, тантана барышында, Ш. Маннур исемендәге бүләккә лаек булган яңа лауреатларның исемнәре игълан ителде. Быел «Чулпан» авыл хуҗалыгы кооперативлар ассоциациясеннән әлеге югары бүләккә комбайнчы Х. Хисмәтов, савымчы-оператор З. Сәләхова, механик С. Мифтахов, Олыяз мәдәният йорты концертмейстеры Э. Салихов, хуҗалыкның элекке баш бухгалтеры Р. Ганиев (үлгәннән соң), Тулбайдагы «Уңыш» кооперативы рәисе Р. Галиев (үлгәннән соң) һәм язучылардан — Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары З. Мансуров, «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире Ш. Әхмәтсафа (Мостафин), «Идел» журналының бүлек мөхәррире М. Закир һәм Ш. Маннурның музей-китапханәсендәге экспозицияләр авторы — Татарстан Дәүләт музее өлкән фәнни хезмәткәре Д. Баһаутдинова лаек булды. Татарстан Мәдәният министры урынбасары М. Низамиев исә Тулбай музей-китапханәсе директоры В. Зәйнетдинова күпьеллык фидакарь хезмәте өчен, «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән Диплом һәм билге тапшырды.

Тантанада катнашкан кунакларга Ш. Маннур юбилеена махсус багышлап чыгарылган истәлек медальләре дә бирелде.

## НӘҖИП ҖИҺАНОВ ИСТӘЛЕГЕНӘ

8 декабрьдә Казанның Арча кырындагы зиратында мәшһүр татар композиторы, СССРның Дәүләт бүләге лауреаты, Казан консерваториясенең элекке ректоры Нәҗип Җиһанов каберенә һәйкәл куелды.

Аны ачканда Идел буе һәм Урал төбәге республикалары композиторларының XIII фестивалена (5—8 декабрь) килгән кунаклар да катнашты. Консерваториянең хәзерге ректоры, профессор Р. Абдуллин, Россия композиторлар берлеге идарәсе рәисе В. Казенин, Татарстан дәүләт симфоник оркестрының баш дирижеры һәм сәнгать җитәкчесе Ф. Мансуров, Татарстан композиторлар берлеге идарәсе рәисе Р. Кәримуллин, «Музыкаль академия» журналының баш мөхәррире Ю. Корев, Башкортстан композиторы Д. Хәсәншин, остазлары хакында чыгыш ясап, бик җылы сүзләр әйттеләр.

Кабер һәйкәлен Санкт-Петербург сынчысы М. Аникушин эшләгән.

Һәйкәлне ачуда Татарстан Мәдәният министры М. Таишев катнашты.

## ЧАЛЛЫ ИҖАТЧЫЛАРЫ БӘЙРӘМЕ

Чаллы төбәге язучылары оешмасының төзелүенә 15 ел тулуга багышлап, КамАЗ башкаласындагы Татар яшьләр театры бинасында тантаналы кичә булды. Анда республикабызның Язучылар берлеге идарәсе рәисе Ринат Мөхәммәдиев, Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов, Чаллы Язучылар оешмасы җитәкчесе Рахмай Хисмәтуллин һәм башкалар чыгыш ясадылар. Соңыннан «Сердәш» иҗат группасы, үзешчән артистлар әдәби-музыкаль тамаша күрсәттеләр.

## КЫЗЫКЛЫ ОЧРАШУЛАР

Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге бүләге лауреатлары — шагыйрә Гөлшат Зәйнашева, драматург Туфан Миңнуллин һәм Татарстанның халык артисты, җырчы Миңгол Галиев Казан шәһәрендәге 10 нчы татар гимназиясендә укучы балалар һәм мөгаллимнәр белән очраштылар.

* * *

Язучылардан — «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррирләре Мансур Вәлиев, Шаһинур Мостафин, Казан дәүләт педагогия университеты доценты, әдәбият галиме Фоат Галимуллин һәм «Сөембикә» журналының бүлек мөхәррире, прозаик Роза Мулланурова Әгерҗе районы мәктәпләрендә, мәдәният сарайларында булып, әдәбият сөючеләр белән кызыклы очрашулар үткәрделәр.

## ШАГЫЙРЬГӘ — ЧӘЧӘКЛӘР

21 гыйнварда М. Җәлил исемендәге опера-балет академия театрында шагыйрә Шәмсия Җиһангированың иҗат кичәсе булды. Анда шагыйрәнең яңа шигырьләре һәм аның сүзләренә язылган көйсанлы җырлар яңгырады. Ш. Җиһангировага, тамашачыларның кайнар рәхмәте билгесе булып, бихисап чәчәк бәйләмнәре бүләк ителде.

## АКТАНЫШТА — ТУГАН ЯК МУЗЕЕ

Район үзәгендәге мәдәният сараенда ачылган әлеге музейда (оештыручысы — И. Гарипов) Актаныш төбәгеннән чыккан әдәбият-сәнгать эшлеклеләренә урын түрдән бирелгән. Язучылардан Р. Ишморат, Н. Баян, Г. Афзал, З. Мәҗитов, Р. Хисмәтуллин, Р. Хәлиуллина, Э. Шәрифуллина, артистлардан М. Мутин, Н. Җиһаншин, С. Хөснияров, рәссамнардан А. Сәфәргалин, В. Маликов, З. Басыйров, композитор И. Закиров, А. Хөсәенов, җырчылардан Ә. Афзалова, Х. Шәйдуллин, Г. Фарукшин, А. Вәлиев һ. б. турында бирелә гаҗәеп кызыклы язмалар, экспонатлар тупланган.

## ИБРАГИМ САЛАХОВ АРХИВЫ — КАЗАНДА

Татарстан Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре, илебезнең төрле төбәкләрендә булып, анда яшәүче милләттәшләребез белән элемтәләр урнаштыралар. Фәнни хезмәткәр Зөфәр Мөхәммәтшин, мәсәлән, күптән түгел генә Казагыстанның Көкчәтау өлкәсендәге Кызыл Яр авылында булып, шунда яшәүче аксакал язучыбыз — Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Ибраһим ага Салахов белән очрашты. Өлкән әдибебез яшь галимгә дистәләрчә папка чәчмә һәм тезмә әсәрләрен, меңәрләгән дәнә хатларын тапшырды.

Архив материаллары арасында аның «Мәхәббәт картаямы?» повесте, «Колыма хикәяләре»нең беренче варианты, «Имәннәр тамыр җәйгәндә», «Көкчәтау далаларында» дигән романнарының кульязмалары да бар.

## ЛЬВОВТА — «ТУГАН ИЛ»

Күптән түгел генә Львов шәһәрендә татарлар тарихын һәм татар, гарәп телләрен укыта торган шимбә мәктәбе эшли башлады.

Аны «Туган ил» исемле татар җәмгыяте оештырды. Бу җәмгыять әлеге төбәктә яшәүче милләттәшләребезне берләштерүче үзәккә әверелде. «Туган ил» Ураза, Корбан гаете кебек дини бәйрәмнәребезне үткәрүдә дә башлап йөри. Якын киләчәктә мәчет төзү күздә тотыла. Җәмгыять, картларга һәм балаларга даими ярдәм күрсәтү максатыннан, «Хәйрия» фонды да оештырды.

## «ТУГАН ЯК»НЫҢ ЯҢА ТАЛАНТЛАРЫ

Түбән Новгород өлкәсендә нәшер ителүче «Туган як» гәзите, инде менә берничә ел рәттән, журналистика өлкәсендә елның иң яхшы язмалары өчен Кави Нәҗми исемендәге, уңышлы әдәби әсәрләр өчен Һади Такташ исемендәге премияләр бирен килә.

1994 елда К. Нәҗми исемендәге бүләккә «Семечки фаҗигасе» исемле күләмле язмасы өчен Мансур Хафизов, һ. Такташ исемендәге премиягә ел дәвамында газетада басылган лирик шигырьләре өчен Зәкия Хәбибуллина лаек булды.

### ЯКТАШЫБЫЗ УҢЫШЫ

Мәскәүнең Кырым валында — Рәсәй рәссамнәренең үзәк йортында Татарстанның Бөгелмә каласында туып-үскән Рәшит Сафиуллинның шәхси күргәзмәсе булып үтте. Якташыбыз, 1968 елда Казан сәнгать училищесын тәмамлагач, театр һәм кинода, дизайн сәнгате өлкәсендә 12 ел эшләгәч, Казандагы кайбер биналарны бизәүдә катнашкан. Мәскәүнең Ленком театрында «Гамлет» спектаклене, «Мосфильм» да «Сталкер» кинокартинасына декорацияләрне дә ул ясаган.

Останың шәхси күргәзмәсенә 60 тан артык әсәре куелган иде. Үз стиле, алымы, тамашачыны уйландыра торган фәлсәфәсе булган рәссамнең иҗади әсәрләре күпләр күңеленә хуш килде.

### СӘХНӘДӘ — ТАТАР МОҢНАРЫ

Украина башкаласында «Татар җыры» фестивале зур уңыш белән узды. Анда әлеге республиканың төрле төбәкләрендә яшәүче үзешчән артистлардан йөзләгән кеше катнашты. Харьков шәһәреннән килгән «Дуслык», «Йолдыз», Львовтан — «Туган ил», Киевтән «Шатлык», «Алан» ансамбльләре чыгышларын тамашачылар көчле алкышларга күмделәр. Зөлхәбирә Хәлиуллина, Әлфия Шевченко, Тәнзилә Монасыйпова, Гүзәл Сәйфетдинова, Муса Гайсин кебек талантлы җырчылар тыңлаучыларны үзенчәлекле аһәңнәре белән сөендерделәр.

* * *

Инде бернечә ел рәттән Чувашстан Республикасының Урмай авылында «Урмай моңнары» исемендәге татар эстрада җырлары фестивале үткәрелә. Урмайлылар быел да бу матур гадәткә тугры булып калдылар. Урмай авылы халкы Сембер, Сарытау, Свердловск, Пермь өлкәләреннән, Татарстан һәм Удмуртия республикаларыннан килгән җырчыларның чыгышларын яратып кабул итте.

### «ГАТА КАМСКИЙ ФОНДЫ»

Татарстан хөкүмәте карары белән, җөмһүриятебездә «Гата Камский» фонды оештырылды. Ул 20 яшьлек шахматчыбызга матди һәм рухи ярдәм күрсәтүне максат итеп куя. Милләттәшебез хәзерге вакытта дөньяның шахмат таҗын дәгъвалаучыларның берсе булып санала. Әлегә Гата АКШ җыелма командасы өчен чыгыш ясый, гаиләсе белән Нью-Йоркта яши. Киләчәктә ул Татарстан флагы астында, җөмһүриятебез данын яклап та көндәшләре белән шахмат тактасында көч сынашачагын белдерде.

### ГОЛЛАНДИЯ КҮГЕНДӘ — ТАТАР «ЙОЛДЫЗЛАРЫ»

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры артистлары ай ярым дәвамында Голландия тамашачыларына иң яхшы спектакльләрен күрсәттеләр. Венера Ганиева, Зилә Сөнгатуллина, Айдар Фәйзрахманов, Мөнир Якупов, Равил Идрисов, Сәет Рәенбәков кебек танылган «татар опера йолдызлары»ның чыгышлары көчле алкышлар белән бүләкләнде.

### ЯПОНИЯ ТАМАШАЧЫЛАРЫ АЛКЫШЛЫЙ

Татарстан Композиторлар берлеге идарәсе рәисе Рәшит Кәлимуллин һәм Казан консерваториясенең кыллы квартеты күптән түгел генә Япониядә уза торган халыкара фестивальдә катнашты. Әлеге фестиваль вакытында татар музыкасы көннәре дә уздырылды. Рәис-композитор япон тамашачылары алдында лекцияләр белән чыгыш ясаса, бертуган Шамил һәм Камил Монасыйповлар, Марат Зарипов һәм Альберт Әсәдуллиннар квартеты татар композиторларының әсәрләрен башкардылар.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Матбугат өлкәсендәге казанышлары өчен һәм тууына 60 яшь тулу уңаеннан, «Татарстан хәбәрләре» газетасының үз хәбәрчесе, язучы Рәхимов Җәмит Гата улы, Җөмһүриятебез Президенты Указы нигезендә, Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

# АНЫҢ ФАТЫЙХАСЫ

Рухы олуг, гайрәте чиксез, зәвыгы мең төрле Бакый Урманченың хәзинәсендә замандашлары һәм иҗатын барлаучы белгечләр тарафыннан тулаем рәвештә өйрәнелмәгән, әһәмияте һәм күләме тәгаенләнмәгән сәнагы байлыклары, иҗади серләре, җәүһәр-табышмаклары бихисап әле. Бу, беренче нисбәттә, аның кодрәтле шәхесенә караган мәсьәләләрдән — риваятьләр, иҗади колачлыгы, «протей»лыгының чыганаклары; бу — аның мәрмәр, агач сыннар, нәкышьле тукымалар астында сулкылдап калган саф вә самими шигъри чишмәсе; бу — бүгенге көндә аны дөньякүләм мәшһүр фикер ияләре: Хәйям, Гёте, Шопенгауэр, Хайдеггер, Сартрлар белән бер рәткә куярлык иҗат фәлсәфәсеннән гыйбарәт... Әлбәттә, шәхес мәсьәләләре инкарь ителгән, унификацияләнгән бер чорда, асылы белән инкыйраз корбаннары булган төпченүчеләр өчен дөнья мәдәниятеннән тулысынча хәбәрдар булып, Шәрекъ дөньясына йөз тоткан, иҗатын-мохитен татарча, мөселманнарча корган һәм эзлеклелек, дәвамлылык, таза консерватизм принципларын иҗат концепциясе итеп игълан иткән Урманче — бәләкәчләр илендәге Гулливер кебек — заман эстетикасы өчен ят һәм куркыныч иде. Тарих сукмакларыннан килгән ата-баба мирасын, аның көр вә хөр күңелен, моңын-мәдәниятен, сәнгати осталыгын һәм, бигрәк тә, тормыш кору зәвыгын үзләштереп, унтугызынчы гасырдан XX гасырга тапшырган Оста тәрәккыять юлына вә гөлләнү чорына бары тик 1917 елгы инкыйлаб бәрабәренә генә «сикереп» чыгу сыман хилаф теорияләргә аркасы белән, яисә «Сөембикә»сенең кайгылы йомык күзләре белән генә карый алды. Әлеге теорияләр белән агуланган, алданган яшь замандашларының бер өлеше өчен «ачкычы югалган серле сандык» булып калган, хаклыгына ышанган һәм чорындагы ялгышлыкларны һәм киләчәкне фәйләсуфләрчә күргән, авырлыкларны нәбиләрчә, пәйгамбәрләрчә күтәргән Карт, һичшиксез, фаҗигале фигура да иде... Бәлкем, шуңадыр, ул моңлы җырлар җырлый иде, саз-скрипка уйный һәм, мөгаен, алдагы буынга исәп тотып, аңа үзенең йөрәгеннән ташкын булып аккан шигырьләрен — «киләчәккә хатларын» багышлый иде...

Шундый әле бүген дә сере ачылмаган, аның кәрамәтчелеген, даһилыгын сурәтләгән өлкәләрнең берсе — җанына, йөрәгенә якын, чын күңеленнән сөйгән төбәкләреннән булган, графика сәнгате, аныклап әйткәндә, Г. Тукайның «Шүрәле» поэмасына багышланган төрле чорда, төрле техникада һәм форматта ирештерелгән бетмәс-төкәнмәс әсәрләр сериясе. Аларның хронологик рамкасы гаҗәп — 1923 — 1991 еллар, чама белән 70 ел. Димәк, оста гомере буе шушы ак бит өстенә төшкән манзараларны, зур асыл үрмәкүч кебек, «чиккән», үргән, нечкәрткән, камилләштергән.

Әсәрләрнең техникасы төрле булуга карамастан, аларның нигезендә — татарның кульъязма китабы куенында туган, тегәрҗеп кебек, бертуктаусыз сузылып барган, гарәп каллиграфиясенең дәвамы булып килеп баскан сыгылмалы каләм рәсеме. Сизелер-сизелмәс кенә шуышып барган нечкә сын-сызымнар, алсу-кызыл, яшел-фирәзә су булуларыннан туган төсле таплар белән керешеп, адәмнең беренче уе кебек саф, тормышның шигъри гүзәллеген мәдхияләгән, фикер тирәлекләрендә туган шигъри алымнарны, әйтерсең, уйнаклап торган күзгә чайкалу-айкалуларына ирештергән; шул рәвешле алар әкияти пространство тудырып бастыралар... Аның эчендә сюжет шаукымнары: авыл, җигелгән ат, арба; орнаментлаштырылган яшел-алтынсу, күпбизәкле урман, урман мәхлуклары, Былтыр һәм Шүрәле,

Шүрәленең бармакларын кысу сценасы... Һәм 100 данәгә якын кәгазь бите саен шушы өч-дүрт манзара... Гаҗәп! Нинди шифрлы язу — криптограмма бу? Шушы алга барган саен сюжеттан ераклашкан, кирәкмәс детальләрдән арынган, поэманың формуласына аның «алтын кисеменә» якынлашкан рәсемнәрдә — акыл иясе Урманче нинди тамырлар, бәгырь кисәкләре эзләгән икән? Ни өчен шушы дистәләрчә ел барган рухи алышта (низагъта) Шүрәленең фәлсәфәсе белән иман иткән? Нинди бальзам, нинди шифалы дару бу битләрдә? Әйе, Урманче Шүрәленең кыяфәтен, кешегә охшатмый яисә хайванлаштырмый һәм шул ук вакытта балаларча, аның асылын тере булмаган табигатькә — агач, куак кәүсәләренә тиңләп, метафизикларча баклаудан баш тарта. Юнан-Рим мифологиясендәге Пан, Фаннарга охшаган Шүрәле, урман йортында туган рух буларак, яшел-сары абагалар, чәчәкүләннәр, күбәләкләрчә төренгән коллаж булып күз алдына килеп баса. Ул — изге табигатьнең гүзәл бер заты, аның иҗаты, сакчысы, вә фантазиясе... Аның симфониясе. Җанлы мәгънәсе.

Бертуктаусыз, бөркет сыман Шүрәле тирәсендә әйләнгән Урманченың соңгы эшләренең берсе — инде әсәрнең «абсолют физикасын» гәүдәләндергән гүзәл абстракт рәсем. Музыка. Зыңгылдап торган кыска-кыска төсле нурлардан торган ниндидер утлы рухи манзара, төсле магма, космос... Һәр агачта, яфракта, таяк башында, чәчәктә ниндидер җанлы тетрәнү, уяту бар: әйтерсең лә Тәңре аларга җан ишарәсе өргән һәм шул рәвешле табигатьтә, этноста, һәр хәйят вә бөҗәктә иҗат итү, иш тудыру, гүзәллеккә омтылу теләге туган... Менә шушы җанлы вә җансыз табигатьнең киселешендә — безнең борынгы ата-бабаларыбызның интеллектуаль иҗаты барлыкка килү мизгеле һәм алтын боланнар, канатлы атлар, пошилар белән рухланган ыругдашларыбызның кичке хисләренең музыкасы булган мәҗүси Шүрәленең килеп чыгу чоры яши... Туу ноктасы һәм үлемсезлеге. Шүрәленең гүзәллеген, Данте, Гёте, Шекспирларның гүзәл уйдырмалары дәрәҗәсендәге бөеклеген, мәңгелеген, аллегорик көчен аңлаган Урманче, аның белән илһамланып, эш чорында үзенә дәрт һәм дәрман алган... Һәм безгә — бу нөсхәләрне гыйбарәле фатыйха, талисман бөти итеп, киләчәк гомерләргә калдырган.

**Розалина ШАҺИЕВА,**
сәнгать белгече.

**Тышлыкның беренче битендә:** рәссам Бакый Урманченың «Шүрәле» картинасыннан фоторепродукция.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган язучы Марсель Галиев.



# ЯҢА КИТАПЛАР




РАЗИЛ ВӘЛИЕВ. **Кышкы учак.** *Шигырьләр, җырлар.* Казан. Татар. кит. нәшр. 1994. 382 б. Тиражы — 7000 данә.

Бу китап — Разил Вәлиев иҗатын мөмкин кадәр тулы итеп күрсәткән басма. Танылган шагыйрь, Татарстан яшьләренең М. Җәлил исемендәге бүләк иясенең төрле елларда иҗат ителгән иң яхшы әсәрләре — шигырьләре, җырлары һәм тәрҗемәләре тупланган анда. Китап тугыз бүлектән (Беренче карлыгачлар. 1962—1968; Зәңгәр кабырчыклар. 1968—1971; Яшен тамыры. 1971—1977; Ядкарь. 1977—1987; Бер алманы бишкә бүләек. 1987—1994; Хыялый Мияубикә. 1962—1976; Без — Кояш балалары. 1976—1981; Нур саласым килә сүзләремә. 1962—1994; Шагыйрьләр мәҗлесе. 1964—1994;) тора. «Шигырь китапханәсе» сериясендәге бу сайланма шигырьләр җыентыгы затлы тышлыкта, камил типографик ысул белән нәшер ителгән. Китапка кереш сүзне танылган шагыйрь һәм әдип Марсель Галиев язган. Китап «Җыен» фондының матди ярдәме белән чыгарылган.

**Көмеш беләзек:** Рус һәм татар мәктәпләренә өстәмә әдәбият (Төзүчесе Х. Фәйзрахманова, фәнни редакторы профессор Н. Юзиев). Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 1995. 222 б. Тиражы — 30 000 данә.





Әлеге җыентыкта әдәбиятыбызның проза өлкәсендә танылып өлгергән яшь әдипләрнең унсигез хикәясе тупланган. Авторлар арасында Фоат Садриев, Ринат Мөхәммәдиев, Альберт Сафин, Әхәт Гаффар, Фәүзия Бәйрәмова, Рашат Низамиев, Зиннур Хөснияр һәм башкаларның исемнәрен күрәбез. Әсәрләрдә күп кенә гыйбрәтле язмышлар тасвирлана, яшьләр һәм өлкәннәр, кеше һәм табигать, иман һәм әхлак кебек мөһим мәсьәләләр күтәрелә.

Китап Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы тарафыннан мәктәп укучыларына өстәмә әдәбият буларак тәкъдим ителә. Гомумән, әле соңгы елларда гына оешкан «Мәгариф» нәшрияты татар әдәбиятын пропагандалауда, яшь буынга әхлакый-эстетик тәрбия бирүдә бик тә күркәм, файдалы эш башкара.

Җыентыкка кереш сүзне тәнкыйтьче Мансур Вәлиев язган. Әйтергә кирәк, бирдәге хикәяләрнең күбесе иң элек «Казан утлары» битләрендә дөнья күргән иде.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог